# мөдәррис

# вәлиев

## **гамәл дәфтәре**

әдәбият
һәм тормыш турында
уйланулар

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2003

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2 Рос=Тат)-4
В21

**Вәлиев Мөдәррис**

Гамәл дәфтәре: Әдәбият һәм тормыш турында уйланулар.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.— 447 б.

ISBN 5-298-01305-8 © Татарстан китап нәшрияты, 2003

# Ният

Укучыга тәкъдим ителә торган бу китап еллар дәвамында әкренләп язылды. Әмма аны «төннәр буе хәреф җыеп» түгел, ә бер сулышта иҗат ителгән, мәхәббәт хаты кебек самими-ихлас сәхифәләр хасил итте. (Үз хезмәтемә мондый инсафсыз бәя өчен кичерә күрегез.) Күпмедер дәрәҗәдә «сайланма» булса да, биредә төрле дәрәҗәдәге проблемалар, әһәмияте-кыйммәте төрлечә булган әсәрләр, аларны язган шәхесләр хакында сүз алып барыла. Әдәби тормышыбызның якты көннәре белән эңгер-меңгерләре, олы вакыйга-күренешләре белән гадәти хәл-әхвәлләре чиратлаша.

«Заман кемнең заманы?» дигәндәй, үткән гасырның 80 нче еллары әле бездән әллә ни еракта калмаса да,— килешәсездер, бу — ил әдәбиятындагы шактый ук кызыклы, мәгънәле чорларның берсе. Ул елларның күгенә күтәрелеп карасак — башлар әйләнеп китәрлек.…

Гомәр Бәширов һәм Әмирхан Еники, Хәсән Туфан һәм Сибгат Хәким, Нәби Дәүли һәм Салих Баттал, Мөхәммәт Мәһдиев һәм Аяз Гыйләҗев... Әле болар — азмы-күпме аралашып калган, инде бакый йортка күчкән каләм ияләренең кайберләре генә. Татар әдәбиятыннан хәбәре булган замандашка бу исемнәрнең һәркайсы — кабатланмас бер галәм. Һәммәсенең иҗатына лаек дәрәҗәдә тукталу мөмкин түгеллеген аңлаган хәлдә, аларның якты рухы, ул дәвернең әдәби-мәдәни «һавасы» шушы китапта да беркадәр чагыладыр, дип әйтергә батырчылык итәм.

Һәрхәлдә,— ниятем шул иде.

Төрле сәбәпләр аркасында, берара кулымдагы каләмне, әдәби хәрәкәт барышыннан бигрәк, китап нәшер итү хәлләрен тасвирлауга җәлеп итеп тордым. Бәлки, бу хәлне үзем өчен югалтуга да санар идем,— әгәр шул елларның әдәби тормышында башка рәвешле, бүтән сыйфатта катнашырга туры килмәсә, «көнем өчен түгел, денем өчен» яшәмәсәм.

Инде күпмедер дәрәҗәдә тарихка күчә баручы сәхифәләрне кабат күздән кичерү, аларда әле дә көйрәп торган куз-күмерләрне актару — әлегәчә кылган гамәлләрне барлау өчен генә түгел, сайлаган юлыңны дәвам итү максатында да кирәк.

Шуңа күрә, бер караганда, аз гына җил исеп кую белән кабынырга торган учак янында кебек хис итәмен үземне.…

Икенче караганда, алдымда — гүяки яшәешнең күп төсмерләрен, күңелнең төрле-төрле тибрәнешләрен үз эченә алган, тынгысыз уй-фикерләр йомгагыннан һәм риясыз тойгылар челтәреннән тукылган намазлык.

Йөзем милли рух кыйбласына таба юнәлгән.

«Илаһи, ният кылдым...»


АЧЫ ӘРЕМ ИСЕ
ТӘЛЛИТУТ
ИСЕҢДӘМЕ?..
БЕЗ БИК ЯКЫНБЫЗ
ТУФАН ТӘРӘЗӘСЕ
ХӘТЕР ҖИЛЕ
ГОРУР БЕР ҖЫР
УТНЫ КҮЧЕР!
ТЫНГЫСЫЗ ЙОРТ ХУҖАСЫ
СҮЗ КАДЕРЕ
ЧЫНЛЫККА ОМТЫЛУ
ХӘЙРЕТДИН АГАЙ ЧАҢ КАГА...
АВЫЛ ХАЛКЫНА НИ ҖИТМИ?
ӨЛКӘР — ӨМЕТ ЙОЛДЫЗЫ
ИДЕЛ ТӨБЕНДӘГЕ ЧИШМӘ

ЫШАНАСЫ КИЛӘ
МӘҢГЕЛЕК ГАМЬ ТУФРАГЫННАН
ШАГЫЙРЬЛӘР НИГӘ КАРТАЙМЫЙ?
ДӨНЬЯНЫҢ КЫЛ УРТАСЫНДА...
ЮЛЫ ҖИҢЕЛЛӘРДӘН КӨНЛӘШМИК
БАЛАЧАККА ЕШРАК КАЙТЫГЫЗ!
ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР
СӨЕНСЕННӘР ӘЛЕ САБЫЙЛАР!
ИСКЕ СӘГАТЬ ДӨРЕС ЙӨРИ
БЕРЕНЧЕСЕ — СОҢГЫСЫ?
КӨНДӘЛЕКТӘН СӘХИФӘЛӘР
ЧЫНЛАП ТА ШУЛАЙМЫ СОҢ?
АЧКЫЧ ЭЗЛӘДЕМ...

## АЧЫ ӘРЕМ ИСЕ

Сезнең онытырга хакыгыз  юк, аңлыйсызмы?..
Әмирхан Еники

Мин инде аны күрермен дип уйламаган идем. Күпме сулар аккан... Ә ул, катлы-катлы итәк-чабуларын җыештыра-җыештыра, иреннәрен үзалдына мыдыр-мыдыр кыймылдатып, болдыр баскычыннан менеп килә...

Әдрәпи әбинең килеш-килбәтендә иң әсәрткәне,— шомырт тамырыдай кара бармакларыннан, аларга сырышкан саргылт балдакларыннан бигрәк,— әнә шулай, җәйге челләдә кәбестә кебек катлы-катлы киенеп йөрүе иде. Итәкләренә басып абынмас өченмедер, ул бик вак атлый, әмма шактый җир китәргә өлгерә. Өй борынча хәл белешеп йөри дә, авыл биргән күчтәнәч-төенчекләрен күтәреп, олы юл ягына китеп югала...

Атналар-айлар узгач, кайсыдыр хәбәр ишетеп кайта: «Имеш, Чистай юлында буранлы көнне туңып үлгән икән»,—ди... Яисә: «Юк, үлмәгән, каядыр Ташкент якларына китеп югалган»,— дип сөйлиләр. Карчыклар: «Мескен,— диләр,— адашкан шул инде»,— диләр, күз яшьләрен сөртәләр.

Без малайларга ул чакта әле аңлашылып җитми: ничек адашты икән, кайда адашты икән Әдрәпи әби?

Төртмешрәк теллеләр аның турында «җиңел Әдрәпи» дип тә ычкындыргалыйлар.

Ул үзе дә, ике сүзнең бере итеп: «Адашканмын шул мин... Адашып ла калганмын!» — ди...

Инде онытылып барганда гына, авылда янә: «Әдрәпи килгән!» — дигән хәбәр тарала. Үлмәгән дә, югалмаган да икән. Иң күңелле вакытка —туйгамы, бәйрәмгәме махсус туры китергәндәй, ул үзенең дөньяда икәнлеген белдерә. Әдрәпи әбинең яңадан килеп чыгуы бөтен вакыйгалардан да мөһимрәк булып тоела башлый: аның шулай безне онытмавы, читләтеп үтмәве авылның дәрәҗәсен арттыра кебек. Ул олысын-кечесен танып, исемнәре белән эндәшә, әллә кайчан гүр иясе булган авылдашлар турында сораша. Үзе һаман: «Мин адашканмын шул... Әле дә булса үзебезнең авылны, нәнәмне таба алмыйм бит!» —дип такмаклый.

Әдрәпи әбинең кайсы авылдан икәнлеген төгәл генә белүче дә юк шикелле. Күрәсең, ул билгеле бер вакыт эчендә Җиргә кире әйләнеп кайтучы Койрыклы йолдыз төсле, шактый еректан, хисапсыз күп авыллар аша үтеп киләдер... Бәлки әле, үз авылында, үз йортында да шулай кунак буладыр,— бары исенә генә төшерә алмый китә торгандыр...

Еллар үткәч, Әдрәпи әби белән кабат очрашу мине әллә ничек сискәндереп, оялтып җибәрде: кадерле хатирәләрнең җуела башлавын, балачак сукмакларыннан, бабайлар кабереннән аерыла баруымны искәрткәндәй булды ул.  Кешенең кыска хәтерлегә әйләнүе, үткәнен һәм нәсел-нәсәбен онытуы белән әлеге шул зиһене адашкан карчык фаҗигасе арасында коточкыч уртаклык бар икән ләбаса!

Кешелек тарихында хәтер тамырына балта чабуның күп кенә мисаллары билгеле. Халык кадәр халыкның үз тарихын, исемен, хәтта телен җуйган очраклар... Сугышта әсир булган кешегә номер сугып, аны әти-әнисе кушкан исемнән мәхрүм итәргә, туган ил белән тоташтыручы күпердән үткәрмәскә маташулар...

Ләкин хәтернең тамырын корытуы җиңел түгел. Кешеләр, окоп эзләре тигезләнгәч тә, сугыш мәхшәрендә югалткан туганнарын эзләп табалар. Хәтта тыныч көннәрдә үзләрен язмыш иркенә ташлап киткән куркак әтиләрен күрәселәре килә... Ике арага үз ихтыярлары белән киртә корган ата-аналарын аңларга һәм акларга теләп, туган телләрен өйрәнергә азапланалар... Әйтелмәгән васыяте калган Акъәбинең «Я — башкирин, бабушка, башкирин!» дип күкрәк кагучы оныгы Геннадий сыман... (Ә.Еники әсәрендә). Исемен югалтып кына халык үлми әле. Телен оныткан халыкның тамыры корый...

Хәтерсезлекнең төрле сурәтләрен чагылдыра безнең әдәбият. Бер карыйсың, ул — Илдар Юзеевның «Сандугачлар килгән безгә» әсәрендәге урман каравылчысы. Сәер чиргә сабышкан Хәмзин. Икенче карыйсың — махсус аппаратлар белән зиһене юдырылган «ярымкешеләр» (Адлер Тимер-

галинның «Уян, сөеклем!» исемле хыялый хикәясендә). Мондый күренешләр, адәм баласының табигатенә чит булганга күрә, ак җирлектәге кара таптай күзгә бәрелеп тора, игътибарны җәлеп итә, уйландыра. Әх, шулай авырулар галәмендә дә фантастикада гына булсачы ул онытучанлык галәмәте!..

Хәтер метафорасы безне тормышның нинди катламнарына алып керә, кеше күңеленең кайсы караңгы почмакларын яктыртып җибәрә соң? Әдипләребезнең әледән-әле артка әйләнеп карый башлавы ни белән бәйләнгән?

Әлеге сорауга җавап эзләгәндә, сүзне күбебезнең исендә калган әсәрләр мисалында дәвам итү урынлырак булыр кебек.

Бу очракта без, берьяклы күренүдән тартынмыйча, хәтерне тормышта төп таяну ноктасы итеп таныган геройларга һәм дүңгәләк кебек җирсез-тамырсыз бәндәләргә текәлебрәк карый алырбыз.

Халык үзенең әкият-мәзәкләрендә үк җиде диңгез артына китеп тә туган илен онытмаган, асылын җуймаган каһарманнарын данлый һәм, киресенчә, бераз читтә йөреп кайткач тырманың исемен «исенә төшерә алмаган» әтрәк-әләмнәрне хур итә.

Тугандаш казакъ әдәбиятында Әбиш Кекилбаев һәм соңрак кыргыз-татар әдибе Чыңгыз Айтматов әсәрләренә килеп кергән төрки риваять, мәсәлән, хәтереннән мәхрүм калган адәм баласының олы фаҗигасе — кешелеклелеген югалтуы турында сөйли.

Сарүзәк далаларын басып алган жуаньжуаннар рәхимсез сынау уйлап табалар: әсирләрне, такыр итеп кырылган башларына яңа суелган дөя тиресе ябыштырып, эссе кояш астына ташлыйлар. Чәчләре, тыгыз чи тирегә үтеп керә алмыйча, борылып, кире баш эченә таба үсә. Бу газаптан исән калган зат үзенең кемлеген дә хәтерләмәүче, хуҗасының гына әмеренә буйсынучы колга —маңкортка әйләнә. Аны инде әсирлектән коткару да мәгънәсез.

Найман ыругыннан бер ана, һичнигә дә карамыйча, үз улын бу афәтле язмыштан коткарырга, аның үлгән зиһенен уятырга омтылып карый. Ай-һай, юкка гына!.. Маңкорт әнисен танымый, хуҗасының боерыгын үтәп, аның йөрәгенә ук ата. Найман-ананың башыннан ак яулыгы шуып төшә... Ана яулыгы, ак канатлы кошка әйләнеп, кычкыра-кычкыра очып китә. «Исеңә төшер: син кем баласы? Исемең кем синең?!» — дип иңри ул...

Маңкорт турындагы риваять мине балачагым хатирәләре белән бергә укмашып тетрәндерде. Авылын оныткан Әдрәпи әби язмышыннан мең мәртәбә куркынычрак булуы белән. Яшәешнең гасырларга киткән тамырларын ачып җибәрүе, илләр һәм халыклар язмышын колачлап алуы белән.

Заманалар буталышында, хәтер чоңгылларында адашып-иләсләнеп калган карчык белән ятлар тарафыннан хәтере урланган маңкорт арасында турыдан-туры уртаклык эзләмим. Әмма ыруыннан, әнисеннән аерылган маңкорт та безнең Әдрәпи әби кебек илдән илгә каңгырып йөргәндер һәм: «Безне адаштырганнар шул... Адаштырганнар безне!» — дип сыктагандыр кебек.

Маңкорт хакындагы риваять, Айтматов әсәренең («Буранный полустанок» — «Гасырдан озын көн») идея үзәгенә әверелеп, глобаль бәйләнешләрне сурәтләгән «космик фантазия» белән янәшә куела. Ракета күтәрелгәндә бөркелгән ут йомгагыннан ак канатлы кош аерылып калгандай һәм Җир кешесенә: «Кем баласы син? Исемеңне хәтерлә!» — дип кычкыргандай була. Романның бөтен агышы халыклар язмышы, кешелекнең киләчәге хакында уйлану һәм кайгыртуга юнәлдерелгән. Маңкорт турындагы риваять, адәм баласының хәтереннән мәхрүм калуы — кол һәм мәхлук җан иясенә әверелү ул, дип искәртсә, галәм белән бәйле киләчәк хикәяте исә шуңа өстәп үз кинаясен белдерә: кешелек иң югары үсеш баскычында да үзенең тарихын һәм гасырлар дәвамында тупланган әхлакый тәҗрибәсен югалтмаска тиеш. Җитди кисәтү!

Маңкортлык һәр адымда, һәр хәрәкәттә күренергә мөмкин. Акъәбинең отставкадагы улы,—үзенең үлеп баручы анасын: «Ну, ничего, түлке син паникага бирелмә»,— дип юатырга азапланучы солдафон,— имән муенлы, йомры башлы Суфиян, мәсәлән, шундый маңкортларның берсе. Ул әни дигән изге җан иясенә кадер-хөрмәт күрсәтүне оныткан, рәхим-шәфкать хисен үтергән — үз ихтыяры белән «чи тире кигән». Суфиян ишеләр маңкортка караганда кызганычрак һәм куркынычрак түгелме икән әле?

Без, мөгаен, маңкортны әнисен үтергән өчен гаепли алмыйбыздыр. Хәтере юдырылган әсирнең теләсә нинди адымы табигый һәм ихтыярсыз. Үлем түшәгендә яткан әниләре белән рәтләп сөйләшергә, аның васыятен тыңларга да теләмәгән балаларның хәтерен кем томалаган соң? Алар бит әхлаклылыкның нәрсә икәнен бик яхшы беләләр. Рус әдибе Валентин Распутинның «Соңгы чик» («Последний срок») әсәрендәге Анна әбинең балалары да, кыяфәтләре, үз-үзләрен тотышлары белән

бик зыялылар югыйсә (сиксәненче елларда бу әсәр дә зыялы халык арасында бик танылган иде), әҗәлен көткән әниләренең һәр сүзеннән кызык табып: «Үлем турында сөйләп туйдырдың инде!» — дип, көлә-көлә китеп баралар. «Үләмен мин, үләмен. Менә күрерсез. Бүген үк. Көтегез инде, печтик кенә көтегез инде. Бүтән берни дә кирәкми миңа»,— дип өзгәләнә карчык.

Тамакка утлы төер утыртырлык язмышлар. Акъәби дә, Анна карчык та бәгырь җимешләрен шәфкатьле булырга, кеше хәленә керә белергә өйрәткәннәр; бүген алар, туклык-муллыкта яшәүче, җәмгыять байлыкларын ике куллап үзләренә көрәүче балалары шул сыйфатларын җуя бармасłармы, дип борчылалар.

Әлеге борчылу хисе һәм кырыс чынбарлыктагы мисаллар зур әдипләрне — Ә.Еники, Ч.Айтматов һәм В.Распутинны бер үк гамәлгә этәрә —кешеләр арасындагы изге мөнәсәбәтләрнең таркалу сәбәпләрен эзләргә мәҗбүр итә. Наркоз бирмичә «яру» — операция ясауга тиң гамәл бу. Эшләнми калган игелек, тирән үкенеч тойгысы белән ваемсыз геройларын гына түгел, безнең һәммәбезне дә газап утына салалар алар. Әлеге әсәрләрдән безгә: «Кыска хәтерле булмагыз, рухи һәм әхлакый сафлык чыганакларына юлны онытмагыз!» — дигән өндәү авазы ишетелә. Өндәү генә дә түгел... «Үткәненнән йөз чөереп кенә «кеше» булырга маташкан бәндәләр мотлак өметсез: иң җаваплы мәлдә алар иманын да сатарга сәләтле»,— дип кисәтү.

«Әйтелмәгән васыять» (Ә.Еники), «Әни килде» (Ш.Хөсәенов), «Җомга көн кич белән» (А.Гыйләҗев) кебек әсәрләр,— кыска хәтерле балаларны гаепләүдән бигрәк, олы җанлы аналарга мәдхия. Ана белән бала мөнәсәбәтләрендә адәм баласының кешелеклелек тамыры, дөнья белән иң садә, иң тотрыклы бәйләнеше ачыла. Сафлыкка, ихласлыкка кайтырга чакыру, туганлык-кардәшлек элемтәләрен ныгытырга өндәү әсәрдән әсәргә көчлерәк яңгыраш ала. И.Юзеевның «Соңгы сынау», Т.Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» әсәрләрендәгечә, ана метафорик мәгънәдә —Хәтер, Намус гәүдәләнеше буларак күз алдына килә башлый. Ана образы белән бергә халыкның рухи хәзинәсе, гореф-гадәтләре, тарихы, тормыш фәлсәфәсе күтәрелә.

Шундый әсәрләрнең берсе — Сибгат Хәкимнең «Васыятьләр» поэмасы. Олы төшенчәләрне уртак җирлектә берләштереп, киң колачлы гомумиләштерүләргә омтыла ул. Бәхилләшү һәм үлмәс мәхәббәт поэмасы. Соңгы йотым суны иренендә тойган ананың яшәүдән, тормыштан туймавы һәм аның соңгы сүзләрен, соңгы күз карашын күңеленнән кичереп утыручы улының әнисенә мәхәббәте... Изге тарих һәм хатирәләр яктысы, тигез янган унлы лампа уты сыман, бу йортны, бу әсәрне эчтән балкытып тора. Бу якты моң ана һәм туган ил төшенчәләренең аерылгысыз бөтенлеген раслый.

Ана төшенчәсе белән Ватан төшенчәсе халык иҗатыннан, аның борынгы риваятьләреннән үк бергә үрелеп килә. Муса Җәлилнең «Алтынчәч» поэма-либреттосындагы тугыз баһадирны үстергән Тугзак-ананы гына искә төшерик. Туган илен ятлар басып алгач, табигать-ана кочагында сыену тапса да, Җик-мәргән, үзенең тамырын, нигезен, нәселен эзләп, Тугзак эргәсенә кайта. Баскыннарны илдән куарлык көч аңа табигатьтән генә килми, ул хәтер көченә, ата-анасы, агалары каны коелган газиз туфракка таяна, нинди генә михнәтләр күрсә дә иленнән язмаган Тугзак-анадан фатиха ала.

Икенче бер әсәрендә Җәлил, киресенчә, ананың үзе үстергән кыю улларына таянуы, алар белән горурлануына басым ясый («Ана бәйрәме»). Бу очрак шагыйрьнең ананы, хатын-кызны тереклек чишмәсе итеп тасвирлаучы Көнчыгыш әдәбияты традицияләренә мөрәҗәгать итүе белән кызыклы.

Җәлил иҗатының үзгендә анага һәйкәл тора. Ул һәйкәлнең нигезенә салынган иң тере чәчәк — Рәхимә апа Җәлилованың балаларына атап чыгарган үзәк өзгеч бәете... Димәк, Муса Җәлил турындагы күпчелек әсәрләрдә шагыйрьнең иң хәлиткеч мизгелдә әнисен искә төшерүен сурәтләү һич тә очраклы хәл түгел. Инде искә алынган әсәрләрдә («Моңлы бер җыр», «Соңгы сынау») шагыйрьнең тап төшмәгән намусы белән күзгә-күз калуы әнә шул рәвешле гәүдәләндерелә. Мәкерле Мефистофель Җәлилне үлем алдыннан тормышының иң газиз мизгелләренә — балачагына, яшүсмер елларына кайтара. Иблис аны иң авыр газапка дучар итә — хәтер уты белән яндырып сыный. Шагыйрь үзенең үткән юлын күз алдыннан кичерә. Ләкин бу — чигенү түгел, үзен үлемгә алып килсә дә, Ватан өчен, киләчәк өчен көрәштән хасил булган тормыш юлы белән горурлану. Мефистофельнең киләчәк көннәрне дәһшәтле буяуларга манып өркетергә теләве дә шуңа күрә куркыта алмый аны.

Шагыйрьнең какшамас рухи көче — сайлаган юлына тугрылыклы булып калуында, хатирәләр тамырының тирәнлегендә һәм ныклыгында. Ул үзенең бөтен асылы белән туган халкыннан, тарихыннан үсеп чыккан, Алып батырлардан, Алпамышлардан көч алган. Ватан һәм тарих алдындагы җаваплылык Җәлилне тигезсез көрәш мәйданына рухландыра, үлем яки хыянәт дигән соңгы чатта

үлемсезлек юлыннан алып китә. Адәм баласы үлем турында уйламый булдыра алмый, үлем турындагы уй кыска гомер юлын һәм Җиңүдән соң булачак тормышны күз алдына китерүендә дә чагыла. Ләкин... вариантлар юк! Илгә кайту юлы бер генә. Шагыйрьнең кешелек, рух һәм вөҗдан таныклыгы — илгә кайтасы «Моабит дәфтәрләре». Монологлардан торган бу оптимистик трагедия, «кеше гомеренең мәгънәсе һәм үлемсез дәвамы — халык хәтерендә, ил хәтерендә яшәү» дигән ышаныч белән сугарылган.

«Эш күрсәткән ирне ил онытмас!» Яшәү белән үлемсезлек арасындагы хәтер күпере, менә шул рәвешле, героик язмыш, сугышчан шигърият мисалында абайлана, һәм бүгенге әдәбиятта әлеге төшенчәләр тагын да тирәнәя, яңа яктан ачыла бара.

Вак мәнфәгатьләргә күмелеп, «кешечә яшәп калырга» тырыша-тырыша, рухи үлемсезлеккә ышанмый башладык түгелме? Үлем-җитем хәлләре эш арасындагы бер мәшәкать, күздә тотылмаган бер чыгым гына булып тоела башламадымы? «Нишлисең, үләргә булгач кайда да барыбер... Өйдән мәет озату — бик авыр, бик мәшәкатьле эш ул»,— дип уфыралар Акъэбинең якын кешеләре. Ч.Айтматов романындагы Казангапның укымышлы улы Сабитҗан әтисен кая, ничек күмсәләр дә риза — ерак барасы булмасын да тизрәк башкарып кайтасы булсын. Акъэбине җирләгәннән соң телләренә бер юньле сүз килмәгән Суфияннар кебек үк, Айтматовның Шаймәрдәне дә үзен бик авыр хәлдә хис итә: «Димәген ки, Казангап карт нитеп нитте инде! Димәген ки, үзенең юлын, теге ни, ну, әйтик, төгәлләде инде»,— дип, авыз эчендә ботка пешерә. Үткән ни дә, хәтер ни болар өчен! Якын кешеләренең җәсәден кая куярга белмиләр.

Ә бит халыкның гади генә йоласына да нинди тылсымлы, мәгънәле көч салынган! Ул йола үлгәннәрдән бигрәк исәннәргә кирәк.

«Мәңгелек йорт»ка китүчене җир куенына тапшырыр алдыннан, ил картларыннан берәү үз-үзенә эндәшкәндәй генә сөаль бирә:

— ...Нинди кеше иде?

Җавапны һәркем үзалдына гына кабатлый,—акрын, тыныч, саллы,— шыбырдап җиңел туфрак коелгандай: «Әйбәт кеше иде...»

Дөнья йортыннан күчкән бәндәсенә фани дөньяның, аны белгән һәм белмәгәннәрнең бәясе шундый.

Суфияннарга, Сабитҗаннарга киткәндә кем әйтер шушы сүзне? Алар өчен бит кеше үлгәнче генә бәяле. Идегәй карт сүзләре белән әйткәндә: «Аларга үлем һични түгел икән, тормышның да бәһасе юк булып чыга бит».

Шулай итеп, яшәү мәгънәсе, аерым кеше һәм буыннар хәтере турындагы катлаулы мәсьәләләргә таба янә бер борылыш ясала. Адәм баласының рухи асылы ачылып китә торган мөһим борылышларның берсе. Истәлек алымы белән язылган әсәрләрнең уңышы, нигездә, әлеге шул борылышны табу-тапмаудан тора. Хәтер көче белән үткәннәрне «терелтү» тасвир алымы гына, хәтта тема яки аерым проблема гына да булып калмыйча, әсәрнең һәр күзәнәген хасил итүче, «төзүче» вазифасын башкара.

Әдәбиятыбыз тарихында, халык иҗаты җәүһәрләрендә хәтер көчен сыйфатлаучы төп билге — сагыну хисенең дәрәҗәсе. Туган якка, якын кешеләреңә җан тартуы, аларны онытмау һәм юксыну тойгысы... Ул сабыр сагыш, уйлап карасаң, «Сак-Сок» бәетләреннән үк киләдер әле. Зур дөнья, катлаулы тарих җирлегендә сагыну тойгысы үзе дә күп катламлы, күп төсмерле. Рекрут, әсир һәм зимагур көйләре, «Кара урман» кебек моң чишмәләре авыр язмышка эчке нәфрәт, аны үзгәртергә омтылыш булып яңгыраган.

Туган-үскән туфрак турындагы хатирә кешене һәрвакыт бәрәкәтле хәрәкәткә, эшкә-гамәлгә, көрәшкә ашкындырып тора. Хәтта җиңелү белән тәмамланса да, бу көрәшнең төп юнәлеше — үз асылыңа кайтырга омтылу теләге югалмый. Кайвакыт ул адәм баласының иң соңгы, бердәнбер юлы булып чыга.

Мисыр тәхетен яулаган кодрәтле солтанга да язмыш шундый бердәнбер мөмкинлек калдырган. Мәмлүк солтаны Бәйбарс турында Морис Симашко дигән язучының «Әрем» исемле повесте шул хакта. Илен, тудырган әнисен хәтерләми Бәйбарс. Тик... дан-дәрәҗәгә ирештем дигәч кенә, үз куллары белән ятимә һәм кол ителгән кыз баланың төшләнеп елавын ишеткәч, шәфкатьсез хаким кинәт

барысын да исенә төшерә: атасының баскынчылардан һәлак булуын, үзенең кол ителеп сабый чагыннан ук дала куенынннан аерылганлыгын... Кыпчак даласының җанга якын ачы әрем исен! Мәшһүр Бәйбарсны шул хатирә, тәхетен һәм байлыгын ташлап, ач далага — туган туфрагын эзләп китәргә мәҗбүр итә.

«...Тау битендәге үләннәрне селкетеп-тарап җылы гына җил исә. Ачы әрем исен китерә ул миңа — туган туфрак исен... Коры җирдә, эссе кояшта үскән ак әрем исе бик үткен була... Үзгәрми һәм бетми торган ис ул минем өчен!» «Соңгы китап»ның беренче кисәге менә шул сүзләр белән ябыла. Хәтер — үткән заманнар сөземтәсе генә түгел, кешенең бүген үз-үзен тотышына, киләчәктә кыласы эшләренә нигез, алшарт, сәбәпче дә икән ул.

Халык күңеленең көзгесе булган әдипләр иҗатында сагыну-җирсү халәте, нигездә, якты хисләр, кешелекле мөнәсәбәтләр чыганагына әверелә. Шуңа күрә, истәлек алымы белән язылган әсәрләр үткән көн күләгәсеннән аерыла алмау, тотылмаган төлкене юксынып сыктау түгел, халыкның күңелендә һәм көнкүрешендә тупланган бай тәҗрибәгә, рухи хәзинәгә мөрәҗәгать итү булып аңлашыла. Әнә М.Мәһдиевнең шәп йөрүче Зәкәрҗаны, улы үлгәч иләсләнеп калган Әсма карчыгы яисә «артист» Гаптыр-Габдерәкыйпләре, аларның самими хәйләләре, сүз тәмен белеп, «сайландырып» сөйләшергә яратулары... Без аларны баштарак кына, күрешкәнче генә ятсынып торганбыз икән: кабатланмас чырайлы Зәкәрҗаннар, Хәдичәттиләр тора-бара безнең якыннарыбызны, авылдашларыбызны, танышларыбызны хәтерләтә башлыйлар. Язучы конкрет образлардан, шәхси язмышлардан, аларның кырыкмаса-кырык төрле мәшәкатьләрен тасвирлаудан киңрәк гомумиләштерүләргә алып чыга: аяк астындагы җирне тоярга, «ачы тәҗрибә авазы»н онытмаска чакыра. Ул үзе дә иҗатының һәр яңа баскычында туган төбәгенә әйләнеп кайта, анда яктырып калган яшьлек аланнарын барлый. Туган як — әдипнең таяну ноктасы да, төп юнәлешен билгеләүче кыйбласы да.

Авыл — татар кешесе өчен аеруча кадерле: ул — әхлак һәм гадәт-кагыйдәләребезне, эстетик культура традицияләребезне саклаучы күңел сандыгы. Анда туган тел чишмәләре аеруча саф көе саклана. Авылны искә төшергәндә, андагы үзгәрешләргә дә күз йомарга ярамый, билгеле. Ул үзгәрешләр күңелне борчып кына калмый, беркатлы авыл кешесен рухи имгәтә, изә, сыта, кайчакта һәлакәткә үк илтә...

Борынгы һәм бүгенге тормышны иҗтимагый яшәү шартлары җирлегендә чагыштырып язылган әсәрләр — истәлек-повестьлар, истәлек-романнар безне менә шушындый хәлләрдән кисәтү-саклау максатын да куялар шикелле. Аларда авыл кешесенең яңа шартлардагы халәтен аңларга омтылу өстенлек ала.

Салам түбәләр, сукыр лампаларның онытылуы түгел, коендырган суы белән бергә баласын да чыгарып ташлаган кебек, кыйммәтле рухи хәзинәнең югалу ихтималы борчый әдипләребезне. Ана сөте белән кергән хезмәт сөючәнлек, гаилә кануннары, туганлык һәм күршелек мөнәсәбәтләре, табигать белән якын кардәшлекне тою... «Табигать һәм кеше», асылда, урман-суларны, җәнлек һәм кош-кортларны кешедән сакларга кирәк, дигән фикергә төрле мисаллар китерүче модалы рубрика гына түгел. Табигатьне саклау — безнең өчен, иң беренче чиратта, киләчәк буыннар каршында җаваплылыкны онытмау, тормыш табигыйлеген, кеше табигатенең сафлыгын саклау булып аңлашыла. Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә»сендә, Илдар Юзеев геройларының тимер кешеләр белән көрәшендә, хәтта Аяз Гыйләҗевның «урман үзебезнеке» дигән кинаясендә дә бу шулай: җирдән, традицияләрдән аерылу нәтиҗәсендә кеше тормышының табигый бөтенлеге, табигый төсләре җуела баруы — бүгенге көннең һәм бүгенге әдәбиятның төп мәсьәләләреннән берсе дип тану.

Бүгенге дисәк тә, шәхеснең рухи дөньясына шәһәр һавасының, цивилизациянең йогынтысы турында элек тә аз уйланмаганнар (Ф.Достоевский яисә Л.Толстой фәлсәфәсен, Һ.Такташның егерменче еллардагы иҗатын искә төшерик). Һәр табыш нәрсәнедер югалту хисабына бара...

Берара, Мәскәү тәнкыйтьчеләреннән күрмәкче, безнекеләр дә: «Киләчәк — шәһәр кулында; авыл җырчыларының урыны — тарих чүплегендә»,— дип яза башлаганнар иде. Әдәбияттагы «шәһәрләшү» хакында кычкырышып, күпме яшь этәч тавышын югалтты...

Аннары «авыл прозасы» турында бәхәсләшүчеләр арасында: «Үткәннәргә тиешле хөрмәтне күрсәттек — җитте. Инде авылның бүгенге хәленә игътибарны тупларга кирәк»,— дип чакыру көчлерәк яңгырый башлады. Төп мәгънәсен генә алганда, үткән белән бүгенгене каршы кую ягыннан бу фикернең иске булуы ярылып ята. Шул ук вакытта анда үзенчә хаклык та бар. Урта буын әдипләрнең автобиографик әсәрләр белән мавыгып китүе нәтиҗәсендә утыз-кырык ел элек булган авыл сурәте

төрле вариантларда кабатлана башлады. Илленче еллардагы колхозны бераз сиплəп кенə «бүгенге» дип күрсəтергə тырышу мисаллары да юк түгел. Хəтер көчле — авыл түренə əллə кайчан хəл ителгəн проблема менə дə утыра. Суы-газы килгəн зур авылда янгын сүндерү өчен куелган иске мичкə сыман. Үткəн белəн бүгенге нисбəтенə мисал эзлəп ерак барасы юк: əйтик, Мөхəммəт Мəһдиев иҗатына гына мөрəҗəгать итəргə кирəк.

М.Мəһдиевнең язганнары — ипи камырының «форма»га салынуы кебек, кеше хəтеренең гаҗəеп бер рəвеш алуы. Ул əсəрлəрнең кешелек тарихына кереп калган зур-зур вакыйгалар, олы шəхеслəр хакында түгел, гап-гади авылның гап-гади Əркəшəлəре һəм Хəдичəттилəре турында икəнлеген дə белəбез. Ə менə алардагы драматик киеренкелекне берни дə йомшарта алмый: сурəтлəнгəн хəл-əхвəллəрнең гадəтилеге һəм кыскалыгы да, үз геройларыннан авторның һəрвакыт диярлек мыек астыннан гына көлеп торуы да. Хəтта əлеге дə баягы сюжет (дөресрəге, фабула) дигəн нəрсəгə исе китмичə, укучыны үзе телəгəн якка борып йөртүе — аны əсəрнең эчке агымына буйсындыруы да. Əгəр болар кимчелек саналса, «Без —кырык беренче ел балалары»ндагы, «Торналар төшкəн җирдə»ге үзəк өзгеч моңга фальшь, ялгыш нота керми калмас иде, мөгаен.

Шулай да, китапның соңгы битен япкач, күңелгə һəм зиһенгə нидер җитенкерəмəгəн кебек тойгы кала... Нидəн икəн бу? Нəрсə җитми соң замандашларыбызның «хəтерлəүче проза»сына? Минемчə, тормышның үзе кебек күпкатламлылыкка, күпмəгънəлелеккə ирешү җитеп бетми. Хəзергə ул бик садə һəм җанга якын курай көен хəтерлəтə. Аның моңы кеше хəтеренең тирəн чоңгылларында яткан кайбер хатирəлəрне һəм тойгыларны уята. Ə бит язучы тормышның берничə кылына берьюлы кагылып, хислəр давылы, фикерлəр өермəсе дə кузгата алыр иде. Ни кызганыч, кайчак ул соңгы ноктасы куелган вакыйгаларны сүтəдер, процессның үзенə ирек куймыйдыр, укучының, Чапаев турындагы киноны карагандагы сыман, «бəлки, ярга йөзеп җитəр?..» дип өметлəнеп тору ләззəтен киметəдер кебек...

Тарихка, традициялəргə, үткəнгə мөнəсəбəт дəрəҗəсе адəм баласының бабаларыннан калган рухи мирасны үзлəштерергə сəлəтле булу-булмавын билгели. Ул гына да түгел. Хəтер тирəнлеге, хəтер тотрыклылыгы — дөньяга караш бөтенлеген, шəхес өлгергəнлеген күрсəтүче сыйфат. Аны шушы өлгергəнлеккə ирешү юлындагы чакрым баганалары белəн чагыштырырга мөмкин булыр иде. Хəзерге заманның кайбер яшьлəрендəге традициялəргə җиңел караш аларның шəхес буларак үсешен тоткарлап, маймыл бабаларына якынлаштырса, өлкəннəрнең хəтерсезлеге соңрак килүче буыннарда — балаларында, оныкларында туганлык элемтəлəрен яңартуга, тарихны аңлауга омтылышны көчəйтə. Гаҗəп хəл... Əмма хəтер диалектикасы əнə шундый бугай. Хəтернең актив көч булуы, узган гомернең иң асыл вакыйгалары белəн горурлану һəм кылган хаталарны онытмыйча, аларны аклау өчен күбрəк игелек эшлəп калырга ашыгу рəвешендə дə күренергə мөмкин.

Əхəт Гаффарның «Бер йотым су» хикəясендəге герой əнə шундыйлардан. Аның хатасы — тормыш авырлыгыннан. Асылында ул — бөтенлəй башка, яхшы күңелле кеше, шуңа күрə дə аны бүгенге хəтере, бүгенге вөҗданы газаплый. Ə.Гаффарның иң уңышлы əсəрлəрендə, бигрəк тə «Язлар моңы»нда галиҗəнап Вакыт хакимияте урнашкан. Хəтер аның геройларына «өченче үлчəм»дə яшəү мөмкинлеге, тормыш яссылыгыннан күтəрелеп, тиз агышлы чынбарлыгыбызда үз урыннарын табу мөмкинлеге бирə. Язучының өлкəн буын вəкиллəрен тасвирлаган образлары үткəннəн бигрəк килəчəккə йөз тота, үткəн белəн килəчəк арасына рух күпере сала. Алар безгə мирас итеп халыкның кешелеклелек нигезлəрен, үлемсез əдəп-низам кагыйдəлəрен алып килəлəр**.**

Билгеле, кайбер яшь язучыларыбыз иҗатындагы өлкəн замандашларыбыз һəр очракта да халык идеаллары гəүдəлəнеше булып җитми. Карчык-корчыклар, багучы-имчелəр экзотикасы белəн мавыгу, хəтта гариплəр экзотикасы (?!) да очраштыргалый əле бездə... Шулай да мондый кыланмышлар, минем уемча,— уза торган чир. Һəрхəлдə, əтилəре канында сугыш эченə кергəн, əнилəре канында окоп казырга йөргəн буынның хəтере тирəн, заман агышында үз урынын табарга омтылышы зур. Ə бу — тормышта үз урыныңны табу, кемнең варисы булуыңны һəм мирас итеп нинди хəзинə алуыңны аңлау дигəн сүз. «Сезнең онытырга хакыгыз юк...» — Əмирхан ага Еникинең «Соңгы китабы»ннан, соңгы васыяте...

Адлер Тимергалинның «Мəңгелек хатирəлəр» дигəн əсəрен фантастика сөючелəр генə укыган булуы мөмкин. Əмма анда тасвирланган хыялый күренешнең тормышчан җирлеге, мəгънəсе шактый

гыйбрәтле. Хәйдәр бабайның баш миенә тирән кереп оялаган һәм әлегәчә яшеренеп-оеп яткан мәңгелек хатирәләрне тылсымлы кристалл уята.

Бүгенге әдәбиятта якын һәм ерак үткәнгә, аерым шәхес, буын, халык хәтеренә мөрәҗәгать итү, халыкчан характерларны киң тормыш материалында өйрәнергә тырышу нинди «магик кристалл» белән бәйләнгән соң? Бөтен дөньяда «борынгы» стильнең бер модага әйләнүе беләнме? Әллә кечкенә генә мәйданда зур киңлек һәм тирәнлекләрне берләштерергә мөмкинлек бирүе белән җәлеп итә микән хатирәләр алымы? Бер сүз белән генә җавап бирүе кыен, әмма бу тирән агымның чишмәләре төптәрәк ятадыр кебек. Ул җәмгыятебез ирешкән иң зур рухи казанышларыбыздан берсе — замандашларыбызның тарихи хәтере тирәнәюе, кешелекнең үсеш юлын катлаулы һәм югалмас мирас итеп күз алдына китерүе белән, бүгенге зур тизлекләрне ачык тойган әдәбиятның тормышка актив мөнәсәбәте белән бәйләнгән.

Әйе, уйлап карасаң, барысы да үз эзенә кайта. Хәйдәр карт хатирәләре аша борынгы тарих җанлана, әби-бабайларның «әйтелмәгән васыяте» бүгенгә килеп ирешә, ул «яңа, таныш түгел» буынны кыю эзләнүләргә рухландыра.

Нелли исемле кыз Роберт исемле сөйгәнен хәтере җуелудан — ярыммаймылга әверелүдән коткарып кала.

Найман-ана улын һәлакәттән саклап калу өчен бердәнбер юлны сайлый: маңкортның үле хәтерен терелтергә дип өзгәләнә.

Минем Әдрәпи әбиемне дә туган авылы турындагы, игелекле кешеләр турындагы хатирә еллар буена ил гизәргә, безнең күңелләрдәге миһербанлылыкны уятып йөрергә — *яшәргә* мәҗбүр итә.

Әнә нинди көчкә ия икән ул — Хәтер. Үткән көннәр көле түгел, иртәгә туасы таңның кояшы икән ул. Буыннар арасындагы мәңгелек күпер, кеше нәселенең, халыкның, илнең үлемсезлеге икән! Моны онытырга хакыбыз бармы безнең?

1982

## ТӘЛЛИТУТ

Илдар Гата улы Хәлиуллин
рухына бер дога булсын.

Казан арты гына димәссең,— марига «арка терәп» утырган татар авылларына барып җиткәнче, көн кичкә авышырга өлгерде. Инде, күп булса, биш-алты чакрым гына калгандыр... Йә, бераз сулу алыйк, дип, ниндидер инеш буенда машинаны сүндердек.

Күзге коры җылымса кич аяк астыбызга калын чирәм түшәп куйган иде. Якын-тирәдә авыл-утар абайланмаса да, шактый озын торыклы тирәкләрнең иске зиратны хәтерләтеп бер тирәгә җыелуы, буадагы суның төпсез кара төскә керүе, колаклар чыңлап куярлык үле тынлык — хәтта бакаларның кичке «концерт»тан туктап калуы — әллә ничек сәер дә, шомлы да булып тоелды. Яр читендә боегып торган карт өянкеләр, алардагы тубал-тубал карга оялары әлеге тойгыны көчәйтте генә.

Хәвефләнүемне сизенгәндәй, юлдашларның берсе:

— Авыл урыны бу... Рус авылы иде. Әле берничә ел гына беткәненә...— дип куйды.

— Бер агай нигезеннән купмаска ни тырмашты. Ахырда, карчыгы гүр иясе булгач, каладагы малае алып китте үзен,— диде шоферыбыз.

— Әнә инешнең аргы ягында үргә таба бер урам сузылып киткән иде. Без басып торган төшендә — янә бер урам. Ике як, ике бригадага бүленеп, ярышып эшләрләр иде... Хәзер күз бәйләнгәнгә генә йорт урыннары бик беленми.

Чыннан да, авылга көтү кергәндә купкан тузан сыман, күз күреме җирне иңләп, эңгер сөреме тарала... Кара-кучкыл буа суы да өскәрәк күтәрелә бара, озакламый ул ярларыннан ук ташып чыгар төсле... Сискәнеп киттем. Исемә төште: төн карасы ягылганчы иске нигез урыннарында уйнап йөргәнне белсә, дәү әни и орыша иде безне: кояш баегач, йорт иясе кайтып, үз нигезен таба алмый елап торыр; сезгә шуның шаукымы кагылыр, дип куркыта иде... Сискәнүемнең сәбәбе, юк, ул түгел. Күз алдымда бүтән манзара терелде: кинәт кенә өянкеләр артыннан арыган-талчыккан күләгәләр килеп чыгар да, буа ягыннан кайтып килүче рус агайларының мыдыр-мыдыр сөйләшүе, анда-санда капка келәләренең шылтырап төшүе ишетелер кебек тоелды. Каяндыр зират тирәсеннән — көтү кайтканда адашып калган ялгыз бәрән бәэлдәве килгәндәй булды...

— Авылның исеме ничек соң? — дидем мин, әлеге күренешне күз алдымнан куарга теләп.

— Надеждино... Зур, матур авыл иде...

Бу төбәккә килеп беренче казык кагучы ир-егетнең Надежда атлы кыз баласы яисә сөекле кешесе булганмы? Бәлки, зур ниятләр белән тормыш учагын тергезеп җибәргәндә, Өмет (Надежда) дигән олы мәгънә салгандыр халык үз нигезенә?

Авыл үзе бетсә дә, мәңгелек чиркәве кукраеп калырга тиеш иде бит... Мунча миченә сүтеп ташып бетермәгәннәрдер ич инде аны? Әллә чиркәүсез — «алласыз» авыл булганмы бу?!

Юлдашларымның яшьрәге, таптыгыз ласа илтифат итәрлек нәрсә, дип битәрләгәндәй, буа ягына ук төшеп китте. Икенчесе дә, кунак хәтерен саклап кына, ахрысы, сүзне таныштыру рухында дәвам итте:

— Инешнең исеме юк. Ә авыл исемнәре әкәмәтрәк инде безнең якта...— дип куйды.— Пөшәңгәр дисеңме анда, Пошалыммы... Моннан ике-өч кенә чакрымда — Болгар авылы! Киңрәк җир-су эзләп, мари ягына аерылып чыккан пүчинкәне халыкта әле дә Никкүчтек дип йөртәләр...

«Ник күчтек!» дип үкенгәннәр бугай соңыннан,—бер кискән икмәк кире ябышмый шул. Кушамат кына ябышып калган. «Никкүчтек» — халыкның усал итеп көлүе дә, чын күңелдән жәлләве һәм, ахыр килеп, гыйбрәте, тормыш фәлсәфәсе дә шунда!

Ә исемсез инеш буендагы Надеждино авылы? Нишләп әле ул җир йөзеннән бөтенләй юкка чыккан?..

Нинди шомлы җилләр уйнаган бу тарафта, нинди афәт, җылы ояны туздырып, киләчәккә өмет яктысын сүндергән?..

Тыгыз чирәм катламыннан да төртелеп-бүселеп чыккан ташлар төсле шул сораулар өстендә басып торам... Миңа, Кама аръягындагы гөл туфрагына ияләнеп үскән угланга, кырысрак, катырак тоела шул бу җир! Соңрак сөйләделәр: таш тудырып торучы басулар бар икән бу төбәктә,—элеккерәк елларны хәтта кырдан таш чүпләргә мәктәп балаларын алып чыккалаганнар...

Яклавыма һич мохтаҗ булмаса да, дөреслеккә хилафлык кыла алмыйм: без бит әле Казан арты туфрагының ташлы гына түгел, ашлы да икәнлеген беләбез; һөнәре барга көн күрсәткән, ил табынына куярлык икмәк, ил күрке булырлык тырыш кешеләр үстереп килгән як ич бу!

Бал кортлары кебек тырышып-тырмашып тереклек иткәндер Надеждино халкы да. Таркалуы да, бәлки, умарта күче сыман булгандыр: «ил анасы» үлгәндер авылның... Өмете өзелгәндер... Куе әрәмәлекләр белән йөзек кашы төсле каймаланган бу аланны ташлап киткән кешеләрнең тагы кайдадыр төпләнеп яши алуы акылга сыймый.

Ятим зират, салкын тынлыкка чумган буа тарафларына карап торганда, үземнең туган якларым — исемсез инешләр буенда коргаксып килүче бәләкәй генә Мәүләшә, Мулла авылларын күзалладым... Сезне дә шул язмыш көтә микәнни, канатларым?..

Кайда гына булмасын, нинди генә чишмәләрнең суын эчмәсен,— адәм баласы үзенең туган җиренә тартым билгеләрне эзлидер. Тукайны үстергән төбәктә дә елның теләсә кайсы фасылында үзеңә таныш, якын төсләрне тапмый калмыйсың. Йә басу-болын рәвешләрендә, йә — су агышларында... Әнә бит, нәкъ безнең Болгар — Биләр якларындагы төсле: көрәк батырып алуга, көмештәй су бәреп чыга; һәр кизләвенең үз тәме, үз кирәмәте!

«Кирәмәт» димәктән, ташлы текә яр битеннән күз-күз булып сирпелгән чын могҗиза иде шул ул! Кем белгән бит Казан арты чишмәләренә сокланырга ярамаганын... Күз тутырып кына карасаң да, киемеңнән бер җеп өзеп, суына саласы икәнен... Хәер, белсәң дә, истән чыгар иде, бәлки, ул мәлдә... Шул көнне һичбер сәбәпсез кәефсезләнеп китүемне бары тик чишмәләренә «күз тидерүем»нән генә күрделәр...

Шуннан соң мин үзем дә ташкалада яшәргә мәҗбүр булган бихисап әбиләрнең «су тоткандыр» дигән сүзләреннән авыз ера алмыйм, туган якларындагы гап-гади чишмәләргә, исемсез инешләргә багышлап укыган догаларын тирәнрәк аңлый барам шикелле... Ул суларның бөтен хикмәте — туган төбәктә тибеп чыккан булуларында икән бит!

Дөньядагы иң изге кизләү — авылдашларыбызны гасырлар буе тәмле чәй суыннан өзмәгән, артып калган дымын бәрәңге бакчалары очыннан сызылып китүче исемсез инешкә биргән, әниләр кебек юмарт һәм сабыр бер чишмә икән! Сагыну сусынын басса — ул гына баса, җанга сихәт бирсә — ул гына бирә... Адәм баласына зур авырлык килгәндә, дөньяның теләсә кайсы почмагыннан туган илләргә таба ашыга-ашыга кире йөгерүче хәтер чишмәләребез сау була күрсен!

...Без бер елны Тукайның балачагы узган авылларда йөреп кайттык. Тукай гомеренең дүрт мизгелендә яшәдек. Дүрт авыл чишмәсенең суыннан авыз иттек. Кушлавыч кизләвендә шагыйрь туган нигезнең затлы тереклек дымы сакланырга тиеш иде... Өчиле чишмәсендә Кәбир мулла ихатасының карт өянке шәүләсе уйнады... «Дөньяга иң элек күзе ачылган» Кырлайда исә, куш учына алып, безгә Габдулла үзе су эчерде сыман. Сасна бер читтә, Сасна суыннан зират какыларының ачы тәме килер кебек тоелды... «Бар күңелләрдән җылы, йомшак кабер ташы»на — әнисенең якты рухына, сабыйлыгының кыска бәхетенә сыенып елардай чаклары булгандыр ла шагыйрь баланың...

Безне (Мөхәммәт Мәһдиев һәм рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов белән өчебезне) бу сәфәргә алып чыккан көч — Тукай балачагының шаһитларын күрү теләге иде. Юк, «менә тушында Апуш белән икебезгә Су анасы очрады» дип әкият сөйли торган бабайларны эзләмәдек. Безгә Шагыйрьне тәгаен күргән шаһитлар кирәк иде...

— Таба алдыгызмы соң?! — дип сорарсыз.

Таптык, әлбәттә. Гомер буе күз алдыннан китмәс инде алар: нәни Габдулланың тәпиләрен хәтерләүче сукмаклар; аны уенга кызыктырып торган кашка тау битләре, инеш буйлары; аның әле ду-чат килеп йөгергәнен, әле олыларча уйга батып калганын күргән карт өянкеләр, шомыртлар...

Шул ук вакытта безне шаккатырган күренеш — дүрт авылда да ниндидер уртак яклар, охшаш манзара ачылып китүе! Үксез сабыеның йөрәк яргыч югалтуларын йомшартырга теләгәндәй, һәр карьядә табигать таныш рәвешкә кергән, «ятсынма, бәбкәм» дип, аны үз кочагына сыендыргандыр, күрәсең. Ак-садә балалык дөньясы нәкъ менә бирелә бөтен төсләргә чәчелеп киткән. «Зуп-зур Тукай»

булгач та, шул төсләрне юксынып, эзләп яшәгән ул. Хәтта — «күз карашымда хәзер үзгәрде әшьялар төсе»,— дигәндә дә... Барча төсләр уңып, янә бергә кушылгандай, дөньяның салкын кары — чирле үпкәсенә, салкын кәфене какча тәненә ябылганда да... Күңел гөлләренең генә иң җете төсләре тоныкланмаган, керләнмәгән, ул төсләрдә — даһи Тукайның җан аклыгы.

Тоташ тетрәнүләрдән торган бу хәят һәм иҗадият әле кайчан да булса чын трагизмы, чын бөеклеге белән ачылыр... Үзе әйтмешли, килер бер көн...— олы иҗаты белән «биш минутлык төш шикелле генә» бала чагы арасындагы ефәк җепләр дә ачыграк беленер... Иң бәхетсез көннәрендә дә шагыйрь җаны, күбәләккә әверелеп, туган тарафларына — гомер таңына очкан ич: «Яд итәм, бизсәм үземнән, мин сабыйлык чакларын..» Фаҗигасе зур шушы сүзләрнең!

Үксез баласына табигать-әнкә куенында яшәү өчен ифрат кыска вакыт биргән Казан арты. Ә шул күк капусы ачылып алгандай бер тын эчендә дә күңел күзе матурлыкны күбрәк күреп калырга өлгергән:

И күңелнең шаулап аккан чишмәдән
сафрак чагы!
И гомернең нурланып үскән яшел
яфрак чагы!

Җир йөзенең кабатланмас ямен — табигатьтәге төсләр, исләр, авазлар хәзинәсен үзең дә «яшел яфрак чагыңда» күреп, тоеп-ишетеп калырга кирәк икән шул! Соңыннан иң атаклы концерт залларында да балачак урманының аһәңен ишетермен димә... Туган туфракка сабый чакта җибәргән тамырлар гына кешене ватанлы итә, хәтерле итә — бәхетле итә. Табигать баласы икәнлегеңне тою нәкъ шул чорда ярала һәм, Тукай әйткәнчә, «һәр чәчәк — сеңлең, апаң; абзаң — үсеп торган агач» икәнлеге күңелгә мәңгегә берегеп кала. Күпме еллар үтсә дә, бу туганлык тойгысы өзелми. Кәүсә белән кабык арасыннан яфрак очларына таба суырылып менгән ширбәтле дым шикелле, кан тамырларында уйный ул хис. Шуңа күрә адәм баласы һәр язда гөрләвекләр белән бергә уяна, күпереп-парланып торган җир исе аның бөтен тәнен кытыклый. Тал песиләренең оялчан матурлыгыннан әсәренгән күңел әллә кайларга ашкынып тыпырчына!..

Без малай чакта — хәтерегездәме, Исламетдин, Әгъзәметдин, Фәрдегалләм...— «тал песие» дигән сүз бөтенләй юк иде кебек. Безнең авылда аны «тәллитут» дип йөртәләр; үз йоласы, такмазасы да бар иде әле ул тәллитутның! Андый йоланы инде безнең энекәшләр белми, бала вакытларыбыз төсе булган «тәллитут» сүзен дә алар онытып баралар бугай... Безнең хатамы соң бу —тапшырып калдыра алмаганбызмы? Әллә һәр буын әйләнә-тирәсендәге җисемнәрне, күренешләрне үзенчә таный, аларга исемне дә үзенчә кушамы? Бәлки, шулайдыр?!

Кешелек дөньясының да балалык чорында табигать көчләре белән танышуы, аларны тылсым иясе итеп күрүе, аларга табынуы бары тик көнкүреш хаҗәтләре аркасында гына булгандыр дип ышанасы килми. Монда һичшиксез үзенә бер шигърият, иҗат гамәле бар.

Табигать сурәтләре (сандугач, күгәрчен, Сак белән Сок...) мифлардан һәм җыр-бәетләрдән тәрәзә йөзлекләренә, кульяулык читләренә «килеп куна»... Дикъкать итебрәк карасаң, һәр хәрефтән, ташка сурәте уелып калган борынгы күбәләк сыман, тамгага әверелгән табигать мизгеле  карап тора!..

Тәүге тапкыр кем күреп сокланды да: «Карале, каен!..» — дип ачыш ясады икән? Гап-гади исемдә, кушаматта да әллә нинди хикмәтләр йомарланып калгандыр әле, уйлап карасаң. Әнә бит, «нара-а-ат!» дип кычкырабыз, ә кайтавазы ташкүмергә әйләнгән тарих урманнарыннан ук килә: борынгы бабайлар телендә ул «кояш агачы» мәгънәсен аңлаткан!..

Табигать белән бәйләныш әнә шундый беренче тойгылардан, исем кушу иҗатыннан, ышанулар шигъриятеннән башланадыр әле ул?..

Чәңки-чәңки, чәңки җылан,
Чәңки башлы кара җылан...

Исегезгә төштеме? Миңнисаның әнисе өйрәткән әфсен ич бу! Кайсы Миңниса дип, Гомәр Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повестендагы Миңниса инде. «Әби әйтә, салават күперен бармак белән төртеп күрсәтергә ярамый, ди». Гумәре дә әллә ниләр белә: «Бисмилла әйтәсең дә өермәнең нәкъ уртасына китереп сугасың! Бөтен өермәң, алтын булып, аяк астыңа чәчелә дә китә! Белдеңме?»

Китапны ябып куйгач та, шул «...Чәңки җылан» дигән бүлеге тоташтан шигырь белән язылгандыр сыман тоела башлый. Зиһенеңә, күңелеңә халык шигъриятенең кайнар дулкыны килеп кагыла... Ак еланга ышанулар, шуңа бәйле әкиятләр искә төшә. Халыкның «елан белән баканың теле бер» дигән сүзенә дә тормыш тәҗрибәсеннән туган сөземтә, киная генә түгел, каршылыклар берлеген үзенчә аңлатучы фәлсәфәсе сыйган ич...

Дөнья яратылуы турындагы миф-риваятьләр, «ни өчен ни булган» рәвешендәге әкиятләр һәм һәртөрле ияләргә ышану, юраулар, фал ачулар... Бабаларыбызның табигатьтән аерылгысыз «көне һәм дине» хакындагы бу хәзинә бездә ни дәрәҗәдә тупланган? Тупланган кадәресе дә тузан җыеп ятмыймы?

Шүрлеккә үреләм һәм... «Славян халыкларының табигатькә шигъри карашлары» дигән өчтомлыкны кулыма алам. Язылган, басылган дәвере —унтугызынчы йөз уртасы. Янәшәдә Каюм Насыйри китабы. Аның егерме бите — «Казан татарларының ышанулары һәм гореф-гадәтләре». Русчадан тәрҗемә, чөнки төп нөсхәсе рус телендә, үткән гасырда Петербургта нәшер ителгән...

Без, әлбәттә, төшебездә көтү куганнарын күрсәк, әбиләребез кебек: «Сугыш кузгалыр»,— дип, тиргә батып уянмыйбыз. Яисә, өстеннән үрмәләп маташкан үрмәкүчне сыпырып төшергәндә, кем инде «миңа яңа күлмәк үлчи» дип ышансын, җүләр! Ләкин бабаларыбызны шагыйранә ялганга ышанып яшәүдә, хәтта томаналыкта гаепләп, бик күпне югалтмыйбызмы?

Урман юлы буйлап атлаганда, берәү киселгән агач төбенә тибеп китә, икенчесе аны патефон тәлинкәсенә охшатып, хыялга бирелә: «Бу сырларда, бәлки, ниндидер көй язылып калгандыр, шуны уйнату җаен тапсаң иде!» — ди. Теге адәм эч пошканнан ботак сындырып бара. Бусы кәүсәләргә сак кына сугып карый: агачның хәлен сораша —саулыгын тикшерә; уйлана: кешене дә шулай шакып, күңелендәге белергә иде, ди,— тыштан гына бик кәперенеп басып тормыймы ул, хакыйкатьтә эче черек түгелме?..

«Әни миндә табигатьтәге бар нәрсәнең дә җаны бар икән, чишмәләр генә түгел, йолдызлар да, җилләр дә сөйләшә икән дигән «иман» тудырды»,— дип яза Хәсән Туфан. Табигатьтәге башка җан ияләре белән якынлыгын, туганлыгын тоймаса, алар арасында ялгыз түгел икәнлеген аңламаса, адәм баласы, шәт, ике аякка торып басарлык, җирдә үзен хуҗа итеп сизәрлек көчкә ия булмас иде.

Тик табигать кенә, безне үзенә охшатып «яратырга» керешкән дә, каршылыклар белән бүленеп, туктап калгандыр шикелле... Җирнең — сүнгән Йолдыз, ә кешенең Галәм заты икәнлеген барыбер истән чыгармаган безнең бабайлар: авылның буйга җиткән һәр сылуын «тулган ай дик нурлы йөзең балкытадыр дөньяны» дип зурлаганнар. Ә үзенең яңа туган кызчыгына Кояш (!) дип исем кушар өчен безнең Закир абзыйларга нинди кыюлык кирәк булган! Күк йөзендәге җисемнәргә исә гап-гади җир исемнәре ябышып калган. Шунда халыкның фикер галәме, тарихи үсеш дәрәҗәсе дә ачылып китәдер шикелле... Гаҗәп түгелмени: төнге күккә ашып баручы йолдызлар кәрванын Киек Каз Юлы итеп күр әле! Бик күп төрки халыкларга ул кем артыннандыр коела-коела барган саламны хәтерләткән. Төректә — Saman Yolu. «Анам кыры» әсәренең дә беренче исеме — «Саламчы Юлы»... (Чыңгыз Айтматов, шулай, үз халкын Киек Каз Юлына күтәреп, бөтен дөньяга күрсәтте. Әле дә анда, «сәмави-космик» яңгырашка ишарә булып, Тулганай исеме балкып тора.) Ә рус һәм Европада яшәүче халыкларның хыялый күзләренә ул «юл»да түгелеп калган «сөт» күренгән: Млечный Путь (русча); Milky Way (инглизчә), Voie laktee (французча), дигәннәр; грек теленнән кергән «галактика» сүзе дә «сөтсыман» дип тәрҗемә ителә...

Ниһаять, кайсы йолдыз асларында туугa карап, язмышны юрауда да бабаларыбызның космик фикерләүгә, әллә нинди закончалыкларны табарга омтылышы сизелә. Бүген ясалма юлдашлар Җир ихтыяҗы белән орбитага чыккан кебек, йолдызлар җемелдәвенә карап, илләр-дәүләтләр иминлеген күзәткән, һава хәлен чамалаган борынгы кеше. Йолдызлы күк гөмбәзе, сәйяр болытлар һәм очар кошлар күңелне алгысытып, никадәр биеккә әйдәгәндер! Әмма адәм баласының хыялы җирдән аерылмаган. Чөнки шул туфракта, табигать куенында, аның кырыс кануннарына каршы тора-тора көн итәсе булган!

Бер яктан, әлеге кырыслыкны йомшартырга тырышу (хәзер дә, боз ява башласа, әбкәйнең ишегалдына кисәү агачы чыгарып ташлавы искә төшә), икенче яктан, әкиятләрнең бөтенесендә дә диярлек, табигатьнең — Әйләнмәле карама яисә Ак бүре кыяфәтенә кереп — кешене яклавы шул турыда сөйли. (Сүз уңаеннан, барыбызга да мәгълүм «Сандугач һәм Чишмә» кебек әсәрләрдә бу традициянең гаҗәп яклары белән кабатлануын, гомумән сугыш елларында язылган китапларда та-

бигатьнең дошманга каршы көрәштә ярдәм итүен искә алыйк.) Ниһаять, шәһәр һәм дәүләт байраклары да шул туфрак төсе булган, шул халыкка «химая иткән» рух сурәте белән аерыла (Казан гербындагы Канатлы җылан яисә рус «чар»ларының тәхет сакчысы — ике башлы бөркет, мәсәлән...)

Адәм баласының дөньяга килгәннән башлап бөтен тормышы, халәте табигать фасылларына бәйләнгән. Төрки халыкларның беренче таш «китап»ларында ук тереклек дөньясының, ел әйләнешенең холкын-фигылен, хәрәкәт механизмын сынап, алдагы буыннар өчен теркәп куярга омтылыш сизелә. Дөрес, бу багланышларның тирәнлеген, тотрыклылыгын күрү шактый читен: яндырылган күперләребез байтак... Хәтерсезлек тә көчле... Тукай ачынып әйткәнчә, «нишлисең, тәкъдир шулайдыр, халкыбыз шул бик надан...» Дингә каршы көрәшәбез, дигән булып, татар халкының мифларын, ышануларын туплаган юньле китап та чыгара алмаганбыз. Кайдадыр чәчелгән, җуелган, онытылган. Аның урынына күршеләр белән уртаклык көчәйгән: «Микула җитми җәй булмый, Микула җитми кыш булмый»,— дигәннәр бабайлар. Русның үзендә мондый әйтем күренми дә шикелле. Микула дигәне исә дини календарь бәйрәме — искечә майның 10ына һәм декабрьнең 6 сына туры килә икән. Ләкин халык сынамышының чиркәү белән һичнинди алыш-биреше юк. «Раштуа, питрау, покрау» кебек хәтәр дини атамалар рәхәтләнеп татар агаеның календарена да кергән. Ел әйләнәсенең һәр көненә үз мәгънәсе — ачы тәҗрибә авазы салынган, шуңа карап яшәү ритмы билгеләнгән. Табигать белән аңлашылмаучылык килеп чыкса, әнә шул ритмны санга сугарга теләмәү генә сәбәпче булган.

Монда, гайре табигый көчләрнең күңелен күрергә тырышу белән бергә, әлбәттә, җаен китереп, «хәйләләү» дә юк түгел. Кояшны үз тирәндә әйләндерергә, дөньяның «кендеге» булырга омтылыш бик тыелгысыз булып, әледән-әле бәреп чыккалаган. Әйтик, хәйләкәр Агай белән уртагына бер елны — шалкан, икенче елны бодай чәчеп алданган Аю турындагы әкият тә шундый омтылышның җимеше бит! Без ул Аюдан авыз күтәреп көләбез, ә бәлки, жәлләргә кирәктер аны, кызганырга кирәктер?!

Өй каршысына утырткан тупыл түбәдән биегрәк булып үсә алмый, дип әйтәләр иде безгә — малайларга. Табигать исә бу фикернең тамырдан дөрес түгеллеген исбатлый иде. Килеп туган каршылыкны ни рәвешле хәл итүләрен хәтерлим: «башбирмәс» тупылны утынга тураклыйлар һәм албакчага бүтән — күндәмрәк, базыграк буйлы агач утырталар... Әйтерсең лә өйнең үсә алмавына тупыл гаепле...

Кул-гамәл табигатькә каршы баргаласа да, нечкә күңел, аек акыл һәрвакыт аңлашу һәм гармония эзли. Буыннан буынга тапшырыла килгән гыйбрәт-тәҗрибә һәм көнкүреш фәлсәфәсе шаһит моңа. Борынгы китаплардан башлап уздырылган фикер — адәми затны табигать күрке итеп тасвирлау да — кешелеклелек өчен көрәшнең мөһим бер юнәлеше. Иң яхшы әсәрләр бу теманың яңадан-яңа катламнарын ача; карурман эченәрәк керә барган кебек, табигать баласының рухи тормышын тирәнрәк, тоемлырак итеп аңлый барасың. Ләкин шундый чаклар да була, күңелне икеләнүле уй тырнап ала: кешене табигать белән янәшә куеп, чагыштырып тасвирлау ниндидер котылгысыз өлге-стереотипмы соң әллә?

«Куркак куян», «хәйләкәр төлке» ише катып калган сурәтләр, «ярамый!» дип бармак селкеп торучы плакат-хикәяләр тәмам басып китә башласа туа андый тәэсир. Сер түгел ич: чын әдәбиятка тартылу башланганда гына, «табигать турында» дигән булып, күпме төссез-хиссез парчалар, матур тышлы китапка әверелеп, безнең юлны бүлә...

Кемдер, фотосунарчы исеменә дәгъва итеп, газета-журналда карачкы рәсемнәрен бастырса, икенче берәү шул ук алым белән «натуралист язмалары» өлкәсендә каләм шомарта. Асылда, икесе бер үк шөгыльдә; салкын карачкыларына орынган саен, җан чиркана, әкрен-әкрен хисләр суына. Иң аянычы шунда: әлегедәй «өлге»ләрдән соң инде чын әдәби күренешләрдән дә таныш фикерләргә иллюстрация, «коеп куйган» мораль-сөземтә эзләргә керешүең бар. Теләсә кайсы әсәрнең биген шулай кәкре кадак белән каерып ача алмасаң, ачуың килә башлый!

Хисам Камаловның «Куян күзе нигә кызыл?» дигән хикәясе дә, мәсәлән, шундый каршылыклар уртасында калган иде... Дөресрәге, ул каршылык әсәрнең үз эчендә үк куерып килә, бөтен хикмәт әлеге конфликтны ничек аңлауга гына бәйле иде...

«...Нигә кызыл?» дигән сорауны Әлфис исемле малай этисенә бирә. Кем аның этисе? Бүтән эшкә кулы ятмаганга куян үстереп көн күрүче бер агай. Куян балаларын лабораториягә илтеп тапшыра да

уч тутырып акча алып кайта (анда ун көнлек куян канынннан дару ясыйлар икән). Үзе үстерешкән озынколакларның кая китүен яхшы белә малай. Куян бәлешен дә бик ярата. Әмма күңелендә бу җан ияләрен җәлләү тойгысы артканнан-арта бара. Ә көннәрнең берендә яшь куяннан ничек итеп кан сауганны ул үз күзләре белән күрә. Шул төнне беренче тәвәккәл адымын ясый...

Аңлашылганча, хикәя гади генә вакыйгага корылган. Аны укып чыгу белән туган беренче тәэсир шулай ук бик ачык: бер якта — ачкүзле ата хөрәсән, икенче якта — «табигатьне яратучы» малай. Кыйссадан хыйсса, ягъни мораль — кешеләрнең рәхимсезлеген фаш итү, шуңа каршы протест уяту.

«Юк, хикәя каты бәгырьле атага нәфрәт уятыр өчен язылмаган, алайга китсә, Әлфис үзе дә куян бәлешен ярата,— дип каршы төшә икенче фикер.— Монда иң мөһиме — чынбарлык һәм мәҗбүрият белән беренче тапкыр йөзгә-йөз очрашу газабы тасвирлана, шуңа күрә малайның кичерешләре дә тирәнрәк, каршылыклырак».

Матбугатта да шуңа охшаш кылычка-кылыч килеп алу булды.

Күрәсең, «Куян күзе...» хикәясе табигатьне яклау темасына язылган, дип раслаучыларда да беркадәр хаклык бардыр. Тик «табигать» төшенчәсе генә биредә икенчерәк эчтәлекле: сүз кешенең эчке табигатен, рухи гармониясен саклау хакында бара. Менә шул мәгънәдә әлеге әсәр безнең күңелләргә кереп урнашкан «Алмачуар»лар традициясен дәвам итә шикелле.

Галимҗан Ибраһимов «Алмачуар» хикәясен «Бер мәхәббәтнең тарихы» дип атаган икән, бу һич тә очраклы хәл түгел. Мәхәббәтле һәм кырыс дөньяны тирәнтен кичереп аңлау сыйфаты бездә табигать белән аралашу дәвамында формалаша. Шул тирәлектә кешенең тышкы һәм эчке матурлыгы ачыла. Табигать белән каршылыкка кереп, аңлаша алмаганда яисә аңа хыянәт итүгә үк барып җиткәндә исә кешенең рухи дөньясы җимерелә, язмышының фаҗигале яклары өстенлек ала.

Тормышыбыздагы каршылыклар дөнья хәл-әхвәлләрендә, замандашыбыз күңелендә һәм табигатендә, аның яшәешендә ничек чагыла? Бүген бигрәк тә яшьрәк буын язучылар иҗатында бу сорауга җавап эзләү процессы кызыклы. Арадан Фәүзия Бәйрәмованың эчендә дөрләгән утка түзә алмыйча үз-үзен ярга ташлаган балык кебек бәргәләнүче геройлары игътибарны җәлеп итә. Җимерелә баручы иллюзияләргә, кеше күңелен сындырып сынаучы заман каршылыкларына бирешмәслек көч һәм таяныч эзли язучы...

Адәм баласының ялгышуларына, фаҗигаләренә табигать үзе дә битараф түгел дип ышанасы килә (әнә бит, гаилә таркалуын, хуҗалары аерылышуын бигрәк тә этләр газаплы кичерә, дип язалар...). Әкиятләрдәге Әйләнмәле карама шикелле үк, куенына сыендырсын иде ул безне! Бу багланышларны тирәнтен тойган чын сәнгать әсәрендә дә табигать үзалдына, ниндидер күренеш («пейзаж») рәвешендә генә яшәми. Каһарманнарның язмышында ул турыдан-туры катнаша, аларның уй-хәрәкәтләренә юнәлеш бирә, шул рәвешле, укучының да фикер агышына, чынбарлыкны кабул итүенә тәэсир ясый.

Соңгы елларда китапларыбызда аеруча активлашып киткән (күбебез зоопаркларда гына күрү бәхетенә ирешә алган) бүреләргә игътибар итик. Алар арасында «саф» бүреләр (бигрәк тә сугыш елларының кышкы юлында очрап торганнары һәм «Тамгалы бүре»дәй мәхлуклары) белән бергә эттән азганнары да («Ак маңгайлы бүреләр») ишәя бара. Беренчеләре, «табигать санитары»ның яманатын йолып, кешенең бүредән дә миһербансызрак булуын расласа, икенчеләрендә (мәсәлән, Аяз Гыйләҗевның «Җомга көн кич белән» әсәренең финалында) аяусыз чынбарлыкка киная — тамырга чабылуның, «этлектән чыгарылу»ның нинди аяныч нәтиҗәләргә китерүе, нинди рәвешләр алуы күренә. Беренчеләре дигәннән, Фаил Шәфигуллинның «Тамгалы бүре»се дә, «Ак маңгайлы бүреләр»е дә явызлыкка явызлык белән җавап кайтару идеясенә туры килми. Бүреләр биргән кешелеклелек сабагының бүтәнчәрәк чишелешен сайлап ала язучы. Нәбирә Гыйматдинованың «Соңгы очрашу» хикәясендәге эт-бүре бу җәһәттән үзенчә гыйбрәтле.

Ә Чыңгыз Айтматовның «Ахырзаман» романындагы бүре халкы... Балаларыннан яздырган кешеләргә бик-бик рәнҗи Ана бүре. Үчен ул «ике аяклы бүре»ләрнең үз угылларын урлап кына кайтара ала... Малайның этисе исә, бүрегә атам дип, газиз баласын харап итә... Табигатькә зыян салу кешенең үзенә җәза булып кайта, аның нәсел дәвамын өзә. Борынгыларның бүрегә изге җан (ия, тотем) итеп карауларын да искә алсак, бу —адәм баласының үзе изге дип инанган нәрсәләргә каршы кул күтәрүе булып аңлашыла... Асылда, «Ак пароход»тан ук сузылган фикер йомгагы алга таба сүтелә! Шул

рәвешчә, мәсьәләнең аеруча катлаулылыгын, аеруча җитдилеген Айтматов янә бер тапкыр искәртергә тырыша.

Ничек болай килеп чыкты соң әле? Табигатьтән рәхим-шәфкать көтеп тормаска чакырдык, елгаларның агышын кирегә боруыбыз белән мактандык. Үз тамырыбызны корытырга керешкәнбез түгелме соң? Сабак-тәҗрибә дә бар иде югыйсә: табигать безнең электән килгән хаталарыбыз, исәпсезлекләребез өчен эзәрлекли башлагач, карурманнар урынына — «урман-ышыклау полосасы» дигән каһкаһәле исем белән — тарурманнар утыртырга мәҗбүр булган идек инде. Тик шул хәлләрдән соң да сазлыкларны корытып, болыннарны сөрдек. Авылларны, зиратларны, иген кырларын су астында калдырдык... Судан бастырылган урманнарның әнә хәзер дә шәрә ботак очлары тырпаеп күренә. Йодрык селкеп безне каһәрләүләреме, әллә, кулларын өскә чөеп: «Коткарыгыз!» —дип ялваруларымы шулай?

Табигатьтәге тигезлекне, җир-сулар әйләнешен бозуга авазадаш булып, игенчене җирдән биздерү, үткәнне инкарь итү кебек ямьсез күренешләр тамыр җәя килде. Уңдырышлы туфракны йота баручы комсыз ерганак шикелле, алар узынганнан-узына барды. «Киләчәксез авыллар» теориясен уйлап чыгардык. «Шүрәле каргаган» авыллар ишәя барганда,— үзебездән җаваплылыкны төшерү өчен!.. «Киләчәксез телләр» турында авыз тутырып чүбек чәйнәгән арада, ярты милләт телдән язды... Бата башлаган корабтан качучы күселәр кебек, газиз туфрагыннан «культуралырак» бакчага сикереп, тамырсыз көе булса да, башкалардан җәһәтрәк үсәргә уйлаган, бөтен дөньяны хәйләләргә азапланган «табигать ялгышлыклары» барлыкка килде...

Әнә шул хәлләрдә эт-бүреләр безгә табигатьнең кырыс кисәтүен җиткерә.

Табигатьне саклау бүген генә барлыкка килгән проблема түгел ләбаса. Ни өчен соң нәкъ менә хәзер аңа күбрәк игътибар итәбез? Күрәсең, моның төп сәбәбе — электәге һәм хәзерге «буйсындыру» нәтиҗәләренең капылт, берьюлы күренә башлавыдыр. Инде соклану, мәхәббәт хисе уяту — традицион, искергән алым, ә яңалык ул —мохитне саклау турында чаң сугу, дип санаучылар бар... Мәктәптә, табигать белеменнән бигрәк, мохитне саклау фәне укытылырга тиеш, дип игълан итәбез. Бу фикерләр колакны торгыза торгызуын. Әмма Саклау проблемасына Тану, Аңлау мәсьәләләрен каршы кую да дөрес булмас иде. Җир-суларыбызны актив саклау — кисүдән тыю гына түгел, үстерергә омтылыш, ихтыяҗ уяту да ич әле ул.

Табигать — гөлләр теле, сурәтле фикер чишмәсе, дибез. (Русның «приРОДа», «РОДник» кебек сүзләрендә дә тудыру, чыганак мәгънәсе сыенып тора...) Шул ук вакытта үз-үзебезне сынап карыйк әле: нинди үлән-чәчәкләрне төсе, исе буенча аера алабыз? Югыйсә бу бит — туган телне белү кебек үк тәүге ихтыяҗ! Бу — «табигать белеме»нең иң беренче баскычы. Кызганыч, без укый торган китапларда табигатьнең яшәешен тою — конкрет төсләрне аеру, исләрне сизү — торган саен кыенлаша бара. Барчасы да тоташ «хәтфә» төстә (көз көне булса, әлбәттә, «алтын» төсендә)... Әллә соң үзләре басып торган җирне язучыларыбыз галәм биеклегеннән генә тасвирлый башладылармы?

«Икенче баскыч» дип билгеләргә мөмкин булган этапта без тышкы билгеләрдән эчкәрәк үтеп керәбез, табигать серлелегеннән кеше күңелендәге хәзинәләр байлыгын тоярга омтылабыз. «Һәр чәчәк — сеңлең, апаң...» иконлегенә ышанып, олы белән кече мөнәсәбәтләренең катлаулы үрелешен күрә-күрә, ярату һәм җәлләү тойгысы тәрбияләнә; без шулай кеше хәленә керергә, башкаларны матур һәм ямьсез яклары белән кабул итәргә өйрәнәбез.

Әлбәттә, мондый баскыч-басмалар бик шартлы. Аларда дәвамлы хәрәкәт — әйләнә-тирә дөньяны һәм үз-үзебезне тирәнрәк аңлый бару процессы чагыла. Үз-үзебезне,—димәк, басып торган җиребезне, нигез туфрагыбызны, шәҗәрә-тамырларыбызны да, дигән сүз.

Өченче баскыч безне әнә шул «торналар төшкән җир»гә, аның гади дә, ахыргача төшенеп бетү өчен бер кеше гомере генә җитмәслек дәрәҗәдә тирән дә фәлсәфәсенә якынайта.

«Туган җир туфрагы...» Мәктәп дәреслегенә кергән, сабый күңел белән тоеп, күздән яшь чыгарган шундый хикәя бар. Ул әсәрне мин хәтер чоңгылларымдагы күренешләр, инде бу дөньядан кичкән, бары тик минем балачагымда гына яшәүче якын кешеләрем белән бергә сагынам. Кабат кайтып укудан нәрсәдер тыеп тора: беренче кайнар тәэсир җуелыр да, нәүмиз калырмын төсле...

Ниһаять, бу өченче баскыч: табигать — мәңгелек тема; ул, тормышыбыздагы иң вак нәрсәләрдән алып дөньякүләм мәсьәләләргә кадәр колачлый торган глобаль тема да, дип раслый. Чөнки, шагыйрь әйтмешли, «диңгезләрнең өсте япмаган...»

Бер-берсеннән ерак араларда, үзгә шартларда яшәүче кешеләрне ни берләштерә? Аларның хәтта уйларында уртаклык каян килә?

Кайчак андый якынлыкның серен җиңел генә чишәрсең кебек. Мәсәлән, безнең Фаил Шәфигуллин белән абхаз язучысы Фазыл Искәндәр китапларын янәшә куеп укыганда... «Кәҗәмөгез йолдызлыгы» һәм «Созвездие Козлотура» дигән исемнәрне күрүгә үк, шундый тәэсир уяна. Икесендә дә төп «каһарман» — кәҗә... Акрын-акрын бер фикергә киләсең: бу ике язучыны, Каф-тау итәгендә яшәүче каһарманнар белән безне күзгә күренмәс җепләр бәйләп тора! Иҗатның чын серләре менә шунда башлана...

Дөньяның капма-каршы полюслары, килешмәүчән каршылыклары кеше күңелендә гаҗәеп бәйләнешларга керә. Галимнәр, әйтик, болгар бабаларыбыз күзаллавында Каф (ягъни Кавказ) тавы «ни өчендер» төньяк тарафта булып чыга, диләр. Әкият-мифларыбызга әллә кайдан гына диңгез, тау сурәтләре килеп керә. Дөрес, дөньяда күчмә сюжет дигән нәрсә бар, күп дәверлек аралашу-бәйләнешләр тәэсире дә калын катлам булып утырган. Ә бәлки, кайсыдыр күзәнәкләрдә, геннарда тарихи хәтер сакланып, кайтаваз булып киләдер: Каф тавының аргы ягыннан — җылы диңгезләр итәгеннән, мәһабәт таулар куеныннан?..

Бик күп халыклар мифологиясендә кешенең кошлар нәселеннән булуы искә алына. Ә безнең «Сак-Сок» бәетендә әле «кабат» кошка әверелү дә бар! Хыял гынамы бу, әдәби сурәт кенәме? (Минем әби: «Бәндәләр арасында нәсел җебен эттән яисә мәчедән башлап килүчеләр дә бар: алабай ыруына бәйлеләре — усал, мыраубикә дәвамчылары куштан булыр»,— ди иде...) Игътибар итеп карасаң, табигать сурәтләре аша кешенең җиргә, тормышка, дөнья барышына тарихи-фәлсәфи мөнәсәбәте ачыла. Җир-сулар, һавалар хәле белән ил-көн, кеше язмышы, тынычлык турындагы уйлар бергә үрелә.

Кайчакта хыял гына иңли алырлык, күнегелгән кысаларга бик үк сыешмый торган фикерләр килеп ишетелә: Америка индеецлары телендә төркиләр белән уртак сүзләр табылган яисә Урта диңгез атауларында бабаларыбызның бик борынгыда сүнгән учак урыннары беленеп тора, имеш... Шунысы гаҗәп: халыклар бер урыннан икенче урынга күчә, иске нигездә яңа шәһәр-авыллар калка, аларга яңа хуҗа үз исемнәрен куша, ә хәтер тотанагы булып барыбер табигать — җир-сулар кала. Кырымда татар эзен җуярга теләп, авыл-салаларның исем-атын Вишневое, Яблочное дигәндәй «шәраб исемнәре» белән алыштырганнар. Әмма тамырын корыта алмаганнар. «Коктебель»дән «Күктүбә» үрләп чыга, «Аю-даг»ка «Медвежья гора»ның буе җитми. Елга, тау исемнәрен тиз генә җил очыртып алып китә алмый. Шуңа күрә Болгар ташларының да тамыры тирән...

Иң матур исем — кешенең үз исеме, диләр. Иң хикмәтле исем, күрәсең, кешенең туган иле, дөньяга күзе ачылган төбәк исемедер: андагы басу-урман, җир-су атамалары... Идел, Чулман, Чирмешән... Агыйдел, Дим, Сөн... Һәркайсы бер җыр! Рейхстаг диварларына барып җиткән бәхетлеләр үз исемнәре белән янәшә туган җир исемен тикмәгә генә язмаганнардыр. Бабайлардан калган китапларда да шулай бит: тәхәллүс-кушамат итеп үзләренең төбәк атамасын теркәгәннәр. Каргалыдан — Әбелмәних Каргалый, Иске Кандалдан — Габделҗаббар Кандалый...

Ил-төбәк исеме белән сүз алу — иңгә бик олы җаваплылык күтәрү! Шул ук вакытта ул — җиргә таяну, тирән тамырларга тоташу да.

Гасырлар, гарасатлар кичеп исән калган исемнәр уйландыра. Исеме калып, җисеме югалган күренешләр йөрәкне яндыра. Гадәти бер авыл тирәсендә генә дә күпме андый урыннар: Болан сазлыгы, Торна күле, Тәллитут буасы...

«Тәллитут»... Шундый сәер кушаматлы тегермәнче Тәлха абзыйның нәсел-нәсәбе әле дә исәнме? Тәллитут буасыннан шарлап аккан су тавышын юксынып, тын кичләрдә авыл урамына кем дә булса чыгамы?.. Хәер, без үскәндә үк инде анда тегермән дә, буа да юк, исеме генә калган иде; тик шунысы сәер: төшләремдә мин ул тегермән буасында балыклар сикерешкәнен күрәм...

Ә Казан артындагы Надеждино — Өмет авылы кемнең булса да төшенә керә икән? Аның карт өянкеләрен, иске зиратын, исемсез инешен сагынып искә алучылар бар микән?..

Бәлки, Өмет авылында туган иң соңгы малайдан да кайдадыр еракта-еракта — хәзер ул яшәгән шәһәрдә:

— Сезнең авылның елгасы ничек атала иде? —дип сорарлар.

Малай, мөгаен, аптырабрак калыр: «Исемсез иде бит ул»,— дип уйлап куяр; әмма, үзе дә сизмәстән, теле:

— Инеш...— дип тибрәнер.

Иптәшләре, аны үртәгән кебек, авыз ерырлар:

— Фи, елга ни дә, инеш ни,— аның исеме бардыр ич?! — диешерләр.

Сынатмасын иде шул чакта Өмет авылы малае, җаным, батырлыгын җыеп әйтсен иде:

— Исеме шулай аның, баш хәрефтән языла — Инеш! — дисен иде.

Ул малайны мин шундыйрак итеп күз алдыма китерәм. Туган туфрагын, инде җир йөзендә юк авылын, ичмаса, ул онытмасын, якласын иде, дип телим. Бу теләгемне Шәүкәт Галиевның исемсез инеш турындагы бер парчасы да хуплап тора. Мин аның һәр сүзен үз кичерешләрем белән яңартып укыйм. Соңгы җөмләсендә тукталып, уйга калам:

«Туган җирдә исемсезләр дә югалмый...»

1987

## ИСЕҢДӘМЕ?..

Балачакка кайту
кешенең гомерен озайта...
Әнием сүзе

Яңа яуган кардан алмагөл исе килә...

Тәрәзәдәге туңны эретеп, алмагөл сурәте төшерәм...

Кайдадыр аны ислемай гөле, ислүлән, бадьян гөле, әнис үләне дип йөртәләр. Ә безнең якларда — алмагөл, алма гөле...

Салкын кыш уртасында алма гөленең исе сагындыра. Ул мине кояшлы хатирәләр аланына дәшә, бәхетле һәм газаплы кичерешләремне яңарта:

— Исеңдәме?! — ди.

Исеңдәме?.. Сезнең капка төбендә, нишләптер, куерак, дәртлерәк үсә иде ул алмагөл... Дәү әниең дә аны, синең чәчеңнән сыйпаган күк, яратып назлый, яңакларын куеп-куеп исни иде... Менә ул чатнама суык гыйнвар төнендә, инде иренен балкашык белән су гына тидереп торганда, «алма гөлен... иснәр идем...» дип, туңган тәрәзәгә таба йөзен бора; хәлнең авырлыгы олыларны да чарасыз итәдер — ырым-шырымга ышану көчәя, әллә кайсыннан шундый сүз чыга: аяз төндә нарасый теләге кабул була, имеш, диләр, әҗәлнең янәшәдә генә икәнлеген сизенеп, синең барлыгыңны да онытып, ярымпышылдап сөйләшәләр; ә син әле әкиятләр дөньясыннан аерылып ук бетмәгәнсең, тылсым-могҗиза көченә бик тә, бик тә ышанасың килә... Ишегалдында кар шыгырдый, син — яланөс, ялан-баш, оекчан; баш очыңа тәкә хәтле йолдызлар чекрәешеп баса; «Үлмәсен иде дәү әнием, үлмәсен иде!..» —дип ачыргаланып кычкыруыңнан Киек Каз Юлы чайпалып китә... Юк, йолдызлы күк синең ялварып иңрәвеңне ишетми...

Исеңдәме?.. Ул елны алма гөлен дә сары сукты, корылыктан тәмам кибеп ярылган иде җир, хәтта пәке кадаш уйнап булмый; болыннарда мал иренен эләгерлек үлән юк. Көтү чираты тигәндә, сыерларны җыеп тотар әмәл калмады. Малай кешегә йөгерү болай да күбрәк тия — көтүдән җык булып кайтып утырган идең... Ник инде ул көнне әниең өйдә туры килмәгән дә сыерыгызны саварга күрше апага әйтеп калдырган? Ник кенә күрше апа үзе урынына сиңа яшьтәш кызын кертергә бул-ган?! Сезнең сыер болай да юаш түгел, ят кулны сизеп алса, тагы да холыксызрак; әнә инде ул куз-галып ук китте, зур ак чиләк бер читтә тәгәрәп кенә калды; күрше кызы үҗәтләнеп чиләкне торгыза, сиңа да нидер әйтә бугай: очкынлы җете күзләрен, үпкәләп турсайган матур иреннәрен күрәсең, әмма эндәшкән сүзе башыңа барып җитми, баскыч төбенә сине кемдер кадаклап куйган шикелле; ул арада сыер, үртәлеп, чиләккә таба борылды, гайрәт белән башын чайкап алды — барысы да күз ачып йомганчы; кыз кинәт, «аһ» итеп, йөзен каплады...

Шул көннән соң аның ни шатланып көлгәндә дә очкынлана алмый торган бер күзе гел сиңа те-кәлгән, гел рәнҗеп, намусыңа тукына кебек иде... Кибеп ярылган җир, сап-сары алма гөле, хәерсез сыер әле дә төшләргә керә, сиңа ялгышыңны төзәтергә тагын бер мәртәбә мөмкинлек бирә; ләкин бу юлы да — инде ничәнче тапкыр! — нигәдер каушап каласың, нәрсәдер кулдан тота... Күпме кабатланырга мөмкин бу газап?! Чигә тамыры авырттырып тибүгә уянып китәсең: «Онытмадыңмы?.. Хәтерлисеңме?.. Исеңдәме?..»

Тәннән китмәгән җөйләр, күңелдән җуелмаган сурәтләр адәм баласына шул сорауны тукып тора.

Җитмеш биш елдан соң Галәмне урап кайтып килүче Койрыклы йолдыз да, гүя Җирне сәламләп, шулай дәшә: «Исеңдәме?..» — ди.

Әй, ул Галлей кометасы дигәннәрен, магнитофон кәтүге кебек итеп, кирегә әйләндер идең дә анда язылып калган авазларны бер тыңла идең!.. Йә булмаса, иске кино тасмаларын ураган галәмәт бер йомгак булсын иде ул! Сүтеп җибәрәсең дә үзен, фәлән еллар элек төшереп киткән сурәтләрен кайтадан карыйсың!..

Кешелек дөньясының иң борынгы, иң мәгънәле әкият-хыялларыннан берседер ул, шәт,— Вакыт агышы белән идарә итү! Кадерле үткәннәрне кире кайтару, бәхетле киләчәкне якынайту... Йә, һич

югы, котылгысыз эри баручы мизгелләрне туктатып, җир йөзендәге иң гүзәл чәчкәне — кеше гомерен мәңгелек итү!

Күп сулар аккан. Вакыт турындагы әкият чынга ашмаган. Әмма, гомер тәүлегенең бик кыска булуына карамастан, адәм баласы тормышның чиксезлеген аңлаган, үзенең дәверләр кичеп яшисе дәвамына ышанган. Шул ышану аңа көч биргән. Яшәү учагын сүндерми сакларлык, таш калалар төзерлек, йолдызларга исем кушарлык дәрт биргән! Вакыт агышының җимергеч дулкынына каршы торып, тарих хәтере пирамидаларга һәм ук очлыкларына әйләнгән, кабер ташларына һәм китапларга теркәлә барган. Катлам-катлам, баскыч-баскыч булып... Кешелек, тора-тора да, шушы баскычлар буйлап үзенең үткәненә — бала чагына кайтып килә... «Балачакка кайту кешенең гомерен озайта...»

Шулай итеп, Вакыт елгасы Кеше гомере каршында көчсезрәк булып чыга! Адәм баласы аның агышын туктата, хәтта үзе теләгән якка борып җибәрә ала! Һәртөрле тарихларда, китапларда Вакыт-Хәтер елгасы... кирегә таба агып ята! Тарих — никадәр гаделрәк, китап никадәр шәбрәк булса, бу агым шулкадәр көчлерәк. Аның басымы, җегәре, ничә дәверне иңләвеннән бигрәк, халык тормышының нинди тирәнлекләрен айкый алуында күренә.

Агымга каршы йөзү рәхәтен кичерәсең килә икән, әнә шул китапларга кереп чум...

Агымга каршы йөзү, дип әйтүе генә җиңел шул...

Үткәннәргә әйләнеп кайту — ул үзеңне иң кырыс сынауларга дучар итү дә дигән сүз. Балачакның күңелебездәге саф чишмәләрен томалап бетермәдекме әле без? Элеккечә үк ихлас, эчкерсез булып кала алдыкмы? Үзебезнең фәлән абзый малае, фәлән апа кызы булуыбызны «онытып», кем әйтмешли, чабатабызны түргә элмәдекме?

Кайчандыр бергә тәгәрәп үскән малайлар, кызлар, йөзгә-йөз килеп тә, сөйләшер сүз таба алмый таптанып торабыз — шул да булдымы агымга каршы бару?! Авылда башны күтәреп карарга да вакыт юк, мәшәкать күп, дигән булабыз. Ә калада, якташлар белән күрешим, дисәң, бик ансат бер юлы бар, имеш: вокзалга гына төшәсе... Анда сезнең якка кайтырга торучылар очрамый калмас.

Кызганыч: дөньяда балачакка озатып җибәрә торган вокзаллар юк. Мәгәр, балачакка кайту юлында очраша калсалар, төрле буынга караган, төрле «погон»лы кешеләр дә үзара тизрәк аңлаша алырлар иде: олыларга дөньяның яктылыгы, җылылыгы мулрак тияр, яшьләргә тормышның хикмәте иртәрәк ачыла башлар иде!

Менә шуңа күрә дә балачакка, яшьлеккә алып кайтучы китапларның бик зур табышмагы бардыр кебек тоела миңа.

Кайчан — гомеренең кайсы мәлендә, иҗатының кайсы ноктасында — шушы китабына керешә язучы? Нинди көчләр аны кулына каләм алып, күңелендәге иң кадерле истәлекләрне кәгазьгә түгәргә мәҗбүр итә? Ай, Кояш тартылуларының тәэсире буламы, магнит давыллары яисә биоритмнарның катнашы юкмы монда; әллә соң бала вакытларын, әти-әнисен төшендә күреп уянгач, беренче эше итеп, шул китапны язарга утырамы ул?

Кайвакыт язучылар бу сернең бер читен генә ачкан кебек тә булалар...

«Илле яшь — гомер тавының иң биек ноктасы. Шуннан соң адәм баласы таудан түбән төшә башлый»,— ди Вакыйф Нуруллин, «Ике урам арасы» дигән автобиографик әсәрен язарга керешкәндә. Һәм берочтан, уңайсызланган, акланган сыман («биографияңә иртәрәк тотынгансың...» дигән шелтәне алдан күреп): «...Алай озын гомерле, нык нәселдән түгел мин. Шуның өстенә тагын 1979 елда... теге дөньяга китеп барудан чак котылып калдым»,— дип, кинаяләп аңлатуны да кирәк таба.

«Үзебезнең авылдан ерак, бик ерак идем... Баш әйләнгән, тәэсирләр шундый көчле — ниндидер бер мизгелдә үзеңне онытып, югалтып торасың... Нәкъ әнә шул мәлдә нигәдер минем йөрәгем сулыгып-сулыгып алды һәм... туп-туры үзебезнең авылга кайтасы, искә төшкән кешеләр белән капка төбендә очрашып, рәхәтләнеп бер сөйләшәсе килде».— Бу, әлбәттә, Мөхәммәт Мәһдиев — «Торналар төшкән җирдә».

«Кайдан мин, кем мин?.. Менә ни өчен... күп дистә еллар аша кайтып, бала һәм үсмер чакларымны күрәсем килә иде. Ниһаять, мин бу озын сәфәргә тәвәккәлләп чыктым»,— дип сабыр гына башланып китә Әмирхан Еникинең «Соңгы китабы».

Хәер, әсәрләрнең исемендә үк анык максат, ачык мәгънә күрергә мөмкин: «Без бәләкәй чакларда» һәм «Үсә төшкәч» (М.Әмир), «Малайлыкта кунакта» (И.Гази) һәм «Без үскәндә» (Г.Гобәй)... Аннан соң «Агымсуларга карап» (Ш.Маннур) һәм «Туган ягым — яшел бишек» (Г.Бәширов), «Минем

тәрәзәләрем» (Ф.Хөсни) һәм «Язмышка юл» (Н.Дәүли), ниһаять, «Җиләкле аланнар» (Р.Төхфәтуллин) искә төшә... Автобиографик әсәрләргә алай ук ярлы түгел икән безнең әдәбият. Һәр әсәрнең исеме үзенчә отышлы, үзенчә аклана икән. Әмма аларның барысын да берләштерүче исем барыбер — «Соңгы китап» бугай.

Табышмак, миңа калса, әнә шул «соңгы китап» дигән төшенчә эчендә ята.

Берничә ел элек Әмирхан Еникинең яңа әсәрен «Казан утлары»нда әлеге исем белән тәкъдим итә башлавы күпләрне аптыраашта калдырган иде. *Соңгы китап?!* Өстәвенә — бөтен гомер юлын яңадан (әллә соңгы тапкырмы?..) күздән кичерергә керешү... Кайбер укучылар әнә шулай хафага төштеләр шикелле. Бер-бер артлы хатлар ява башлады, һавада өметсезлек исе аңкып китте...

Язучының һәрвакыттагыча зирәк, олпат булып калуы, гади, әмма сискәндереп җибәрерлек исемгә никадәр тыгыз мәгънә салганлыгы тора-тора гына аңлашыла бара. Һәркем аны үзенчә кабул итәр һәм, мөгаен, үзенчә хаклы булыр... Шулай да миңа аның иң якын мәгънәсе бер: кешенең үз заманы һәм киләчәк алдында соңгы чиккәчә намуслы булып калуы!

Менә шул «соң дәрәҗә»гә ирешү бик тә, бик тә авыр булса кирәк. Язучы үзе күргән, тормышта, «ике урам арасында» булган хәл-әхвәлләрне ифрат тәфсилләп, һич ялгансыз тасвирлап килә, ләкин — дөнья шул бу! —берзаман аның теге яки бу очракта «матуррак» булып күренергә тырышуын сизеп каласың. Үзенә уңайлырак ноктадан торып фикер йөртүе абайлана... Юк, аның күңеле изгелек белән, сагыну һәм үкенү хисе белән тулы, бары тик... Җанын ярып салырга кыюлыгы җитми. Бүгенге дәрәҗәсенә күләгә төшүдән дә сагаеп кала бугай... Агымга каршы йөзү кыен шул!

Кызганыч, әлбәттә. Югалту шактый зур. Шулай да бөтенләй гафу ителмәслек хәл түгел: автор үзенең йомшак ягын укучыдан барыбер яшерә алмады бит. Бу да кырыс чынбарлыкның үзенчә ачылып китүе!

«Соңгы чик» турында сүз алып барганда, без, мөгаен, «Соңгы китап» янына «Последний поклон» дигән бер исемне янәшә куймый кала алмабыз. Иң әүвәл тышкы охшашлык күзгә бәрелер. Бу кадәресе әле очраклы туры килүдер, дип уйлыйк. Бездә аны «Бәхилләшү» дип тәрҗемә кылдылар, һәм шулай дөрес тә булса кирәк. Әлеге әсәрнең («Последний поклон»ның), аз-азлап, егерме ел дәвамында иҗат ителүен беләбез; моннан күпмедер еллар элек булган бер телевизион тапшыруда язучы үзе дә аны «иң зур китабым» дип юкка гына атамагандыр, күрәсең. Шул җәһәттән «Бәхилләшү» белән «Соңгы китап» арасындагы эчке аһәңдәшлеккә колак салыйк, әлеге янәшәлекнең «соңгы китап» төшенчәсен көтелмәгәнчә баетып җибәрүенә игътибар итик. Ләкин бу да әле иң мөһиме түгел...

Шул ук тапшыруда Виктор Астафьев «иң зур китабы»н ничек, ни өчен яза башлавын сөйләгән иде. Хәтердә шулайрак калган: кунаккамы, эш беләнме, туган авылына кайта язучы. Шунда аңа читтән килеп төшкән таныш түгел бер кыз очрый. Сүз иярә сүз чыга... Кызыкайның телен кычыттырып торган бер тема бар икән: тотына, минсиңайтим, бу яклардагы халыкны сүгәргә, әллә нинди гөнаһларда гаепләргә! Язучыбыз исә бу көтелмәгән, нахак сүзләргә шулхәтле рәнҗи, авылдашларын яклап ни әйтергә дә белми. Яла ягучының авызын томаларлык җавап кайтара алмавы да эчен пошыра, тынгылык бирми. Аннары соңгы елларда менә шундый, үзе эчкән коега төкерүчеләр, авылны кыргыйлыкта, мәңгелек томаналыкта гаепләүчеләр ишәя бара бит. Кичекмәстән кулга каләм алырга, берни дә уйлап чыгармыйча, кешеләрне үз исемнәре белән язарга кирәк. Белсеннәр әле аның авылдашларының да кем икәнлекләрен! Гомер-гомергә тормыш йөген төпкә җигелеп тарткан гади кешеләрнең учактагы куз кебек кадерләп саклаган күңел яктысын күрсеннәр әле!

Менә шулай бер кызга «үч итеп» языла башлаган әсәр икән ул «Бәхилләшү».

Бу вакыйгада, минем карашка, аеруча кызыклы нәрсә — язучының иң соңгы чараны сайлавы. Иң соңгы дәлил итеп үзенә таныш, уйлап чыгарылмаган кешеләргә таянуы, аларның уйлап чыгарылмаган тормышын тасвирларга керешүе. Гади генә әйткәндә, һәр нәрсәне үз исеме белән атарга алынуы. Кешенең асылына алып кайта торган «соңгы китап»ларның төп вазифасы әнә шунда булса кирәк. Ерак Себер авылында булган хәл-әхвәлләрне татар агайлары, татар апайлары «бу бит безнең хакта да» дип укыйлар икән, әлеге бурыч үтәлгән дигән сүз.

«Без — кырык беренче ел балалары» кебек әсәрләрдәге балачак тәэсирләре дә әнә шуңа күрә дөньякүләм әһәмияткә ия! Алардан башка сугыш турындагы дөреслек һич тә тулы булмас иде. Бөтен бер буын язмышын, «шинельсез солдатлар» хакыйкатен яклап, алар окоп хакыйкатен раслаучы иң җитди әсәрләр белән бер сафка бастылар.

Юк, әлбәттә, тылга яки фронтка, сугыш заманына яки тыныч елларга туры килүенә карап, хакыйкать ике төрле була алмый. Дошман чолганышында, кискен көрәш шартларында яшәү безне аеруча уяу булырга һәм, авызыңда кара кан булса да, кеше алдында төкермәскә өйрәтте. Безгә әле дә ятлар алдында сер бирергә ярамый. Ләкин һәр нәрсәнең икенче чиге дә бар. Артык «уяулык» күрсәтеп, үз иптәшеңә, хәтта халкыңа зарар салырга, сер бирмик, дигән булып, дөреслекне үз-үзеңнән, халыктан яшерә башларга мөмкин. Узган дәверләр шушы яктан шактый гыйбрәтле булды...

Ярым-йорты дөреслек ялган, яла, әләк тегермәненә су коя. Яртылаш кына дөреслектән йөрәкне май баса, зиһен үшәнләнә, алга таба бару туктала! Җәмгыять үсешенең бүгенге көне әнә шулай чаң кага, җиргә, тормышка якынаюны, халыкның аңында һәм көнкүрешендә барган катлаулы хәлләрне бөтен чынлыгында өйрәнүне таләп итә.

Бармактан суырып алынган «конфликтларны» чишә-чишә, искечә фикер йөртүне заманга яраклаштыра торгач, китапларыбызда шактый тынчу һава барлыкка килә башлаган иде. Еллар узган саен «чын хикәя»ләргә сусау арта барды. Документаль прозага, тарихка тартылу күзгә күренеп көчәйде. Һәм кинәт... язучылар балачакларына, яшьлек елларына «кайта» башладылар. Автобиографик әсәрләр активлашты, аларга игътибар артты. Бу да очраклы хәл булмаска тиеш!

Дөньяның асыл йөзен, тормыш-яшәешнең беренчел нигезен ачарга омтылу алып кайта  балачак хатирәләренә. Бу омтылыш Гомәр Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повестенда аеруча көчле. Анда — авылның мәңгелек яшел чирәме һәм иксез-чиксез аяз күге, гасырлар буе тупланган йолалар һәм гореф-гадәтләр хәзинәсе, анда — дөньяның сабыйларча гади һәм табигый-бөтенлекле сурәте белән бергә, халык тормышының гаять катлаулы психологик һәм эстетик тасвирламасы...

Тарихи бөтенлеккә ничек ирешә соң Гомәр Бәширов? Мавыктыргыч сюжет яисә тарихи вакыйгалар хроникасы беләнме? Юк, минемчә,  кечкенә генә күренештә дә аерым шәхес һәм халык язмышына бәйле олы мәгънә ачу, гомумиләштерү осталыгы белән.

Катлам-катлам сәхифәләрдән, сәйлән кебек тезелеп барган юллардан «Җидегән чишмә» сыман чын халыкчан көй-моң саркып-күтәрелеп чыга: кыска-фани тән тереклеге белән мәңге-бакый дәвам итәсе җан яшәеше бергә үрелә... Ул көй инде сине гадәти көнкүреш ярыннан юып-ялмап алган да... дистә-дистә бөҗралы тугыз дулкын сыртында чиксез дәрья уртасына илтеп салган... Кинәт кенә, шагыйрь әйтмешли, якын дигәнебез ерагая, якыная бара ераклык... Кара чоңгылларда югалта-җуя язганнарың аермачык булып күз алдыңа килә: телең, иманың, туфрагың-дәүләтең...

Гомәр Бәширов дигән олы Дәрьяның чишмә башында безне нинди хисләр били? Укучының уйлары тулы гасырны иңләп-буйлап мәшһүр Казан артына тартыла. Күкрәгенә тормыш авырлыгы басса да, сулышы иркен, күңеле якты калган төбәккә. Иманасы азлыктан кимсенсә дә, иманы нык булган Яңасалага. Бәшир углы Гомәр дигән малай шунда дөньяга аваз салган, шунда аның бишеге тирбәлгән. Әдипнең илһам чишмәсе, таяныр туфрагы монда.

Авылның, авыл кешесенең төрле дәвердәге язмышы — татар әдәбиятында да, күрше урыс прозасында да төп үзәннәрнең берсе. Ихтимал, байтак исемнәр, китаплар санап китәр идек... Әмма Бәширов «авылы» алар янында югалып калмый. Югалып калмый гына түгел, үзенчә, үзгә булып тора ул. Моның хикмәте автор сурәтләгән дәвергә, аерым каһарманнарга яисә башка төсмер-нечкәлекләргә генә бәйләнмәгән. Бүтәннәрнең хезмәтен кечерәйтү бәрабәренә берәүне күтәрергә маташу зур хилафлык булыр иде, шуңа күрә бөтен җаваплылыгы белән икърар итәм: әлеге повесть-романнар арасында Гомәр Бәширов «авылы» симфоник яңгырашка ия булуы белән аерылып тора. Әйтик, шул ук «Туган ягым — яшел бишек» үзе бер симфоник поэма түгелмени? Язучының үз хәтерендә элекке көнкүреш детальләрен, әхлак, йола үзенчәлекләрен бөтен нечкәлегенә кадәр торгызып, шул туфракта үскән милли характерларны күз алдына китерә алуы зур гомумиләштерүләргә нигез булып ята. Татар халкының катлаулы язмышы, дөнья һәм тарих каршындагы якты йөзе хакында шигъри повесть иҗат ителә. Әнә шуңа күрә мондый әсәрләр чит телләргә тәрҗемә иткәндә дә үзенең тирәнлеген, нәфислеген җуймый. Сибгат Хәким әйтмешли, әдәби әсәр дөнья базарына дип махсус эшләнми, туган илендә танылса, үз халкы культурасының аерылгысыз өлешенә әверелсә, аңа тел чикләре киртә була алмый. Андагы тормыш чынлыгы, сурәтләр һәм кичерешләр ихласлыгы, мәгълүм сюжет-композиция кысаларына сыеша алмыйча, ярларыннан ашып ага... Һәм шул ук вакытта гаҗәеп тыгыз мускуллы хикәяләү рәвеше, сурәтләр пластикасы, мондый төр китапларда сирәк очрый торган бербөтенлек...— болар барысы бергә килеп, Гомәр аганың әдип буларак каләм көче турында сөйли торган тулаем иҗатына хас сыйфатлар.

Тагын да күзгә ташланганы — язучының теге яки бу каһарманын тасвирлап бирү рәвеше. Мәсәлән, хатын-кызны «сәхнә»гә чыгарганда аерым бер иплелек, ихтирам күрсәтүе... «Намус»тагы Нәфисә, Мәүлиха түтиләрне яисә «Җидегән чишмә»дәге башкорт кызы Шәүрәне генә түгел, кайдадыр икенче-өченче планда — күләгәдәрәк калган кызларны, апайларны да юмарт мәхәббәт нуры белән коендыра ул. Хәтта хатын-кызның шулай беркадәр арттарак —«почмак» яктарак торуы әсәрнең бүтән каһарманнарын бәяләүдә янә бер үлчәм, контраст җирлек итеп алына, әлеге күренешнең үзен «ике планлы» итә. Аннары шунысына да колак салыйк: «үзе» (ире) белән, «олан» (баласы) белән шулай сөйләшүче хатын-кызлар күпме безнең хәзерге әдәбиятта... һәм тормышта? Ә ир-аттагы ныклык, сабырлык тасвирын язучы үзенең басынкы, салмак, саллы хикәяләү рәвеше белән көчәйтә сыман:

— Нигәч... Мин гүр иясе булгач, белешләремне белеп чык. Әйт: һәммәгезгә дә бәхил булып китте, диген. Сора: бирәсем калмадымы икән? Бар, дисәләр, түлә, минем өстемдә калдырма. Булмаганны әйтмәсләр. Мин ялганчы кешеләр белән белешмәдем.

Талканы шактый ук коры булган ата кешенең инде үлем түшәгендә якты дөнья белән алыш-бирешне төгәлләп ятуы, улы белән бәхилләшү күренеше менә шулай сурәтләнә.

Яисә — искә төшерик әле — сылу Саҗидә җиңги исеменнән окоптагы солдатка хат язу... Мөлдерәгән моң да, искиткеч сабырлык, тыйнаклык та сыйган шул күңел чайпалып алуына...

Яки менә табигать баласы Бикә түтинең усал кычытканнар, ата казлар белән сөйләшеп йөрүе, берьюлы ике хода канаты астына сыенырга өмет сузуы...

Яисә... Яисә...

Бәширов вакыйганы яки аерым кеше язмышын сөйләп бирми, ул аны кулың белән кагылып, җылысын тоярлык дәрәҗәдә җисемле итә, сурәтләп күрсәтә: төсләрне аер, исләрне той, ап-ачык булып төрле яктан килгән тавышларга колак сал. Хат шикелле ихлас, дога кебек тылсымлы-җыйнак, чигештән нечкә-нәфис аһәңле туган тел стихиясе бөтен барлыгың белән шул мохиткә суырып ала...

Төрки бабайларның меңел элек ташка чокып калдырган мондый сүзе бар: «Су тамыры корыса — яшь яфраклар корыйдыр». Халык тамыры корыса... дигән ачык кинаяле-кисәтүле бу әйтем Гомәр Бәшировның әдәби дөньясында яшәгәндә бик еш искә төшә.

Анда — халыкның дөньяны, тормышны үзгәртеп кору өлгесе булган әкиятләр, ышанулар, йолалар фәлсәфәсе.

Анда — тере җан иясенә, хәят чишмәләренә якынайта торган табигать бишеге.

Анда — адәм баласын дөнья белән турыдан-туры бәйләүче йомшак һәм җылы ана кулы, кырыс һәм гадел ата кулы.

Ниһаять, анда — авыл хезмәтенең һәр заманда үзенчә ачыла торган шигърияте, чын мәгънәсендә җир хуҗасы-иясенең көндәлек иҗат-гамәле, горур холкы-фигыле һәм пакь-самими кичерешләре. Хәтта кимлек һәм гариплек күренешләрендә дә бөтенлеккә, матурлыкка, гармониягә омтылу хәләтен күреп, күтәреп ала әдип. Боларның һәркайсын татарга гына хас милли асылы белән, табигый һәм төгәл буяулар сайлап тасвирлый.

Шуңа күрә укучы аның әсәрләрен инде бу дөньядан кичкән, бары тик хәтер тирәнлегендә генә яшәп калган якын кешеләрен сагына-сагына укый.

Юк, бу гадәти генә сагыну хисе түгел! Гомәр Бәширов «авылы»ннан башланган инеш бүген, олы дәрья булып, Татар әдәбияты диңгезенә койган мәлендә, саллы дулкыннары белән ярга кага. Һәртөрле ыгы-зыгыдан, фани гамьнәрдән араланып, яшәү мәгънәсе, дөнья барышы, халкыбызның «су тамыры» — бүгенгесе, киләчәге турында уйланырга мәҗбүр аның бу иҗаты. «Халык зур ул... Ул әле әллә нинди кара көчләр басканга күрә генә бу күренештә йөри» (Г.Тукай) дигән мәгълүм хакыйкатьне искә төшерә. Югалтканыбызны табарга, тергезергә, ә тапканны, яулап алганны күз карасыдай сакларга өнди.

Әлбәттә, узган юлга борылып карау теләге, үткәннәрне сагыну хисе кешенең табигатенә салынган: «Сабый чагын сагынмакта һәр шагыйрь дә...». Үзең дә сизмәстән, «күңелне хатирәләр өермәсе биләп ала... Әллә кайчаннан йокымсыраган әллә кайсы кылларны тибрәтә...» Ләкин балачакның җиләкле аланнарында безне Заман авазлары сискәндерә: «Җил уңаена аермачык ишетелә: соңгы хәбәрләр тапшыралар. Аланда дөнья хәлләре яңгырый. Бик тынгысыз һәм шактый шөбһәле дә хәбәрләр...» Ә бит «болай ук булыр дип уйламаган идем. Бары тик көрешеп кайтырга дип кенә килгән идем мин сезгә, бала чагым аланнары!» — ди язучы, үзе дә аптырашка калган сыман... (Р.Төхфәтуллин «Җиләкле аланнар»). Сагыну хисе әнә шулай, заман гамьнәре белән кушылып, катлаулана.

Сагыну хисе генә алып кайтамы балачакка?

Кабат укып карыйк әле Аяз Гыйләҗевның «Мәхәббәт һәм нәфрәт»ен, укып карыйк аның «Язгы кәрваннар»ын. Кырыс һәм якты әсәрләр. Иң тәэсирле буяулар белән Вакыт сурәтен төшерергә, иң сизгер прибор — бала күңеле аша чор импульсларын тапшырырга омтылып язылган китаплар. Шул ук вакытта без язучының дөньяны киң, олы бәйләнешләрендә ачарга, заман тормышына җитди анализ ясарга теләвен дә күрәбез.

Тормыштагы катлаулы хәрәкәтне, четерекле бәйләнешләрне бала, яшүсмер күзләре белән тасвирлау — әдәби алыммы ул? Әдәби алым булуы да ихтимал. Ләкин үзмаксат түгел. Биредә язучының максаты ифрат җитди: тормышны аңларга өйрәтү... Ихтимал, бу зурдан кубыбрак әйтү булыр; әлеге җөмлә артында ук: «Йә, ничек, өйрәтә алганмы соң?!» — дигән бер усал сорау посып торырлык күләгә дә бар. Ә минемчә, максатның зурдан куелуы үзе генә дә аерым әһәмияткә ия. Әлеге әсәрләр, чыннан да, яшь укучының күңелен җитди уйлар, тирән кичерешләр белән баету, аны фикерләүдә тормышчанрак, олырак итү, үстерү эшенә үз өлешләрен кертәләр. Ә бу эшнең, белгәнебезчә, ахырыазагы юк, һәм анда, бик күп бүтән көчләр белән бергә, дөньядагы барлык-барлык гуманистик китаплар да катнаша.

Балалар әдәбиятын, М.Мәһдиев әйтмешли, «тавык чебиләре карашып һәм күрше әбигә утын ярып, су китереп ярдәм итә торган «положительный» малайлар турында» язылган китаплар гына билгеләми. Тарсынмыйк, андый әсәрләрнең дә үз укучысы, үз урыны бардыр! (Тимурчылар хәрәкәтенең кәгазьдә генә кала баруы яшь буында каты күңелле кешеләрнең ишәюе булып кайта...) Әмма әлегедәй китаплар — ашыйсы килгән балага көн саен бер балык тотып бирүне хәтерләтә. Ә бу —мәсьәләне ахыргача хәл итү түгел, бу — вакытлы, ярым-йорты чара гына; бераз исәя-үсә төшкәч, безнең үзебезнең дә балык тотасыбыз килә; менә шул чакта инде «балык тотарга өйрәтә торган» китаплар кирәк була. Кызганыч ки, турыдан-туры шушы максатны — үстерү максатын куйган әсәрләр күп түгел. Ә ихтыяҗ зур. Менә кайда ул вакансия!..

Шөкер, безне яманлыкка өйрәтүче китаплар әлегә юк шикелле. Әмма яхшыны яманнан аерырга җитәрлек дәрәҗәдә өйрәтә торган китаплар күпме?

Дөньяны бәяләү бизмәнен биш баллы система белән генә алыштырып бетермәдекме? Мәктәпне, укытучыны изге итеп карау кай арада сукыр мәхәббәткә әверелергә өлгерде?.. Мәктәпне тормыш куйган таләпләрдән, тәнкыйть сүзеннән аралап, без хәтта ата-аналар белән көрәштек. Кайчакта бу көрәш нигезсез дә булмагандыр. Ләкин мәктәп тирәсенә «кытай стенасы» корып җиткергәндә генә... Пыяла калпак астында калган балалар көн мәшәкатьләреннән, җир тойгысыннан, хәтта туган телдән аерыла башладылар, инде унсигезенче яшь белән барганнары да «тормыш бусагасына» гына бастылар... Ә бит шушы еллар эчендә мәктәп тормышына багышлап күпме әсәр язылды. Алар арасында мәгълүм кимчелекләрне генә булса да таныган, алардан арынырга вакыт җитте, дип чаң сукканы булдымы? Нигәдер андый китап истә калмаган.

Әйе, үсүче кеше бу катлаулы дөньяда гел яхшылык белән генә очрашып тормый. Тыштан «дөрес» хәрәкәт итүче икейөзлеләр, оятсыз затлар, тагын әллә кемнәр арасында да яшисе бар. Берсенең дә маңгаена кем икәнлеге язылмаган. Карап торышка әллә ни дәһшәтле булмаса да, кара көч үз эшендә: иммунитеты булмаган йөрәкләрне ул тиз кимерә.

Ә иммунитет, ягъни каршы тора алу сәләте нилектән җитми? Мәктәптә дә, өйдә дә безне тормыш чынбарлыгыннан араларга, янәсе, «җәрәхәтләмәскә» тырышкангамы әллә? Без укый торган китапларның җавабы «артында» булганга, һәм аларның һәммәсе диярлек уңай чишелеш белән беткәнгәме? «Положительный малайлар» турында гына язылган китапларны укыгач, уйланыр, бәхәсләшерлек мәсьәләләр калмый, билгеле. Инде мондый «җиңел үлчәүле» әзерлектән соң җитди нагрузканы күтәрә алмасак, хәтта күтәрергә теләмәсәк тә гаҗәп түгел. Җилгә каршы нигә барырга, агымга каршы нигә йөзәргә?..

Катлаулы бәйләнешләр белән чуалып беткән тормыш чытырманына яшь йөрәкләр ничек килеп керә?

Дөнья күләмендә танылган китаплардан тыш, чор һәм җирлек ягыннан безгә якынрак берәр исемне искә төшерик. Мәсәлән, Мостай Кәримне... Аның «Озын-озак балачак» әсәрендәге малайларны... Уен белән тормыш арасындагы чикне узганда, алар үзләрен ничегрәк хис итә? Хәер, монда әлеге чикне аерып кына күрсәтүе дә кыен. Язучының яшь геройлары әсәрнең буеннан-буена «чик буе полосасы»нда яшиләр кебек. Шуңа күрә аларның балалыктан олылыкка күчеше дә табигый,

сизелер-сизелмәс кенә булып тора. Яшүсмер малайлар белән коточкыч янәшәлектә тормышның матурлыгы һәм ямьсезлеге икеләтә кискенрәк, контрастлырак — ифрат дәрәҗәдә чын булып ачыла. Кырыс дөнья үзенең бөтен авырлыгы белән изәргә ябырылып килгәндә, язучы шушы малайларны, үзенең балачагын, кешелеклелекне яклап көрәшкә ташлана...

«Озын-озак балачак»ның төп үзенчәлеге, минемчә,— кеше гомеренең иң кызыклы бер дәверен «олы тормышка әзерләнү чоры» дип баласытмыйча, җитди төсләрдә, асыл мәгънәләре белән тасвирлауда. Әлеге максатына ярашлы рәвештә, язучы дөньяга бала күзе белән карау түгел, ә балага... үз күзләрен «биреп тору» юлын сайлый.

Ә Мөхәммәт Мәһдиев малайлары? Аларны да бер күрү белән хәтерләп каласың. Бигрәк тә шунысы кызык, әсәргә «алып керү» белән, алар төрлесе төрле якка чабыша башлыйлар. Бүтән берәр язучы булса, ул тиктормасларны бер тирәгә җыя-җыя хәлдән таяр иде шикелле... Ә менә бусы, Ш.Маннур әйтмешли, «мин» дигән малай. Бер карыйсың — ул үзенең яшьтәшләре арасында, аларның бөтен хикмәтләрен «тылдан» күзәтеп утыра; икенче карыйсың — бу малай күздән эреп югалган, хәзер ул Әлтафиләргә, Әркәшәләргә, Гыйззәтуллиннарга таркалып чыккан; инде менә ул, еллар аша үрелеп, үз яшьтәшләренең, үз балачагының башыннан сыйпап уза: чәчендә чал, күзендә яшь... Күр әле, «мин, мин» дигәләп искә төшергәли торса да, чынлыкта, «мин» дигән ул малай юк икән ич «Без — кырык беренче ел балалары»нда! Без аның юклыгын сизмибез генә икән. Чөнки бөтенесен дә аның күзләре белән күрәбез, үзебез дә сизмәстән, аның уена ияреп-буйсынып барабыз. Гаҗәп хәл!

«Озын-озак балачак», «Агымсуларга карап», «Без — кырык беренче ел балалары» кебек әсәрләрдә — шушы «икеләтелгән» караш: бер яктан, табигатькә һәм кешеләргә балаларча сиземләүле якынлык, икенче яктан, матурлык һәм яшәеш кануннарын олыларча җитди аңлау бергә кушыла. Аларның «ике адреслы» булып чыгулары да шуннан. Яшь укучыны вакыйгалар агы, тышкы хәрәкәт ныграк җәлеп итсә, олы кешене күңел хәрәкәте, хис-кичерешләр тирәнлеге дулкынландыра төшә. Димәк, бу китаплар белән бала чагында очрашкан кешене киләчәктә янә бер ачыш көтә әле!

Борынгылар, адәм баласы олыга-кечегә бүленми: җаннар бер яшьтә, дип санаганнар. Бу ышануда гаҗәеп фәлсәфә бар. Тормышның бербөтенлеген тану һәм рухи тәҗрибәнең буыннан буынга тапшырыла килүен искәртү...

Безне «үстерә», күңелебезне рухи тәҗрибә белән баета торган китапларның буш җирдә барлыкка килмәве мәгълүм. Монда язучының шәхес буларак байлыгын, көн-заман агышына карашы үткенлеген дә, ниһаять, үзенә генә хас балачак тәҗрибәсен дә исәпкә алмый мөмкин түгел.

Казан артының хикмәтле кешеләре, хикмәтле әкиятләре белән бизәлгән, бәхетле мизгелләргә һәм газаплы кичерешләргә мул булган балалык көннәре... Бәләкәй Апушны «зуп-зур Тукай» итүдә аларның өлеше азмы! Ә Тамбов урманнарындагы усак яфраклары шавының Такташны шагыйрь итүдә катнашуын кем инкарь итәр?.. Туган як болыннарының «сөйли торган материя»сеннән, Кармәт күгендә пәйда булган Койрыклы йолдыздан Туфанны аерып кара!..

Сабый чак тәҗрибәсе — ул безне туган җир, туган тел белән ялгап торучы иң нечкә, иң мөһим җеп. Ул — кайнар туфракның ярмаланып кыштырдавын, дымсу чирәмнең кетер-кетер үсүен ялан тәпиләрең белән тою кебек үк, йөрәкне кысып ала торган рәхәт бер тойгы. Туган төбәк сурәтләре, үз-үзеңне белә башлаганнан бирле күреп-аралашып яшәгән кешеләр, авыл хикәятләре... Болар барысы бергә, балачакның кыйммәтле тәҗрибәсе булып, әдипнең бөтен иҗаты буенча бара, язган һәрбер юлын — эчтәлеген, рухын сугара, барча күзәнәкләренә тарала.

Әйтик, Аяз Гыйләҗев китапларын укыганда, Югары авыл, Түбән авыллар тирәсендә әйләнә торгач, шактый җисемле булып бер манзара күз алдына килә... Син аны үз авылың төсмерләре белән дә тулыландыра төшәсең; тора-бара, бу төбәкне элек-электән белгәнсеңдер шикелле тоела, ул инде күңелеңдә яши башлый...

Җанга якын күренешләр — чишмә-су буйлары, урам-тыкрык, әрәмәлек, болын-басулар — язучының төрле әсәрләрендә рәшә төсле ияреп-озата баралар. Һич тә көтелмәгән урыннарда, кайчак хыял көче белән тергезелгән дөнья таралып китәр төсле тоела башлаганда, чынлык талисманы булып, балачак сурәтләре калкып чыга.

Хәтта ерак дәверләр катламын күтәрүче китапларда да ташкүмер эчендә калган урман шавы кебек балачак тәҗрибәсе яши!..

Нурихан Фәттахның «Сызгыра торган уклар» романын ачабыз да укып китәбез: «Бөтен җир өстен, киң даланы аксыл яктылык белән сыеклатылган караңгылык каплап алган иде. Күктән, көндәгечә елмаеп, йолдызлар карый, йолдызлардан бик нык аерылып, *китек табак сыман* ай балкый иде...» Егерме ике гасыр элек балкыган айны язучы кайчан шундый итеп — китек табакка охшатып күргәндер, кистереп кенә әйтүе кыен. Аның әле генә «каләм очыннан төшкән» ай булуы да бик ихтимал. Әмма нарасыйларча самимилек бөркелгән әлеге сурәтнең балачак тәҗрибәсе белән баглы булуына ышанасы килә! Ни генә әйтмик, язучы да — бала, бу дөньяның олы яшьтәге баласы бит...

Шунысы гаҗәп: «балалар өчен» дип мөһер сукмаган китапларга да, катлаулы тормыш мәсьәләләре хәл ителеп, күңел драмалары уйналып яткан бер мәлдә, каяндыр Бала йөгереп керә. Еш кына ул унөч-ундүрт яшьлек үсмер бугай. Ни өчен унөч-ундүрт яшь? Чөнки, «беләсез, бу шундый вакыт инде — йөрәктә җыр-моң туарга гына тора! Хыялның да бик җилкенгән, эзләнгән, очынган чагы». Бу — үз-үзенә «урын таба алмыйча гел борчылып йөргән, нидер сизенеп көткән иртә яшьлек...» Еллар үтә, Әмирхан Еникинең әлеге хикәяләренә («Курай», «Җиз кыңгырау») без шул узылган еллар катламы аша карыйбыз... Ә теге Малай һаман да булса ундүрт яшендә!.. Ләкин аның үсеше — олырак мәгънәсендә — безнең күңелләргә күчеп дәвам итә.

Иҗат дөньясының нечкә төсмерләрен тояр өчен менә шушы Малай да бик әһәмиятле икән. Әсәргә ул үткән белән киләчәкне ялгый торган офык сызыгы булып керә, рәссамнар әйтмешли, «перспектива бирә». Ә ераклашкан саен зуррак, ачыграк булып күренә баруны «кире перспектива» дип атыйлар шикелле. Балачак хакында сүз барганда да шул төшенчә төгәлрәк.

…Юлда ике апаның сөйләшеп кайтуы колакка керә. Тыңламас җиреңнән тыңларсың: рәхәтләнеп гөрләшәләр, әйтерсең лә болар автобуста икәве генә. Киленнәрен, кияүләрен искә алып, сырхауларын санап бетергәч, сүз үзеннән-үзе үткән гомер темасына күчә. Апаларның берсе көтмәгәндә бу темадан баш тарта:

— Бала чагымны төшләремдә күрсәм дә, йөрәгем урыныннан куба. Уф, ярый әле төш кенә икән, дип сөенеп уянам... Кире кайтмасын иде инде  ул заманнар!

Автобуста беркавым тынлык урнаша. «Сагынмыйсыңмы?» дигәне шундый җавапны әле башына сыйдыра алмый утырадыр... Ирексездән шул якка борылып карыйм. «Кире кайтмасын иде!» дигән апаның күзләренә яшь тамчысы эленгән. Тавышына сагыш-моң, өзгәләнү бәреп чыга:

— Әй, яшьлек — яшьлек шул инде... Чабаталы, канлы-яшьле булса да! Бер минутын кире кайтарыр өчен әллә ниләр бирер идем!

Шушы сөйләшүне, магнитофон тасмасына яздырып калган кебек, кабат-кабат күңелдән кичерәм. Анда бер караганда гади генә тоелган сорау бар: кешенең ни өчен бала чагына кайтасы килә? Хәтта ул бик газаплы, канлы-яшьле булса да?..

Без инде әлеге сорау тирәсендә шактый әйләндек. Ләкин балачакның тарту көче, үзенә күрә «гравитация кыры» нидән гыйбарәт булганлыгын ахыргача ачыклап бетерә алырбызмы икән?.. Күрәсең, ул без белгән законнарга нигезләнмидер.

Шулай да бер нәрсә ачык: балачак тойгысы —бу гаҗәп халәт — бездә тормыш-вакыт агышына сизгерлек белән бергә арта.

Гомер уза, җир ераклаша һәм бер үк вакытта якыная да бара. Беренче тапкыр яланаяк тойган җир — салкын тәнне көтеп торган җир... Шушы бер-берсенә бик ерак һәм бер-берсенә искиткеч якын аралыкны кеше үзенең бала чагында калган төстәше белән сөйләшә-сөйләшә уза. Вакыт-вакыт алар бергә кушылып китәләр, ә кайчакта берсен-берсе танымый ук торалар...

Гомер юлы кылдан нечкә, кылычтан үткен. Кешене шул юл буе бер сорау эзәрлекли: «Исеңдәме? Адәм баласы икәнлегеңне онытмадыңмы?» Ә заман ашыктыра, куалый,—уйланып торырга вакыт юк; сорауны эченә яшерә дә алга атлый кеше. Сер бирмәскә — өндәү билгесе шикелле тураеп барырга тырыша. Шактый вакытлар бу аңа мөмкин дә була... Ләкин көннәрнең берендә җегәр кими, көч-дәрман китә башлый, һәм әлеге эчтәге сорау билгесе кешене яңадан бөгеп китерә: «Адәм баласы икәнлегеңне онытмадыңмы?» — ди.

Балачакка багышланган китаплардан да безгә әледән-әле шул сорау ишетелеп тора. Әнә бер киштәдән бабайларның малай чагы эндәшә. Менә бу китапта — әти-әниләребез яшьлеге... Кызык бу сөйләшү. Ике яр арасында — без — алар башлаган эшне дәвам итүче, тормышны алар ярдәмендә тирәнрәк аңларга омтылучы буын. Теләгебез бар, сәләтебез бар; илне, дөньяны матуррак итәсебез

килә,— булыш безгә, Китап! Балачакны — күңелдәге сафлыкны — кер тидерми саклыйсы иде. Үзебезгә бирелгән вакытның мәңгелектә бер тузан бөртеге генә түгеллеген исбатлыйсы иде.

...Ә Галәмдә, Галлей кометасы тәүмәлеге булып, зур сорау билгесе очып бара:

— Исеңдәме?! — ди.

Ул миңа... *«Исеңдә тот!»* булып ишетелә.

1987

## БЕЗ БИК ЯКЫНБЫЗ

Өфө юкәләре безнең хакта да әле
Яфрак яра-яра сөйләрләр...

Нажар Нәҗми

Безнең эш бүлмәсендә бәләкәй генә бер җир шары тора. Ул безгә, уенын-чынын бергә кушып әйткәндә, глобусларның гына түгел, дөнья дигәнеңнең дә бик бәләкәй икәнлеген искә төшереп торсын өчен кирәк. Җае чыкканда, шул җир шарына бармак очлары белән генә кагылабыз да — әйләнә дөнья... Ул, чыннан да, артык зур түгел шул: бер-берсенә сыенып утырган берничә кисәк коры җир һәм Океания дип аталган тоташ бер зәңгәр материк...

Глобус-җир шары әйләнә; без дөнья гаме, илләр-халыклар язмышы турында, төркиләр белән Шумер культурасын тоташтырган тамырлар, төркиләр белән Америка индеецлары арасындагы якынлык турында сөйләшә башлыйбыз. Һәм, әлбәттә, «без бик якынбыз» дигән нәтиҗәгә киләбез.

Без бик якынбыз...

Өйгә кайткач, мин гаилә архивын актарам, менә инде ничәмә тапкыр иске, саргайган конвертларны аралыйм,— башкорт даласындагы сәер генә исемле бер авылда яшәп ятарга тиешле якын туганнарның адресын эзлим. Безнең абыз-апай дөньядамы икән әле, аның балалары безне хәтерлиләрме икән?..

Без бик якынбыз: абыз-апай — минем дәү әнием белән бертуган; моннан унбиш-егерме еллар элек, ул әле, үзе әйтмешли, әүхәтендә чагында, кече улы белән киленен дә ияртеп бер кайткан иде. Менә хәзер инде адресларын да табып булмый, аралар әллә ни ерак булмаса да, хәбәрләр йөрми. Дөньяда микән син, абыз-апай? Безнең хәтерсезлеккә, үз балаларыңның каты бәгырьлелегенә рәнҗеп ятмыйсыңмы икән? Без инде күрше хакын, дуслык хакын хакламаслык, күрше яки дус кына да түгел, кан кардәшләр булуыбызны истән чыгарырлык хәлгә килеп җиттек микәнни?..

Бәлки, бу — бүрәнә аша бүре куу, булган-булмаганны артык купайтудыр, алай ук хафаланырлык сәбәп-нигез дә юктыр? Шулай гына була күрсен иде! Китапларда гына гыйбрәт өчен язылсын иде андый хәлләр!

Менә әле Нажар ага Нәҗминең «Кем уйлаган...» исемле китабын укып чыккач та, еракта яшәүче якын туганнардан хат-хәбәр алган кебек, куанулы һәм йөрәкне кысып куярлык бер хис кичердем. Ул хис бигрәк тә китапны ябып куючы битләрдәге бер гади генә җөмләдән, ишек ачылганда сискәнеп киткән лампа уты сыман, дерт итеп, тартылып-талпынып калды. Иҗат һәм шигърият турындагы, татар әдипләренә багышланган хатларын, шул рәвешле китабын тулаем төгәлләп килгәндә: «Бу язганнарым безнең әдәби бәйләнешләребезне киләчәктә тирәнрәк һәм киңрәк сыйфатта дәвам итү теләге белән дә туган дип фараз ителсә иде...» — ди Нажар ага һәм, әлеге сүзләрен әйтер өчен җирлек әзерләгәндәй: «Без бик якынбыз»,— ди...

Әйе, чыннан да без бик якын шул.

Ыру-нәсел шәҗәрәләреннән дә ышанычлырак, көчлерәк һәм тирәнрәк туганлык тамырларыбыз бар. Үзгәртеп-сипләп булмый торган нык тарихи нигезләребез, уртак язмышыбыз бар.

Соңгы елларда, кайберәүләрнең тырышлыгы белән, «туган» төшенчәсе «дус» дәрәҗәсенә күчерелсә дә, безнең уртак җырларыбыз үрелеп үсүен дәвам итә.

«Татар теле» исемле зур җегәрле шигыре, «Юкка түгел, юкка түгелдер», «Син — гомер агышларым», «Өфе юкәләре», «Сиңа тагын мин бер киләм әле» кебек ягымлы җырлары белән генә түгел, тулаем иҗаты белән Татарстан укучыларының да үз шагыйренә әверелгән Нажар Нәҗми китабын укыганда күңелне әнә шундый уйлар били.

«Кем уйлаган...» — истәлекләр, иҗади портретлар һәм уйланулар җыентыгы. Рәсүл Гамзатов белән Кайсын Кулиев, Яков Ухсай белән Семен Данилов портретларыны яисә башкорт һәм татар әдипләре иҗатына багышланган тәнкыйди прозамы,— һәр очракта заман, әдәбият һәм шагыйрьнең шәхси җаваплылыгы турындагы сүз югары дәрәҗәдә алып барыла анда.

Кешелекле хисләр, чын күңелдән сөенү һәм ара-тирә яңгырап киткән борчулы ноталар да биредә анализ сабырлыгын, фикер дәлиллеген басып китә алмый; теге яки бу мәсьәләгә шәхси мөнәсәбәт бер үк вакытта гадел һәм таләпчән булып та калырга комачауламый.

Дөресен әйткәндә, кемнең әле үз фикерен яшереп кенә объективлыкка ирешә алганы бар? Бүген проза һәм поэзиядә дә, әдәбият турында фикер йөрткәндә һәм аңа бәя биргәндә дә, аерым күренешләрне тасвирлаудан бигрәк, аларга мөнәсәбәтеңне ачык, дәлилле итеп белдерү әһәмиятлерәк була бара. Бу — «объектив» сурәтләүдән кыенрак, чөнки биредә шәхеснең үз каланчасы беленә, бердәнбер «ут ноктасы» — позициясе ачыла.

Нәҗар ага менә шулай, ахыргача объектив һәм эчкерсез булып калу өчен, сүзне үзеннән, үз язмышыннан башлый. Шагыйрьнең туу чыганаклары, җирлеге-туфрагы турындагы бу сүз әлеге шул туфрак кебек үк табигый да, саллы да. «Кем уйлаган...» дип, сәерсенебрәк, тартыныбрак керешеп киткән әлеге автобиографик язмалар — зур иҗат сандыгының бәләкәй ачкычы. Аларның әһәмияте соңыннан бөтен бер китапка исем булып китүләрендә дә күренә түгелмени? «Кем уйлаган...»

«Мин үземне шигърият дөньясына ниндидер бер көтелмәгән шифалы җил тарафыннан очырылып төшкән орлыктан үсеп чыккан үсенте итеп хис итәм һәм шушы орлыкның бик уңдырышлы туфракка туры килгәнен күрәм. Ул туфрак — минем туып-үскән җирем, халкым һәм безнең чынбарлык. Алар белән гомерлемен дә, шигырьлемен дә»,— дип тормыш йомгагын сүтә шагыйрь. Безнең күз алдында аның балалык һәм үсмерчак тәэсирләре яңара, яшьлек һәм беренче иҗат сәхифәләре ачыла. Булачак шагыйрьнең һөнәрле агайлары, тормыш һәм әдәбияттагы дуслары, остазлары, яшь, сылу Әминә, көрән алаша, туган авылы Миңеште...— һәркайсы моңсу булып, кадерле булып истә кала. «Шигърияттә дә шулай булсаң иде — үзеңчә берәү генә булып, берәүгә дә охшамасаң һәм исемең дә шулай, кешеләр күнеккәнче, ятрак булып тоелса иде...» — дип искә ала ул үзенең Миңештесен.

Шәхси тормышыннан, тәэсир-уйлануларыннан замандашлары иҗатына чыга, шәхси язмышларда чор сурәтен күрә шагыйрь. Аның автобиографик язмаларында ук безнең көннәргә дә бик якын, безне бүген дә бик борчый торган сорауларга җавап эзләү башлана.

Нәҗар Нәҗминең уйланулары,— тыштан караганда салмак агышлы, сабыр тавышлы бу «Кем уйлаган...» — үз иңендә шактый авыр һәм борчулы сораулар күтәреп торуы белән, шундый типтагы башка бер китапка да охшамаган. Дөресрәге, ул сорауларга җавап эзләү үзе күпләр инде күнегә төшкән юлдан бармый. Без бит хәтта проза әсәрләрендә дә фикер-анализ агымының бер юнәлешен генә сайлап алырга — ахыр нәтиҗәне күргән-бәяләгән хәлдә, «шуңа ничек ирешелгән?» дигән сорауга җавап эзләргә тырышабыз. Бу —чагыштырмача җиңел юл һәм аның тормышны, әдәбиятны аңлатуга керткән өлеше дә шул җиңеллеккә бәрабәр. Билгеле булганча, тормышта да, әдәбиятта да соңгы ноктасы куелган, тәмамланган күренешләр без теләгән кадәр үк күп түгел. Димәк, аларны тәгәлләнмәгән процесс итеп карау һәм аңлату кирәк. Хәтта кайбер талантларның китаплардан тыш гомере инде өзелгән булса да...

Шагыйрә Саҗидә Сөләймановага багышланган хатында гына түгел, башка бик күп урында, гомумән күпчелек очракта Нәҗар Нәҗми шушы авыр юлны сайлый. Йомылып калырдай сорауларны кире ача, темаларны ача, башкаларга да ачык калдыра. Аның уйланулары, фикерләре беркайчан да авторитетларның киң җилкәсе артына сыенмый, шигырь кебек үк яклаучысыз, укучы белән күзгә-күз кала.

Бер борчыла: ялгыш аңламасыннар иде, ди,—шул ук вакытта ярашмый, шомартмый, мондый чакта ярдәмгә әзер торучы «түгәрәк» сүзләрдән баш тарта. Чөнки шагыйрьне зуррак, җитдирәк борчулар били: иҗатта җаваплылык, намуслылыкны яклый, табигыйлек, бөтенлекнең җуелмавын кайгырта ул. Хәтта «чын шигырь Александр колоннасы кебек үз авырлыгы, үз һәлмәклеге белән торырга һәм яшәргә тиеш»,— дигән сүзләрендә күпме борчылу!

Уртакул шагыйрьләрнең әрсезлеген, бик тиз үрчүен, бер-берсен яклашуларын, ниһаять, әдәби процесска бәя һәм тон бирергә маташуларын күреп тә әрни аның күңеле. «Йөзсез яшәү мөмкинме соң? Мөмкин түгел,— ә яшиләр!»

Шушы җитди мәсьәләләрнең асылына карап, Нәҗар Нәҗми иҗат һәм тәнкыйть принциплары, талантны тану-бәяләү критерийлары турында катгый фикерен белдерә. Ул җиңел генә «төзәтелә» торган әсәрләрне, оригиналь булыр өчен генә «мөгез» чыгаруларны чын талант җимешләреннән кискен аерып куя, әдәби күренешләрне бәяләгәндә фасонына карап кына бер чыбыктан сөрүче тәнкыйтькә каршы чыга. «Нигә әле без, талантларга бәя биргәндә, әзрәк «фәстерергә» куркабыз?..

Сәнгать ул, табигать шикелле, тигезлекне белми һәм белергә дә теләми...» дигән сүзләр, хәтта беркадәр «фәстерү» булганда да, бик урынлы һәм актуаль кисәтү булып яңгырый.

«Кем уйлаган...» — чын талантның табигатен аңлау һәм аңа мөнәсәбәт турындагы китап. Нәҗар аганың «Шагыйрь шигырьдән шигырьгә туа» дигән канатлы сүзләрен раслагандай, әдәбияттагы талантлар юлы турындагы фикер дә бу хезмәттә сәхифәдән сәхифәгә үсә, аныклана бара.

Башкорт шагыйре Хәким Гыйләҗевка багышланган иҗат портреты язучының үсешен күзәтү җәһәтеннән аеруча гыйбрәтле. «Күп очракта әдипләребез кем булуларын үзләренең нинди мәктәп, нинди институт бетерүләре белән бәйлиләр. Димәк, аларның язучылык сәләте — табигать тарафыннан бирелгән бердәнбер сәләт...» — Мәкаләдәге кызыклы борылышларның берсе әнә шулай башлана. «Хәким Гыйләҗев, мәсәлән, язучы булмаса, бәлки, аннан рәссам чыгар иде, һич тә булмаса, галимлек юлы белән китәр иде,— дип дәвам итә автор.— Ул төрле яклап талантлы, аның кулыннан төрле эш килә...»

Кабатланмас иҗади йөз һәм табигыйлек (Яков Ухсай), «табигать тарафыннан яратылган кантар (глыба)» булу (Гамил Афзал) турындагы уйланулардан талантка ышаныч, талантка ихтирам мәсьәләләре кузгатыла: «Минем дә синең кайсыбер шигырьләреңне укыганда аягүрә басасым килде». Бу юлларда иң югары дәрәҗәдәге таләпчәнлек тә бар. Чөнки хәтта Туфан, бала җанлы Туфан да, дип искә ала Нәҗар ага, «күңеленә, поэзиягә ят һәм чит булган, хилафлы нәрсәләргә рәхимсез һәм принципиаль иде».

Менә шул рәвешле, иҗат принциплары һәм талант табигате хакындагы фикерләр бер төенгә килеп бәйләнә, һәм бу һич тә очраклы хәл түгел. Төрле шагыйрьләр иҗатына кагылышлы күзәтүләрнең нечкәлеге, фикер һәм образ логикасына үтә сизгерлек, җегәрле тел бу китапны укучы күңеленә тагын да якынайта.

Әлбәттә, «һәркемгә ошау мөмкин түгел, һәркемдә үзең турында әйбәт фикер калдырыр өчен берничә катлы булырга кирәк». Нәҗар Нәҗми, анализ юлларыннан иң авырын сайлаган кебек, үз фикерләрен бәян итү өчен дә бердәнбер формага — ихлас булуга йөз тота. Китапның өчтән бер өлешен алып торган «Ачык хатлар» әлеге омтылышны тагын да ассызыклап тора. Ул хатлардагы күңел җылысы, китапның соңгы битләренә таба көчәйгәннән-көчәя барып, «Ут күршеләр» дип исемләнгән иң ахыргы бүлекчәдә аеруча юмарт һәм эчкерсез гәүдәләнеш ала. Алты хат, һәркайсы берәр татар шагыйренең иҗатына гына кагылса да, нинди зур хезмәт булыр иде. Ә бит бу хатларда — китапның алдагы өчтән ике өлешендә барган сүзнең сөземтәсе, аның, башкортчалап әйткәндә, иң югары кимәле (дәрәҗәсе). Бу хатларда — талантның тормыш һәм иҗат биеклеге, гражданлык йөзе, сәнгатьнең милли асылы һәм интернациональ табигате турында уйлануларның билгеле бер «уртак ваклаучы»га китерелүе.

Менә Нәҗар ага татар шагыйренең бер шигырен «кычкырып укый», башкаларны да тыңларга чакыра. Барыбызга да бик таныш юллар...

Миңа гармун, гармун җитми читтә,
Юлларыма ятар таң нуры.
Яңгырасын иде Европаның
Уртасында татар гармуны...

Шигырь тулысынча укыла. Шагыйрь каләмдәшенең бер әсәре аша бөтен иҗатына, алай гына да түгел, тулаем татар поэзиясенә үз бәясен бирә сыман: «Бу — халкыңны, аның интернациональ миссиясен шундый югарылыкка күтәрү түгелмени! Ул югарылык Тукайлардан, Җәлилләрдән килә...» Тугандаш халыкның күренекле әдибе язган бу «Хатлар», аның Муса Җәлил һәм Хәсән Туфан батырлыгы турында уйланулары, әнә шундый югары бер мотивта берләшеп, безнең күңелләргә кайта.

...Сүземне бәләкәй глобустан, кайдадыр хәбәр-хәтерсез яшәп ятучы абыз-апалардан башлаган идем. Тора-бара, төп игътибарны Нәҗар ага китабына туплагач, укучыларда каршылыклы бер тәэсир калуы ихтимал. Сүз башындагы шүрәле онытылды, дип уйлаулары мөмкин... Юк, алай түгел! Халык тикмәгә генә: «Үзен таныган илен таныр, илен таныган күршесен таныр»,— ди мени... Ә бәлки, җир читендәге индеец «агай-энеләр» турында искә төшерү дә шушы сөйләшү өчен кирәк булгандыр әле.

Без бик якынбыз бит...

1983

## ТУФАН ТӘРӘЗӘСЕ

...Тәрәзәмдә ут булмагач та,
Синуйлыйсың:«Туфан тынята»?!

Хәсән Туфан

Хәсән аганы мин күреп кенә калдым. Яшен яктысы кебек бер мизгел эчендә. Ул минем өчен һәрвакыт кайдадыр өстә, биектә булды. Әле дә шулай күз алдымда тора: рухы белән генә түгел, җәсәде белән дә күккә ашып барадыр төсле...

Минем алда — атаклы яшеле белән гарәп хәрефләрен вак кына тезеп барган кулъязмалар, шагыйрь каләме тиеп чуарланган битләр. Алар катлам-катлам, һәркайсы артында — озын юллар, ерак еллар... Хәсән ага һәр катламга бер-ике сүз белән генә ишарә биреп ала да әкрен генә сораштыра: үзең ничек соң, язасыңмы, ниләр язасың, кайсы яктан буласың?.. Кинәт ул урыныннан ук талпынып куя, күзләре йомшак сагыш белән яктыра: «Минем дә әнием Әлкидән иде... Якташ икәнсең... Тагын килерсең әле... Күрешербез әле...» — ди.

Бу — Туфан белән якыннан беренче (һәм соңгы) күрешү; бу — «казна эше» белән аның өенә бару ихтыяҗыннан гына тигән бәхетле очрак — ашыкмыйча, икәүдән-икәү сөйләшү; мондый җайның бүтән кабатлануы мөмкин түгел кебек. Ә баксаң-күрсәң, янә бер кабатлануга инде вакыт та калмаган икән...

...Мәңгелекнең берәр почмагында
Очрашырбыз әле без тагын,—

дип, Хәсән ага арабыздан китеп барды.

Борынгылар, хәтта иң якын ике адәмне дә бер-берсеннән аралап, каплап торган пәрдә булыр, икәүнең бере дөньялыктан күчкәч, ул пәрдә төшәр дә, исәне үзен калдырып киткән затның никадәр кадерле-газиз булганлыгын шунда гына күрер, дип ышанганнар.

Хәсән Туфан үзе исән чакта ук әдәби җәмәгатьчелекнең һәм укучыларның игътибарын тоеп, халык ихтирамын казану кебек мәртәбәгә ирешеп китте, татар поэзиясенең зурлыгын билгеләүче шәхесләрнең берсе булып танылды. Хәтта шулай булуына да карамастан, аннан аерылгач, күзне каплап торган ниндидер пәрдә төште сыман, аның иҗаты, әлегәчә беребез дә күреп-иңләп бетерә алмаган яклары белән, тагы да тулырак булып ачылып китте. Шик юк: еллар узган саен, ул әле бөтенрәк, олырак булып күзаллана барыр, үзенең чын бәһасен киләчәктә алыр...

Мин дә аңа — ерак киләчәккә —
Сүзсез генә
Сораулар бирәм:
«Безгә анда — яңа гасырларда —
Укучылар очрарлар микән?..»

Игътибар итик әле шушы сүзләргә! Никадәр өмет һәм борчылу бар аларда!

Кайта-кайта шагыйрьне аңларга омтылам — әсәрләнәм һәм уйга батам... Күздән мөлдерәп яшь чыга... Ә ул җылы кулы белән йөрәкне бәйли күк.

Читләтмәде мине, кимсетмәде
Җир йөзенең һичбер имәне;
Тик берсе дә, сезнең кебек итеп:
— Улым, бәгырем, бәбкәм,— димәде...

Мин шагыйрьнең күңел тәрәзәсенә килеп каплангандай булам, анда — Туфаннар йортына, Кармәткә килен булып төшкән якташымны таныйм: Гөлзизә апаны — шагыйрьнең әнисен...

«Дөньяның, табигатьнең матурлыкларын күрергә әни өйрәтте мине... Үтә нечкә күңелле, үтә шагыйрь җанлы булгангадыр, тормышның безне чолгап алган ямьсез якларын минем күздән яшерергә, күңел күземне табигатьтәге ямьлелекләргә юнәлтергә тырышкан булган, күрәсең, ул...»

Менә бит, Хәсән аганың бөтен иҗаты дәвамында гөл-чәчкәләр, иманнәр, таллар белән сөйләшеп килүенең хикмәте кайда икән...

...Сүз кушасы килә талларга:
— Сез беләмсез кая барганны?..

«Кая барганны...» — Укый-укый, кичерә-кичерә, бер сөземтәгә якынлашам: Туфан шигъриятенең иң тетрәнеп торган ноктасы — киләчәк көн турындагы уй бугай.

«Кая шулай ашкынасың, йөрәк?.. Киләчәккә җитәр өченме?»

Киләчәк турындагы бу уй иң беренче нәүбәттә Туган ил**,** Халык язмышы белән бәйләнгән.

Күрәсең, шагыйрьнең күңеле тыныч түгел. Кайдадыр юллар арасында, гадәти сүзләр артындарак — борчулы чырай... Кайдадыр киеренке уйлар эзе, киеренке сораулар баш иеп тора... Сорауларга үз җавабын эзли Туфан. Дулкынланып һәм газапланып. Тарихның калын катламнары аша күтәрелеп, бүгенге чынбарлыкны үз йөрәге аша үткәреп. Ул — авыр елларны сабый җаны белән кичергән, аннан соң да четерекле юлларда сыналган. Кем кем, ә менә ул инде кешегә иң кадерлесе — үзе кичереп тапкан хакыйкать икәнен белә.

«Безгә анда — яңа гасырларда...» Хәвефле сорау өлгереп килә... Аны тормышның, тарихның оптимистик барышы, якты нәтиҗәләре генә басып китәргә мөмкин. Аңа җавап халкыбызның катлаулы олы язмышы рәвешендә гәүдәләнә, һәм шигырьдә ул киләчәккә өмет, ышаныч булып яңгырый:

Денем син, бәгърем, туган тел,
Күрәсең, шуңа күрә,
Башымны идерсәләр дә,
Йөрәгем аягүрә лә,
Йөрәгем аягүрә.

Киләчәк хакындагы уй — Туфан иҗатының башлангычында ук: «Алып китче моннан киләчәккә безне син, вакыт!» (1925). Ул — «брамат» Хәсәнне «бунтарь» Такташ белән туганлаштыручы иң төп уртаклык. Киләчәк капкаларын ачкан дәвер таңында, «киләчәккә хатлар» язган еллар язында бөреләнеп, сәяси репрессия бозлары сукканнан соң да исән кала һәм 50 нче еллар уртасында яңа бер көч белән ачылып китә бу сыйфат. Илнең рухи сафлануга, яңарышка йөз тотуы Туфан гөлләренә шифалы яңгыр була:

Барган саен юллар күңеллерәк,
Барган саен еллар җылырак!

Туфан иҗатының буеннан-буена, акрын-акрын чалымлана килгән юлчы сурәте, ниһаять, безнең каршыга ук килеп баса, кул суза. Хәзер инде миңа, мәсәлән, аның ни өчен әледән-әле үткәннәргә әйләнеп каравы да аңлашыла башлый: «Үткәннәргә әгәр кайтсак та бит, һичбер вакыт артка бармадык». Ул безне дә үзенә ияртә — яңа биеклекләрне узылган юл аша бәяләргә чакыра.

Әйе, Туфанның яшәү рәвеше — чын мәгънәсендә юл халәтендә. Аның бу — күчә баручы офыклар белән генә каймалап алынган зур дөньясы, эчкәрерәк, тирәнгәрәк кергән саен, шулкадәр иркен, чиксез, мәңгелек булып тоела башлый...—әйтерсең чыннан да «без кайчандыр Җиргә бергә килдек, миллиард еллар бергә яшәдек...» Шунысы кызык, 1940 елгы әлеге юллардан («Очрашырбыз әле» шигыреннән) нindидер очкын 1953 елга, «Сөйли торган материя»гә сикерә: «Ничә миллион гасыр үтте инде безнең шушы Җиргә килгәнгә... Син бер гөлгә инде әверелгәнсең, ә мин менә —кеше дигәнгә».

Заманнар башны әйләндерерлек тизлек белән бер-берсенә якыная, янәшә килә, «офыкларның аргы яклары да» күренерлек булып бергә кушыла. Һичшиксез, шунда ук баягы сорау әйләнеп кайта: «Безгә анда — яңа гасырларда — укучылар очрарлар микән?..» Икесе ике чордан, ике шигырьдән «өзеп» алынган юллар, әмма бу — Туфан, мондый «баланс» Туфанга хас. Каршылыкларны ул нindидер тигезләшеп, маңгайга-маңгай терәшеп торган мәлендә тотып ала, шигыренең барча күзәнәген шул киеренке халәттә яшәтә. Туфан интонациясенең тылсымын да, минемчә, менә шушыннан эзләргә кирәк. Баштагы чор иҗатында бу киеренкелек еш кына тышка бәреп чыгып, сыртын кабарткан кыятаулар шикелле, рельефлы төс ала — шунлыктан аны абайлавы да җиңелрәк кебек; ә менә аннан соң бөтен басым эчкә таба борыла, тирәнгә туплана. Монда инде — океан иңкүлекләре... Фикер басымы, сурәт җегәре, хис киеренкелеге гади күзгә күренми дә диярлек:

Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр,
Нәрсә әйтер туганнарыма?!

Туфан — киеренке кичерешләр шагыйре. «Җил-давыллар белән очрашудан» туган нык җегәрле уйлар шагыйре. Бу югары «вольтлы» уй-фикер хәрәкәтен, иҗади накалда яшәү процессын каләмдәше Сибгат Хәким һич көтелмәгән тарафтан тасвирлый: «...Мин, тәрәзә пәрдәсен күтәреп, Туфан утын эзлим. Төн уртасы узган, ул уяу, ул яза... Аның тәрәзәсендә ут сүнми торып, мин йокларга ятмыйм, уңайсыз...»

Төн уртасыннан соң тәрәзәдә янган ут —киеренке ут: бу өйдә йә зур кайгы бар, йә — зур шатлык... Туфан тәрәзәсендә — шул ике чикне берләштергән гүзәл гамь уты. Ул биек тәрәзәдән әле ерак киләчәккә дә, еллар аша үрелеп, Туфан яктысы төшәчәк. Иҗатта кыюлык һәм намуслылык таләп итеп, үз-үзеңне ахыргача сарыф итәргә өндәп:

Кемнәр сез?
Безнең дәваммы?
Һәм безнең нәселме сез?
Тукайлар изге җоласын
Үтәргә әзерме сез?!

Гамьле кичерешләр җәясенә тартылган тойгылы фикер угы. Шигырьнең бу халәте, Туфаннан бигрәк, аның оныклары саналырдай шагыйрьләр иҗатына күчеп калгандыр кебек... Газинур Морат, Рафис Корбан, Ркаил Зәйдуллаларда әнә шундый шигъри «магнит давыллары» тоелып-көчәеп килә. Туфанча гүзәл гамь татар поэзиясенең яңа буыннарында дәвам итә.

...Бу урында мин яңадан Хәсән ага белән тәүге һәм соңгы күрешүгә әйләнеп кайтам. Беләм: аның белән озын гомер юлын бергәрәк узган, күп хатирәләр саклаган бәхетлеләр бар. Шул ук вакытта әлегедәй очрашуны да бер генә мәртәбә кичерергә мөмкин икәнлеген беләм.

Иҗатыннан еллар дәвамында акрынлап күчә, туплана һәм көчәя килгән эчке җегәр Шагыйрьнең үзе белән очрашкан мәлгә инде ниндидер бер «критик нокта»сына җиткән булгандыр, күрәсең. Югыйсә ул кинәт, бер тында бөтен дөньяны яктыртып-айкап җибәргән яшен яктысы күк, күңелгә уелып калыр идемени?!

Шул яктыда мин җисмән һәм рухани рәвештә киләчәккә багланып яшәгән остазның сынап һәм өмет белән караган күзләрен күрәм:

...Киләчәк көнгә Тукайны
Сез алып барасы бит!

1985

## ХӘТЕР ҖИЛЕ

Сугыш алиһәсенең түтәлендә
әҗәл орлыклары өлгерә.
Борынгылар сүзе

*Бабам сөйләгәннәрдән (ул — ике бөтендөнья сугышы солдаты, немец-илбасарга каршы алты ел сугышкан): «...Герман җиренә кергәч, сугыш бетәрәк ниндидер эч пошу басты. Балаларны сагынуга чик-чама калмады. Күзне йомсам, төшкә керәләр... Күңелем тулып, немец малайларының башларыннан сыйпый идем...»*

...Ул сугышның яшеннәре ялтыраганда, безнең буынның әле дөньяга киләсе бар иде. Безне аның күкрәүләре куып җитте. Сугыштан калган авырлыкны без әниләребез иңендә күтәрештек, сугышның сүнеп өлгермәгән утын әтиләребез күкрәге белән каплаштык. Хәзер дөньяга алар хәтере аша, алар бүләк иткән күңел күзләре белән карарга өйрәнәбез.

Шуңа күрә кайчагында үзгәрәк фикерлибез, үзгәрәк бәя бирәбез икән — сезгә каршы килү булып аңлашылмасын, өлкәннәр! Ул — яшьлектән, тормыш асылын төшенеп бетмәүдән дә түгелдер. Ул — сезнең фикер-хөкем йөртүнең дәвамы, яңа буыныдыр, мөгаен.

Сез сугышны авыр, фаҗигале итеп искә алганда, без аңа батырлык күрсәтү өчен мәйдан дип караган идек,— кичерегез безне, агайлар!

Сез сугыш тылының аһ-зарында көйгән яшьлегегезне кызганганда, без ул кителгән көзгедә сезнең матур-саф күңелегез чагылышын күрәбез, үпкәләмәгез безгә, апайлар!

Бездә дә күпмедер хаклык бардыр, мөгаен. Изге Яуның мәгънәсе канлы афәттән, кара кайгыдан гына торырга мөмкин түгел...

*Хәтергә кереп калган: «Сугыш — кешелекнең күкрәге аша узган пуля шикеллерәк. Яра эзен үзе үк көйдереп, арулandырып калдыра...»*

Тормыштагы хәлләрне, аларның әдәбиятта чагылышын күзәтү бездә әнә шундый уйлар уята. Әнә фронтовиклар ашыга-ашыга бер-берсен эзли, таба. Сугышчан дуслар очрашуына инде, әтиләре васыятен үтәп, аларның уллары килә.

Хәзер илебездә һәр өч кешенең икесе — сугышны китаплардан гына укып белгән буын вәкиле, диләр. Әнә сугыш яшененең соңыннанрак килеп җиткән күкрәүләре сыман, бүгенге әдәбиятны яңа сыйфатлар белән баетучы «хәрби» әсәрләр... Аларның авторлары арасында 1945 елдан соң туганнар да күбәя бара. Ватанны яклау темасы шуңа күрә бер үк вакытта заман темасы да булып кала.

Шулай да әлегә ул әсәрләрнең күпчелеген үзләре ут эченнән чыккан ирләр яза. Алар бүген дә яу кырында калган кеше турында күзгә карап сөйләшүне дәвам итәләр, шул чорның гадәти һәм тетрәндергеч тормыш йомгакларын сүтәләр. Бу хакта күпме генә язылса да, үз сүзләрен әйтә алуларына ышаналар. Чөнки әлеге әсәрләрнең нигезендә — сугышны үз язмышың итеп, тормышыңның аерылмас кисәге итеп тою. Бер сүз белән әйткәндә — шәхси кичерешләр. Шәхси кичерешләр аша кырыс хакыйкатьне аңлау юнәлешендә янә бер биеклек яулана. Монда башкаларны кабатларга мөмкин түгел. Һәркемнең язмышыннан сугыш үзенчә узган.

Менә шуңа күрә дә, әйтик, «Һәркемнең гомере бер генә» романы күп еллар узгач шартлаган минаны хәтерләтсә дә, Хисам Камалов: «Соңгармадым микән?» — дип шикләнми. Сугышны бары тик «үзенчә» генә тасвирларга тырышмый. Тарих китабына кергән вакыйгаларга, исемнәргә таянмый, шаккатыргыч сурәт чаралары эзләп интекми. Унсигез яшендә күргәнен ул бүген аяз һәм борчулы күк астында күз алдыннан кичерә. Дәһшәтле чынбарлыкны — кешеләрнең үз-үзен тотышын, хәрәкәт һәм кичерешләр сурәтен мөмкин кадәр тәгаен-төгәл искә төшерергә кирәк. Аның өчен тормыш һәм әдәбият дөреслеге әнә шунда. Шуңа күрә Х.Камалов сугыш эшен һәр детальнең үзегенә үтеп сурәтли, һәр күренешне үзәккә алып нечкәли, тәфсилли. Кайчакта шул траншеяларда адашып, күмелеп калырсың кебек. Ләкин, элемтәче Әнвәр сузган телефон җебе буйлап баргандай, бер деталь икенчесенә килеп ялгана, бер герой язмышы башкаларныкы белән үрелә башлый. Ул — зур Җиңүгә

өлеш керткән сугышчыларның берсе икән; аның, үзгәлекләреннән бигрәк, типик, уртак сыйфатлары истә кала, меңнәр белән берләштергән язмышы калкып чыга.

Әйе, сугыш турындагы әдәбиятның үзәгендә — дөнья борчулары һәм өметләре белән яшәүче герой. Йөрәгенең һәр тибеше, һәр гамәле ил язмышы, халык киләчәге белән бәйле кеше образы. Бу персонажларның «узып барышлый» гына килеп кергән дип саналганы да гади һәм очраклы түгел.

Безнең алда сугыш дигән зур дөнья, сугыш дигән гаять катлаулы образ ачыла башлый. Фронттагы һәм тылдагы аерым бер кеше драмасын, теләк һәм мәҗбүрилек нисбәтен бөтен тирәнлеге белән аңлау, аңлату җиңел түгел. Бу бурычны үтәү өчен безнең язучылар олы проблема нигезенә тоташкан иң мөһим детонатор җебен эзлиләр. Алар өчен барыннан да мөһиме — замандашларыбызны рухи һәм әхлакый мәсьәләләр турында уйлануга җәлеп итү, һәр әсәр белән шушы юнәлештә бер генә адым булса да алга таба атларга омтылу.

Әлеге темага язылган әсәрләрнең иҗтимагый-фәлсәфи колачы, заманчалыгы менә шундадыр. Алар фаҗигале һәм шанлы үткәннән безнең көчебез, киләчәккә ышанычыбыз нинди нигезгә корылган дигән сорауга җавап эзли, бүгенге көнебезнең дәверләр чылбырындагы урынын, әһәмиятен тоярга булыша.

...Сугыш, үзенең гадәтенчә, бу юлы да бик вакытсыз башлана. Ул зәһәр телле Васфикамалларга кадәр: «Яши белмәдек, тормышның кадерен белмәдек»,— дип әйттерә, аларны ирләренең сөялле учларына сыенып өзгәләнерлек итә. Тыныч көннәр бик тә кадерле булып кала. Һәм, ниһаять, «бомба шартлап түгел, сандугачлар сайрап уяткан» таңда да: «Сугыш кичмәгән булсак, шушы матурлыкны күрә белер идек микән?» — дип уйландыра Мөхәммәт Мәһдиев үзенең героен. Әле аңа кадәр озын-озак елларга сузылган канлы көрәш һәм авыр эш көннәре бар, җиңүне якынайтасы бар.

Солдат, рус әдибе Константин Симонов әйтмешли, иң авыр вакытта,— иң авыр урынга һәм иң авыр хезмәткә куелган кеше. Атҗабар Хисмәте дә моны яхшы аңлый, авырлыктан курыкмый, әмма алдагы сугышның нәрсә икәнен күңеле белән сизә: «Фашист дигән эт чылбырдан ычкынган. Ә ул — бик хәтәр эт. Без кая барганыбызны беләбез. Безгә кайтулар булмас инде. Әйе, кайтулар — едвали...» Бу сүзләрдә — котылгысыз фаҗигане тою, аның якынлашып, изәргә ашкынып килүен күрү. Шул ук вакытта җиңүгә, тыныч киләчәккә тирән ышаныч: «Бәхил булыгыз. Тату яшәгез».

Үлем тырнагыннан үлемсезлеккә атлаган Муса Җәлил күз алдына килә. Аның, мәсәлән, «Сугыштан соң» дигән шигыре. «Май аенда тагын җыйналырбыз... Кайберәүләр булмас бу табында... Без шәрабтан түгел, ә шатлыктан җырлашырбыз, бәлки...» Киләчәккә өмет белән карау утлы сиратлардан горурлыкны һәм намусны югалтмыйча чыгарлык көч биргән. Әмма үлем туеның бик күп ямьсезлекләрен күргән солдат ничек итеп кешелек сыйфатларын җуймый кала алган? Ничек итеп газраил хезмәтчесенә әверелмәгән? Әдәбият бу сорауга тормышчан характерлар һәм ситуацияләр аша чынбарлыкның үзеннән җавап эзли.

«Кеше китә — җыры кала» (М.Мәһдиев) һәм «Һәркемнең гомере бер генә» (Х.Камалов) әсәрләре тормышның әнә шундый логикасына тугрылыклы. Аларда сугыш һәркемнең өенә, тормышына шәхси проблема булып керә. Ул, теләсә нинди авыр сынау астында калгандагы кебек, кешенең бөтен рухи көчләрен эшкә җигә, күңел төпкелендә яткан иң яшерен хәзинәләрен яктыга чыгара. Канлы көрәш һәм тормыш кырыслыгыннан, дошманга нәфрәттән тупаслана башлаган җан җылыга, яхшылыкка тартыла. Үлем ачысын тоеп яткан Айкилдиевның әле дә булса мәхәббәт утына үрелүе, комбат белән Фира арасындагы мөнәсәбәтләр әнә шундый. Окоп читендәге чәчәк кебек табигый, гүзәл һәм фаҗигале.

Язмышның кырыс холкына буйсынмаучы мондый геройлар һәр әсәрдә бар. Ләкин һәр очракта алар үзенчә ачыла.

Габдрахман Әпсәләмовның җете романтик төсләргә бай булган «Алтын Йолдыз» һәм «Газинур» романнарында, мәсәлән, аларның рухи көче укучыны да тау елгасы кебек ашкындырып, бөтереп алып китә. Х.Камалов хикәяләвендә укучының игътибары К.Симоновчарак — күбрәк сугыш күренешләренә юнәлтелә. Кискен, хәлиткеч мизгелдә төрле характерлар, йөзләр чагылып үтә, кешенең фаҗигасе һәм рухи ныклыгы ачыла. Биредә бөтенләй капма-каршы диярлек — тыныч, эшлекле тон өстенлек итә, җәелебрәк, ашыкмыйчарак акканлыктан, вакыт-вакыт ярлар абайланмый башлый, бөтен агыш тукталып калгандай тоела, характерлар үсешен абайлау кыенлаша. Ләкин шушы сабырлык, басынкылык белән язучы үзе сурәтләгән хәлләрнең җитдилеген, драматик катлаулылыгын, тирәнлеген искәртергә тели төсле.

Миргазиян Юнисның «Биектә калу» әсәрендә дә вакыйгалар ташкын булып акмый, геройлары бик уйчан һәм җитди. Повестьның эчке агымы, гомумән, укучыны иярткүдән битәр, бөтен юнәлеше белән аңа таба борылган кебек; өерелеп-өерелеп килүче авыр дулкыннарга каршы ишеп барырга мәҗбүрсең. Әмма бу — ялыктыра торган каршылык, ясалма катлауландыру түгел. Тормыш сөземтәсенең бик тирән катламнардан саркып чыгуын тояр өчен, чын фаҗиганең һәм чын бәхетнең янә бер чыганагын аңлый башлар өчен кирәк ул каршылык.

Геройларның хәрәкәт активлыгын сурәтләү дә һәр язучы өчен үз иҗат һәм тормыш принциплары белән бәйләнгән. Х.Камалов, мәсәлән, геройның үлеме дә бары тик батырлык булырга, ягъни ниндидер файда китереп калдырырга тиеш дигән схемага буйсынмый. Алексей Баранов «ялгыш» килеп тигән снаряд кыйпылчыгыннан һәлак була. Бөтен фронт буенча соңгы һәм хәлиткеч һөҗүмнәргә күтәрелгән вакытта, җиңү көннәренә дә озак калмаганда. Очраклы үлем бигрәк тә үкенечле. Ләкин ул көчле характерның тормыш бәясен очсызландырмый, ә яшәү мәгънәсе турындагы сорауны тагын да катлауландыра,  киеренкеләндерә.

Уйлап карасаң, Сәйрин Сәләховның да һәлакәте шактый очраклы. «Нибары» парашюты гына ачылмый... Шулай да М.Юныс героенда романтик канатлар, баллада чалымнары бар, батырлык аның бөтен тормышына бәһа булып аңлашыла. Бу яктан «Биектә калу» безнең «каһарманлык прозасы»н үстерүгә күп хезмәт куйган Г.Әпсәләмов әсәрләренә тартымрак. Шул ук вакытта ул —тыйнак, гадәти батырлык, кешенең күңелендә ясалган батырлык турында баллада. Героиканы җиргә якынайтып сурәтләргә омтылуы исә бу әсәрне Х.Камалов романы белән якынайта. М.Юныс җирне нык тою аша күкнең баш әйләнгеч биеклегенә сокландыра алган. «Түшәме» биек әсәр язган. Сәйрин Сәләхов тормышындагы иң киеренке мәлләрнең берсеннән башланган бу повесть азакка кадәр шул югары нотада кала.

...Сугышның соңгы көннәре якынлаша, җирдә яз тантана итә. Безнең геройларның күңелен нинди генә уй-хыяллар биләми! Алар инде туплар гөрселдәве турында гына уйлый алмыйлар. Татар егетен каклаган каз һәм аерыласы кичне генә үбешеп калган кыз сагындыра, якут егетенең күз алдында боланнар йөгерешә...

Геройның үткәненә кайту һәм аның хәлиткеч мизгелдәге батырлыгын бала чактан ук куркусыз, намуслы, шук яисә юаш булып үсүеннән күрү...— шактый сыналган һәм бигрәк тә документаль прозада очсызлана төшкән алым, әлбәттә. М.Юныс та (бәлки, прототип язмышына бәйле хәлдәдер?) үз юлының бер өлешен шундый әзер эздәнрәк үтәргә мәҗбүр. Тик биредә бер «каптырма»лы наив нәтиҗәләр ясалмый, бәйләнешлар гадиләштерелми.

Шундый катлаулы бәйләнешларның бер яссылыгы — әсәрдәге тел күренешләре. Аларны ничектер зур тел төшенчәсе белән берләштерү ихтыяҗы да тумаган. Аерым сугышчыларның — Сәйриннең, Максимның, Марсель Ялчинскийның рухи «тел»лары күз алдына килә. Сугыш чынбарлыгы белән йөзгә-йөз калган шәхесләрнең көче, аларның тарих һәм ил язмышы алдында үз бурычларын аңлаулары һәм ахыргача үтәүләре шушы тел белән бәйләнгән.

Якут халкы вәкиле Майнагашев яу кырына тамыры-туфрагы белән күчеп утырган төсле.

Көньяк егете Марсельнең юанычы — әнисен искә төшерү һәм музыка. Әнисе һәм музыка Марсельне бүтән кешеләр күңелендәге моңны да тирәннән аңларлык итеп үстергән. Шуңа күрәдерме аның милләте дә аерып кына әйтелми бугай... Моңлы милләт баласы — Ялчинский.

Сәйриннең дә сабырлыгы, сафлыгы, гаделлеге —нәсел-нәсәбеннән, әти-әнисеннән. Егетнең «тылында» тагын бер пакь күңелле изге җан бар: Сәйринем кайткач коймак пешерермен дип, үзе ач яшәсә дә, он саклап торучы Разия... Чын мәгънәсендә халыкның рух-фәлсәфә һәм көнкүреш тәҗрибәсенә таянган көчле характерлар!

Яшәешнең тирән катламнарына үтеп керү ягыннан бу повесть Әмирхан Еникинең «Без дә солдатлар идек» дигән әсәре белән аваздаш. Ул уртаклык тышкы билгеләрдә үк абайлана. Очучы егеткә әнисеннән килгән хат. Авыз гармуныннан сызылып чыккан татар моңы... Һәм Төхфәт абзыйга хатыны юллаган күптин-күп сәламнәр. «Фашисттан тере калган җыр» дип, авылына алып кайтырга исәпләгән көй...

Ничек әле ул?

Агач башкайлары тәсбих әйтә
Әкрен генә искән җил белән;
Сәвешеп-сәвешеп тә кауша алмаган

Бер без генә түгел, ил белән...

Тормышның иң авыр көннәрендә, күңеленең иң тирән кизләвеннән тибеп чыга ул — малай чагында ук әтисеннән ишеткән дә, кабат исенә төшерә алмый йөргән җыр.

Төхфәт абзыйның улы булырдай Сәйринне бүтән бер көй әсәртә. Басып торган җире кебек чал, оча торган күге кебек иркен-киң сулышлы «Гөлҗамал», «Шәмдәлләрдә генә утлар яна...» Халыкның тынычлыкка омтылуы турында сөйлидер бу җыр. Аны күп михнәт күргән, күп югалтулар, күп сагыш кичергән татар кызлары чыгаргандыр, дип уйлана егет.

Безнең халыкта хәрби маршлар юк. Комсызлыктан туган сугышны ул гомер-бакый онытылмаслык итеп, тарих теле белән каһәрләгән.

Корабларда килгән чакта ашамадым
ашларны;
Шул Николай патша гына сатты
безнең башларны...

Әйе, үз тарихында кан коюларны күп күргән халкыбыз. Югалтулары күп. Түгелгәне —туфракта. Хәтта «Йосыф кыйссасы»н язган шагыйрьне дә ил намусын яклаган яу башы итеп сурәтлиләр икән, без моңа ышанабыз. Чөнки әдәбият, гомумән, халыкның кайнар йөрәк тибешеннән яралган. Халкыбыз нинди генә югалтулар кичермәсен, йөрәген һичкайчан илбасар итегенә олтан итәргә юл куймаган. Тигәнгә тигенен калдырмаган. Яуда шәһит булган алыпларын да онытмаган. Зур иҗтимагый вакыйгаларда катнашу аның фикерләү рәвешенә яңа төсмерләр керткән. Ул изге көрәштә Ватан байрагының җиңүен данлаган:

Наполеонның эшләпәсе канга
тапланган иде;
Без сугыштан кайткан чакта, илләр
шатланган иде.

Менә ул — ил дигәндә яу булу, азатлык намына гомереңне дә кызганмаска әзер тору. Ватандарлык тойгысын бер тын белән белдерү. Без бүген яңа заман әсәрләрендә дә шул аһәңне ишетәбез, шул күркәм традицияләрнең лаеклы дәвам ителүен, аныклана һәм тулылана  баруын  күрәбез.

Сугыш турындагы әдәбиятыбызның иң төп кыйммәте, мөгаен, илаһи пакьлек, тугрылык һәм миһербанлылык идеясен гәүдәләндерүдәдер. Газинурлар, Сәйриннәрнең гөнаһсыз яшьлеген, үлемсез уй-хыялларын, өзелеп калган җырларын ул Рифкать Миргазизовлар буынына мирас итеп тапшыра (Разил Вәлиев «Яшисе килә»). «Әхлакый идеализм»га алар туган җир моңы аша тоташкан («Бу тавыш, бу моң бары тик Симетбашта гына. Мондый тавышлы, мондый трельле бакалар Германиядә юк, Австриядә юк. Сайрагыз, авылдашлар,  сайрагыз!» — М.Мәһдиев). Ул аларга әниләр сөте белән кергән («Карт анам... Синең күңеленә мин бары тик якты булып кына кайталам».—И.Юзеев).

Гомерләре исемсез биеклекләр түбәсендә өзелеп калса да, бер уч көлгә әверелеп билгесез киңлекләргә сибелсә дә — ил бәхете өчен кан койган ир-егетләрнең бөек рухы үзләрен көтеп торучы хатын-кыз күңеленә кайта: ана, хатын, бер үбешми дә калган кыз бала күңеленә.

Сәйрин Сәләховның әнисе сугыш беткән көнне карчыклар җыя. Улының һәлакәте турында әле хәбәр алынмаган. Аның исән калу шәрәфенә карчыклар җиренә җиткереп бер дога кылалар. Ананың күңелен күрик дип, егетнең дә «базарын күтәрәләр», күңел салган кызын да өзми-куймый мактыйлар. Ул ашка килүчеләрнең мәҗлес әдәбе, табын һәм гәп кору рәвеше, ул мөнәҗәт әйтешүләре! Бу — халыкның күңел догасы, гади сүзләр белән аңлатып булмый торган җаны, мәңгелек Моңы. Аны бары тик тоярга һәм бәлки, Миргазиян Юныс язганча, аңларга гына мөмкиндер.

Тетрәндергеч финал. Сокландыргыч финал. Иҗатның «терек суы» белән җан иңдергәч, биектә калган геройлар...

Фронт чынбарлыгы якты төс-төсмерләрдән генә тормаган, билгеле. Иңгә төшкән авыр йөк үзәкләре нык булмаганнарны тиз сафтан чыгаргандыр. Ә бит аларның да Җиңүгә нинди өлеше кергән. Бөек эшләрне фәрештәдәй кешеләр генә эшләгән дип ышану — инде узылган дәвер.

Сугыш авазы ераклашкан саен, аңа лаек мөнәсәбәт тә арта һәм дошманны тар-мар итү өчен нинди зур көч кирәклеге турында әдәбият та кыюрак һәм ачыграк сөйли бара. Бик вакытлы сөйли. Чын шаһитлар кими барганда... Әле алар исән чакта...

Дәһшәтле көннең кара төсләренә дә күз йоммый әдәбият. Шулар арасында бигрәк тә — аның типик булмаса да, фаҗигале корбаннарына — төрле дәрәҗәдәге хыянәтчеләргә. Әйе, хыянәтне дә онытырга ярамый!

*Галия апа сөйләгәннәрдән (укытучы, тыл фронты ветераны): «...Гомер булмастай хәл: авылга дезертир кайтканлыгы беленде. Озакламый тагын бер хәбәр таралды: хыянәтченең хатыны йөкле икән! Бигрәк авыр хәл инде. Тикшерүчеләргә үзе: «Мари көтүчесе алдады»,— дип әйтергә мәҗбүр булган... Күрүчеләр булса да, дезертирның эзенә төшүе җиңел түгел иде... Бер ташландык өйнең идән астына оялаган булып чыкты. Кайтып-китеп йөрергә түш белән шуышып үтәрлек кенә «сукыр тычкан юлы» казыган! Шул юл идән астыннан... әбрәкәй астына килеп чыккан...»*

Хыянәтчене якты дөнья белән тоташтыручы ишек бәдрәф авызы булган...

Яу кырын ташлап качкан бәндәгә әдәбиятта урын бирү никадәр авыр булмасын, аның да бит караңгы күңел төпкелендә үз табышмагы ята. «Җан көеге»н язганда Мирсәй ага Әмир нәкъ менә шундый каршылыклы уйлар кичергәндер. Ул, чынлап та, героеның җир бакасыдай салкын, шөкәтсез җанына кагылырга җирәнебрәк торган төсле; дезертирның рухи халәте күбрәк хатыны һәм әнисе драмасында ачыла.

Рус язучысы Валентин Распутин да шундыйрак язмышка дучар булган героена хатыны аша бәя бирә. Һәм бу — тикмәгә түгел... «Гомер буе исеңдә тот» («Живи и помни») әсәрендәге Андрей Гуськовның түбәнлеккә тәгәрәве Камәретдиннекеннән катлаулырак, каршылыклырак, әлбәттә. Әмма аларның икесендә дә ил каршындагы бурычны — җан саклау инстинкты, окоп теләктәшлеген курку тойгысы кысрыклап чыгарган. Якын кешеләренең коточкыч ялгышуын күргән гөнаһсыз хатыннарга ни хәл итәргә? Яшәү мәгънәсен һәм намус төшенчәсен алар башкача аңлый алмыйлар. Шуңа күрә аларның тавышы аеруча үзәк өзгеч. Ул — куркаклыкны, хыянәтне кире кагу, янә бер кат вөҗдан утында яну һәм сафланып чыгу.

Гадәттән тыш хәл дисәк тә, хыянәтнең төрле рәвешләре булган кебек, төрле сылтаулары да табылган. Н.Дәүли әсәрләрендәге лагерь полицайларын, белорус язучысы Алесь Адамовичның җәзачыларын («Каратели» әсәрен) искә төшерик. Фашистка ялланып үз халкын аскан-кискән адәм актыклары да бу адымнарын ничектер аклыйлар, аңлаталар бит. Алар да ике аяклы, ике куллы дигәндәй... Аларның да яшисе килә!

Хыянәт трагедиясе әдәбиятта катлаулы әхлак проблемасы итеп карала, һәм бу — дөрес юл дигән тәэсир калдыра. Х.Камалов, мәсәлән, әлеге коллизияне сугышка кадәрге тормыш мөнәсәбәтләре белән бәйләнештә ала. Сугышка кадәрге гаделсезлекләр һәм башбаштаклыклар, мәгълүм ки, хакимият исеменнән башкарылып, күпләрнең властька карата үпкәсен, ачуын, нәфрәтен уяткан. Шактый четерекле мәсьәлә! «Ә сукыр ачу булса? Ачу бит яшен кебек, бушанырга җай, сугар нәрсә эзли... Яшен иң якын ноктага суга! Сугышта шундый нокта — Ватан...» Язучы, әнә шул рәвешле каршылыклар эченә чумырып, геройларының характерындагы, үз-үзен тотышындагы эчке механизмны табарга омтыла, аларның күңел төпкелен яктыртып җибәрергә җай эзли.

Сугыш иң гади инстинктларны көчәйтә, шуңа нисбәтән иң гади әхлакый кагыйдәләр искә төшә. «Ут чәчәге»ндәге Габделнурның үз-үзен тотышын нәкъ менә шул инстинктлар билгели. Табигать биргән курку тойгысы аңарда кешелеклелек, җаваплылык хисеннән өстен булып чыга.

М.Мәһдиевтә андый «ике төпле» геройлар күп түгел. Була калса да, ул аларны «әкрен-әкрен китерә көйгә».

Габделнурның «Евгений Онегин»ны тәрҗемә итеп мәхәббәт хатлары язуын искә төшерик. Язучы шул чакларда ук, үз итеп кенә, егетнең «чөен төшереп» куя. Ләкин, белгәнебезчә, бу —шактый каршылыклы характер. Яу кырын һәм яралы иптәшен ташлап китсә дә, аны турыдан-туры фаш итү җиңел түгел. Язучы ихтыяры белән Габделнур үзен-үзе каһәрләүгә дучар ителә. Иң әүвәл сугыштан «телен онытып» кайта. Бу очракта таныш күренешнең мәгънәсе көтелмәгән яктан ачыла: туган телдән, туган илдән аерылу фалы булып! Ана телендә эндәшмәкче булса, куркак җанның теле тартышыр кук.

Ниһаять, мәгънәсез тормышның бердәнбер мәгънәле финалы — көчле яңгыр астында калган Габделнурга инде онытылыр кебек тоелган сугыш авазы дәһшәтле күк күкрәүләре булып кайта. Адәм баласының эчке һәм тышкы конфликтлары бергә кушыла — «күк йөзе, соң тапкыр зыңгылдап, аның баш мие аркылы җир белән тоташа». Бу ни булды соң әле? Ул бит инде шундый ук гарасатта бер

тапкыр җанын саклап калган иде! Намус эзәрлекләвеннән кача-кача, теленнән, туфрагыннан язды. Ләкин Бөек Күк астында качып калыр төш юк икән...

Фронтовик рус шагыйре Михаил Луконин язган: «...Буш күңел белән кайтканчы, буш җиң белән —яхшырак»,— дигән юллар искә төшә...

Югалтулар ачысын үсмер иңнәрендә күтәргән, тормышка мөнәсәбәтен ул авыр көннәрдән саф көе алып чыккан буын шагыйре шул шигырьнең дәвамын яза кебек:

...Буш җиңнәргә карап тешең кыс та
Исән кулларыңны йомарла.
*(Шәүкәт Галиев)*

Шигъри аваздашлык кына түгел, бу — тарихтан бүгенге көнгә сузылган күпер; утлар-сулар кичкән солдатның гамәленә һәм рухына яңа заман, яңа буыннар бәясе. Габделнурлар, Андрей Гуськовларга сугыштан да авыррак әнә шул сират күперен кичәргә туры килә...

Әдәбият тарихы шаһит: «сугыш әсәрләре»нең асылы-үзәге — Ватан каршындагы бурыч темасы — Бөек Җиңүгә юл кыскара барган саен тагын да аныклана, конкретлаша төшә. Бүгенге әсәрләрдә ул катлаулы чорның катлаулы шәхесләрен аңларга омтылу, фашизмны җиңүнең иҗтимагый-тарихи һәм әхлакый тамырларын ачу юнәлешендә дәвам итә.

Ә сораулар... Алар һәр заманда бертөрлерәк яңгыраган. Сугыш кемгә кирәк? Ни өчен кешеләр кан коеша? Адәм баласы ничек яшәргә тиеш? Әдәбиятның катлаулы үсеше юлыннан, бөтен кешелек дөньясы тарихыннан сузылып киткән сораулар. Бөек Толстой исеменнән дә тарих шул сорауларны кабатлаган. Һәр чорның аларга үз җавабы бар.

Егерменче гасырның иң зур фаҗигасендә һәлак булган Сәйрин Сәләхов: «Сугышны комсызлык тудыра»,— дип саный. «Яшәү белән үлем арасында» йөргән әдип (Н.Дәүли) соңгы сугышны фашизм белән коммунизмның кылычка кылыч-килүе дип бәяли...

Сугыш хатирәсе белән бәйле вакыйгалар һәм язмышлар хәзерге әдәбиятта еш кына, яңа рамга куелган иске рәсемнәр кебек, тыныч тормыш белән уратып алынган. Ул әсәрләрнең геройларын, беренче чиратта, бүгенге дөнья проблемалары борчый. Җавап эзләп алар кабат ут эченә керәләр — кордашларының әхлакый максимализмын, рух сафлыгын һәм бөеклеген сагыналар. Көлгә әйләнүе мөмкин булмаган хәзинәне!

*Сугыш кайтавазы: Берлин өчен барган көрәшләрдә авыр яраланган яшь егетне сугыш кырыннан табып алалар. Ул телдән калган, исемен хәтерләми, үзенең кайда икәнлегенә дә төшенерлек хәлдә түгел... Госпитальдә аны Солдат дип йөртәләр, чөнки чын исемен берәү дә белми...*

*Күп еллар үтә. Газаплы озын еллар. Ләкин врачларның түземлеге, тырышлыгы бушка китми; көннәрнең берендә Солдат аңына килә, аңа хәтере, тел ачкычы кайта. Ул авырлык белән генә исемен әйтә, үзенең кайсы яктан икәнлеген исенә төшерә, әнисе янына алып кайтуларын үтенә.*

*1974 елны сугыштан кайтучы Солдатны бөтен авыл каршы алырга чыга. Бу көнне кешеләрнең хәтере тагын бер кат яңара. Өметләр яңара, мәхәббәт һәм нәфрәт хисләре яңара...*

Әнә шулай сугыш авазы тыныч тормышыбызга, тыныч елларда иҗат ителгән әсәрләребезгә килеп керә. Сугышны үзләре кичергән замандашларыбыз аның елъязмачыларына әверелделәр.

Бүген язылган әсәрләр, тышкы формалары белән никадәр генә җыйнак, локаль, беркадәр чикләнгән булып тоелмасын, аларда төрле дәверләр багланышы сиземләнә, фаҗигале-героик чор тудырган идеяләрнең Вакыт сынавын ничек үтүе чагыла.

Тормышка һәм әдәбиятка һәр буын үз язмышын алып килә. Сугыш турындагы әдәбиятның икенче дулкыны иҗат мәйданына «41 нче ел балалары» — В.Нуруллин, М.Шабаев, М.Мәһдиевләрнең аяк басуы белән бәйле. Бу — Ватан сугышының халыкчан характерын, кешелекне яклаучы асылын яңа яклардан ачарга дип килгән буын. Окоптагы солдат язмышы аша гына түгел, тыл чынбарлыгы аша.

Бу — гаҗәеп дулкын,— бер бездә генә түгел, бөтен ил әдәбиятында уртак күренеш. Аның эчке бердәмлеге, аваздашлыгы һәм шул ук вакытта образларда, язмышларда, интонацияләрдә кабатланмавы — нәкъ сугыш чоры әсәрләрендәге кебек. Чөнки әлеге уртаклыкның нигезе бер үк — киләчәк турында уйлау, тыныч көннең кадерен белеп яшәү.

Фани кичерешләр хөкемдары — Вакыт, окоп эзләре җуела барган саен, сугыш турындагы әсәрләрнең тышкы төзелешеннән башлап төп рухына кадәр үтеп керә, аларның асылын билгеләүдә активлыгын арттыра. Геройлар яшәешенең үзенчәлекле әхлакый-фәлсәфи мәйданында — хәтер

киңлегендә ул үзен аеруча кыю тота. Искә төшерә һәм оныттыра, ялгышларны төзәтә һәм яңа хаталарга сәбәп чыгара...

Ләкин без ялгышмаска һәм онытмаска тырышабыз. Моның өчен, әлбәттә, әдәбиятыбызның бөтен үсеш юлын торгызу, сугыш елларында Хуҗа Насретдин мәзәкләреннән алып шинель кигән шагыйрьләребезгә кадәр җиңүгә хезмәт иткәнлеген белү кирәк. Үлем кочагыннан һәм ут эченнән язылган хат-васыятьләрендәге һәр сүзнең кадерен тойганда гына Ватан сугышы әдәбиятының чын кыйммәтен аңлауга якынаеп буладыр.

«Дошманның үз җирендә азау тешен җимерәбез. Ямьсез, күңелсез бу җир. Ят җир... Үзебезнең Идел буйлары белән дөньяның кай җирен чагыштырасың!» — Шушы ят туфракта, туплар тавышы тынарга санаулы көннәр калганда һәлак була Фатих Кәрим. 36 яшендә. Немецларны 37,8 биеклегеннән бәреп чыгаргач, аларның дулкын-дулкын булып килгән көчле һөҗүмнәрен бастырганда. Биеклекне фашист ала алмый, ул биеклектә татар шагыйре торып кала...

Юк, сугыш чоры поэзиясе турында: «Яралары ачык булса да, чын авыртуны сизми әле»,— дип әйтергә тел әйләнми. Чагыштырып карыйсың: бу — татар шигыренең җанлану чоры, яңа иҗат баскычына күтәрелү чоры. Сугыш алдыннан кысылыбрак киткән тамырлардан кайнар кан йөгерә, коргаксый башлаган хис чынлыгы, тормыш хакыйкате көчәя. Тыныч вакытта күңелдә бөреләнеп кенә килгән ниятләр яңа шартларда тирәнрәк, колачлырак төс ала. (Шул ук ашыгыч кына язылган хатларда никадәр зур иҗат теләкләре!) Аяусыз чынбарлык күпләрнең йөзен, күзен ача, Ә.Давыдовлар, Х.Камаловлар буынының бөтен язмышын билгели.

Дөрес, бу буын прозаиклар зур әдәбиятка туплар тынгач кына килә. «Фронт миңа бик күп материал бирсә дә, иҗатымда төп сызыкны табарга булышса да, әдәби осталык биеклекләренә мендермәде, аларны бик авыр хезмәттә яулап аласы бар иде әле»,— дип аңлата моның сәбәпләрен Г.Әпсәләмов. Сугышка үпкәләп булмый. Әлеге буынга ул тормыш сабагын ут һәм кан белән катыштырып «укыта». «Яра эзен үзе үк көйдереп, арулandырып калдыра...»

Шуңа күрә, авыр сынаулар кичсә дә, сафлары нык сирәгәйсә дә, бу — «югалган буын» түгел, изге көрәш утыннан, тыл сынауларыннан чыныгып, пакьләнеп чыккан буын. Ул үзенең яшәү рәвеше белән дә, әсәрләре белән дә сугыштан соңгы тормышка һәм әдәбиятка зур тәэсир ясый. Бу шәхесләр, бу әсәрләр үткән белән киләчәк арасына басканнар. Бөек Ватан сугышы турындагы әдәбият панорамасы да аларның иҗаты аша чагыла кебек.

Нинди чор (сугыш алды; сугышның төрле дәверләре; сугыштан соңгы вакыт; җитмешенче-сиксәненче еллар) ноктасыннан һәм нинди буын (сугышта катнашкан; тылда эшләгән яисә ул чакта үсмер бала булган; ниһаять, Җиңүдән соң туган яшьләр) исеменнән язылуына гына карасаң да, гаҗәп киң һәм төрле безнең ул темага иҗат ителгән әсәрләр. Тәнкыйтьче-галимнәребез хәрби прозаның иҗтимагый функцияләренә — дан җырлау, анализлау һәм тәрбияләү вазифасына басым ясыйлар.

Фронт һәм тыл чынбарлыгын сурәтләүдә реалистик төгәллекнең арта баруы, бу темага язылган әсәрләрнең аналитик һәм тәрбияви функцияләре көчәюе, әлбәттә, икесе дә — бик мөһим һәм бер-берсенә бәйле казанышлар. Ләкин сугыш турындагы әдәбиятның тормышчанлыгы һәм тәэсир көче турында уйланганда, аның төп тенденцияләре нигездә кеше язмышын аңлау дәрәҗәсе белән билгеләнергә тиеш, дигән фикергә киләсең.

Әдәбиятка һәр буын үз язмышын алып килә. Хәтер җиле аларның һәркайсына үзенчә кагыла. Ул иске учак урыннарын тузгытып, янып бетмәгән күмерләрне көйрәтеп җибәрә. Хакыйкатьне раслый һәм күзгә төтен җибәрүне кире кага. Кыска хәтерлеләргә бармак янап үтә.

*Дәһшәтле Дулкын — сугыш дулкыны — тыныч ярдан чигенгәндә, Кешенең яшьлеген, саулыгын, бәхетен алып киткән. Бүген Кеше шуны эзләп, кире тартып алырга теләгәндәй, әлеге Дулкын артыннан ташлана, кара дәһшәт авызына яңадан үзе барып керә... Бу көрәш кем файдасына тәмамланыр? Әйтүе кыен. Ләкин кешелек мондый корбаннарга үзе бара: алар Дулкын кире кайта алмасын өчен, яңа буыннар өстенә ишелеп килә алмасын өчен кирәк.*

Ветераннар сугыш эзләреннән йөри, ә ул аларның үзләрен эзәрлекләп килә. «Зинһар, сак булыгыз, иске, шартламый калган мина кырларында йөрисез!» — дип кисәтсәң дә, ишетмәсләр иде... «Китә, пенсиягә җитә алмыйча, бакчаларда гамьсез яллар өчен верандалы йортлар салмыйча...» (Ә.Давыдов.) Сугыш әле дә йомылып бетмәгән яралар булып эзәрлекли — дөньялар тыныч булмаганда, тәндәге иске ярчыклар да кузгала. Сугыш әле дә төшләргә кереп интектерә. М.Мәһдиевнең Асафы да әнә, һәр иртәне йөгерү юлларына чыгып, саташулы төшләреннән дәвалана дәвалануын, әмма, аңа карап, хати-

рәләр авырлыгы кимеми —алардан йөгереп кенә китә алмыйсың шул. Әмирхан ага Еникинең истәлектән бер генә сәгатькә булса да котылу өчен хикәя язганын сөйләгәне бар иде... «Бер генә сәгатькә» дигән хикәясен.

Әйе, сугыш — аны кичергән буыннар өчен аерым бер хатирә, хәтта тормышның билгеле бер кисәге генә дә түгелдер; ул кеше гомеренең һәр күзәнәгенә таралгандыр кебек. Еллар үткән саен аның төсмерләре якыная, җетеләнә генә бара. Сөйлиләр, язалар, дөньяга бәя бирәләр: бөтенесе шуңа нисбәтле. Космонавт һәлакәте разведкага киткән дус үлеменә тиңләнә... (Ә.Давыдов). КамАЗда да шагыйрь үз буынының ерак төсен эзли. «Ватан сугышы кешеләре»нә күбрәк өмет баглый, аларга күбрәк таяна.

Сибгат Хәкимнең «Үрләр аша», «Дәверләр капкасы» поэмалары —халыкның изге көрәш елларында ачылган асыл сыйфатларын барлап йөрү, алар нурының яңа буыннарга күчеп яшәвенә ышану. Шуңа күрә шагыйрь заман яшьләрен үз итеп, фронтовикларча сәламли: «Яңа буын Теркиннарга сәлам!..»

Халык батырлыгы турындагы хәтер — безнең өчен рух һәм көнкүреш тәҗрибәсе, ул — бөек казанышларга яңа буыннарның хөрмәт күрсәтүе. Үлгәннәрнең түгел, онытылганнарның гына гомере кыска. Афәтле еллар хатирәсе безне күкләр аязлыгын, балалар елмаюын җитдирәк бәяләргә өйрәтә. Сугыш турындагы әсәрләрдә чынбарлыкның, кеше язмышының тирәнрәк чагыла баруы да — безнең тулырак, мәгънәлерәк итеп яшәргә өйрәнүебез билгесе ләбаса! Үз кадерен үзе белгән халык көндәлек мәшәкатьләр күләгәсенә ябышып ятмый, үткәненә дә, киләчәгенә дә башын югары тотып карый. Менә шуңа күрә, эстафета торган саен яшьрәкләргә күчә барса да, Ватанны саклау кебек изге темага язылган әсәрләр ташкыны кимеми. Аның чишмәсе — халык хәтере: халыкның горурлык хисе һәм югалтулар әрнүе, Бөек Җиңүнең тыныч көннәрдәге лаеклы дәвамы. Аның төп юнәлеше, төп үзәне — заманның актуаль сорауларына җавап эзләү. Бу ташкынның бер яры —фронт һәм тыл ветераннары, икенче яры —аларның уллары, оныклары.

*Авылдан язганнар иде: «Бездә бер яңалык бар бит әле. Кырмавык Зәкиләренең хәбәрсез югалган дип йөргән аталары табылмагае. Төш куйдырганда (юратканда.— М.В.) сакалы-мыегы җитү килеш күргәннәр. Капка төпләрендәге бүрәнәгә кайтып утырган, имеш. Исән ул, кайтырга тиеш, дип юрыйлар...*

*Зәкиулла абзыйның улын күрдем: «...Исән булуына өметләнеп яшәмибез инде. Быел да менә Польшага барырга җыенам. Соңгы хаты шуннан килгән... Беләсең бит, чит илдә солдат зиратларыннан кала әйбер минем күзгә күренми. Фамилияләп укыйм. Бабай каберен эзлим. Күп алар анда — безнең мәрмәр плитәләр...»*

Безнең буын сугышның ни икәнен китаплардан гына укып белә, дигән сүз дөрес түгел. Ул бүген дә һәйкәлләре, ветераннары һәм толлары белән үзен искә төшереп тора. Без аның кайнар сулышын тоябыз.

Бүген сугыш безнең буынның төшләренә кереп сискәндерә. Ягъни Асафлар үзләре генә түгел, малайлары да үлем уены кайтавазларын тоеп яши. Кинодан, китаптан гына күчмидер, нindидер күзәнәкләрдә сакланып киләдер, мөгаен, бу халәт?..

Сугыш каһарманнарына яшь әдипләр иҗатында куелган һәйкәлләр дә шул хакта ачык сөйли.

Тыныч күк астында үскән буынны утлы еллар сәхифәсен ачарга нәрсә мәҗбүр итә соң? Кайдан, нинди импульслар килә аларга?

И.Юзеевлар буыны өчен сугыш нужа камытын иртәрәк киюдән, өчпочмаклы солдат хатларыннан башлана: «Мин, ун яшьлек малай, капитан-артиллерист әтиемә шигырь белән хат язам...»

Разил Вәлиевләр буыны — «салкын сугыш» җилләре искән, ут-күз генә чыкмагае, дип борчуга салган еллардан: «Мин — яшьтәше атом бомбасының...»

Халык хәтере, халык гаме менә шулай яңа буыннарга күчә. Илне яклап зур яуда катнашкан замандашлар безнең яшьләр әдәбиятына герой булып керә.

Әхәт Гаффарны, мәсәлән, фронтта булган кешенең дөньяга җете күзләр белән карый алуы җәлеп итә. Аның соң дәрәҗәдә намуслы һәм гадел булуы. Язучы үзе дә өлкән буынны, аның кичерешләрен тасвирлауга җаваплылык белән килә. «Сугыштагы кеше»дән бигрәк «сугыш һәм кеше» турында яза. Гомер бәясенә торырлык бурычларыбызны искә төшерә.

Иң әүвәл сугыш чынбарлыгын гаять катлаулы күренеш итеп тоярга кирәктер безнең буынга. Әйтик, ут-кан эчендә ять-яшь сугышчы кызларның матур киенәсе, шаярасы, назланасы килмәгәнме?

Ничек кенә әле! Аларның сөйләвендә, хатирәләрендә охшаш урыннар сизелә икән, ул да булса — авырлыкны ирләр белән тигез күтәргән хәлдә, күңелләре белән хатын-кыз икәнлекләрен онытмау. Тәмәкене шоколадка алыштырумы ул яисә аяк чолгавыннан суырып алынган җепләрне манып сөлге чигү белән мавыгумы...

«Сугыш әдәбияты»ның бай хәзинәсе, зур психологик ачышлары яшь әдипләрне аеруча җитди булырга чакыра. Аның тирән агымында көтелмәгән бусагалар аз түгел. Мәсәлән, яшьләр иҗатында, шулай ук кайбер документаль проза әсәрләрендә еш кына обстановка төгәллеге белән геройларның китапчалыгы, психологик яктан чырайсызрак булуы каршылыкка керә.

Ә.Гаффар да төгәл тасвирларга омтыла, геройларның үз тавышларын эзли, таба. Аларны үзе теләгәнчә хәрәкәт иттерергә, үз ихтыярына буйсындырырга ярата. Олы мәгънәсе белән күңелгә якын «Язмыш» исемле хикәя, мәсәлән, бертын белән көйдереп алырдай. Дөрес, «материал каршылыгы»н җиңелрәк сындыру аны шактый суыткан. Тышкы эффект артык зураеп, язмыш кадәр язмышны абстракциягә әйләндерә башлаган, конкрет һәм зур мәгънәне томалый язган.

Шунысы куанычлы, язучының сугыш һәм кеше драмасын ачкан соңгы әсәрләрендә декорация төгәллегеннән бигрәк эчке дөреслеккә омтылыш көчәя. Тормыш катламнарын тирәнрәк алган саен, «материал каршылыгы»н җиңү кыенлаша аңа, язганнары да табигыйрәк, кызыклырак була бара.

Яшьләр иҗатында Бөек Ватан сугышына игътибар кешелекле киләчәк, тынычлык өчен көрәш мәсьәләләре белән табигый үрелеп үсә. «Сез кайсы халыктан? дисәләр, Батырлар исемен атадым...»

Кызганыч, безнең патшалар сугышсыз тора алмый. Сугыш уты яңадан-яңа буыннарның тамырын көйдерә... Рифкать Миргазизов турындагы повесте белән Разил Вәлиев бүгенге яшьләрдәге җаваплылык хисенең потенциаль мөмкинлекләрен сиздереп куйды. Фронтовик Асафлар буынының «Хәзер егетләр вакланды...» дигән сүзләренә җавап та, үз кордашларын тормыш мәгънәсе турында уйланырга чакыру да бар анда. «Яшисе килә!» —әсәрнең исемендә үк Абдулла Алишның соңгы хат-васыятеннән бер очкын бар: «Без соңгы сулышыбызга кадәр халкыбызга тугрылыклы булып калабыз. Ах, нинди *яшисе килә*!»

Тамырлар тирән, багланышлар тирән. Кадыйр Сибгатуллин, Мөдәррис Әгъләмовлар, эстафетаны үзләреннән алдарак килгән буыннан алып, кырыгынчы елларның хис үзәген хатын-кыз, балалар күңеле аша ачуны дәвам итәләр. Хәтер көче аларда да үткәннән бигрәк киләчәккә юнәлгән: «Әгәр дә Ватанга кирәксә — халкымнан калкачак мең Җәлил». Нәкъ сугыштан соңгы, сугыш вакытындагы, сугыш алды елларындагы кебек...

Ул тамырларга тагын да игътибарлырак булыйк! Бүгенге көнне агымдагы тормыш-көнкүреш дәрәҗәсендә генә түгел, культура тарихы, фикер тарихы, халык тарихы җирлегендә —тамырлар аша да аңлау таләп ителгәнен башка әсәрләребездә дә онытмыйк! Чөнки тамырының никадәр тирән булуы нәкъ менә яфракка ныграк сизелә.

*Уйландырган күренешләрдән: кайсы гына чорга, кайсы гына халыкның тарихына барып чыксаң да, аңа яшәү көче бирүче чишмәләргә юлыгасың... Хазар-Каспий диңгезе буендагы Кыз каласы да шундый. Риваятьләр данына уралган шигъри кальга ул,— беркайчан да, бер яуга да бирелмәгән горур Кыз-кала. Нигезендә —кое. Тарихның үзе кебек тирән, үзе кебек карт ул кое; инде сигез гасыр буе агып ята икән. Калын диварлар, кыя ташлар аша үтеп, саф чишмәләргә тоташкан. Суы әле дә чәйгә яраулы. Камалышта калган алыпларга сихәт биргәндер, вакыты белән, бәлки, иң соңгы корал да булгандыр ул...*

Туган илдәге Изгеләр чишмәсе, Кызлар тавы, авыр көннәрендә халыкның таянычы булган риваять-бәетләр, җыру-мөнәҗәтләр күңелгә килә. Теле, тылы...

Герман җире — яшел үлән,
Әллә кайтам, әллә үләм...

Латвиядә, Саласпилс үлем лагере урынындагы ямь-яшел чирәм уртасында калгач, башлар әйләнеп китәрлек итеп, «чын безнеңчә, милли» көй — «Сагыну» көе искә төште.

Яшел үлән — вакытсыз өзелгән йөз мең җан тирбәнеше, яшел үлән — сугыш авызына яшьли кергән җиде мең бала гомере. Аларның башыннан сыйпагандай, сабый чәче кебек йомшак үләннәрне аралый-аралый, әкрен җил исә...

Туктале, җил, исмәле җил...
Кисмә гөлнең чәчәген...

Сугыш — кешелеккә каршы иң зур җинаять. Ләкин безнең ата-бабаларыбызга ул сабыйлар бишеген — афәттән, кешелеклелекне ерткычлыктан саклау өчен көрәш булган. Менә шуңа күрә Асаф тыныч көннәрдә дә «кеше өчен көрәшеп кан түгә» — малаен яклап үзен куркыныч астына куя. Менә шуңа күрә «кырык беренче елгылар» үзләренең «сугыш вакыты урта мәктәбе» турында кайта-кайта сөйлиләр — бүгенге яшьләргә көн күрү, кеше хәленә керү сабагы бирәләр.

Сугыш турындагы әдәбият — бик күп фаҗигаләрдән тезелгән дисбе. Тоташ авырту-әрнү тойгысыннан гына торадыр төсле. Авырту — кеше тәненең сәламәт тойгысы. Шул тойгыны югалтсак, без зарарланган төшебезне табып дәвалый алмас идек. Күп каны коелган кеше, әнә шулай, авыртуны тоймый башлый икән...

Сугыш турындагы әдәбият, безнең кешелекле асылыбызны яклап, кара көчләргә каршы яуга күтәрелә.

Сугыш турындагы әдәбият — безнең авырту тойгыбыз. Ул безне «кан коелу»дан — зур рухи югалтулардан саклый.

1985

## ГОРУР БЕР ҖЫР

...Сулыш алсаң, эчкә «сугыш» үтә,
бигрәк тә бу соңгы елларны...

Ренат Харис

Икесе ике төбәктә булган әдәби очрашуларда, сүзләр сөйләнеп, шигырьләр укылып беткәч, кинәт зур залның әллә кайсы почмагыннан гына торып:

— Сез менә кызлар турында, әниләр хакында күңелгә ятышлы шигырьләр укыдыгыз. Анысына рәхмәт. Мәхәббәт — барчабыз өчен дә мәңгелек тема. Әниләргә без гомер буе бурычлы. Ләкин менә, ни бит... Кая карама — ир-ат кулы җитми башлады бит әле. Гаиләдә ир кешенең абруе кими. Егетләребез кызлар иңенә салына... Ир-егетләр турында шигырьләрегез нигә аз? — дип сорадылар.

Арабыздагы шагыйрьләр бер юлга уен-көлке белән уздырырга тырыштылар. Кызлар турында булса да, егет кеше өчен языла инде ул, дигән булдылар; биредәге шагыйрьләр ир-егет затыннан булгач, һәр шигырь үзе үк ирләр сүзе түгелмени, дип тә карадылар.

Инде шул ук сорауның икенче төбәктә, бөтенләй бүтән шагыйрьләр белән булган очрашуда, сүз куешкан кебек кабатлануын ишетү мине нык кына уйга салды. Юк, тикмәгә бирми бу сорауны халык. Тормышыбыздагы хәл-әхвәлләр турында уйландыра ул.

Тулы бер дәвер тыныч күк астында яшәвебезне бәйрәм иткән көннәрдә буыннар хәтерендә бер-берсенә һич охшамаган тәэсирләр, хатирәләр яңара; алар бер-берсен тулыландыра, шушы бөек күренешнең тәэсирен тоярга, мәгънәсен аңларга булыша.

Мәңгелек ут кебек Хәтер талпынуында: җиңүчеләрне — һәлак булганнарын һәм хәбәрсез югалганнарын, көн саен арабыздан китә барганнарын һәм әле исәннәрен — һичберсен онытмыйча яд итү, аларга чиксез рәхмәт хисе бар; янә —Җиңүнең төп нәтиҗәсе булган бүгенге тормышның кадерен белү, аны сакларга һәм тагы да ямьлерәк итәргә омтылу бар; ниһаять, шушы Җиңүнең ифрат зур авырлыклар белән яулануын, сугышның нинди афәт белән янавын онытмыйча, хәзерге дөньяның сулышын борчылып тыңлау да бар.

Шагыйрь әйтмешли, «...ә бездә кырык ел хәвефсез-сугышсыз, әллә бу — иң матур чор микән?» (Г.Афзал) дип сөенерлек һәм мәгълүм дәрәҗәдә хәвефләнерлек бер заманда яшибез бит.

Ватан сугышы рухы безне бүгенге көнебездә әнә шулай сискәндереп, горурландырып һәм уяулыкка өндәп яши.

Бөек Ватан сугышы темасына кагылмаган шагыйрь юк.

Окопта һәм фашист тоткынлыгында язылган әсәрләр — бүгенге шагыйрьләр өчен «чынлык, ут һәм сөю»нең иң югары үрнәге. Ул әсәрләр, сугыш турындагы иң яхшы китапларның геройлары кебек үк, берьюлы өч заманда: үткәндә, бүгенгедә һәм киләчәктә яшиләр. Шул заманнар багланган урында тормышның тирән агымы тоела, мәңгелек кануннары калка, вакыйгалар һәм кешеләрнең асылы ачыла. Кешелеклелек өчен көрәштә бу әсәрләрнең роле зур: замандашыбызны тормыш-яшәеш хакында уйланырга, халыкның тарихи язмышында шәхси өлешеңне тоярга чакыру, хәтта мәҗбүр итү бар аларда. Аларның бүгенге әдәбиятка тәэсире дә шул дәрәҗәдә дәвамлы һәм нәтиҗәле.

Туплар тынып егерме-утыз ел үткәч, фронтовик әдипләр хәтерендә ул көннәр ерагаеп, бербөтен булып оеша, укмаша барды. Хатирәләрдән иң мөһим мизгелләр яңарып, иң асыл детальләр сөзелеп, окопта янәшә яткан гадәти егетләрнең чын мәгънәсендә Каһарман икәнлекләрен аңлау килде.

Илбасарларга каршы яуның кеше рухын гаҗәеп биеклекләргә күтәрүе хакында көчле әсәрләрне фронтовиклар һәм аларның традициясен үзләренчә баетучы яшьрәк буын шагыйрьләр иҗат итте. Вакыт, шәхси тәҗрибә, әдәбиятның яңа биеклекләрне яулавы, бәхеткә күрә, фронтовик шагыйрьләребез файдасына булып чыкты. Дөреслекне күзгә карап әйтүләренең тормыш биографиясе белән расланган булуы алар иҗатында төп уртак сыйфатка әверелде.

Ә арада иң кызыклыларның берсе — сугышны бала күңеле белән кичергән буынның әдәбиятка килүе булырга тиеш. Ул буын прозада «Язгы кәрваннар» һәм «Без — кырык беренче ел балалары»н

язу өчен килде. Ә.Баянов «Сез аңларсыз мине» циклы белән үзен — шагыйрь, ә «Яшьлегемне эзлим» повесте белән прозаик итеп танытты.

Бер үк чорда, бер буыннан, әйтик, С.Хәким —«Үрләр аша», «Дуга», икенче буыннан Ш.Галиев — «Әткәйгә хат», М.Шабаев «Җирән Конрад» поэмаларын язып, сугыш һәм тынычлык турында яңа биеклектән торып сүз әйттеләр. Алардан соң килгән буын вәкиле М.Әгъләмов — кордашлары исеменнән «Замандашым монологы» поэмасын иҗат итәсе шагыйрь — конкрет күренешләрнең эчке мәгънәсен үзенчә ачарга омтыла:

Бүген кем дә белми...
Бабаларым белгән күптәннән:
Тупыл утырткannар,
Ә тупыллар —
Яшеннәрне яхшы үткәргән.

Сугыш һәм аның батырлары турында, күрәсең, менә шулай гади һәм җылы итеп язар вакыт җитте. Бизәмичә, шау-шау күтәрмичә. Ләкин йөрәккә сугарлык итеп.

Шул ике яр арасында шәхсән минем өчен аеруча кызыклы тоелган, объектив караганда да әдәбияттагы кызыклы күренешләрнең берсе булган «41 нче ел балалары» — Ә.Баяновлардан башлап Р.Харис, Р.Әхмәтҗановларга кадәр «суырып» алган буын иҗаты үзенә җәлеп итеп тора. Талант дәрәҗәсе, әдәбияттагы хезмәтләренең күләме ягыннан аларны һич тә элгәреләренә һәм соңрак килүчеләргә каршы кую ниятем юк. Ләкин әлеге буын әдипләрнең иҗатын үсмер һәм балалык елларының кырыс, олы тәҗрибәсеннән аерып аңлау мөмкин микән? Алардагы бу үзенчәлек үтә дә конкрет төше-үзәге, сулкылдап-тибеп торган йөрәге булган шигырьләрендә күренә.

...Кырык берләр китте армиягә,
Ә мин калдым, калдым аерылып.
Сугыш җиле, әткәй, күкрәгемдә
Салкынаеп тора кар булып. (*Г.Рәхим)*

Ә.Баянов, мәсәлән, тылда сугыш йөген тарткан ат сурәте аша: «Мин — ат кына түгел. Мин — авылың синең!» — дигән гомумиләштерүгә чыккан иде. Ш.Маннапов сугыш гарасатын һәм җиңү мәгънәсен ат образына бәйле икенче күренештән эзли:

Хәтеремдә сугыш шулайрак калган:
Күрдем аны баткан атның күзеннән
Һәм аңладым — сабый күңелем белән —
Ат коткарган авылдашлар сүзеннән.

Армиягә китүче атлар турында Р.Гәрәйнең:

Аларга да җиңел булмагандыр
Соң кат күрү туган җирләрне.
Кемдер шунда: «Атлар елый...» — диде
Һәм үзе дә үксеп җибәрде,—

дигән юлларын эпиграф-эстафета итеп алган «Ат иярләү» поэмасында Р.Харис замандашларга ил каршындагы бурыч чынбарлыгын һәм кеше гомеренең бәһасен тулырак аңлау мөмкинлеген бирде.

Күрәсең, тора-бара килә ул аңлау — яу кырында һәлак булганнарның өзелеп калган асыл сүзен ишетү... Кырык елдан соң: «Газапларын алар әйтә алмады, Гүя китте миңа калдырып»,— дип язар идеме фронтовик шагыйрь Х.Камалов, кырык елдан соң «Безне өйдә көтәләр» кебек роман-трагедияләр иҗат итәр идеме ул? Сугыш болай да, М.Әмирнең бер герое сүзләре белән әйткәндә, безнең халыкка күп нәрсәләрне аңларга ярдәм итте. Ләкин, сугыш турында җитди проза еллар үткәч язылган кебек, шигъриятькә дә чын мәгънәсендә сугышның прозасы беркадәр кичегеп килде.

Ул бүген халыкның ачы тәҗрибәсе һәм йөрәк сыктавы булып яңара, ул безгә яшәү кадерен белү өчен кирәк. Бу олы бурычны үтәү елдан-ел күбрәк рухи көч һәм йөрәк җылысы түгүне таләп итә бара. Шуңа күрә сугыш турында язу җиңүчеләр хатирәсен гомуми сүзләр, гомуми пафос белән рәнҗетмәү булып та кала.

Безнең көннәр әдәбиятында сугышның тышкы драмасы, гади күзгә үк ташланып торган фаҗигасе эчкә үтеп керә, йомыла, агач үскән саен кәүсә эчендә кала барган боҗралар кебек, ул хәзер эчке драмага әверелә:

Авыр димим сине,
җиңел димим,
үлчәп булмый сине, Замана.
Утыз яшькә җиткән егетләрнең
икенче кат чәче агара.
*(К.Сибгатуллин)*

Бу инде сугыш хакыйкатен, аның тылдагы тормышка тәэсирен, батырлык яки куркаклыкны, җиңү яисә фаҗигале ялгышу күренешен атау, тасвирлау гына түгел, бу — кеше күңеленең иң җаваплы мәлдәге халәтен, уй-хис хәрәкәтен, эш-гамәлләрнең эчке механизмын күрергә, сурәтләп бирергә омтылу.

Сугыш, кызганыч ки, безнең өчен хәтер-хатирә генә түгел, бүгенге яшәү рәвешебез дә булып кала. Кайбер халыклар өчен сугыш — милли азатлык өчен көрәшнең канлы-яшьле бер рәвеше, шундый ук әһәмияткә, мәгънәгә ия «Ватан сугышы».

«Сулыш алсаң, эчкә «сугыш» үтә» (Р.Харис)  торган бу елларда:

Июнь җиле киләчәктән
Хатирәләр китерә...—

дип, бер нюанс белән генә әллә нинди ассоциацияләр уята алган Ф. Сафин; капкага кадәр кырып-кырып юган пакь күңелле әнисен:

Ә ул моннан кәвешен дә
Сөртеп чыккан дөньяга,—

дигән юллар аша безнең күз алдына китергән З.Мансуров;

Яшисе килә, яшисе,
Агачтай тамырланып,—

дип, үзенчә бер оптимистик омтылыш, җегәр белән килүче Р.Низамиев кебек яшьрәк буын шагыйрьләр иҗатында да без традицияләр яктысын, фронтовикларның әхлакый максимализмы дәвамын күрәбез. Тормышчан тирәнлеге һәм кырыс зирәклеге белән тетрәтә торган шигырьләр шушы юлда язылыр дип өметләнергә тулы нигез бар.

Шул рәвешле, Бөек Ватан сугышы темасы безнең ил әдәбиятында һәм, аерым алганда, татар поэзиясендә, гаҗәеп бер күренеш булып яши. Сугышны күрмәгән бәхетле буын иҗатында ул ир-егетлек, гражданлык асылы сыналу, яшь кешенең рухи җегәрен туплау, эшкә җигү булып та аңлашыла. Яшь авторларның шигырьләре сугыш турында гына түгел, ул — аларның тормышны һәм кешеләрне үзләренчә аңлаулары, тормышка үз карашларын шул рәвешчә белдерүләре дә. Бу җәһәттән аларның: «Мин бердәнбер көтеп алган малай идем нәселебездә. Мин кайтырга тиеш өйгә!» (М.Әгъләмов) кебек өмет һәм фаҗига тулы юлларында фронтовик әдипләр белән аһәңдәшлеге, эчке кардәшлеге дә, сугыш фәлсәфәсен беркемгә дә охшамыйча, тик үзләренчә аңлаулары да чагыла.

Ахыр чиктә, яшәү матурлыгы һәм мәхәббәт олылыгы турындагы, сагыну һәм якынлык хисләре салынган шигырьләр дә ватандарлык тәрбияләү вазифалы була алмыймыни? Чит туфракка башын салган Г.Кутуйның «Сагындым, бик сагындым сине, Туган ил!» дип башлана торган нәсере Ватан сугышы солдатының җиңүгә омтылышын җырлаган иң көчле әсәрләрдән берсе түгелмени? Окопта мылтык түтәсенә куеп язылган, фашист тоткынлыгында җәллад балтасы астында иҗат ителгән әсәрләрнең күпмесе мәхәббәт һәм тыныч тормышка сусау хакында! Халыкның «...калды Туган ил генә» дигән җырларында да мескенлек, сыктау, сыгылып төшү түгел,— бу да батырлыкка, көрәшкә, җиңеп өйгә кайтырга рухландыру. Өендә көтеп торучысы, туган иле, халкы булмаган кеше — космополит — ут эченә керми...

Әнә шуңа күрә сугыш турындагы әсәрләр үткәнгә хөрмәт күрсәтү генә булмыйча, табигый рәвештә, бүгенге тыныч-имин тормышны яклаучы, киләчәкне афәттән сакларга рухландыручы әсәрләр булып та яшиләр. Разил Вәлиев бер шигырендә, ветераннар:

...шәһәр урамында

Моңсуланып, җиргә сыенып,
Йөри алар кибет саен кереп,
Ипи муллыгына сөенеп,—

дип язса, сугыш хәтерен яңартучы күп кенә әсәрләребездә халык хәтере булып калыккан һәйкәл һәм обелисклар аеруча күзгә ташлана.

Кызганыч, «Мәңгелек ут (яисә һәйкәл) янында язылган» шигырьләр арасында таш салкыны бәреп тормаганнары бик аз. Аларда баштан ук коры акыл уены, схема өстенлек итә. Алар, поэзиядә ут белән, бигрәк тә Мәңгелек Ут белән шаяру ярамый, дип тагын бер кабат кисәтәләр сыман.

Сугыш темасы, гомумән, шартламый калган иске бомба кебек, үзе белән саксыз кыланганны, белер-белмәс килеп орынганны кичерми.

Сугыш — мәгълүм «тунгус метеориты» сыманрак, әлбәттә, аннан чагыштыргысыз дәһшәтлерәк, тирәнрәк эз калдырып, гасырлар үткәч тә җөйләре нык беленерлек булып, халыклар күңеленә төшеп ярылган афәт. Аның хәтта әйләнә-тирәсендәге күренешләр аша чагылган тәэсирен дә җитдирәк итеп өйрәнәсе, шигырь телендә әйтеп бирәсе бар әле.

...Бездән соң да чүлмәк калыр микән?
Ниләр эшләр Вакыт?! *(Р.Миңнуллин)*

Без бүген дөньяга галәм киңлегеннән орбиталь станцияләр биеклегенә күтәрелеп карыйбыз. Ләкин бу безне күрәкараучылыкка дучар итми, киресенчә, авыр яуланган Җиңүнең дөнья күләмендәге, тарих җирлегендәге әһәмиятен аңлау һәм әсәрләрдә зур җаваплылык белән гәүдәләндерү бурычын йөкли.

...Инде менә ничәнче мәртәбә билгеләп үтелгән тынычлык тантанасына, сугышта һәм тыныч елларда Җиңүебез хөрмәтенә Җир, махсус кар астыннан чыгып, көтеп-әзерләнеп тора шикелле. Һәм бу көннәрдә, кар астыннан чыккан иске дә һәм яңа да җир кебек, вакыт япмасы каплап торган яралар ачыла, хатирәләр уяна. Хәрби комиссариатлар янында, төркем-төркем булып, армиягә алынучы егетләр, аларны озатып калучылар җыйнала. Йөзләрдә — борчылу да, өмет тә. «...Калганы — ...буыннарның яңаруы..., өстәлдәге икмәк..., яшәтүче өмет...»,— ди шагыйрь.

Татар поэзиясе — яу кырында «солдат поэзиясе» дигән мактаулы хәрби звание-дәрәҗә алган шигъриятебез; ул мәхәббәт кебек үк мәңгелек теманы — Тынычлык һәм Туган илне саклау поэтикасын яңа якларыннан ача барсын, хәрби комиссариатлардан килгән повестка шикелле үк, замандашларыбызны җитдилеккә, уяулыкка өндәсен!

1985

## УТНЫ КҮЧЕР!

Хисамны мин, ул икенче фронтта сугышып йөрсә дә, үз взводымдагы солдат кебек хис итәм...

Сибгат Хәким

Авылда комбайнчы булып эшләүче абзам бар минем. Унсигез яшеннән сугышка алынган. Гомере буе баш күтәрми эшләгән. Бик йомшак күңелле, сабыр-ихлас кеше. Зурдан кубасы берәр эш килеп чыкса, аның белән киңәш-уңаш итәргә тырышам. Ашыкмый-кабаланмый тыңлар, суына төшүеңне көтәр, шуннан соң гына җай белән үз киңәшен бирер. Кем әйтмешли, беркайчан да яшелли урмас.

Беренче карашка ук Хисам Камалов ничектер әнә шул абзамны хәтерләтте. Менә ул җыйнак кына эш бүлмәсендә, сине бик игътибар белән тыңлый-тыңлый, сөйләшеп утыра... Яисә ишегалдына һава суларга чыккан, тирә-күршеләр, бала-чагалар арасында... (Берара без Хисам абый белән күршеләр булып яшәдек. Нәкъ шул чорда аның иҗаты хакында сүз әйтергә туры килгән иде. Танылган тәнкыйтьчеләребездән берәү, әлеге «әшнәлек»не бик тиз фаш итеп, «әдәбиятка азмы-күпме мөнәсәбәте булган күршесе турында мактау мәкаләсе язып чыгу» дип бәяләде. Кызганыч, хәзер инде без күршеләр түгел. Ләкин, шәһәрдә яшәгән урамнар ераклашкан саен, «әдәбиятка азмы-күпме мөнәсәбәте булган» бу якты шәхеснең иҗаты миңа якыная, аңлаешлырак була бара...)

Үзе кебек үк, тормыш юлы да тыйнак.

Җидееллык мәктәп тәмамлагач, колхозда ат караучы булып эшли.

Яше тулар-тулмас фронтка китә. Авыр сугышларның берсендә каты яралана. Ел ярым гомерен госпитальдә уздыра. Бер аяксыз кала. Унтугыз яшеннән...

Госпитальдә беренче тапкыр һөнәр үзләштерә. Тыныч һөнәр — колхоз хисапчысы булырга әзерләнә. Тормышка, кешеләргә ышанычы яңара, балачактан ук күңелендә яткан хыяллары уяна. Озакламый ул — Бөгелмә педагогия училищесы студенты. Аннары — Казан педагогия институты.

Шуннан соң унҗиде ел китап нәшриятында редактор булып эшли. Беренче китапларына Х.Камалов фатиха биргән яшь язучылар гына да шул еллар санынннан артыграк.

Шагыйрь үзе дә остазлары исемен хөрмәт белән телгә ала. Әхмәт Фәйзи, Сибгат Хәким, Әнвәр Давыдов... Иҗатына һәрвакыт илтифатлы булган, үсешенә ярдәм иткән кешеләр.

Беренче шигырьләрендә—сугыш калдырган ялардан әрнү-көенеч һәм яңадан сафка  кайту сөенече. Шуңа күрә беренче җыентыгы да — «Яңадан сафка».

Аның шигырьләре һәм поэмалары, соңгы елларда аеруча зур куәт алган прозасы тормыштагы урының, кыйблаң турында уйландыра. Алар зур ышандыру көченә ия. Шулай да бу иҗат (артык тыйнаклыгы, оялчанлыгы аркасындамы) тәнкыйть күзеннән күләгәдәрәк калган. Укучы да аның белән соңара төшеп очраша төсле.

Сугыш дәһшәтен үз башыннан кичергән шагыйрьләр буыны... Алар өчен таяну ноктасы да күпмедер дәрәҗәдә уртак: авыл, яшьлек, фронт. Шушы җирлектә мәңгелек төшенчәләр турында уйланулар бөреләнә. Юк, җирлек димәктән, бередә киңрәк, тирәнрәк мәгънә ята: ул — шагыйрьнең нигез-туфрагы, шәҗәрәсе һәм, ниһаять, иҗат критерийлары.

Хисам абый үзенең «бик вакытсыз килгән» яшьлеге турында искә алырга, сөйләргә яратмый. Күрәсең, ул хатирәләр гади сүзләр белән генә аңлатып бетерә алмаслык дәрәҗәдә изге дә, кагылсаң тоташ газапка әйләнерлек иске яра сыман әрнүле дәдер. Ләкин шагыйрьнең язмышы шундый: ул иң тирәндә яткан тойгыларын шигырьләренә сала.

Без сугыш еллары шигърият енең, бизәк өчен генә матур сүзләр белән мавыкмыйча, нинди ачы булса да, дөреслекне күзгә карап әйтергә омтылуын беләбез. Гаделлек һәм чынлык, йөрәк һәм вөҗдан поэзиясе. Халык рухының ныклыгын да, тирәнлеген дә гәүдәләндергән ул.

Шигърияткә 50 нче еллар башында гына килсә дә, Х.Камалов үзенең язмышы белән генә түгел, бөтен рухы, иҗаты белән шушы чорга карый сыман.

Миңа — унсигез яшь,
Әле куркам.
Гел аталар, ай-яй, кыен ла!
Һавада һәр чинап очкан мина
Башка төшәр төсле тоела.
Минем әле
Үлем күргәнем юк...

Яшәү чиге белән үлемсезлек турында, үз бурычыңа тугрылыклы булу турында менә шулай яза шагыйрь. Солдатларча ачыктан-ачык һәм чын күңелдән. Лаф ормыйча, күкрәк какмыйча.

Сугыш турындагы шигырьләр бүген язылган тәкъдирдә дә ихласлыгын, чынлыгын җуймый. Киресенчә, канлы һәм данлы ул көннәр ераклашкан саен, аерым нечкәлекләреербөтенгә укмаша барган саен, хакыйкать җетеләнә, зурая, якынрак була бара бугай.

Хисам Камалов та шул заманнардан бирле чын мәгънәсендә алгы сызыкта кала. Артиллериядә ул элемтәче булган. «Сугыш алласы»ның күзе һәм колагы. Күз алдына да нәкъ шундый булып килә: Сибгат Хәким әйтмешли, дошманның йөрәк тамырына баскан да: «Утны күчер!» — дип кычкыра сыман...

Шагыйрь-солдат, үз позицияләреннән чыгып, сугышчан бурычын яхшы аңлый. Ул тормыш күренешләренең бик табигый, әмма башкалар күзенә чалынмаган мәгънәләрен эзли. «Газапларга баеп, шатлыкларга саранланса да», язмышының якты сәхифәләрен ача ул, укучыны дөньяның кояшлы якларына чакыра.

Сүз, билгеле, Х.Камаловның окопта үткән яшьлегенә багышланган шигырьләре турында гына бармый. Гомумән, аның поэзиясендә сугыш темасы үзәккә куелмаган. Язылган кадәресендә дә беренче тапкыр үлем белән очрашкан яшь солдат яки тәнендә һәм җанында калган яралар турында уйланучы ветеран хис-тойгылары тасвирлана. Бер карыйсың, ул — хаталанган солдатны йолып калган замполит, икенче урында — чигенә алмаган пулеметчы... Хәтта чигенүләр, хаталар белән генә мавыга төшү күзгә ташлангандай була. Ярсулы һөҗүм картиналары кайда? Ни өчен дошманны тетрәтүче туп тавышлары ишетелми? Бу сорауга җавап эзләгәндә, Хисам Камалов иҗатының кызыклы һәм каршылыклы ягы ачыла: аны, сугыш мәхшәренең тышкы күренешләреннән бигрәк, кешенең иң авыр вакытта яшен яктысыдай ялтырап киткән асылын сурәтләү кызыксындыра... Шулай, сугыш — бик авыр хезмәт, «өйрәтелгән ерткыч»ның өненә кадәр барып юк итү тоташ җиңүләрдән, «ура!»лардан гына тормый. Шул ук вакытта яу кырындагы чигенүләр —рухи позицияләрне ташлау түгел әле!

Вакыйгалар давылы эчендә шәхеснең җанын ярып салу, фикерләр һәм хисләр гармониясенә ирешү җиңел түгел. Болытлар куера, әмма кайвакыт, яшене күренсә дә, зарыгып көткән яңгыры таммый.

Х.Камалов иҗатында да булгалый торган хәл.

Кулына каләм алгач та дигәндәй язылган «Яну» поэмасын тәнкыйть, нигездә, шулай бәяләгән иде. Аңа Ватан сугышы фронтындагы эпизодларны артык субъектив планда аңлату, хакыйкатьтән читләшеп, «вакыйгалар колы» булып тасвирлау хас, дип күрсәтелде.

Чыннан да, поэма нигезенә шагыйрьнең үз күзәтүләрен салуы сизелеп тора, иң киеренке, иң мөһим моментларда ул үзен дә геройлары арасында хис итә: «Бер «юнкерс» килеп, безнең өстә миналарын коеп әйләнде...» — ди. Шул ук вакытта шәхси кичерешләрнең бөтенлеген җуярга теләмәү, киң полотно тудыру максаты белән күргән-белгәнне тәфсилләп сөйләү әсәрне бер үзәккә тупларга комачаулый. Заманында әдәби тәнкыйть «Яну»ның әнә шул таркаулыгына игътибарны юнәлткән дә иде инде. Ләкин бер уңайдан шагыйрьгә «хакыйкатьтән читләшү» кебек зур гаеп ташлау һәм, асылда, әлеге әсәрнең әһәмиятен сызып ташлау урынлы булдымы икән? Ватан сугышы нинди генә масштаблы күренеш булмасын, ул аерым «эпизодлар»дан, гади солдатлар язмышыннан аерылгысыз...

Хисам Камаловның күпчелек геройлары — үзе кебек үк риясыз, ихлас күңелле кешеләр. Кылган эшләрен фәлсәфә пәрдәсе белән йомарга яки хәлиткеч адымда качып калырга тырышмыйлар алар,

киресенчә, язмыш сынавына җиңел булмасын алдан ук белеп керәләр. Мондый фидакарьлек, табигый һәм тыйнак батырлык укучының да күңелен кузгата.

Хисам Камалов хис һәм уй-фикерләренең тормышчанлыгын форма гадилеге белән дә беркетә шикелле. Шигыренең һәр күзәнәге — гап-гади кешеләр үзара сөйләшкән төсле:

...Кинәт фриц
Дальнобойный белән төкерде.
Котелокка блиндаж түшәменнән
Туфрак тулды, ашны бетерде.

Әйе, гади язу җиңел түгел. Кайвакыт менә шулай шигырь белән проза арасындагы кыл өстеннән үтәсең. Рус шагыйре Евг.Винокуровның прозаизмнарны шигъриятнең «бас регистрлары»на охшатуы, аларда зур тәэсир көчен күрүе искә төшә. «Киселмәгән ефәк көе», «керендерә мина белән, кая керер тишек юк...» кебек халыкчан гыйбарәләргә, «буй зифасы аның сынында...» дигән тасвирларга үрелеп, шагыйрьнең үз күңел гөлләре дә үсә: «авыр яраларга күнегеп була, җиңелүгә булмый күнегеп».

Шагыйрь иҗатындагы тыенкы рух, солдатларча кырыс форма кайнар хис һәм эзләнүчән фикер агымын тагын да куәтлерәк итеп күрсәтә.

Шагыйрьнең лирик герое иң авыр сынаулар кичкәндә дә сынмаган. Шуңа күрә аның сүзе саф һәм тыйнак, үзәк өзгеч дәрәҗәдә чын.

Белсәң, әнкәй, дошман тылларына
Разведкага барган чакларым,
Мин куркудан догаң гел укыдым,
Җаным саклап кеше сатмадым.

Кабат-кабат канатлары каерылган сабыр холыклы һәм нечкә күңелле кеше күзләре белән дөньяга карау җиңел түгел. Аның бик тирәндә яткан көчле рухын тиз генә абайлап өлгермисең. Әнисе кебек үк: «Үзе юаш, үзе тәҗрибәсез, ничек калсын шушы мәхшәрдә?..» — дип чын күңелдән борчыласың. Сыкранулары күбрәк төсле.

Шулай да гаҗәп бит: шигырьдән шигырьгә күңелдәге образ ачыклана, зурая, куәтлерәк була бара. Аның сагышы да, шатлыгы да, сафландыргыч һәм рухландыргыч ташкынга әйләнеп, безне бөтереп ала.

Шагыйрьне адәм баласының дөнья белән алыш-биреш вакытында, кешеләр арасында үзен ничек тотуы кызыксындыра. Шул рәвешчә, ул тормышның рухи эчтәлеген аңларга һәм безгә аңлатырга омтыла.

...Теләсә нинди әрне күтәрермен,
Тик син генә мине ташлама!

Тән һәм җан газапларыннан горурлыгын җуймый чыккан кешенең мәхәббәт хакына яңа югалтулардан курыкмавын шулкадәр табигый итеп сурәтләү һәркемгә дә бирелми.

Сугыштан соң кырык еллап гомер үткәч, Х.Камалов сугыш турында зур күләмле әсәрләр иҗат итте. Сүз барыбызга да яхшы таныш булган «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр» һәм «Үлгәннән соң яздым» исемле өч роман хакында бара. Әлеге трилогия — язучының бөтен гомере белән әзерләнгән, шул өч романда — тормышының аерылгысыз бер кисәге.

Без монда сугыш дигән зур дөнья, сугыш дигән гаять катлаулы образ белән очрашабыз. Ил өстенә килгән афәт һәм аерым бер кеше драмасын сурәтләү һәм аңлату искиткеч авыр.

Әлегәчә иҗатында прозаизмнарга нык таянып килгән шагыйрьнең «авыр артиллерия» жанрында үзен шактый иркен тотышы әллә ни гаҗәпләндерми. Шагыйрьлек анда иң гади язмышлы кешеләрнең күңел байлыгын, кешелеклелек матурлыгын тасвирлаганда гына танылып-сизелеп китәдер шикелле... Шулай да бу трилогияне укыганда сораулар туа тора, аларга җавап табуы да кыенлаша бара. Капма-каршы кебек тоелган ике сыйфатны — күренеш-вакыйгаларны тәфсилләп, нечкәләп тасвирлау белән сүзгә саранлыкны ничек бергә куша алды икән язучы? Сугышта разведкага йөргәндә, дошман уты ас-

тында элемтә урнаштырганда канына сеңеп калганмы бу сыйфатлар? Ә төрле кешеләрнең фронтта табышу-очрашуы һәм һәлакәте бер-берсен хәтерләтеп куйган чаклар — аларны ничек аңлатырга?

Хәер, бөтенләй дә аңлашылмаслык хәл микән бу?.. Әнә бит, фәлән героеңның исеме бик үк матур яңгырашлы түгел, алыштырыйк әле, дип, редакторлар мөрәҗәгать иткән икән,— Х.Камалов берничек тә риза булмаган. «Ничек алыштырмак кирәк, аның чын исеме шулай иде бит!» —дип кырт кискән. Миңа калса, бу һич тә «тормышта шулай булган»га ябышып яту түгел, бу, гади генә итеп әйткәндә,— принципиаль җавап: хакыйкать бөтенлегенә омтылу билгесе.

«Безне өйдә көтәләр» дигән исемне «патриотик түгел» дип үзгәрттерергә теләүчеләргә дә аның җавабы катгый.

«*Аны өйдә көтәләр!»* — Менә ни өчен ут эченә керә солдат, ул үз өен, нәселен дошманнан яклау өчен изге яуга чыгуын яхшы белә. Романнардагы һәр геройның «бәләкәй» тылы күз алдына килә. Алар үзеннән-үзе ничектер зур тыл төшенчәсе белән бәйләнә. Сугышчының ил алдындагы бурычын аңлавы һәм аны гомере бәрабәренә булса да үтәве, ахыр чиктә, шушы тыл белән бәйләнгән.

Сугыш чынбарлыгы аша кеше табигатен, халык язмышын аңларга омтылу. Замандашларыбызны рухи һәм әхлакый асылыбыз турында уйлануга җәлеп итү. Бу әсәрләрнең иҗтимагый-фәлсәфи колачы, заманчалыгы менә шунда. Даут, Мирхас кебек асыл егетләрнең, Фәимә кебек мәхәббәттә тугрылыклы, кыю кызларның гөнаһсыз яшьлеген, үлемсез уй-хыялларын, өзелеп калган җырларын язучы безнең чорга —яңа буыннарга мирас итеп тапшыра. Дөрес, Х.Камалов романнарында ачыктан-ачык мондый күпер салынмаган, ягъни вакыйгалар агышын безнең көнгә китереп бәйләү күренми. Ләкин безне ул көннәр белән тоташтыру вазифасын замандашыбыз-язучы турыдан-туры үз өстенә ала.

Яңа заман алдыбызга яңа бурычлар куя. Әмма позицияләр үзгәрешсез кала. Без фронтовикның: «Утны күчер!» — дигән тавышын ачык ишетәбез һәм яхшы аңлыйбыз.

Аның җанын аңлап, якын күреп, Сибгат Хәким болай дип язган иде: «Хисамның тормышында, дөньяга карашының нигезендә Бөек Ватан сугышының роле искиткеч зур... Хисамны мин, ул икенче фронтта сугышып йөрсә дә, үз взводымдагы солдат кебек хис итәм...»

Хисам Камаловның үз язмышын күздә тотып язган «Яраланган пулеметчы» турындагы шигыре дә шул фикерне раслый:

Калдырыгыз пулемет төбендә,
Мин чигенә алмыйм барыбер!

1980

ТЫНГЫСЫЗ ЙОРТ ХУҖАСЫ

Кеше гомере — олы бер тау,
Вакыт аны ватып ала,
Һәм кабергә куяр өчен
Бер кечкенә ташы кала.
Нәби Дәүли

Ул үзенең шигырьләренә охшаган.

Алар кебек үк ярсу-кайнар, эчкерсез-хыялый... Һәр сүзе-ымы, һәр ишарәсе белән шуны раслап тора. Яшьлегендә шактый гаярь, кыз-кыркынның һушын китәрерлек мут егет булгандыр, дип уйлыйсың.

Әле дә истә: әдәби ел йомгакларына багышланган җыелыш бара, болай да зур булмаган залда алма төшәрлек тә урын юк, әмма шул эшлекле ыгы-зыгыда аны — Нәби Дәүлине күрми калу мөмкин түгел иде. Юк, киеме, килеш-килбәте белән бүтәннәр арасында әллә ни аерылып тормый ул, урындыгы да күзгә ташланырлык төшкә туры килмәгән. Иң гаҗәбе шунда: трибунадан поэзия турында доклад укыйлар, Нәби ага исә, аның һәрбер сүзен үз учыннан очырып җибәргәндәй, бик әсәрләнеп, ашкынып, дәрт биреп утыра иде. Таләпчән-катгый фикерләр әйтелгәндә, ул, кулы белән һавада кискен хәрәкәт ясап, «нокта куя»: трибунадан яңгыраган сүз нәкъ менә шул «нокта»да ябышып-расланып кала сыман. Дусларча чеметү-шаярту ишетелеп китсә, залдагы җанланып алуны чал чәчле язучының кычкырып көлүе көчәйтеп җибәрә. Бу мәлдә аның йөзендәге җыерчыклар челтәре шундый языла,— ул әбиләр чуагы чорындагы җиңел пәрәвез җепләренә әверелер дә очып китәр төсле!..

Әйе, таләпне зурдан куеп, әле байтак бәхәсләргә азык булырлык сүзләр әйтелде ул чакта. Һәм әлеге чыгышның «дирижеры» гына түгел, авторы да Нәби Дәүли булуы (тамагы авыртып торганлыктан гына аны башка берәүдән укытуы) — залдагыларның һәркайсына мәгълүм иде. Сүз үзенең иясеннән аерылмаган булып чыкты. Бәлки, шуңа күрә дә ул икеләтелгән тәэсиргә — үзенә күрә «стереофоник» яңгырашка ирешкәндер.

Каләмдәшләре, кордашлары Н.Дәүлине уяу янартау шикелле кайнап-күкрәп торучы әдип буларак беләләр. Кемгәдер аның холкы яхшук дуамал булып та тоеладыр. Ләкин ул янартау күкрәгендә нинди давыллар уйный?.. Нинди көчләр аны хәрәкәткә китерә?

Белгәнебезчә, Нәби Дәүлигә чын мәгънәсендә танылу шактый соңарып, әмма көтмәгәндә, дәррәү килде. Көннәрнең берендә укучы бу исемне «Яшәү белән үлем арасында» дигән повесть белән бергә, иң беренче чиратта, әнә шул китап авторы буларак күтәреп алды. Әлеге әсәр кайнар чынбарлыгы белән җәлеп итте, фаҗигале язмышлары белән тетрәндерде.

Яңадан-яңа буын укучылардан менә утыз ел буе хатлар килеп тора икән, бу хәл «Яшәү белән үлем арасында» повестеның дәвамлы тәэсир көче турында сөйләмимени!

Әмма Вакыт елгасы ага тора, инде хәрәкәттәге тәнкыйтьнең игътибар үзгәнә башка, яңа әсәрләр килеп керүе — табигый хәл. Һәм нәкъ менә хәзер, шау-шу басылгач, таныш сәхифәләргә кабат әйләнеп кайту, тәэсир-кичерешләрне яңарту язучының иҗади йөзен тулырак күз алдына китерү максатында кызыклы булыр иде.

Тормыш язучыны утлы сиратлардан еш кичәргә мәҗбүр иткән, кырыс сынауларда сынатмаска-сыкранмаска өйрәткән. Һәр өйгә фаҗига-афәт алып килгән сугыш аның өлешенә хәтәр борылмалар әзерләп куя... Ил туфрагына дошман аяк басканның икенче көнендә үк яу кырына киткән Нәби Дәүли авыр бәрелешләрнең берсендә йөзләгән иптәшләре белән чолганышта кала һәм тоткынлыкка төшә. Язмышы бөтенләй билгесез сукмакларга кереп китә, илдәгеләр өчен «хәбәрсез» югала. Ләкин язучы — гади солдат, гади әсир түгел, ул, яшенне үзенә тарткан имән кебек, бөтен хәтәр хәлләрне үз йөрәге аша уздыра. Башкалар бер кичергәнне мең кабат кичерә. Хис-тойгылар чынлыгы, мең көзге аша үтеп бер ноктага туплангандай, аерым шәхеснең генә түгел, тулы бер буынның фаҗигасен күз алдына бастыра. Менә ни өчен ул безнең бөтен күзәнәкләргә үтеп керә, көйдереп ала...

Теге яки бу әсәрне язарга этәргән сәбәпләр, аларның «чынлыгы» турындагы сорауларга язучы халкы күнеккән инде. «Яшәү белән үлем арасында» повесте уңаеннан исә бу сорау аның әхлакый нигезе белән бәйле рәвештә дә булырга мөмкиндер. Йомылып килүче яраларны янәдән кузгату кирәкме? Әсирлекнең күзгә күренмәс фронт сызыгын, «алгы сызыктан да алдарак булган окоплар»ын тасвирлаганда, бүгенге укучыны ышандыра алырсыңмы? Н.Дәүли әлеге сорауларга әсәрен язарга керешкәнче үк җавап бирергә тиеш булган. Повестьны укыганда, без язучының шул хакта сөйләвен көтәбез, кинәт кенә тоныкланып киткән күкрәк тавышын ишеткәндәй булабыз. Кешеләр, сез бу сүзләрне кабат-кабат «әйләндереп» тыңлагыз һәм уйланыгыз, ди сыман ул.

«Сугыштан соң Казанга кайткач, мин һәр көнне диярлек вокзалга барып йөри идем. Ул көннәрдә демобилизацияләнгән солдатлар белән шыгрым тулы эшелоннар бер-бер артлы килеп кенә тора. Вокзалда туганнарын, дусларын каршыларга төшүчеләр хәтсез күп... Кичкә таба перрон бушап кала. Шул вакытта мин бер карт кына хатынны күрә торган идем. Ул да, мескенем, кемнедер каршыларга килә иде, күрәсең...

Шулай беркөнне без тагын буш перронда икәүдән-икәү генә калдык. Менә ул хатын миңа якын ук килде дә: «Кайтмадымы?» — дип сорады. «Юк, кайтмады шул»,— дидем мин. «Кемне көтәсез?» — «Дусларымны». Хатын яшь тулы күзләре белән миңа карады да: «Мин дә улымны көтәм, ә ул бик сагындырып кына кайтырга уйлый, ахрысы»,—

диде, авыр сулап».

Язучының йөзендәге җыерчыклар, чәнечкеле тимерчыбык сыман, тирәнрәк уела төшә, ул бөтен гәүдәсе белән, кемнедер әче җилдән ышыкларга теләгәндәй, алга таба талпынып куя.

«Ялгыз ананың бердәнбер улы сугышның башында ук фронтка киткән,— дип сүзен дәвам итә ул.— Бары бер генә хаты килеп калган. Ә инде өч айдан соң аның хәбәрсез югалуы турында военкоматтан язу китергәннәр... «Хәбәрсез югалды, дисәләр дә, йөрәгем ышанмый,— диде хатын.—Йә бүген, йә иртәгә кайтып төшәр шикелле...»

Мин өйгә кайтып барам. Ә башымда уйлар кайный. Күпме алар ялгыз аналар, ятим калган балалар?! Тукта, мин ул «хәбәрсез югалганнар»ны белмимме икән? Мин аларны күрмәдемме? Бәлки, алар минем белән янәшә булганнардыр!.. Әйе, мин ул «хәбәрсез югалганнар»ның адресларын беләм. Ләкин ул адрес буенча хат бармый, аннан хат та килми. Ул адресны аналар, балалар белсеннәр иде, дидем мин. Аларның язмышларын, көрәшләрен күрсеннәр иде. Шул теләк белән мин шушы повестьны яздым...»

«Яшәү белән үлем арасында» әсәренең публицистик җегәре, үзенчәлекле стиле, әнә шулай, нинди укучыга йөз тотып һәм нинди ният белән язылуыннан башлана. «Мин хәбәрсез югалган идем» дигән кереш өлештә төп максат ачыктан-ачык күрсәтелә: «Кем иде соң ул фашист? Мин сиңа шул турыда сөйләргә телим»,— ди язучы. Мондый конкретлык безне ике юл чатына куеп, бераз сагаерга мәҗбүр итә: сурәтләр чынлыгы һәм аналитик фикер тирәнлеге белән җәлеп итәрме ул; гомуми пафос дулкынында, әзер өлгеләр буенча алып китмәсме?

Н.Дәүли беренче юлдан китә һәм, реалистик буяулар сайлый-сайлый, немец халкының фаҗигасен ачуга керешә. («Германия нинди матур ил икән!.. Чәчәк аткан гүзәл табигать эчендә фашистлар да яши дип ышанасы килми иде».) Ул, кайбер әсәрләрдәге кебек, фашистларны ахмак юлбасар итеп кенә сурәтләсә, аларның «барыннан да элек кешегә охшаган булулары белән куркынычлы» икәнлекләренә ышандыра алмас иде. Иң мөһиме шунда: укучыга фашизмның кара йөзе якты җирлектә — тәннәре әсирлеккә төшсә дә, рухлары белән хөр булып кала алган кешеләрнең тормышка мәхәббәте фонында күрсәтелә. Лагерьда «парикмахерская», «лазарет», төрле «мастерскойлар» ачылу күренешләрен генә искә төшерик. Бу оптимистик трагедиянең нигезендә — ватан солдатының күңел сафлыгы, рух нныклыгы. Теткәләнгән киемнәрдә калган йолдызлы төймәләр дә котылгысыз үлемнән куркып-каушап калмаслык көч бирә. Әнә шуңа күрә фашистларга хәтта үз өннәрендә тынычлык юк, әсирнең яшәүгә, җиңүгә омтылышын нинди рәхимсез шартлар да сүндерә алмый. Әсәр тигезсез һәм тиңдәшсез көрәшнең драматик эчтәлеген сурәтләп, тантаналы финалын шушындый гомумиләштерү рәвешендә тәкъдим итә: «Без Германия җиренә үзебез белән немец армиясенең җиңелү хәбәрен алып килдек».

Бу лейтмотивның «Җимерелгән бастион» романында саклануын, дәвам итүен күрүе кыен түгел. Иң хәлиткеч минутларда роман геройларыннан берсе — Нажия, мәсәлән, турыдан-туры: «Сүз яшәү белән үлем турында бара»,— ди. Билгеле, «Җимерелгән бастион»ның әдәби «ачкыч»ы бүтән, андагы язмышлар төене бөтенләй башкача чишелә. Ләкин язучы әлеге әсәрендә дә тормышның «яшәү өчен

генә түгел, барыннан да элек, явызлыкка каршы көрәш» булуы турындагы сүзен дәвам итә, «фашизм белән кылычка-кылыч килгән» иң кискен бәрелешләрне сурәтли, шул көрәштә «бер Германиянең ике Германиягә» аерылуын күрсәтә... Укучы, бәлки, игътибар иткәндер: сүз «Җимерелгән бастион» турында барганда да, мин әлеге өземтәләрне «Яшәү белән үлем арасында» повестеннан китердем. Һәм менә ни өчен. Безнең кайбер тәнкыйть мәкаләләрендә, әлеге ике әсәрне бер-берсенә каршы куеп, «Яшәү белән үлем арасында» әсәре фашист концлагерьларындагы авыр тормышны гына тасвирлый, әсирләрнең илбасарга каршы көрәшен күрсәтми, дигәнрәк фикерләр ишетелгән иде. Хәлбуки, көрәшне кулга корал алу гына дип күз алдына китерү — бик берьяклы түгелме соң? Әсирлектә «шырпы кебек янып сүнгән» ир-егетләрнең: «Ничек тә исән каласы иде»,— дип өзгәләнүләрен хәтерләгән кеше, яшәү өчен көрәш гадирәк, җиңелрәк, ул —дошманга каршы көрәш түгел, дип уйлый алмас. «Бу сәгать осталары, бу тимерчеләр, бу игенчеләр, бу инженерлар, врачлар, балта осталары әле дөньяга күпме байлык, күпме матурлык бүләк итәрләр иде...» Коры риторика белән түгел, әдәбиятның могҗизалы көче ярдәмендә, бер шәхес хатирәләреннән буыннар хәтеренә күчү күренеше белән очрашабыз. Әсәрдәге бер кушуч якты сагышның, меңнәрчә күңелләрдә тәкрарланып, олы масштабларга ирешүен күрәбез. Ул, һәр таңда чыккан кояш кебек, безне тормыш-яшәеш кадерен белергә өйрәтә.

Әсәрләрдә сурәтләнгән һәм бүгенге укучыларны дулкынландырган вакыйгалар моннан кырык ел элек һәм бер үк вакытта безнең күз алдында бара. Хикәяләүнең үзенчәлекле стиле ачык билгеләнгән: әсирлек көндәлеге, хатирә-репортаж! Язучы үзе тасвирлаган вакыйгаларны бүгенге көн биеклегеннән торып күздән кичерә, кирәк урында ачыктан-ачык аңлатып-шәрехләп ала, кичерешләреннән оялмый, мөнәсәбәтен яшерми. Әмма ул, башыннан кичкән хәлләрне генә сөйләсә дә, игътибар үзәгенә хәбәрсез югалган дусларын куя, күбрәк аларны күрсәтергә тырыша, аларның әманәтен тапшырырга ашыга. Әсәрнең уңышы —менә шул кешеләргә икенче яшәеш бирүдә, алар исеменнән сүз алуда. Чөнки хәбәрсез югалганнар һәм яу кырында һәлак булганнар, җирдә фашизм яңадан баш калкытмасын өчен, көрәш сафында калалар. Алар үткәнгә түгел, бүгенге көнгә, киләчәккә төбәлгән һәм дөньяда тынычлык өчен көрәшкә, яңа буыннарны ватандарлык рухында тәрбияләүгә хезмәт итәләр.

«Яшәү белән үлем арасында» повесте — язучы иҗатындагы иң биек нокталарның берсе. Шигъри әсәрләренең дә чын кыйммәте әлеге биеклеккә нисбәтле бәһаләнә.

Язучының хәтта үткәндәге иҗатын да яңа мәгънәләре белән ачкан төсле булды повесть. Мәсәлән, шигырьләрендә дә автор шәхесенең, лирик «мин» дәрәҗәсендә генә калмыйча, фикер-хәрәкәт активлыгына ия булуы игътибарны җәлеп итте. Аның «мин»е — шәхси дөньяга кереп бикләнү чарасы түгел, ә тормыш чынбарлыгын үз күңеле аша үткәреп, укучыга якынайта торган тәрәзә икән бит. Бу тылсымлы «тәрәзә» төп игътибарны, вакыйганың үзен хәбәр итүдән бигрәк, аның турында уйлануга, аны кичерүгә юнәлтә.

Шагыйрьнең гомумиләштерүче фикере нигезенә тормыш тәҗрибәсе һәм яшәү принциплары салынган. Аңа язмышның беренче һәм авыр сынауларын нарасый бала чагында ук кичерергә туры килә. Бер-бер артлы әтисе белән әнисе дөнья куя. Бу җиһанда ач-ялангач һәм, барыннан да бигрәк, япа-ялгызы калу ачысын татыган малайның күңеле, бәлки, туган җирләреннән еракта, тамак ялы өчен көтү көтеп йөргән заманнарда ук мөлдерәп торган моң чишмәсенә әверелгәндер. Булачак шагыйрьнең холкы-фигыле Донбасстагы зур заводларның берсендә тимерче булып эшләгән чакларында ныгый, формалаша башлагандыр. Аның иҗатка омтылышы да шунда уяна, беренче язмалары татар шахтерлары өчен чыгарылган «Пролетар» газетасында басыла. Бик күп еллар үткәч, Н.Дәүли: «Тирән шахталарда кап-караңгы юллар узган бар, тормыш юлларында адашып калмаска шунда өйрәндем»,— дип язар...

Язучының гыйбрәтле язмышы, үз башыннан кичкәннәрне бәян иткәндә аеруча уңышка ирешүе өч китаптан торырга тиешле автобиографик романга керешкәч тә бик ачык күренде. (Әлеге романның «Язмышка юл» һәм «Кояшка таба» дигән ике кисәге инде укучыга барып ирешә.)

«Казан утлары» журналында «Язмышка юл» басылып чыгу белән, аның дәвамын сорап язган хатлар ява башлады. (Журнал редакциясе, үзенең эш планнарын үзгәртеп, әлеге әсәрнең икенче кисәген басарга мәҗбүр булды.) Ә бер хат эченнән язучыны балачагы үткән төбәккә чакыру килеп чыкты. Нәби Дәүли Царицын даласында үскән әрем кебек әче, әмма исерткеч хуш исле балачагына кайтып

килде. Дүрт яшендә үк аерылган туган яклары белән дә байтак сулар аккач кына күрешергә насыйп булды аңа. Сугышны, концлагерьларны кичеп кайткач, шул хакта әсәр язып танылгач кына.

Ә язучының туган ягы — Кече Чирмешән буендагы бәләкәй генә Мәүләшә авылы. Телгә, җырга кермичә, тыйнак гомер сөргән, игелекле төбәк. Нигезе — борынгы Болгар туфрагында. Биегрәк үргә менеп карасаң, Гаяз Исхакый, Абдулла Алиш, Хәсән Туфан, Салих Баттал авыллары күренер төсле. Туфрак уртак. Язмышларында да ниндидер уртаклык сизелә...

Газаплы, бәхетсез көннәрне күпме генә кичерергә туры килмәсен, Н.Дәүли үзен бәхетле кеше дип саный. Фашист тоткынлыгыннан исән кайтуы, иҗаты белән йөз меңнәрчә укучылар күңелен яулавы — язмыш елмаюы түгелмени?

Шагыйрьнең 1937 елда басылган «Бәхет» исемле беренче китабы, чыннан да, бәхетле булып чыга. Иҗатының башында ук ул зур өметләр уята һәм, Хәсән Туфан фатихасы белән, Язучылар союзына кабул ителә. Сугышка ул язучы булып китә...

Н.Дәүлинең катлаулы иҗат юлы турында уйланганда, төрле чор әсәрләре күз алдыннан үтә. Башлангыч чорда ук язылган, самими сурәтләргә, хыялга юмарт юллар... Җырга әверелгән «Чулпан», «Татарстан — минем республикам» шигырьләре... Яңа төсләр, интонацияләр белән баеган соңгы еллар лирикасы... Н.Дәүлинең балалар драматургиясе, публицистика, ниһаять, прозадагы хезмәтләре барыбызга да мәгълүм. Шулай да, иң яраткан әсәреңне сайлап ал, дисәләр, мин «Өч тамчы су турында баллада»га тукталыр идем.

...Сугыш юлы узган җирдә яралы солдат бер йотым суга тилмереп ята. Командир үз флягасында калган суны аңа бирмәкче: «Эч, туганым, һәм уйлама, аерылам, дип, дуслардан». Җылы сүз, иптәшлек тойгысы үлем белән көрәшкән сугышчыга хәл керткәндәй була, ул инде суны эчми, башка яралыларга суза... Солдат флягасы кулдан кулга күчеп, сусауны һәм йөрәкләр сызлавын басып, комбатның үзенә кире кайта. Ә анда нибары... өч кенә тамчы су булган икән! «Өч тамчы су» балладасы — җәлилчеләр язмышын тасвирлаган «Берлинда окоп» поэмасы, шагыйрь-солдат Фатих Кәрим истәлегенә багышланган «Госпитальдән хат» шигыре белән аһәңдәш. Укучыны алардагы аерым образлар, детальләр, чагыштырулар түгел, ә күңелне кузгатырлык хис һәм гыйбрәтле фикер җәлеп итә.

...Нәби Дәүлинең туган якларында язгы ташуларга мөнәсәбәтле «сыза» дигән матур бер сүз бар. Күңел сызуларын хәтерләтә ул! Бәлки, борынгыдан ук килгән төшенчәдер... Мәгәр сызасыз ташу — кайсы заманда да ташу булмаган инде!

Күз алдыгызга китерегез: язның сәгатьләп түгел, минутлап килгән чагы. Яр битләрендәге кар юешләнгән соры чабуын боз өстенә җәелгән судан ала алмый башлый. Шулай да елга-инешләр кузгалырга уйламый әле... Менә, ниһаять, таң алдыннан авылны ниндидер гөрелте уята. «Һай, сыза төшкән!» — диләр картлар. Урман-кыр суларының — сызаларның килеп әйдәвен генә көткән икән Чирмешән бозы! Шашкын-дәһшәтле, шул ук вакытта үзенең көче-кодрәте белән дә, соңыннан бушану-котылу шатлыгы алып килүе белән дә гаҗәеп матур күренеш ачыла.

Сүзне болай ерактанрак урап алып килүнең сәбәбе шул: сызалы язлар белән Н.Дәүли иҗаты арасында эчке бер уртаклык, якынлык бар сыман. Аның яшенләп-күкрәп килгән шигъри ташкыннары да шулай, әлегәчә сызыла алмый торган күңелеңне кузгата, авыр уйларыңны төбе-тамыры белән куптарып алып китә, җаныңда рәхәт-аяз иркенлек, киңлек кенә кала:

Җил тибрәтә көмеш башакларны,
Бөртек йоклый ефәк бишектә...

Катлаулы тормыш юлы узса да, шагыйрьнең күңеле суынмаган, хисләре тупасланмаган. Аның әсәрләрендә иркәләп-шаяртып, ә кайчак шактый усал һәм ачы итеп көлү дә, публицистик ачыклык та, ил-көн, табигать һәм кеше язмышы турында уйланулар да урынлы яңгырый.

Шигырь техникасы мәсьәләләрендә Н.Дәүлинең эчке каршылыклары — яңа күренешләргә ияләшеп җитә алмыйча, шикләнебрәк каравы мәгълүм. Кискен бәхәс рухы аның фикерләрен, бәлки, икенче чиккә дә алып киткәләгәндер. Әмма «төннәр буе хәреф эзләүчеләр»не тәртипкә чакыруга кадәр барып җитсә дә, бу — шигырьнең мәгънәви тирәнлеген һәм образлы яңгырашын көчәйтү юнәлешендәге иҗади эзләнүләргә каршы чыгу түгел иде. Моңа шагыйрьнең үз әсәрләре үк шаһит. Гап-

гади кабатлаулар ярдәмендә, ул Хатынь авылындагы кыңгырауның тирбәлүен генә күрсәтеп калмыйча, моңын да ишеттерергә тырыша. Яшьлегендә рәссамлыкка әзерләнгән әдип иҗатындагы төсләр уены игътибарны җәлеп итә. Прозасыннан, хәтта публицистик әсәрләреннән моңа кызыклы гына мисаллар китереп булыр иде. «Яшәү белән үлем арасында»гы доктор Василий Петровичның күзләрен хәтерлисезме? «Шырпы сүнгәч тә, ул күзләр һаман янып торалар иде кебек». Сатлыкҗан полицайның исә күзләре юк, алар — «буш тартмага уелган ярыклар» гына... Немец хатынының күзләре «ояларына ут төшкән чыпчык балалары кебек сискәнеп китә». Кыю татар кызы Нәҗия «кар суының тамчысы кебек саф» күзле булып күңелне били.

Янә шуңа игътибар итәсең: Н.Дәүли сүзләрне үзенчә сайлап ала, үзенчә тезә икән. Алар, алдагы җөмләләрнең логик дәвамы булудан бигрәк, яңа фикер учаклары булып кабыналар. Нәтиҗәдә, бу стиль — прозада булсын, шигырьдә булсын — йөрәк тибеше кебек кысылып-киңәеп торучы хәрәкәте, пульсы белән истә кала. Ялтыравык тәңкәләре белән күзне чагылдырмый, сукырайтмый ул. Киресенчә, сугышчан юлын разведчик булып башлаган шагыйрь күңел күзләребезне ачыбрак карарга, күбрәк күрергә чакыра:

Кеше гомере — олы бер тау,
Вакыт аны ватып ала,
Һәм кабергә куяр өчен
Бер кечкенә ташы кала.

...Беренче очрашудан соң инде байтак еллар үткән. Вакыт күп күренешләрне хәтердән юган, күңелдә калганнарына яңа күз белән карарга өйрәткән. Әмма язучыны якыннанрак белгән саен, аның ярым-йорты дөреслек, әзер хакыйкать белән килешмәүчән, тынгы белмәс бер җан булуы ачыла гына бара. Шушы юлда хаталанып үкенгән мәлләре, башкаларны һәм еш кына үз-үзен «уңайсыз» хәлгә куйган чаклары да бардыр, бәлки... Тынгысыз кешегә дөньяда яшәү җиңел түгел. Бу — иҗат утында януның бер рәвеше булганда, бигрәк тә. Истә әле, ул үзенең бер китабын да «Тынгысыз йорт» дип атаган иде. Гәрчә әлеге җыентыкта шундый исемдәге әсәр очрамаса да, авторның «тынгысыз йорт» итеп үзенең күңелен һәм иҗат дөньясын күз алдына китерүе ачык аңлашыла. «Юл башы» исемле поэмадагы, Такташ һәм Туфаннар «мине бу тынгысыз йортка дәштеләр», дигән юллар да нәкъ шул фикерне раслап тора.

Н.Дәүли иҗатына, аның «тынгысыз йорт»ына якынлаша башлагач, бер сәер тойгы уяна: үзеңне җиде җил чатында калгандай хис итәсең. Бу тикмәгә генә түгелдер. Биек йортлар янында һәрвакыт көчле җил-давыл булучан бит. Биек йорт җилне үз янына чакыра, диләр...

1980

## СҮЗ КАДЕРЕ

Кайт әле туган җакка бер иркенләп, җаз әле үзебезсә итеп!..

Әптери агай хатыннан

Ул вакыйганы язучының үзеннән сөйләтәсе иде! Мин шул инде хәл кадәре искә төшереп узсам гына... Ничек иде соң әле ул?..

...Шулай беркөнне Габдулла Шәрәфи дигән язучыбыз үзләренең урам чатына чыга. Бәрәңге алырга. (Шәһәрдә, үзегезгә мәгълүм, урам чатында бәрәңге сатып торулар гадәти күренеш бит инде.) Тик бу юлы бер генә төштә шактый зур чират җыелып өлгергән, һәм инде соңгы капчык төбен кагып торалар, имеш. Сатучы агайның кемгәдер: «Сайланып маташма, нәнә, бәрәңге булгас бәрәңге инде ул, шалкан түгел ис!» — дигәнен ишетмәсә, базар дигәндә кыюсызрак язучыбыз кире өенә үк кереп китәсе икән дә бит... Әмма хәзер инде: «Туктале, чү, сөйләшүе безнең Дөбъяз ягыныкы түгелме соң?!» — дип, якынрак килеп карарга тәвәккәлли. Сатучы дигәне, чынлап та, үз авылдашы — Әптери икән ләбаса! Әптерие дә аны шунда ук күреп ала, хәтта бәрәңгесеннән чиратсыз-нисез өлеш чыгара.

Эшләр болайга киткәч, Әптери дусны өеңә, чәйгә чакырмыйсыңмы соң инде! Яшьлекне, туган якларны искә төшереп, кунагын үзе үк алып килгән бәрәңге белән сыйлый язучы.

— Онытмыйсың икән элеккене. Җугыйсә, әллә ниләрең бардыр әле. Рәхмәт, җәшти, үзебезчә сыйладың, кашартмадың! — ди Әптери һәм, сүз уңаенда, «чыбык очы белән» генә суктырып та куя: — Җазганда гына менә башкача кыланасыз,—ди,— бөтенегез бер төрле җормаслыйсыз. Кемнең кайсы җусыктан, кай төбәктән икәнен дә белмәссең,— ди.

Язучыга бәрәңге генәме соң, гыйбрәт тә, илһам да алып килгән икән ләбаса Әптери! Габдулла Шәрәфи соңыннан менә шул очрашуны хикәя итеп яза. Яза да әлеге дә баягы Әптеригә җибәрә. Туктале, үзеннән укытып алыйм яшьтинең, ди. Озакламый Дөбъяз тарафларыннан менә шундый җавап килеп төшә: «Җарый инде, кыйты керис! —дип яза Әптери.— Бу җулы, исмасам, минем сүзләрне бозмагансың... Кайт әле туган җакка бер иркенләп, җаз әле үзебезсә итеп!..»

Чынлыкта әлеге хәлләр ничегрәк булгандыр, әллә аны язучы үзе генә уйлап чыгаргандырмы,—бу кадәресен әйтүе кыен. Мин дә шушы вакыйга Габдулла Шәрәфинең нәкъ менә үз башыннан кичкәндер дип расларга җөрьәт итмим... Тик шунысы хак — әлеге хикәяттә мин, чын-чынлап, язучының үз чалымнарын күрәм, аның холкын-табигатен тоям, каләмен таныйм. Әйе, ул менә шундыйрак ич: һәртөрле шау-шу, сатулашу купкан җирләрдән урап узса да, эштә-иҗатта үз сүзен, үз эзен ярып барыр; Дөбъяз ягы тумаларына хас булганча, нинди генә хәлләрдә дә ихлас күңелле, оптимист рухлы, ачык йөзле булып калыр. Әсәрләрен укыганда да, Габдулла Шәрәфинең асылда һич «кашартмый»-күпертмичә, тыныч һәм ипле тавыш белән ышандырырлык итеп сөйләп-тасвирлап килүен күрәсең. Үз әсәрендәге каһарманнарга да читтән карап, аларны салкын акыл белән күзәтеп тора алмас кебек: һәрдаим алар белән бергә, алар арасында ул.

Габдулла Шәрәфи әсәрләрен укыганда туган иң беренче тойгы... бәлки, җиңелчә генә баш әйләнүдер... Кислородка ярлы җирдән кинәт урман уртасына килеп төшкән кебегрәк... Бу темп-тизлек заманы, киеренке ритмнар шулкадәр безнең канга сеңеп бара икән; хәрәкәт-вакыйгаларның, соң дәрәҗәгә җитеп кысылган пружина сыман, бәреп-этеп җибәрәсенә исәп тотканлыктан, ахрысы, баштарак ияләшә алмый торасың: көтмәгәндә ачылып киткән киңлеккә, зур «һава» белән, иркенләп сурәтләүгә, төсләрнең сизелер-сизелмәс күчешенә...

Телбизәкләргә, төс һәм жестларга кытлык кичермәгән хәлендә, бу әсәрләрдә чачаклау-чуклау, ясалма экспрессия, ахыр килеп, әдәби алым гына икәнлеге сизелерлек дәрәҗәдәге «әвеш-тәвеш» китерүләр дә күзгә ташланмый. Әйтергә теләгәнен язучы сүз кадерен белеп, төгәл һәм ачык итеп тасвирлап бирә: «...Фляга инде иреннәр өстендә авызы белән капланып ук тора диярлек, ә суы һаман күренми. Ниһаять, солдатның бугаз төене кузгалып, кашлары селкенеп куя. Тузан кунган иягенә нечкә генә ак юл сызып су ага. Башка солдатларның да бугаз төеннәре тамак төпләрен еш-еш капшыйлар. Ләкин бу сусаудан гына түгел. Анда — йота алмаслык төер...» Тормыш дөреслегенә тугрылык, менә шулай, вакыйга-хәрәкәтне тулаем сурәтләүдә генә түгел, хәтта аерым детальләрдә,

тел үзенчәлекләрендә, сюжет-композиция гадилегендә, кыскасы, бөтен язу рәвешендә, өслүб-стилендә икән аның.

Габдулла Шәрәфи вакыйгалар агышын ничектер табигатьтәге, кеше күңелендәге һәм заман-дөнья сфераларындагы авазларга колак сала-сала бәян итә. Шунлыктан аның әсәрләрендәге күп- санлы катнашучылар арасыннан һәрберсе үзенең интонациясе, кайсыдыр бер хасияте, гамәле белән истә кала. Аларның байтагы, мәсәлән, яшь сугышчылар, солдатлар; әле күбесе узып барышлый, эпизодик рәвештә дип әйтерлек кенә күз алдыннан үтеп китә. Сарсынбаев, Соколов, «мут» Галләм... Солдат тормышы аларны, беренче карашка, тальян телләредәй охшаш иткән, һәммәсен дә бер тактага тезгән. Ләкин әсәрнең көй-агышы шундый чиста,— ул әлеге «телләр»нең һәркайсын (ягъни һәр геройның күңел кылын) аермачык, кабатланмас яңгырашы белән аерып күрсәтә. Шуңа күрә укучы һәр язмышны үзенчә кабул итә, аны башкалардан аралап, кызыксынып, кирәксенеп күзәтә башлый. Язучы әйтерсең лә әнә шулай тормыш-яшәеш эфирында гүләп торган мең төрле авазлар арасыннан иң кирәклесен генә аралап-тотып ала!

Ничек ирешә соң ул моңа? Хикмәт нәрсәдә? Уйланып йөри торгач, мин бу сорауга үземчә җавап та таптым шикелле... Габдулла Шәрәфи, билгеле булганча, ут эченә яшьли кергән буын вәкиле, фронтовик язучыларыбыз арасында ул — иң яшьләрнең берсе. Сугышның Ерак Көнчыгышыбызга капкан утын сүндерешкән солдатлар сафыннан. «Сусыз дәрья» исемле повесте белән таныш укучылар яхшы белә: Г.Шәрәфинең фронттагы һөнәре — элемтәче. Ә бәлки, менә шуннан киләдер андагы Сүзгә, Кеше язмышына аерата саклык, сизгерлек?! Элемтәче төгәл, аз сүзле, уяу һәм зирәк булырга тиеш. Аның кулында — гаять мөһим нерв җепләре. Ә бит, уйлап карасаң, яу кырындагы элемтәченең әнә шундый үтә җаваплы вазифасы белән язучылык хезмәте арасында уртаклык юкмыни?!

Яңа буыннар белән үз кордашлары арасында күңел багланышлары урнаштырырга омтылучы әлеге повестьның («Сусыз дәрья»ның) басылып чыккан вакытларын искә төшерик. Тәҗрибәсез язучының беренче күләмле әсәре генә иде әле ул. Ә шул чакта ук Габдрахман Әпсәләмов: «Исәннәр алдында да, һәлак булган солдатларның якты истәлеге алдында да аның (Габдулла Шәрәфинең) намусы чиста... Солдат тормышын шулай тулы һәм үзенчәлекле итеп сурәтләгән язмалар бездә аз әле»,— дип басым ясап әйтте. «Аның намусы чиста!» — бу танылган әдипнең яшь каләмдәшенә фатихасы һәм ифрат югары бәя бирүе иде.

Әйе, «Сусыз дәрья» укучыны кабатланмас материалы, мавыктыргыч вакыйгалары белән генә түгел, эчке моңы, мәгънәле гомумиләштерүләре белән дә җәлеп итә. Ләкин бит ул — Габдулла Шәрәфине язучы итеп таныткан бу повесть — үтә документаль нигезле; белгәнебезчә, анда хәтта геройларның исемнәре дә үзгәртелмичә алынган! Сугыш хакыйкатен тасвирлауда фронтовик-кордашлар һәм яшь буын алдында үзен бердәй җаваплы тою — чыннан да, нәкъ менә шушы сыйфат язучыга тормыш чынбарлыгын әдәби чынбарлыкка әверелдерергә ярдәм иткән, әсәрнең җитди яңгырашын билгеләгән булырга тиеш. Гомеренең кискен борылышлары аны кеше кадерен һәм сүз кадерен белергә өйрәткән.

Кеше язмышына җаваплы-сизгер мөнәсәбәттә булу, бүтәннәрнең уй-фикеренә, хис-кичерешләренә зур ихтирам, илтифат белән карау алга таба да язучының иҗатында, бигрәк тә балалар һәм үсмерләргә багышланган әсәрләрендә, шулай ук каләмдәшләре хакындагы истәлек һәм мәкаләләрендә нык тоелып-сизелеп бара. Әйтик, Габдрахман Әпсәләмов һәм Сөббух Рәфыйков яисә Рафаил Төхфәтуллин һәм Барлас Камалов иҗаты турындагы җыйнак кына язмаларны укып карагыз,— әлеге әдипләрнең күпләр күзенә чалынмаган әллә нинди сыйфатлары, чалымнары ачылып китәр. Ә мохитне, әйләнә-тирәбездәге гармонияне генә түгел, кеше табигатендәге матурлыкны да сакларга чакыру авазы булып яңгыраган «Аккошлар кайтыр әле», яшь укучыларның күңелен чын-чынлап «ефәк җеп белән» үзенә бәйләп барган «Күрше малае» повестьлары, ниһаять, җор һәм гыйбрәтле хикәяләр! Аларда никадәр җылылык һәм кешелеклелек! Бу әсәрләр — күтәрелгән мәсьәләләренең олылыгын, кайнарлыгын кеше күңеле аша ачарга омтылу мисаллары.

Бу урында инде Габдулла Шәрәфине ни өчен тәнкыйтьләгәннәрен дә әйтми хәл юк. Шулай шул, аз яза дип «орышалар» аны. Аннары, яшерен-батырын түгел, тасвир-сурәтләрне һәм вакыйгаларны да «пикантныйрак» — «тозлырак-борычлырак» итәргә чакыргалап торалар. Бигрәк тә «Сусыз дәрья» мөнәсәбәтеннән шундый теләкләр әйтелгән иде. Каләмдәшләре һәм укучылары фикеренә һәрчак колак салган хәлдә, мондыйрак төр киңәшчеләргә үзенең бер мәкаләсендә язучы өлешчә җавап та

бирде кебек: «Сугыш ул — халыклар тормышында иң зур сынау. Вакыйгасын да, баш әйләндергеч мажараларын да уйлап чыгарасы түгел, барысы да үзендә...»,— дип язды ул.

Сугышны күргән, бай тәэссоратлы журналист сукмаклары буйлап үткән язучының, әлбәттә, замандашларыбызга әйтер сүзе аз түгел. Иҗатта активрак, тәвәккәлрәк булу моны раслый гына төшәр иде... Әмма Габдулла Шәрәфинең чыннан да чагыштырмача азрак язуы, бәлки, үз-үзенә артык таләпчәнлек, олы җаваплылык хисе белән бәйледер? Моның шулай ук башка сәбәпләре дә булуы ихтимал... Хәлбуки... язучы өчен иң мөһиме алар түгел, минемчә.

Һәр очракта да каләм белән кәгазь, тормыш белән әдәби әсәр арасындагы биек бусаганы истән чыгармаска кирәк. Анда бит әнә язучыга һәрвакыт теләктәш һәм таләпчән булган агай-эне укучы үзе тора. Ә бу юлы ул безнең иске танышыбыз — «Дәгъва» исемле хикәядәге Әптери сурәтенә керә һәм: «Рәхмәт, җәшти. Кашартмыйсың әлегә. Алга таба да тушылай җаз!» — ди сыман...

1986

# ЧЫНЛЫККА ОМТЫЛУ

В.Нуруллин үз геройларын яраттыра белә, яраттыруның серен, әмәлен белә.

Фәрваз Миңнуллин

Яшел чирәм белән капланган иске чокырлар һәр авыл читендә диярлек бар. Ташланган нигез урыннары гына түгел, алар — сугыш елларында казылган окоп эзләре. Халкыбызның Бөек Җиңүгә ышанычы ерак тылдагы әлеге окоплардан да калкып чыккандыр төсле. Дәһшәтле еллар авырлыгын үсмер иңнәрендә күтәргән буыннар — «шинельсез солдатлар» яшьлеге дә җирнең әнә шул иске яраларына охшаган.

Сугыш чоры балаларының бик табигый һәм самими, шул ук вакытта гадәттән тыш җитди кичерешләре, гыйбрәтле язмышы онытылырга тиеш түгел. Алар, барыннан да бигрәк, сугыштан соң туган һәм туачак яшьләр өчен кирәк. Шуңа күрә ул буын язучыларын — А.Гыйләҗев, Ә.Баянов, М.Мәһдиевләрне иң әүвәл үз кордашларының аманәтен үтәү миссиясе мәйданга алып чыккандыр кебек. Язу рәвешләре белән бер-берсеннән бик нык аерылып торсалар да, язмышларына Бөек Ватан сугышы баскан уртак мөһер якынайта аларны. Геройлары төрле-төрле булса да, асылда — бер чор, бер буын вәкилләре, шул буынның әхлакый йөзен билгеләүче кешеләр. Димәк, ул әсәрдәге уртаклыкның нигезе — тема якынлыгы гына түгел, аларда тергезелгән тормыш дөреслеге, кешелекле юнәлеш берлеге, тормыш сөючән рух бөтенлеге.

Минем яшьтәшләрем өчен бу әсәрләр — әниләребезнең бик иртә агарган чәчләре һәм авылларыбыз читендәге окоп эзләренең телгә килүе кебек. Ул буын көйгән икмәк төсле балачагы, сөялле куллары белән хәтергә уелып кала.

Сугыш елларындагы авыл хакында язылган әсәрләрнең күбесен әнә шундый сыйфатлар берләштерә. Биредә аларның һәммәсен дә атап-санап чыгу максат итеп куелмый. Ләкин тагын бер автор, тагын бер әсәр, һичшиксез, телгә алынырга лаек. Һәм сүз сөрешенең алга таба әлеге язучы турында барасына бәйле рәвештә генә түгел. Киресенчә, язучының бүген игътибар үзәгенә куелуы үзе нәкъ менә шул беренче әсәре белән үк укучыларын тапканга, тәнкыйтьтә дә «боз кузгалу» дип югары бәя алганга күрәдер әле. Әлеге беренче табышларын үстерү нәтиҗәсендә иҗатының матур дәвамына ирешкәнгә күрәдер.

Сүз Вакыйф Нуруллинның «Шинельсез солдатлар» дигән повесте турында бара. Бу әсәр «безнең прозада яңа этап башлануы — «боз кузгалуы» хакында сөйли»,— дип, үз вакытында Рафаэль Мостафин язып чыккан иде.

«Шинельсез солдатлар» — авыр сынаулар басымына ахыргача түзә алмаган яшь хатын фаҗигасен ачкан повесть. Язучы төгәл һәм тыйнак буяулар белән сугыш чорының драматик тормышын тасвирлый. Шул ук вакытта әсәрнең мәгънәви офыгы, перспективасы киңрәк: ул күпчелек геройларының әхлакый сафлыгы, фидакарьлеге һәм рухи ныклыгына таяна.

«Шинельсез солдатлар» — беренче карашка, балачак турында хикәят. Әмма ул, «балалар әдәбияты» дигән булып, ниндидер өстенлек-льготалардан файдаланырга тырыша торган әсәр түгел. Аның яшь геройларына уен гына түгел, уку да авырлык белән эләгә. Бик иртә җитдиләнергә, тәртә арасына керергә туры килә аларга.

Язучы дөньяның сабыйларча бөтенлеге белән тормыш авырлыгын Равил исемле үзәк герое күңелендә кисештерә. Вакыйгаларга алты-җиде яшьлек малай күзе белән карауның отышлы яклары һәм үз кыенлыклары бар.

В.Нуруллинның үз балачагы да, төрле әсәрләрендә сүз алган яшь геройлары — Равил һәм Сафиуллаларныкы кебек үк, сугыш елларына туры килә. Кама буе болыннарында ат көтеп, колхоз эшенә йөреп үсә. Зур кыенлык белән белем ала. Язмыш уртаклыгы белән генә түгел, үзенең холкыфигыле белән дә ихлас күңелле, төпле-җитди, эшкә батыр геройларына охшаган бугай ул. Моның өстенә, язучы буларак тагын бер бәхетле сыйфатка ия — ул үз тормышы белән генә яшәми, укучы күңелендә калырлык геройлары булып та яшәү хокукы ала. Шунлыктан биографик хатирәләргә таяну аның өчен үзмаксат дәрәҗәсендә калмыйча, шәхеснең рухи дөньясын, әхлакый асылын өйрәнү алымнарыннан берсе — иң беренчесе булып аңлашыла.

Бу үзенчәлек «Әгәр син булмасаң...» повестенда бигрәк тә ачык күренә. Кырык-илле ел элек барган вакыйгаларның мәгънәсе, әһәмияте сугыштан соң туган буын укучыларын дулкынландыра ала икән, моның сере дә беркадәр шунда — авторның үз яшьлегенә бүгенге акыл белән, дәвамлы хәрәкәтнең, зур тормышның җанлы кисәге итеп карый алуындадыр. Шуңа күрә «Шинельсез солдатлар»ның да, «Әгәр син булмасаң...»ның да тормышчан пафосы тирән сагыш белән өртелгән. Әмма бу — якты сагыш. Газиз кешеләреңне, кадерле хисләреңне сагынып сагышлану. Ул укучыны сафлыкка, пакьлеккә, яшәеш һәм рух чишмәләребез башланган нигезгә алып кайта.

«Аккан су юлын табар» дигән повестегызны укып, чын мәгънәсендә рәхәтлек, хозурлык кичердем... Минем башыма хәтта: «Автор әллә үзе колхоз җитәкчесе булып эшләдеме икән?» дигән уй килде». Бу хат үз вакытында «Социалистик Татарстан» газетасында басылып чыккан иде.

Авылның тарихи язмышын нечкә тою — гомумән, безнең әдәбиятның ачык бер үзенчәлеге. Шулай да әсәрләребездә күренгән колхоз председательләре, уенын-чынын бергә кушып әйткәндә, кечерәк бер районның бөтен хуҗалыкларын тәэмин итәрлек санга җитеп килә бугай. Ниһаять, санның сыйфатка күчүенә дә өметләнергә буладыр...

А.Расихның «Язгы авазлар», С.Рәфыйковның «Авыл иртәсе» романнарында үзәккә алынган мәсьәләләр соңрак Г.Ахуновның «Чикләвек төше», Х.Хәйруллинның «Канатлар талмасын» повестьларында һ.б. әсәрләрдә яктыртылды. Тик шунысы да бар: хуҗалык итү проблемаларын күтәргән китапларда вакыт агышы аеруча ачык сизелә һәм аларга карата ара-тирә «кичәге авыл», «кичәге җитәкче» дип канәгатьсезлек белдерелүе дә тикмәгә генә түгел.

В.Нуруллинның «Күпер чыкканда» повестендагы Өлфәт Хәкимов, «Чикләвек төше»ндәге Халик Саматов кебек үк, илленче елларда буын ныгыткан председатель. Аларның икесенә дә кыюлык һәм эшлеклелек хас, икесе дә төрле каршылыкларны җиңеп, авылның тормыш хәлен яхшырту өчен тырышалар. Шул ук вакытта бу геройларның иҗтимагый һәм шәхси тормышын сурәтләү нисбәте төрлечә булуы да мәгълүм. Гаилә мәшәкатьләренә баш бирми торганрак булып күренгән «дәүләт кешесе» Саматов белән чагыштырганда, Өлфәт күбрәк мәхәббәт һәм кешелеклелек мөнәсәбәтләрендә ачыла. Ләкин аларны бер-берсенә каршы кую урынлы булырмы икән?

Билгеле, «Күпер чыкканда» әсәрендә әхлакый әһәмияткә ия булган темалар белән авыл хуҗалыгы проблемалары бергә үрелеп бара. Шунлыктан, Өлфәткә карата «кичәге председатель» дигән сүзләр ул хәл итәргә алынган күп кенә мәсьәләләрнең инде көн тәртибеннән төшеп баруын аңлата булса кирәк. Мондый искәртүне кайбер укучыларыннан да ишетү язучыга тәэсир итми калмаган, ахрысы. «Аккан су юлын табар» исемле повестен ул, ниндидер гөнаһысын таныган сыман: «Әнә шул иптәшләрнең теләкләрен истә тотып, шуларга җавап йөзеннән яздым»,— дип тәкъдим итәргә карар кылды. Бусы — бер хәл. Тик менә җитмешенче елны язылган «Күпер чыкканда» әсәреннән соң авыл тормышында зур үзгәрешләр булды, «элекке җиде-ун класс белемле җитәкчеләр урынына махсус югары белем алган, яшь энергияле иптәшләр килде» дигән фикергә ышануы, аны «йотып җибәрүе» инде шактый кыен. Андый кискен үзгәреш җитмешенче елдан соң гына булгандыр дип тә ышаныйк. Ул чакта яңа повестька герой итеп 24 ел председательлек иткән, шул ук Өлфәттән өч-дүрт яшькә генә кече булган Булат Вәлиевне алу акланамы? Әллә гомуми чалымнары гына сурәтләнгән яшь агроном Фәгыйт яңа буын җитәкчесе булып күз алдына басамы? Кыскасы, бу ике әсәрне, гәрчә икесенең дә төп каһарманнары колхоз җитәкчесе булса да, вакыт-чор ягыннан бер-берсенең дәвамы итеп карарга сәбәп юк. Өлфәт белән Булатның характер үсешендә дә, җитди сынауларны кичеп, колхозда абруйлы хуҗа булып җитлегү процессында да эчке бер уртаклык сизелә. Алар шактый еллар буе ызандаш колхозларны бергә-бергә җитәкләгән председательләр сыманрак хәтердә кала. Әмма «Аккан су юлын табар» повесте һәм аның герое язучының үз иҗатында гына түгел, гомумән, прозабыз үсешендә игътибарга лаек вакыйга буларак кабул ителде. Моның сәбәбе нәрсәдә соң?

«Аккан су юлын табар»ның яңалыгы яңа авыл, яңа проблемаларда гына түгел. Аның герое — хуҗаларча һәрьяклап һәм колачлы итеп фикерләргә өйрәнгән кеше, ул зур максатлар, җитди уйлар белән яши, кешеләр арасында намуслы мөнәсәбәтләр өчен көрәшә. Безнең өчен аның менә шундый әхлакый позициясе аеруча мөһим. Әсәрдәге төп конфликт та шул нигездә барлыкка килә, һәрвакыт шәхси мәнфәгатьләрен генә алга сөргән кара эчле Шәйхи белән булган каршылык үскәннән-үсә

барып, яшәү максатлары һәм принциплары арасындагы килешмәүчән конфликтка әверелә. Повесть язучының осталыгы тагын да арта төшүен, геройларның табигый үсешен эзлеклерәк күзәтә алуын, характерлар чынлыгына ирешүен күрсәтте.

Булат,— Өлфәт кебек үк кичәге фронтовик, язучының бөтен геройларына хас булганча әзрәк беркатлырак, ләкин үз сүзен итә торган, кыю һәм намуслы кеше. Шул ук вакытта, ул коеп куйган фәрештә итеп тә сурәтләнми. Укучы Булатка ышана һәм аның кайвакыт каушап калуын, беркатлылыгы белән кайбер хаталар җибәрүен дә кичерә, аңа чын күңелдән теләктәшлек күрсәтә. Димәк, язучы үз героен алдан билгеләп куелган кысаларда гына тасвирлаудан котыла алган. Катлаулы мөнәсәбәтләр бәрелешендә Булатның характеры ныгый, ул, аккан су шикелле бормалы юл үтеп булса да, үзенең төп үзәнен таба. Булат Вәлиев председательлек дилбегәсен үз кулында тоткан егерме дүрт ел эчендә колхоз авылы бик күп мәсьәләләрне хәл итә, зур үзгәрешләр кичерә. Шул җирлектә, әсәр үзәгеннән бик мөһим бер нерв җепселе булып, заманча эш-идарә стиле, җитәкче һәм халык мөнәсәбәтләре турында уйланулар сузыла.

Мәгәр әлеге дә баягы «автордан» әйтелгән сүзгә әйләнеп кайтсак, бу проблемалар янә дә «кичәге» булып чыкмасмы соң?

Әдәби әсәрләребездә бүген авыл чынбарлыгын, аның типик характерларын, заманча хуҗалык итү принципларын күрәсе килү,— әлбәттә, бик табигый һәм урынлы теләк. Шул ук вакытта көн кадагына сугучы темага алыну язучыдан зур кыюлык һәм намуслылык таләп итә. Ул таләпләр үтәлмәгәндә, оперативлык күрсәткән булып халтура тәкъдим итүчеләргә дә, әсәремне язып бетергәнче бу кампания үтеп китмәс микән, дип борчылучы кәсепчеләргә дә юл ачыла. Автор бер көнлек проблемалар белән мавыккан арада (ашлама мәсьәләсеме ул яки зур төзелешкә киткән яшьләр турында фәлсәфәме), тормыш аларны үзе хәл итеп өлгерә, кичәге геройлар яңа мөнәсәбәтләргә керәләр. Алар шул әсәрдә генә фоторәсемдәге кебек тынсыз-өнсез калырга мөмкин.

«Күпер чыкканда» һәм «Аккан су юлын табар» повестьларын укыганда, күңелгә әнә шундый уйлар килә. Колхоз җирлегендә туган кайбер көндәлек мәсьәләләр, бигрәк тә аларның бердәнбер чишелеше белән укучы алдына ачып салынганнары, әлбәттә, кәгазьгә төшкәндә үк «кичәге» булырга өлгерә. Иске көн кадагына сугып утыручы геройларны яңа силос манаралары фонында тасвирлау гына коткармаячак. Ә менә «Күпер чыкканда» әсәрендәге Өлфәтнең рәхимсез вөҗдан газабы, «Аккан су юлын табар» әсәрендәге тормыш позицияләренең килешмәүчән бәрелеше кебек әхлакый коллизияләр исә әле яңа буын укучыларын да дулкынландырыр дип өметләнергә була. Шуңа күрә, әлеге әсәрләрнең декорацияләре, хуҗалык мәсьәләләре күбрәк кичәге авылга караса да, Өлфәт һәм, бигрәк тә, Булат — кичәге көн геройлары түгел. Аларның кешелеклелек дигән олы хакыйкатьне яклаган гыйбрәтле язмышы яңа буын укучылар күңелендә яшәргә хокук ала.

«Шинельсез солдатлар»да һәм башка әсәрләрендә дә урын алган хикәяләү рәвеше — вакыйгаларны төп геройларның үзләреннән сөйләтү алымы — В.Нуруллинны һәм аның укучысын ялыктырмый. Язучыны лирик «мин» исеменнән сүз алырга нинди эчке ихтыяҗ һәм максатлар юнәлтә торгандыр — кистереп кенә билгеләве кыен. Моның, бүгенге поэзиядә лирик башлангыч көчәйгән кебек, укучы белән күзгә-күз калырга, аңа турыдан-туры мөрәҗәгать итәргә, аның ышанычын яуларга омтылу билгесе булуы да бар. Бәлки ул, вакыйгаларны сөйләп кенә чыгуга караганда, хикәяләүче герой артына «яшеренеп», аларга мөнәсәбәтеңне белдерү мөһимрәк, дигән караштан килеп чыгадыр. Тыштан гына гади тоелган бу алым — автор өчен дә, әсәр геройлары өчен дә катлаулы мәсьәлә: чама тойгысын югалтма, укучыны җәлеп ит, ышандыр, уйландыр. Күңелгә ятышып бетмәгән очракларның барысы да әнә шул гадилеккә, чынлыкка ышанып җитмичәрәк караудан түгелме икән?

Ләкин, асылда, язучы үз максатына ирешә, дип әйтү хата булмас: автобиографик нигездә язылган әсәрләреннән соң да ул геройларның күңеленә үтеп керү, аларның тормышы белән яшәү осталыгына ия булуын күрсәтте. «Сүз башы урынына», «автордан» дигән кереш сүзләр дә өстәмә бизәк кенә булып калмый, аларның максаты — әсәрләрдә чагылган язмышларны укучыга тагын да аңлаешлырак, тагын да якынрак итү. Әдәби модаларга иярмичә, авылның үзе кебек табигыйлеккә, сюжет һәм стиль гадилегенә ирешүнең нигезендә исә тынгысыз иҗади эзләнүләр ята.

Җиңел түгел Вакыйф Нуруллинга. Башкалар инде азмы-күпме кагылган темалар белән эш итә — үз сүзен әйтү җиңел түгел. Асылда традицион сурәтләү һәм анализ алымнарына таяна — үз тавышын ишеттерү җиңел түгел.

Аңа бер генә юл кала — кичерешләр чынлыгына, мәгънә яңалыгына омтылу. Сүз-яңгыраш төгәллегенә ирешү һәм үзенең фикерләү ритм-интонациясенә укучысын да буйсындыру. Безнең күңелләргә юл тапкан китаплары әдипнең әнә шул авыр, катлаулы бурычны нигездә башкарып чыга алуы турында сөйли. Аның һәр әсәрен бербөтен итеп туплаган көч — лиризм, документаль төгәллек белән сәнгатьчә гомумиләштерүнең бергә үрелүендә, автор шәхесенең эзлекле һәм максатчан булуында.

Ерак тылдагы окоплар да Җиңү көнен якынайтышкан кебек, аерым кешеләр язмышы аша язучы буыннар язмышына, халык язмышына алып чыга.

1981

## ХӘЙРЕТДИН АГАЙ ЧАҢ КАГА...

Ике башыннан да яна торган шәм мин...

Аяз Гыйләҗев

……Таныш тойгы: биек йорт-
ларын киң колачы белән ике якка тутырып ачып куйган зур проспекттан атлый башлауга, сулышларың иркенәеп, үзең буйга калкып киткән төсле буласың. Югыйсә инде баштан бүрек очып төшәрлек биеклек каршында кечерәеп, мескенләнеп калырга тиешсең кебек. Юк икән! Чын мәгънәсендә зур, хозур, горур мохит үзе белән бергә адәм баласын да үстерә —күңеленә киңлек, рухына илаһилык өсти икән!

Без шушы халәтне әдәбият урамнары буйлап үткәндә дә кичерәбез. Андагы «проспект» һәм «бульвар»ларда, тар «урам»нарда һәм «тыкрык»ларда йөргәндә...… Тын урамнарның, күләгәле тыкрыкларның кабатланмас ямен күрә-күрә, без барыбер әнә шул — кешене калкурак итә торган, заман җилләренә ачык, киң һәм иркен проспектларга таба атлыйбыз. Тагын да төгәлрәк итеп әйтсәк, бүген уйларыбыз безне Аяз Гыйләҗев «проспекты»на әйди.

Бу исем укучыга «Урамнар артында яшел болын» дигән романы, күпсанлы повестьлары һәм сәхнә әсәрләре аша таныш. Бу исем укучыга әлеге әсәрләрнең катлаулы һәм каршылыклы геройлары, шул геройларның тормыш агышын, күңел хәрәкәтен билгеле бер үзәнгә бөтереп салган чынбарлыгы белән якын.

Әйтелгәннәрне дәлилләү өчен, А.Гыйләҗевның соңгы елларда иҗат ителгән ике әсәренә игътибар итик — «Җомга көн кич белән...» һәм «Әтәч менгән читәнгә» повестьларына. Аларның һәр икесендә А.Гыйләҗев үзенә тугрылыклы булып кала: геройларын, бигрәк тә үз рухына якын геройларын, авыр сынаулар аша кичәргә мәҗбүр итә, һәм үзе үк, шушы сынаулардан алар саф көе чыга күрсеннәр иде дип, бөтен сулышы белән теләп-борчылып тора. Һәр ике повестьта да язучының фикер сөреше җирдән — һәркайсыбызга якын иң гади төшенчәләрдән башланып китә, алга таба да аның хис-сурәт стихиясе шушы туфрактан аерылмый, ләкин, тора-бара, әсәрнең кайсыдыр бер өлешендә, көтмәгәндә генә укучыга үз-үзен искә төшереп, үз тормышына кайту мөмкинлеге бирелә: аһ, безнең инде рухыбыз җирдән күтәрелеп киткән, ул инде тыелгысыз төстә аяз күккә ашкына, дөнья, заман, көн агышына гына түгел, үз яшәешеңә дә бөтенләй башка күзләр белән карау зарурияте даулый...

Алга таба сүз күбрәк «Әтәч менгән читәнгә» повесте турында барса да, һәр ике әсәрнең тышкы тукымасында ук бер уртаклык булуын искә алып китәргә тиешбез. Ул — кан кардәшләр, иң якын кешеләр арасындагы каршылык, әлеге каршылыкның бәхәс һәм көрәшкә әверелеп китүе. Хәтерлисездер: бер-берсенә капма-каршы игезәкләр — Бибинур белән Зөһрәбану конфликты, Бибинурның, ана буларак, игелексез балалары белән, Җиһангирның — үз гаиләсе белән, Галикәй картның шулай ук үз балалары белән аңлашып җитә алмаулары, ниһаять, байлык өчен ярышта туганлыкларын оныткан Мирфатыйх белән Сәләхетдин арасындагы мөнәсәбәтләр...— берсе дә очраклы түгел. Үзара инкарь итешү яисә бер якның икенчесен рәнҗетүе нәкъ менә бер «тал тамырлары» арасында булуы белән аянычлы, бәгырьгә төшәрлек дәрәҗәдә кызганыч.

«Әтәч менгән читәнгә» повестендагы Мирфатыйх белән Сәләхетдин гаиләләре арасында булган хәлләр, мәсәлән, асылда — әсәрнең өске катламы гына. Ул вакыйгаларның тышкы азарты, бәйге характеры, телевидениедән спорт ярышларын, «гол ситуацияләрен» күрсәткән шикелле, төрле ракурстан, кайта-кайта тасвирланулары белән дә ассызыклана. Автор, гадәтенчә, биредә дә киеренке коллизия тәкъдим итә: тормышның нигезен — бер гаилә, бер тамыр кешеләре арасындагы бәйләнешләр ныклыгын сынаудан башлый. Гайре табигый күренеш — туганнар, якыннар конфликты аша вөҗдан һәм хәтер кебек проблемалар бөтен кискенлеге белән ачыла.

...Бу ни хәл, ни булган бу кешеләргә?! Хан сарае кебек өйләр кору гына җитми, нәфесләре — икешәр-өчәр нигез урынын биләп алу. Якты көнгә сөенеп, Ходай биргәненә шөкер итеп яшисе урында, күзләрен комсызлык һәм көнчелек уты әчеттерә, йөрәкләрен битарафлык мае баскан. Күрше белән күрше генә түгел, туган белән туган аңлаша алмый...

Төрмә диварыдай читән-койма белән бүленгән йортларга «мал җене» ияләшкәнме әллә? Күршеләр күңелендә уйнаган пәри туен да шул кузгатканмы?.. Әнә бит, берсен фермадан урлап кайткач, Мирфатыйхлар сыеры игез бозаулы булган, йомры башлы Сәләхетдин исә кыяр түтәлләрендә «акча» үстерә. Кыяр димәктән, тормыш тоткасы гына түгел, ут күршеләрне кан дошманына әйләндерерлек «яшел иблис» тә икән бит ул. Ирек куйсаң! Ике арадагы иң соңгы бәрелешнең бүтән бер сәбәбе дә юктыр шикелле. Шул гына — Сәләхетдиннең кыяр түтәлләренә трубадан аккан суның килеп җитмәве генә харап итә. Анысы да, Мирфатыйх йортында су кадерен белсәләр, бик җитәр иде, бәлки... Шуны аңлашырга дип очрашкан җирдән, Сәләхетдиннең карт сөяге шартлап сынып чыга. Чәчләре агарган кордашларның кайчандыр җан дуслар булуына ышанасы да килми, бергә яр сөйгән, матур тормыш корып җибәргән заманнарын әллә инде онытып ук бетергәннәр...

Ни булган бу күршеләргә? Аларны читән-баррикадалар артына постырырлык нинди җилләр искән югары очта? Гомернең кайсы төшендә ике йорт арасыннан «кара мәче» үткән? Сораулар күп, сораулар четерекле. Аларга җавап эзләп, тирәндәрәк яткан катламнарга, шул катламнарда күмелеп калган тарихка күз саласы килә.

Этле-мәчеле яшәүче күршеләр, бүгенге мещаннар тормышыннан кәмитләрнең тормыш сәхнәсендә дә, театрларда да уйналып торган көне. Кешене «ябыкмы, әллә симезме» дип кенә бәяләүче Гөлбикәләр, кунакта тешләгән шикәрен дә кулъяулыгына төреп кайтучы Сәләхетдиннәр дә баштарак шушындый фельетон геройлары булып тоела. Ләкин боларның кыланмышлары бик җитди, акча санагандагы кебек ерылган авызлары ачуны китерә, күңелне болгата. Нинди туфракта шыткан «чүп үләннәр» болар?

Ни дисәң дә, безгә таныш йөзләр, таныш хәлләр. Үз гаиләбездәге рухи гарипләр, үз тормышыбыздагы көндәлек маҗаралар. Сорауларны да тормыш үзе куя. Гыйбрәтле вакыйгалар, тормышчан әсәрләр аша һәркайсыбызга ишетелерлек итеп куела ул сораулар. Җавабын исә безгә бергәләп эзлисе. Сәләхетдиннәргә, тирә-юнебезгә күзне ачыбрак карыйсы, намусыбыз белән күзгә-күз каласы.

— Әгәр без яшәргә өйрәнмәсәк, тук корсак колларына бик тиз әйләнәчәкбез! — дип, «Җомга көн кич белән...» әсәренең герое Җиһангир Сәфәргалин «Өтәч менгән читәнгә» әсәрендәге Сәләхетдиннәрне кисәтә кебек. Чөнки бу соңгыларының күңел җылысын югалта бару исәбенә җыелган малы — үзләренә үзләре үк казыган чокыр. Ул зурайган, тирәнәйгән саен (байлык арткан саен) хәтәррәк була бара. Әйләнештәге акча алтын запасы белән тәэмин ителгән кебек, муллыкка ирешә барган бер чорда кешенең материаль мөмкинлекләре рухи хәзинәсендәге байлык белән ныгытылганда гына чын бәхеткә илтә.

«Сәләхетдин бик ерактан башлаган». Аның үз тирәсендәге кешеләр белән кулга-кул тотынышып мескенлеккә тәгәрәү тарихын бөртекләп, инә күзеннән үткәреп өйрәнү өчен нибары ике көн вакыт бирелгән. Ләкин бу шундый ике көн,— моннан соң, һичшиксез, нәрсәдер җимерелергә, нәрсәдер яңабаштан төзелергә тиеш. Шулай да «сәләхетдинлек»нең әле үткәне бар, өзелеп бетмәгән тамырлары бар. Ул әлегә әнә шул тамырларына ябышып күтәрелергә азаплана.

Сәләхетдин белән Мирфатыйхны «яшьлек дуслары» дидек, хатыннарының да сердәш-ахирәт булып йөргән чакларын искә төшерергә мөмкин. Күр әле, яшьлекләрендә матур булган икән бит бу кешеләр! Соң бүген боларның балалары нигә шулай кылана?

Арага дошманлык кергәнче ике йортны бер итеп йөриләр, әлбәттә. Аннан соң да әле берсенең кызы белән икенчесенең малаен дуслык җепләре бәйли. Иң олылары — Мидхәт белән Хәйдәр дә техникумда укыганда үзара килешкәндәй булалар. Авылга кайткач кына, «биек читән» аларның икесен ике якка бүлеп куя. Нәтиҗә озак көттерми: башта тәмам җимерелеп беткәнче трактор сөзештерәләр малайлар, аннары, берничә ел үтеп, кеше рәтенә керә башлагач, машина узыштырып адәм рисвае булалар.

Бу гаиләләрдә тагын ике «яшь этәч» — үртәшкәндә үк әниләре сүзен сөйләүче Әнәс белән Зәйтүн үсеп килә. Әлегә борын аслары юеш булса да, аларның киләчәкләре бүгеннән абайланып тора, шуңа күрә дә аерым бер борчылу уята... Башкалардан өстен булу хисе белән ләззәтләнеп яшәүче Фирүзәкәй тора-бара ниләр кырыр? Сизгер борынлы Вәзилә апасы юлыннан китмәсме? Ни генә булса да, боларның төп мәсләге ачык: Сәләхетдин утарында «өйгә!» дигән юнәлеш килеш кенә бар. Әти-әниләренең бөтен сүзе шул юнәлешкә генә буйсына: «Җиңелгәнне җиңгә тагалар — бирешмә!», «Юмартлык — даны олы, кабыргасы коры...» Сәләхетдиннең үз фразеологиясе, үз педагогикасы. Аның уенча, мәктәптә дөнья көтәргә яраклы бер генә фән укыталар, ул да булса — санау фәне: «Калган кирәкле фәннәрне мин сезгә үзем үрәтәм»,— дип вәгъдә итә ул. Инде менә иң олы малае беренче җимешләрен китерә башлаган: «шабашкада» эшли дә уч тутырып акча ала, сазаган булса да, «Жигули»е яңа кызга өйләнергә йөри. Күрше Мирфатыйх малае —«кәгеп алса, кызлар янында һәм базарда гел русча сөйләшә» башлаучы Мидхәт тә шундыйрак сабак-тәрбия алып үскәндер, ахрысы. Шактый киң юлда очрашып, бер-берсенә баш бирми егетләр. Лимон кебек сары «Жигули» белән чия төсле «Москвич» шул узыш вакытында җимерелеп эштән чыга. Маңгайлар күгәрә, йөзләре ямьшәя, кул сына. Тик күңелдә мескен хәлгә калган бу ертлачларны кызгану хисе тумый. Дөреслекне эзләгәндә ямьсез күренешләрнең дә көлкеле ягы ачыла икән. Әмма авыз ерылмый, көлеп булмый, көлеп туелган. Күрәсең, кеше көлкесенә калу шундый буладыр инде ул.

Ни өчен жәл түгел соң бу кешеләр?

Беренче карашка битараф-салкын гына тоелган «белешмә»ләрдән, «аналарының күңел пәрдәсен күтәреп карау»лардан башлап, шактый ук рәхимсез, фаш итүче интонация безне дөрес юлдан алып кереп китә. Гөлмәрьямнең күңеле шулкадәр мүкләнгән, аңа Мирфатыйхы белән Сәләхетдин уртак сүз табып килешә башлаганда да каяндыр килгән артистлар сөйләшә кебек тоела, ул инде ире эшне судка җибәрмәс өчен генә шулай тырыша дип уйлый. Гөлбикәсе исә «кияүгә чыгам» дип хәбәр иткән кызына «егетең ябыкмы, симезме?» дип телеграмма суктырган, имеш... Болары әле «баласы» гына — бик өстә яткан, бөтен авылга билгеле мөнәсәбәтләр генә. Тышкы битарафлык артында таш бәгырьлелеккә, миһербансызлыкка, рухи хәерчелеккә йөз тоткан кайбер яшь кешеләр дә күзгә чалына. Шул ук Вәзилә инде, мәсәлән, бөтен дөнья малын үз абзарына җыеп ябарга тырышучы ата-анасы сукмагыннан баручы түгел. Ул азмы-күпме укыган кеше, ике гаилә арасындагы дошманлыкка да шактый эче поша аның, авылның күләгәле якларын да үз җилкәсендә татый («О, ужас! кыргыйлар!..»). Мәгәр кызның тизрәк рәхәткә чумасы килә, аның планнары зурдан, ул планнар асылда шәһәр белән бәйле. Хәер, карурмандагы ялгыз йортта тереклек итәргә дә риза ул. Бары кешеләр арасында яшәргә генә туры килмәсен!

Шулай. Кешеләрдән ваз кичү, кешелеклелекне җую юллары күптөрле. Шул сыйфаттан мәхрүм калып барган адәмнәр фаҗигасенең сәбәпләре дә төрлечә булырга тиеш.

Ни булган соң бу бәндәләргә? Бәлки, чынлап та, көнчелек, мал шаукымы кагылып гарипләндергәндер аларны? Исерек малайлары машина узыштырганчы ук, ап-аек баштан, ике йорт арасында байлык җыю буенча игълан ителмәгән бәйге башлана бит. Капкалар зур машина керерлек булып киңәя, бусагага саранлык менеп утыра, түр башына комсызлык кереп оялый. Көнчелек орлыгыннан кан дошманлыгы үсеп чыга. Һәр йорт-дәүләтнең яңа, үзенчә, әмма бер-берсенә ике тамчы судай охшаш доктринасы билгеләнә: «Күзеңә күренгәнне кулыңа керт, кулыңа кергәнне ычкындырма».

Бәлки, тәмам байлыкка күмелгәч кенә шушылай үзгәрәләрдер болар? Язкилде кешеләре ике күрше егетенең олы юлдан канга батып кайтуын: «Рәхәтлеккә чыдый алмый хәзерге яшьләр»,— дип бәялиләр бит. Мидхәт белән Хәйдәрнең җае чыккан саен «кәгеп алырга» яратуын да шуннан күрәләр. Югары очка су менеп җитмәсә дә, аракы дигәнең бер дә өзелеп тормый икән. Бөтен бәланең башы шундамы — кайберәүләрнең әлеге шайтан суына хирееслегендәме соң әллә югыйсә?.. Алай дисәң, Мирфатыйх белән Сәләхетдиннең башлары бик түгәрәк, исәпләре бөтен: хәтерләрен, намусларын аракы гына юдырып китә алмастыр! Әнә бит, үз авылында килмешәк көненә калган Хәйретдин агай каршында кикрикләре ничек шиңеп төшә аларның. «Үлә күрмә инде,— дип ялваралар.— Үз

акчабызга санаторийга җибәрербез,—диләр.— Үлә калсаң да, зинһар, яңа зиратка күмәргә рөхсәт бирмә»,— дип үгетлиләр.

Нишләп әле тиктомалдан гына Хәйретдин агайны кайгырта башлыйлар соң болар? Тормышның түшәменә төкереп яшәүче таза-таза ирләр нигә ул яңа зираттан шүрлиләр?

Әсәрне укыган кешеләр белә: һичбер риясыз, сабый күңелле Хәйретдин агай тегеләрнең нәкъ авырткан сөяленә баса. Фронтта йөреп тә исән кайткан, ә инде тыныч тормышта үз оясына гына каера-каера куркак күсегә әйләнеп баручы бу бәндәләрдән, бәлки, ул соңгы тапкыр көләдер... Үлемнән курку ике күршене айнытып җибәрә. Алар бит әле туганнар да икән ләбаса, дөнья куа-куа гына кан кардәшлекне онытып җибәргәннәр икән! Инде менә бергәләшеп янчык төпләрен актаргаласалар...

Коры исәпчеллекне, прагматизмны актив фаш итү әнә шулай ике туганның аңлаша башлавы белән тәгәлләнә. Шактый гыйбрәтле күренеш!

Күргәнебезчә, финал комедиячел төстәрәк, «уңай» геройларның хәле уңайга үзгәреп, «тискәре» дигәннәренең төзәлүгә юл тотуы белән тәмамлана. Дөресрәге, боларның күбесе —гыйбрәтле геройлар, аларны гаепләү яки ярлыкау сезнең белән безнең хөкемгә калдырыла. Үз дигәнен эшләүче Җәмилгә дә, «апасын сатып дошман лагерена чыккан» Зөфәргә дә чын-чынлап уңай герой, ягъни «сәләхетдинлек»кә каршы торырлык көч вазифасы йөкләнмәгән. Болар арасында, инде аңлаганыбызча, тәмле телле, изге күңелле Хәйретдин агай гына колоритлы бер фигура булып аерылып тора. Колхозның сенаж манаралары фонындагы янгын каланчасы белән, янгын сүндерү өчен билгеләнгән мичкәле атлары белән, гомумән, үткән замангарак йөз тоткан булса да, бик аңлаешлы, якын, кадерле карт ул безгә. Сәләхетдиннәрне әнә коры гына, саран гына сурәтләү дә бик җиткән, җаннары кибеп-коргаксыган затларга әле анысы да әрәм. Ә Хәйретдин агайнымы! — Хәйретдин агайны телгә алуга, сүзләр сары май булып йөрәккә ята, җөмләсе-тынышы язылып, йомшарып киткәндәй була. Хәйретдин агайның бер күренүе бөтен хикәяләп баруны үзенә ияртеп китә: кайда — аның уйлары, кайда — хикәяләп баручы сөйләме — һич аерып ала алмыйсың. Тегеләргә исә берниндн ышаныч юк: бөтен эш-ниятләре караңгы күңел базына бикләп куелган. Яктыга чыгару белән, ул уй-фикерләр тагын да сукыраеп, миңгерәүләнеп кала, ахрысы, үзләре генә нәрсәдер аңлатырлык хәлдә булмыйлар. Хикәяләүчегә өстәмә мәшәкать ясыйлар: кайвакыт аңа хәсрәт адәмнәрнең черек фәлсәфәсен аралап күрсәтергә эш чыга...

Хәйретдин агайга килгәндә, әлеге каланчасыннан ул Сәләхетдиннәр читәнендәге туннарны да бүре итеп күрә: ике аяклы бүреләрнең нәкъ шул тирәдә булуын чамалады микән әллә?..

Яшьрәкләргә исә дөнья хикмәтләрен аңларлык күңел күзе җитеп бетми: Зөфәргә, шул ук каланчадан торып, апасы күңелендә уйнаган давылны аңлавы кыен. Сәләхетдиннең дә үз «каланча»сы бар: өй чормасына менеп, ярымай уентысыннан күрше йортны күзәтә һәм үзенчә нәтиҗә чыгара ул. Мирфатыйх белән Сәләхетдиннең килешүенә берьюлы ике ноктадан шаһитлык итәләр: берсенең кызы — тәрәзә пәрдәсенә ышыкланып, икенчесенең хатыны — капка ярыгыннан...

Бер үк вакыйгага яңадан кайта-кайта төрле геройларның мөнәсәбәтен ачыклап бетерү, ничектер, телевизордан спорт ярышларын күрсәтүне хәтерләтә, дигән идек. Чыннан да, биредә һәр вакыйга — хоккейдагы сыман «гол ситуациясе», шуңа күрә ул, алка капкага керәме-юкмы,— барыбер, төрле ракурстан кабатлап күздән кичерелә. Кем нинди каланчадан карый бит! — менә шунысы мөһим.

«Биш йөз телле, мең колаклы» Язкилде авылында «сәләхетдинлек»кә каршы чыгарлык яшь, көчле геройлар тапмыйбыз икән, моның өчен язучыны гаепләү гадел булмас. Хәлбуки, һич тә киләчәккә өметсезлек белән карау түгел бу: чынлап торып уйласаң, Сәләхетдиннәргә бер мизгел дә тантана итәргә туры килми бит. Аларның барча кыланышлары комнан бау ишү генә булып чыга. Шул ук вакытта тынычланып калырга да ярамый. Хәйретдин агай юкка гына чаң какмый!..

«Үзеңне онытып күршене сүгү, күршене орышканда үзеңне юмарт, акыллы, сабыр итеп күрсәтү бик ансат бит ул!» Нихәтле генә ачы булмасын, хакыйкатьне танырга, аның бизмәненә үз гамәлләреңне салып карарга мәҗбүр итә бу әсәр. Аның тормышка тәэсире, тәрбияви көче дә шунда!

Аяз Гыйләҗевны шәхеснең чын бәһасен билгеләү мәсьәләләре дулкынландыра. Адәм баласының күңелендәге рухи гармония җимерелә калса, бу аны һәлакәткә алып бара, дип раслый һәм җаны-тәне белән кешелеклелек нигезләрен яклап көрәшкә күтәрелә аның геройлары — Бибинур һәм Хәйретдин агай кебек якты шәхесләр.

Һәрвакыт, һәркем каршында үзен гаепле санаучы Бибинур карчыкка, ниһаять, миһербансыз балаларын соңгы тапкыр яклап калу нигә кирәк була соң? Ни өчен изге ялганы ачылу — балаларының рәхимсезлеге дөньяга фаш булу ихтималы аны соң чиккәчә борчуга сала?

Күрәсең, бу — кешенең үз эчке дөньясын фани дөнья, тормыш кырыслыкларыннан азмы-күпме булса да, хәленнән килгәнчә якларга омтылуы. Бибинурның һаман өмет утын сүндермәскә талпынуы, сәер мәхәббәте, Хәйретдин агай белән икесенең дә дөнья гаменнән аерылган кебек яшәүләре әнә шуның белән — күңел гармониясен, күңел әкиятен сакларга омтылу белән бәйле түгел микән?!

Язучы кешеләр күңелендәге илаһи нурны, гармонияне, мәхәббәт хисен сакларга чакыра, аның һәр ике әсәрендә дә укучының намусына эндәшүче үткен сорау яңгырап тора сыман: «Исеңә төшер, син кем баласы? Кайдан киләсең? Кая барасың?» Халкыбызның әхлакый идеалларын эстафета кебек саклап килеп безгә тапшыручы Бибинурлар, Хәйретдин агайлар бүгенге заман кешесенең йөрәк тибешен тоеп иҗат ителгән, һәм алар язучының бик җитди ачышы дип саналырга лаеклы.

Әнә шулай, тормышның тирән агымындагы киеренке ритмнар килә әлеге әсәрләргә. А.Гыйләҗев, үз табигатенә хас булганча, бу очракта да авыр юлдан — тыгызрак катламнарга таба атлый, ныграк каршылык күрсәткән материалны буйсындырып бара, шул юлда үз-үзен ахыргача сарыф итә.

Заманга аваздаш иҗтимагый-фәлсәфи проблематикасы, әхлакый максимализмы, үзенчәлекле образлар системасы белән А.Гыйләҗев иҗаты күп төсмерле, бай татар прозасында үзенчәлекле күренеш булып яши.

Язучы әйткән сүзнең зурлыгы, мөһимлеге һәркем өчен аерым, үзенчә билгеләнә торгандыр. Укучы буларак күңелем сизә: кайтып-кайтып искә төшәр, кабат-кабат уйландырыр әле бу әсәрләр безне...

...Ә хәзергә мин өстемә киенәм дә урамга чыгам. Әнә өч-дүрт йорт аша гына чыбык очы туганнарның тәрәзәсендә ут күренә. Тышта салкын яңгыр сибәли. Эштән дә арып кайтылган иде. Кырык эшем кырык яры чәчелеп ята. Үзләренең дә туган иткәне юк инде — тормыш вак-төяге күмеп киткән. Малайлары исә кардәшлекне бөтенләй белмиләр... Шулай да җан тартмаса, кан тарта бит. Нишләп торалар икән? Хәлләрен белеп кайтыйм әле үзләренең. Берочтан Аяз Гыйләҗев китабын да алып барыйм. Укысыннар. Уйлансыннар...

1983

## АВЫЛ ХАЛКЫНА НИ ҖИТМИ?

«Мин — су астындагы авыл малае».

Каләмдәшем сүзләре

Әминем авылымны судан басты-
ра алмадылар. (Чөнки безнең тирәдә ГЭС төзерлек зур сулыклар юк иде.)

Әмма аның һавасын суыртып алдылар.

Авылның кинәт тыны кысыла башлады. Ул безнең күз алдында җиргә сеңә бара, таркала, юкка чыга. Май итеп ипигә ягарлык ярмалы кара туфракта сукыр казыклар гына тырпаешып кала. Алар инде беркайчан да яфрак яра алмаячак.

«Казан — Базарлы Матак» автобусы. Юлдашыбыз — алтмышынчы елларда ук авылдан киткән апа — үзалдына сөйләнеп кайта:

— Шаккатам: хәзер авыл халкына ни җитми?! Икешәр баз бәрәңгесе; келәт тулы ите. Бишәр сыер малы асрыйлар. Фураж җитми дигән булып, терлекләренә калач ашаталар. Безнең заманда өч сарыктан артыгын хөкүмәткә тартып алалар иде; бәрәңге бакчасын кисеп, шайтан таягы үстерделәр. Ипинең кыерчыгына түгел, бәрәңгегә тилмергән чаклар булды. Хәзер кибеткә өч көн ипи кайтмый торса, кара тавыш чыга!..

Апаның фикере су булып ага.

— Кайтыйм-китим дисәң, юлы да юк түгел,— дип дәвам итә ул.— И-и, ул «Беларусь» арбасында, сөт багына ябышып йөргән чаклар... Шуңкар тавында гына да язгы-көзге юл өзеклегендә күпме кеше үлә иде!..

Чынлап та, Тукай әйтмешли: «казенный булса да, урманы бар...» — нидән разый түгел соң бу халык?

Шул уйлар белән авылым урамыннан атлыйм. Куәтле техника бәбкә үләнен сытып-изеп узган. Район үзәгендә эшләүче малайлары сагынып кайткан авылны: кайбер капка төпләрендә икешәр «КамАЗ»... Хәер, урамда машина да трактор гына, адәм әсәре күренми.

Авылга, куера барып, эңгер сөреме тарала. Кайбер өйләрдә ут та алып тормый йокларга ятканнар бугай. Тиздән бу урамнар дөм караңгылыкка чумачак.

Күрше авылга бүген артистлар килгән, диләр. Безнекеләр бармагандыр, мөгаен. Ә үзебездә елына бер кино да күрсәтмиләр. Элегрәк, клубыгыз җимерек, дип урап үтәләр иде, хәзер клуб «чиркәү хәтле» — тамаша карарга кешесе генә юк.

Урамдагы, клубтагы бушлыктан, караңгылыктан бигрәк, авыл халкының күңелендә бушлык һәм караңгылык арту ихтималы куркыта мине... Көндәлек мәшәкатьләр, тормыш-көнкүрешнең авыл кешесе аңлап яки кабул итеп бетерә алмаган якка борылуы дөньяның ниндидер ямьнәрен күрергә, тоярга комачаулый шикелле. Ләкин гел дә шулаймы соң бу?

Җиләк кебек чакларын шәһәр тулай торагында үткәргән якташ кызлар, шул хакта сүз чыккач, миңа бик сәерсенеп караганнар иде. «Авылга кайтсак, күңелләребезне агартып киләбез,— диләр.— Без монда мүкләнеп йә күгәреп ятканда, эти-әниләр яшәүдән кызык табалар икән!»

Тыштан сүрән күренгән тормыш учагының кайнар көле астында утлы күмере дә бар әле, димәк! Ни авыр заманнарда да ул ут сүнмәгән. Ә менә аны яңадан үрләтеп, дөрләтеп җибәрү өчен сулышыбыз җитәрме?

Гомумән, авыл халкына ни җитми? Бу сорауга бүген безнең авылның ялгыз карчыкларыннан алып дәүләт башлыкларына кадәр җавап эзлидер кебек. Кем ничек эзли...

Әлбәттә, «китап артында» әзер җавап юк. Әле ярый, җирен сатып баерга хыялланучылар, кемнәрдер төзегәнне җимерүдән башканы белмәүчеләр генә түгел, искене саклап, яңаны төзеп, таркалмый хуҗалык итүчеләр дә бар. Алар аңлый: мәктәпләр, китапханәләр санын кыскарта барган

саен, халык рухының Кызыл китабында тиздән урын аласы «перспективасыз», өметсез татар авыллары исемлеге зурая бара. Аларны мәчетләр генә саклап кала алмас шул.

Мин — өч авыл баласы: берсендә туганмын, икенчесендә үстем, өченчесе миңа белем бирде. Бер-берсенә сыенып диярлек утырган өч авыл. Дөрес, үскән авылым туган авылдан да якынрак булса, мәктәпле авыл исә «килмешәк» икәнлегебезне онытырга бирмәде... Адашып калырлык бураннарда, коры җеп бөртеге калмаслык итеп чылаткан яңгырларда, ни дип кенә ашыга-кабалана барганбыздыр инде? Дәресеңне белмәгәнгә түгел, шул гарасатта юлга чыгып, адашып үлмичә, мәктәп капкасың тапкан, әмма биш минутка соңга калган өчен бөтен әр-хурны күтәрергә дипме? «Юрган астыннан гына чыгып, урам аша торган мәктәпкә керсәң, ничек була икән ул?» — дип гәп куерталар иде безнең кебек «күрексез үрдәк бәбкәләре».

Мәктәп залында «Уңган авылдашлар» дигән стенд эленеп тора: бер үк хуҗалыкка хезмәт итеп, эштә алдынгыларның алдынгысы булса да, анда синең авылың кешеләре юк. «Алар безнең мәктәпне тәмамлады» дигән витринаны төзегәндә, әлбәттә, синең шул «сөйкемсез сөяк» абый-апаларың турында искә алучы да булмаган...

Бу — минем соңга калган үпкәм түгел. Киресенчә! Күрше авылга йөреп укыган кеше белә: ике авыл арасындагы юл безне гомер буена җитәрлек тәэсирләр, тормыш сабагы белән баетты. «Юрган астыннан чыгып» кына мәктәпкә керүчеләр ул бәхетнең ни икәнен дә белмиләр.

Әмма шунысы хак: әлеге юл — безне Авылдан алып китәсе юлның да башы иде. Бәләкәй авыл баласын туган җиреннән аеру әнә шулай башлана икән ул.

Без үскәндә «уполномуч»лар заманы инде үткән, әмма авыл халкын дер селкетеп торучы ике бәндә бар иде. Аларның берсе — Упыр (ягъни управляющий), икенчесе — Пүләвәт (кыр каравылчысы). Упырның күңелен күрмәсәң — бер сәнәк арыш саламына тилмерәчәксең. Пүләвәт исә тыкрыкка очып чыккан тавыгыңны да кычкыртып алып китә, ябып куя,— болай да гарьчел авыл кешесен адәм рисваена калдыра.

Без моны бала вакыттан, үзебез кул арасына керә башлаганчы ук күреп-аңлап үстек дияргә була. «ДТ» тракторының башмаклары белән ду китереп «җир сөреп» ятканда, арабыздан иң көчле, әмма ни өчендер иң ялкау малай үзен «упыр» дип игълан итә. Ул «нәрәт бирергә», ягъни үзенең өлкән агасына охшатып җикеренергә керешкәч, кызларның иң чытлыгы: «Ә минем сыер савасым килми! Мин упыр хатыны булам»,—ди...

Байтак еллардан соң очраттым ул кызны: Казанда укып кайткан, әйбәт кенә һөнәр алган үзе, әмма беркайда да эшләми — күрше авылда «упыр» хатыны икән...

Кайчак мине танышларым гаҗәпкә калдыра. «Безнең авылдан кеше китми»,— дигән булалар. Башкалар кичергән кытлыктан алар да азат түгел икән югыйсә. Әллә беркадәр үзбаш, мөстәкыйль булып яшәү тотамы ул авылларны?

Безнең авыл да кайчандыр үзе бер колхоз булган. Ягъни мәсәлән — «авыл подряды». Үз амбары, тегермәне, башкасы... Йорт саны күбрәк булган күршесенә кушканда, иң әүвәл әнә шул терәкләрен сүтеп ташыганнар авылның. Аңарчы ук мәчетен ишеп, әлеге «үзәк усадьба»га мәктәп клубы итеп салганнар.

Инде уч төбе хәтле белешмә алыр өчен күрше авылдагы «үзидарә»гә яисә район үзәгенә үк йөрүдән башлап, тегесе юк, монысы юк — уникенең берсе юк, дигәндәй, безнекеләрнең үзаллы яшәү мөмкинлеге тәмам киселгән. Кыш көннәрендә хәтта чәй суын да... фермадан алып кайткан көннәре була, имеш.

…Әти үскән авыл урамының
тыкрыгыннан үтсәм,
казлар талый,—
мине

әтиемнең малай чакларына охшатып…

Кызымның дәфтәреннән

Авыл халкына ни җитми? Ни җитмәгәнен ул үзе беләме?..

— Безнең авылны район үзәгенә табарак эттереп булмас микән, бульдозер белән... Түлке зират кына җәл кала. Бер зират хакына гына торабыз бит инде бу җирдә...

Гомере буе шул туфракка маңгай тирен түккән абзыемның ачынып-әрнеп әйткән сүзләре бу. Шахта, сугыш, чирәм җир...— туган төбәгеннән аеру, биздерү өчен аны нинди генә шаукымлы «чаралар» белән измәгәннәр. Авылга кайтып төпләнгәч, гаиләсе ишле булгач, түзгән, китмәгән. Инде... хәзерге иң реаль хокукы — Ходай кушкан вакыты җиткәч, туган авылы зиратында үзенә таман өч аршын җир биләү.

Хәер, адәм балаларын гүрстан да тигезләп җиткерә алмый булса кирәк. Абзый үзенә урын чамалап, шул тирәләрдән урап кайткан әле. Баксаң, влач-хакимият исеменнән халык канын эчкәннәрнең җәсәде анда да иң түрдә — кояшлы үрдә икән, ди...

Абзыем, мыек астыннан көлемсерәп, шул хакта сөйли, ә мин аны фани дөнья хәлләренә алып чыгарга тырышам. Букча күтәреп мәктәптән кайтып килүче бер малайны туктатабыз. Бармагын бөгәбөгә җәһәт кенә санап күрсәтә: аларның классында быел дүрт бөртек бала укый икән. Өмет юк түгел, әмма күңелгә әллә ни җиңеллек тә өстәми бу сан. Бишекләр күзгә күренеп бушый бара. Яшь киленнәр су алмаганга, Югароч чишмәсенең суы тоныклана... Җирәнчә аланында кызарып җиләк пешәр,— җырлый-җырлый җыярга кызлар булмас. Дәүли бабай бакчасында тып-тып алмалар коелыр,— урларга түгел, иелеп алырга да малай заты табылмас. Узып баручы юлчылар: «Бу кайсы авыл зираты икән?» — дип бер-берсеннән сорарлар...

— Авылның зурлыгын, мөһимлеген зиратына карап билгеләсеннәр иде! Безнең күпме халык анда хәзер...— дип фәлсәфәгә бирелә агаем.— Авылның киләчәге зиратта инде...

Абзыема Казан күрсәтеп йөрим. Тукай музее урнашкан атаклы «Шамил йорты» яныннан узып барабыз... Кавказлы имам Шамил, аның генерал улы турында үзем белгәнне әйтим дип авызны ачсам, авылдашым:

— Шамилнең монда да йорты ничава икән! — димәсенме.

Мине шактый аптыраашта калдыруын үзе дә сизде бугай:

— Соң, Шамилнең авылдагы йорты да һаман шул көе, буш тора бит,— диде.

Карасана, бөтенләй хәтеремнән чыккан. Тешсез урт кебек нигез урыннары убылып калган авыл уртасында галәмәт зур, биек бер йорт кукыраеп тора иде шул. «Шамил йорты»,— диделәр. Казанда эш йөртүче Шамил исемле авылдаш торгызып куйган икән. Әмма шул яңа нигез ничә еллар инде буш оя булып картая: хуҗасы торырга кайтмый, ул куйган бәягә сатып алырга теләүче табылмый. Инде тәгаен бу йортка ия табылмас: күксегән, яртылаш черегән гүрничә кемгә хаҗәт хәзер. Өстенә урман ишелеп торган авылда...

Хәләл вә хәрәм малларын мәгънәсез тамашалар үткәрүгә сарыф итүче затларның колагына бер сүз: иң әүвәл туган авылыгызга мәктәп, юл салдырсагыз иде сез. Югыйсә анда хан сарае кебек йортыгыз яки туып-үскән нигез урыныгыз белән иске зират кына торып калачак берзаман.

Шәһәр яны салаларына җыен хөрәсән, булдыксыз бәндәләр күчеп киләдер дип йөри идем. Чыннан да, берара, җиңел тормыш эзләп, авылда көн күрә алмаган кешеләр күчеп китте бугай шәһәр тирәсенә. Алар, гадәттә, бүтән туфракта да тернәкләнә-мантый алмыйча, кабул ителмәгән дога сыман, әмма күпмедер сабак алып, кире әйләнеп кайттылар. Ә менә бүген кемнәр китә? Кемнәр кала?.. Калучыларга рәхмәт, аларга кулләгә төшерәсем килми; мәгәр авылның каймагыннан бер өлеш китә түгелме соң, җәмәгать? Өздереп эшли торган, йөгерек акыллы балаларыннан колак кага авыл. Һөнәр үзләштерергә яисә «бөек төзелешләр»гә китмиләр бит. Үз авылларыннан бүтән төбәктәге авылсалаларга гына күчеп яшиләр. Беләм, кайда да югалмаслар алар. Әмма туган авылларын чынлап та перспективасыз-киләчәксез итүдә аларның өлеше дә бар,— шунысы аяныч.

Район үзәгендәге кайсы гына оешмада, Казан тирәсендәге кайсы гына хуҗалыкта безнең авыл кешеләре юк икән хәзер? Туган ягым соңгы берничә елда гына да дистәләрчә мең кешесен югалткан, дисәм, мине дөньядан артта калганлыкта гаепләргә мөмкиннәр. Янәсе, Америкада әнә халыкның уннан бере генә авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнә, диярләр. Авылның төп үлчәү берәмлеге гектар, центнер, литрлар да, хәтта җан башы да түгел, әлбәттә. Төп күрсәткеч — кешегә кешечә мөнәсәбәт микъдары.

Авылга сталинчылар китергән афәт турында без бүген ачыктан-ачык сөйли башладык. Ерак үткәннәрне фаш итү җиңелрәк, әлбәттә. Инде авылга бәләкәй шәхес культлары салган зарарны да күрергә вакыт җиткәндер, шәт. Культ өрәген хәзер 37 нче еллар шаукымыннан иза чиккән агайларның уллары кабат тудырырга азапланалар. Бу юлы аларның үзләренең культ буласы килә.

— Мәскәүгә хәтле язып карадык. Анда да кешеләре бар, ахрысы,— дип зарланышкан иделәр агайлар, бер кайтуымда.

«Мәскәүгә язылган» кайбер хатларның кемнәр кулына кергәнен, ничек тикшерелгәнен күргәнем бар... Гаделлекне бик җиңел генә китереп бирерләр дип көтәсез, минем беркатлы якташларым!

Элеккерәк елларны, газетада эшләгәндә, ягъни «дүртенче власть вәкиле» булыбрак кайткан-лыктан, җитәкчеләр белән эш йөртү әллә ни кыен түгел иде кебек. Авылдашлар зарын хәл итү дә җиңелрәк булды. Әмма шуның бәрабәренә башлыклар күзлегеннән карап кына байтак кәгазь буялды. Әйе, безгә нәрсә язасын һәм ничек язасын өйрәтергә тырыштылар алар. Халыкның чын гамәлләренә, чын хәленә юлны «күрсәткечләр» һәм үз бәдәннәре белән томаладылар. Шуңа күрә без дөньяның барышын әйбәт һәм начар «юлбашчы»ларга гына бәйләп күрә башладык. Татар язучылары гаҗәеп бер галерея — «председательләр әдәбияты»н дөньяга тудырды. Аяз Гыйләҗев кебек олы әдипләребезнең, әлеге вәсвәсәгә бирелеп алганнары өчен, соңыннан үкенгән чакларын күрергә, ишетергә туры килде. (Һәр талант иясе кебек үк дөньяга сирәк туа торган, һәркайсы кабатланмас нөсхә булган аерым җитәкчеләр турында түгел сүзем. Шунысы да бар, әкияткә тартым очерклар теге заманнарда әле риясыз күңелдән, «шулай кирәк» булган өчен язылды. Ә хәзер...)

Нинди туфрактан һәм уттан яратылган иде соң ул затлар? Без аларның сыерны «кырыес» (КРС — «крупнорогатый скот»), ферманы «мытыфы» (МТФ — молочно-товарная ферма) дип сөйләшүләрен кешеләр язмышын кайгырту дип уйлап йөрдек. Берәр колхозчыга үзе башлап сәлам бирсә, андый председатель гомумән кешелеклелек эталоны итеп күтәрелде. «Җитәкче булып туган» затлылар сыйныфын без дә менә шулай ныгытыштык. Бер эшне таркатсалар, аларга икенче җылы урын әзер торды. Авыл Советы рәислегеннән алгач — баш агроном, анда да эшләре бармаса —дуңгыз фермасы мөдире... Килә ява бер болыт дигәндәй, башыбызны күтәреп карыйк: ничәмә еллар дәвамында бер үк кешеләр, урындык алыштыра-алыштыра, безнең белән командалык итеп яшиләр! Кайсы заманда, кайсы төбәктә булырга мөмкин бу кадәр универсаль «җаваплы работниклар»?

Менә шундый йомык цикл барлыкка килгәнгә күрә, безгә тынчу күлдә яшәргә калды: чишмәләр томаланды, ә моның белән килешергә теләмәгәннәргә бары бер юл — китү юлы гына бар иде. Хәтта читтән килгән журналист тәнкыйте дә фәлән фәләнечнең куәтле элемтәләр челтәре белән япа-ялгыз көрәшкә чыгудан гыйбарәт иде. Әле синең кул-аягыңнан да тотып торалар: киерелеп типсеннәр эчеңә — үзеңне-үзең яклый алмыйсың.

Яшермим, ялгыз әниемнең хәлен белергә кайткач, аның:

— Минем шул җирдә яшисем, шул кешеләр каршысына барасым бар,— дип өзеп әйтүе дә кайчак кулны бәйли иде.

Зур йөрәкле, туры сүзле кеше дә болай хафаланган икән, димәк, сәбәпләре бик җитди булгандыр.

Хәер, «иде...» дип, барысын да үткәннәргә күчерү дөрес булырмы соң? Әйе, хәзер мин, әнинең кордашларын сагынуын искә алып, елына бер тапкыр гына туган якка кайтам, намусыма хилафлык китерерлек бер юл да язып килмим. Әмма сезнең бәхетле исемнән сүз алып шапырынуларны, «җаваплы хезмәткәрләр» каланчасыннан гына карап сезнең тормышны тасвирлаган язмаларны укыйм, радио тапшыруларын тыңлыйм да каләмдәшләрем өчен уңайсызланам.

Шул ук вакытта сезгә дә сүзем бар, агайлар. Сез бит — дөньяны зирәк крәстиян акылы белән таный торган кешеләр. Үзегезнең сөялгә баскан бөтен мәсьәләләрне Мәскәүдән килеп хәл итмәсләрен бик яхшы беләсез!

Хәтерлисездер, безнең авыллар урынын сөрелгән басу итеп төшләрендә күрүчеләр элек тә бар иде. Без ул чакта: һәй, халык кадәр халыкны бабайларның гүр туфрагыннан баш тартырга мәҗбүр итә алалармы соң, дип һаваландык. Инде күрәбез: беркем дә мәҗбүр итми, без үзебез ташлап китәбез, балаларыбызның да «котылуына» сөенәбез.

Ялган оптимизм безгә һәрвакыттагыча бик ачы җимешләр китерә.

Авыл халкына ни җитми?.. Бергә үскән егет — «колхоз менеджеры» хыяллана:

— Биш катлы бер йорт саласы иде дә, малай, бөтен бер авылны уңайлыклары булган квартираларга урнаштырасы иде. Бәрәңгене — басудан, сөтне фермадан алсын. Эштән соң җылы ванна чумып чыксын да диванга кырын ятып телевизор карасын!

Алны-ялны белми эшләгән агайларның, апайларның нинди рәхәткә тиенәсен күз алдына китерү минем дә хыялны кузгата. Шулай да кордашымның яшерен «карталарын» ачарга теләп, сүзенә аяк чалам: биш катлы куначага менеп утыргач, җирдән аерылмаслармы? Аларның бала-чагасы нәрсә күреп үсәр? Туфрак белән уйнамагач, җир җылысы кермәс бит күңелләренә, мал-туар күзенә карамагач, кешелекле хискә ярлы булырлар. Басу уртасындагы ялгыз йорт тора-бара картлар йортына әверелмәсме?

Яшьтәшем үҗәтләнеп бәхәскә ташлана, кайчандыр Белоруссияләрдә күреп кайтканын дәлил итеп китерә. Миңа аның әзер дәлилләре түгел, шул хакта уйлану рәвеше кызык. Бездән алдарак туган буын туйганчы ашарлык икмәк үстерү турында хыяллангандыр. Ә менә бу — шулай ук шактый нужа күреп үскән крестьян малае, утын, терлек азыгы әзерләүдән башлап, ел әйләнәсендә авыл кешесе башына төшкән мәшәкатьләрне яхшы белә. Аның әлегә иң зур хыялы — иген үстерүче, терлек караучы кешеләрне богауларыннан коткару һәм колхоз эшенә җәлеп итү... Бу — аның көлсу туфраклы Мари ягында эшләве белән дә бәйләнгән. Анда һәр эшче кул кадерле. Ул аларның бәһасен белә... Югалтып табылган, кыйммәткә төшкән хакыйкать — әлеге зона өчен.

Авыл халкына ни җитми? Әллә аның иртәгесе көндә бөтенләй гаме юкмы?

«Авылның киләчәге — зиратта инде...» — дигән агай да хаклымы?

Зират туфрагы кебек авыр сораулар. Ата-бабаларыма ләхет алынган җир мине шул сораулары белән үзенә тарта. Шуңа күрә бүген мин юлда. Авылым турында сүз чыгу белән, мин үземне һәрвакыт юлдамын кебек хис итәм. Уйларым үземнән алда йөгереп, авылдашларыма кайтып сыена, аларның хәл-әхвәлен уртаклаша.

— Исән-сау торасыңмы, апа?! Ялгызыңа дөнья куулар бик читендер инде...

— Нихәл, абзый?! Яңа койма тотасыңмы? Алла куәт бирсен!

Дөрес, безне мәктәпләрдә нык тәрбияләделәр. Тәмам фәкыйрьләнеп, «исәнмесес-исәнмесез» дигән риторик ысылдауга карап калдык. Рәхәтләнеп эшләп яткан авылдашка «Алла ярдәм бирсен!» дигән рухландыру сүзе дә искелек, дин тегермәненә су кою булып чыкты. Әйе, моны ныгытып аңлаттылар безгә. Шулай да безнең буын әле, авыл гадәтенчә, очраган һәркемгә беренче башлап сәлам бирә иде...

...Уйларым бүленде: машинабыз, текә генә борылып, «үзәк» белән безнең авыл арасына чыкты. Алда мәктәптән кайтып баручы ике-өч бала күренде. Нигәдер артка борылып карый-карый мыштырдап кына атлыйлар. Безне абайлап алуга, бөтенләй туктап көтә башладылар. Тургайлар сайрап торган кояшлы көндә авылларына кайтырга иренгән сыман иделәр.

Сәламне башлап үзебезгә бирергә туры килде. Матур, тук чырайларында әти-әниләренең төсен табып, һәркайсын танырга тырыштык. Мин исә ашыга-ашыга авыл хәлләрен сораштым:

— Егетләр, быел Саттар чокырына үрдәкләр кайтты микән? Балыкка төшкәнегез юкмы? Абу тегермәне тирәсендә кызылканат ничегрәк каба?..

Юк, болар Абу тегермәненең дә, Саттар күленең дә кайда икәнлеген белмиләр иде...

...Кәгазь-каләмемне читкә куеп, тагын авыллардан урап кайтырга туры килде. Үзем туып-үскән җирләр булмаса да, күңелгә якын якның чакыруы буенча сәфәр чыккан идек. Безне бу төбәкнең

текә ярлардан шаулап агып чыккан изге чишмәләре, шигъри исемле авыллары сокландырды. Карт тирәкле, чал тарихлы зиратлары уйга салды.

Үз җирендә бәхетләрен тапкан кешеләре белән матур булып тоелгандыр бу авыллар, мөгаен. Халыкның газга-суга кинәнеп яшәвенә, телевизор баганалары «урманы», көтүдән кайткан маллар кебек капка төпләрендә басып торган җиңел машиналар белән хозурланып, гармун һәм бала-чага тавышларын сагынып йөрдек. 20 генә йортлы бердәнбер урамлы авылның яшел чирәмендә йөгерешкән балаларны күреп: «Бу авылның әле киләчәге бар!» — дип сөендек. (Төбәк авылларында, исәпләп карасаң, якынча бер йортка бер бала туры килә икән... Күпме бу, азмы?)

Авылның өмете — балалар.

Авылның өмете — туйлар. Олы урамда бүген туй. Иске кинодагы кебек, көтүче егет («скотник») сыер савучы кызга («доярка»га) өйләнә. Бәхетең ишле булсын, яшь кияү! Төкле аягың белән, яшь килен! Бу туфрак үз куенында таш асрамый. Бу туфрак игелекле үсентеләргә көч бирә, аның күкрәгеннән хикмәтле чишмәләр тибеп чыга.

1988

## ӨЛКӘР — ӨМЕТ ЙОЛДЫЗЫ

«Бу хыял миңа бик кирәк...»

Адлер Тимергалин. «Өлкәр»

Э сез фәнни фантастика биләмәләрендә үзегезне ничек хис итәсез? Анда кайбер проблемаларның, фикерләрнең авырлыгы югалу күренешен җиңел кичерәсезме? Йолдызлы күктә, алма бакчасындагы кебек, иркен сулап йөри аласызмы?.. Иҗатның тылсымлы кодрәте белән тергезелгән катлаулы һәм кабатланмас бу дөнья иң әүвәл эзләнүләр романтикасы, ачышлар ләззәте белән матур бит!

Фәнни фантастика — үзенә генә хас мәсьәләләр һәм чишелешләр әдәбияты. Әлеге үзенчәлекнең теге яки бу дәрәҗәдә фән үсешенә дә бәйле булуы табигый. Фәндәге сыман, «мәңгелек» темалар, «үтәли» проблемалар... Шуңа күрә кайчак ул «үксез бала» булып та күз алдына килә. Әдәбияттан аерылып калган, ә фән мәртәбәсенә, янәсе, әле ирешә алмаган. Дөнья фантастикасы тарихын гына искә төшерик: хыялый җирлекне «чын» итеп күрсәтү өчен фәнни дәлилләрдән файдалану яисә, мавыктыргыч киемгә төреп, азмы-күпме гыйльми мәгълүмат бирергә омтылу мисаллары шактый анда.

Фәнни-хыялый әдәбиятны турыдан-туры маҗаралы әсәрләр төркеменә кертүчеләр дә күп. Аның нәсел-нәсәбе, шәҗәрәсе «Мең дә бер кичә» кебек шәрык әкиятләреннән, борынгы маҗаралы хикәятләрдән башлана, дип санаучылар бар. Бу тамырларда — адәм баласының иң изге хыялларына омтылуы, шул өмет-омтылышны чагылдырган төрле ышану-ырымнары. Ләкин фәнни фантастика, үзенең шушы бишегеннән төшеп, инде озын юл үтәргә, зур эчке үзгәрешләр кичерергә өлгергән. Һәркайсыбызның күз алдында ул тагын да яңа сыйфатларга ия була бара.

Акыллы машиналар, ят тереклек ияләре белән Җир кешесе арасындагы мөнәсәбәт татар язучыларын соңгы елларга кадәр бик аз кызыксындырып килде. Әдәбиятның фәнни фикер үсеше белән бәйләнышлы бу төре, нигездә, тәрҗемә әсәрләр исәбенә яшәде диярлек. Шуңа күрә Адлер Тимергалин иҗаты, мәсәлән, кул тимәгән темалары белән генә дә укучыны үзенә җәлеп итә алыр иде. Ләкин һәркайсыбызга мәгълүм: аның беренче әсәрләрен үк чын мәгънәсендә канатлы иткән сыйфат тема үзенчәлеге генә түгел...

Турысын әйткәндә, фәнни фантастика — укучы өчен дә, язучы өчен дә шактый «каты чикләвек»... Беренче карашка, баш әйләнгеч фикерфаразлардан яки чит дөньялар галәмәтен күзәтүдән дә яңарак, кызыклырак нәрсә булмас кебек тоела. Һәм фәнни фантастикада шундый зәвыкка исәп тотып кына язылган әсәрләр шактый. А.Тимергалин, бәхеткә, өстә яткан катламны күтәрү белән мавыкмады. Әлбәттә, укучыны үзең төзегән хыялый дөньяга ияләштерү җиңел түгел, хәзинәдә булганын күрсәтеп каласы килә, һәм шунлыктан урыны-урыны белән чама тойгысын җуюың да бар. Тикмәгәме, уңышлы гына әсәрләрдә, икмәк эчендә оешып калган тоз кебек, коры информация утраулары әледән-әле очрап куя...

Күренешләрнең, мохитнең үзгәлегенә, гайре табигый булуына аерым мәгънә салынганда,— ә язучы мондый форсаттан файдаланырга тырыша,—хосусый нечкәлекләр, «шөреп»ләрдән башлап, күк җисемнәренә кадәр яңабаштан «ярату» (иҗат итү) таләп ителә. Бу очракта ике дилбегәне —хыял очышы белән мәгънә үсешен тигез тоту тагын да кыенлаша. Чөнки, ахыр чиктә, космопланнар гына түгел, галәмдәге сәер күренешләр һәм тереклек ияләре дә, «космик телдә» әйткәндә, укучыны әдәби әсәрнең идея-художество орбитасына алып чыгуда катнашалар. Ул «орбитага» күтәрелә алганда, безгә, «Рәшад эффекты»ндагы кебек, үз-үзебезне: үткәнебезне, хәзергебезне, киләчәгебезне читтән күрү мөмкинлеге ачыла.

А.Тимергалинның бер үзенчәлеге дә әнә шунда: ул татар фәнни фантастикасының урын-вакыт кысаларын киңәйтте. Шулай да бу — мәсьәләнең бер ягы гына әле. Язучы әлеге «өч заман призмасы»

ярдәмендә бүгенге чынбарлык алдында торган проблемалар һәм бурычларны бер ноктага тупларга омтыла. Шушы җирлектән ераклашкан саен, «орбитадан ычкыну» куркынычы да зуррак, ягъни әсәрләрнең сәнгатьчә ышандыру көче кимегәннән-кими бара. Кешеләр белән ят цивилизация вәкилләре очрашуын тасвирлаган кайбер хикәяләрне үзара чагыштырып карасаң, шундый нәтиҗәгә киләсең.

Адлер Тимергалин әсәрләрендә багучылык итәргә, киләчәкне алдан әйтергә тырышу сизелми. Ул бары сорау-проблема куя: бүгенге күренешләр тора-бара нинди рәвеш алырга мөмкин? Без иртәгәге көнгә лаеклы булып яшибезме? Киләчәкне якынайтуга өлеш кертәбезме? Язучы-фантаст — пәйгамбәр дә, кылган эшләребезне күзәтеп-теркәп баручы «гамәл фәрештәсе» дә түгел: «Сез мине үзегезнең вөҗданыгыз дип уйлый аласыз...» («Кабул булсын теләгең» хикәясе).

Кисәтүнең дөнья әдәбиятында сыналган бер юлы — кешеләрне үзләренең киләчәге белән очраштыру. Мәсәлән, Герберт Франкеның (ГФР) «Орхидея күзәнәге» дигән романында «туклык җәмгыяте» шулай тасвирлана... Җир астындагы махсус җылытылган тирәлектә ниндидер җирәнгеч-дымсу җан ияләре — «орхидеялар» яши. «Орхидеялар» кайчандыр кешегә охшаш зат булганнар, әмма тормышның барча мәшәкатен роботларга йөкләп, үзләре ясаган оҗмахта бер гамьсез гомер сөрә торгач, алар әкренләп менә шушындый — үлек сыман хәлгә килгәннәр.

Адлер Тимергалинның «Кайтыр юллар» хикәясендә дә моңа аваздаш күренеш тасвирлана. Алга киткән җәмгыятьле сәер планетада «гипнотормыш» хөкем сөрә. Бирелдәге җан ияләре төш күрүләр дөньясында яшиләр. Аларның тормыш юлы алдан билгеләнгән программа буенча бара. Бу — мәңгелек йокы. Аннан уятучы юк... Г.Франке әсәре белән чагыштырганда, «Кайтыр юллар»ның чишелеше тирәнрәк мәгънәле, ул һичкичекмәстән хәрәкәт итәргә чакыра. Мәкерле планета тозагына эләккән Җир улларының берсе, үзен корбан итү бәрабәренә, ике иптәшен афәтле язмыштан коткарып кала. Алар «цивилизация үз-үзен чагып үтерә торган елан булмаска тиеш» дигән кайнар кисәтүне кешелек җәмгыятенә алып кайтырга тиешләр.

«Сак булыгыз: акыл көченең залимнар файдасына хезмәт итүе ихтимал!» дигән фикер Җир картиналарында да төрлечә гәүдәләнеш таба. Бер очракта, әйтик, кешенең яшерен хисләрендә казыну («Мәхәббәт һәм тәҗрибә»), икенче мисал белән бозык җәмгыятьтә акылның да зыян салуы фаш ителә («Киңәшче-1М»).

Әгәр тормыш үз бәндәсенә бер генә юл — кешелеккә каршы җинаять кылу мөмкинлеге генә калдырса?.. Капйотлардан, ерткычка әйләнгән затлардан алданып-рәнҗетелеп гомерен заяга уздырган, инде якты дөньядан ваз кичкән галим, ниһаять, коточкыч нәтиҗәгә ирешә: кешелекне кырып бетерергә сәләтле бактерияләр уйлап таба («Рибб Локсның үлеме»). Ул «хәзер кеше түгел инде. Ул — цивилизациянең соңгы сәгатьләрен санап утыручы автомат». Ләкин иң киеренке мәлдә бер кызчык (ягъни шул сабый сурәтендәге тормыш) карт галимне авыр төштән уятып җибәргәндәй була...

Тулаем алганда, әдәби тәнкыйть әлегә А.Тимергалин иҗатының тышкы билгеләренә генә игътибар итә. «Бигрәк тә игътибарга лаеклысы шул: хикәядә укучының кызыксынуын уятырлык маҗаралар бар, акыл эшчәнлеген азыкландырырлык фәнни гипотеза бар»,— дип яза арадан беребез. Бу шулаймы соң? Безне «галәмдә тереклекнең көтелмәгән формалары булырга мөмкин», «тимер кимерүче бактерияләр уйлап табылуы ихтимал» рәвешендәге фаразлар ныграк дулкынландырамы, әллә кешелеккә сукыр нәфрәт белән тулы кеше язмышымы?.. Фәнни фараз никадәр кыю тоелмасын, нигезендә кешелеклелек проблемасы булмаса, ул әдәби күренешкә әверелә алмый.

А.Тимергалин, бик күп фантаст-авторлардан аермалы буларак, кешегә хас бер сыйфаттан да мәхрүм булмаган катлаулы характерларны, гыйбрәтле геройларны яратыбрак иҗат итә кебек. Әйе, бүгенге татар фантастикасында каһарманнарга вакансия бар әле! Кәрлә җанлы затларның олы язмышы була алмый.

Әлбәттә, фантастиканың үз «уен шартлары» бар. Ләкин мөһим нәтиҗәләргә «тылсым көче» белән генә алып килә башласак, укучы өчен бу «уен»ның бик җитди мәгънәсе югалмасмы? Уй-хисләренә, омтылышларына аваздаш рух эзләп килүче җаннар адашмасмы? А.Тимергалин әсәрләре үк шаһитлык итә ала: чынбарлыкны танып-белүгә дә, адәм баласының кызыксынучанлыгына һәм яңалыкка омтылуына да чик юк. Иң мөһиме —фикер агышы әзер өлге буенча китмәсен, укучыны, замандашын үзенә иярткерлек кодрәткә ия булсын, сафлыгына кер кунмаган киңлекләргә әйдәсен.

Адлер Тимергалин иҗатының күңелне сөендергән яңа һәм мөһим бер сыйфаты өстенлек алып килә: галәмдәге табышмаклар белән баш ватудан кешелек җәмгыятенең үз карынында яралган күренешләрне, проблемаларны өйрәнүгә күчә бара ул. Фантастик каһарманнары да рухи дөньялары белән замандашларыбызга якыная төштеләр шикелле. Без ерак киләчәккә аларның күзе белән карый алабыз, аларда өмет-омтылышларыбызга таяну ноктасы табабыз.

Кешенең эчке дөньясына язучы үз ачкычын эзли. Бу эзләнүләр вакытында аңа, фәнни зирәклектән бигрәк, кешелекле җәмгыять идеаллары белән яшәүнең мөһимрәк булуы ачыла бара. Чөнки уйлап табуның да, маҗаралы-хыялый күренешләрнең дә төрлесе бар...

Адәм баласын әнә «ярыммаймыл» ясый торган конвейерга салып, үзенең кем икәнлеген онытырга мәҗбүр итәләр. Бу саташкан акыл ияләре тырнагыннан үзенең сөйгән егетен һәм аның кебек күпсанлы корбаннарны егерме яшьлек кыз бала коткара («Уян, сөеклем!»). Фантастик буяулар куе булса да, тора-бара биредә тормышның реалистик сурәтләре өстенлек итә башлый.

Күренеш-детальләрдән зәвык белән, чамасын белеп кенә файдалану А.Тимергалинның башка әсәрләренә дә хас. «Мәңгелек хатирәләр»дә — замандашларыбыз кулындагы гаҗәеп кристалл-ачкыч, «Әфсен түгел...» хикәясендә — Болгар чорындагы мохит, психологик шартлар... Ерак планеталардагы һәм үткән заманнардагы манзараны, вакыйганы тасвирлаганда, безгә таныш-мәгълүм детальләр ярдәмендә фантастик күренешләрне ачу осталыгы бигрәк тә күзгә ташлана. Нәтиҗәдә, хыялый картина Җир үлчәмнәренә нисбәтләнеп, чынбарлык киеменә төреләә. Сәер күк җисеменең «адашкан терлек»кә охшавын күрүдә дә шигърият бар: «Кулга бик ияләшкән эт, хуҗасыннан калса, шулай каңгырып йөри...» («Адашкан йолдыз»).

Гомумән, Адлер Тимергалин әсәрләрендә тел-сурәт чараларын күзәтү дә кызыклы. Анда «сакланганны космос үзе саклар, ди» рәвешендәге, урынын белеп кулланылган халыкчан тәгъбирләр, юмор элементлары «йолдыз яңгыры» булып ява. Юмористик һәм сатирик сурәтләр белән гиперболаның, фантасмагориянең эчке якынлыгы «Гулливер сәяхәтләре» заманында ук исбатланган, татар әдәбиятында алар «Фәтхулла хәзрәт»не үлемсез итешкән. А.Тимергалинның бу җәһәттән иҗат колачы шактый киң: маҗаралы-юмористик хикәяләрдән алып — «кибернетик шаяру»ларга, фантастик памфлетларга кадәр. Шулай да, җорлык димәктән, язучы нәкъ менә җитди генә мәсьәләләрне «мыек астыннан көлемсерәп» тасвирлаганда күбрәк уңышка ирешә. Бер хикәядәге «теле бик кычыткан чакларда да тыелып калган өчен» акча сорарга килүче хатынны хәтерлисезме? Юмор хәтта вакыйгаларның киеренкелеген көчәйтергә дә сәләтле икән! Яисә, йолдызның адәми затка уңай тәэсире бардыр, дигән ырым ничек гади һәм шагыйранә чишелә! Кеше белән дошманлаша белмәгәнлектән «Әүлия» кушаматы алган геройга исә бу хыял-өмет бик кирәк: «ул аны тормыш шакшысыннан саклый».

...Язучыларның бер зур җыелышында Атилла ага Расих: «Фәнни фантастика жанры татар прозаикларын зарыгып көтә»,— дигән иде. Чыннан да, бу юнәлештә бөтен күңелен баглап әлегә бер Адлер Тимергалин гына иҗат итә бугай. Аның уңышлары безне сөендерә, мөмкинлекләре өметләндерә. Әдәбиятыбызга тематик яңалык кына түгел, фикер, сурәт һәм стиль яңалыгы да алып килә А.Тимергалин. Татар фәнни фантастикасының бүгенге торышы, асылда, аның әсәрләре белән билгеләнә, дисәк тә ялгыш булмас. Бу иҗатның үзәк фикерен мәгълүм канатлы сүзләр белән: «Дөньяда кешедән дә кызыклырак нәрсә юк. Иң әһәмиятлесе — аны фикерләргә өйрәтү»,—дип ассызыклап булыр иде. Киләчәк тойгысы аша ул безне бүгенге көннең асылына тирәнрәк төшенергә, чор сулышына сизгеррәк булырга чакыра.

Язучы ачкан фәнни-хыялый дөньяда без инде төп юнәлешне күрә алабыз. Ул юлны Кешегә Ышаныч һәм Киләчәккә Өмет йолдызы яктырта.

1986

ИДЕЛ ТӨБЕНДӘГЕ ЧИШМӘ

*Б*улган, ди, бер Әкият. Ул бик бәләкәй булган. Бәләкәй булгач, аның үсәсе килгән...

Булган, ди, бер Язучы. Көннәрнең

берендә аңа бер зур Фикер килгән. Язучы ул Фикергә бик сөенгән. Аны шунда ук хикәя итеп язарга утырган. Ләкин Фикер артык зур булган шул, аның хикәягә генә сыеп бетмәве күренгән. Әле повестьтан да артып кала икән. Роман хәтле романга да сыеп бетмәве аңлашылган! Каләмен ташлап, уйга чумган Язучы. Шулвакыт аның янына нәни кызы йөгереп килгән. «Әти, әти! Әкият сөйлә әле!» — дигән. Язучы әлеге Фикерне әкият итеп сөйләгән. Чыпчык борыны хәтле генә килеп чыккан, ди, ул әкият... Ә кызчыкның кинәт күзләре очкынланган, йөрәге дәртләнеп типкән, ул шунда ук урамга, иптәшләре янына йөгергән. Әтисенең әкиятен үзе кебек башка балаларга сөйләгән. Ул әкиятне ишетү белән, урамдагы малайлар, кызлар да үзләрендә сәер бер үзгәреш сизгәннәр: аларга дөньяның әллә нинди хикмәтләре аңлашыла башлаган.

Чыпчык борыны хәтле генә әкияттә йомарланып яткан зур Фикер шулай үстергән, ди, аларны...

...Балалар матбугатында Әхәт Гаффарның «чыпчык борыны хәтле» әкиятләре күренә башлагач, әнә шундый экспромт-пародия күңелгә килгән иде. Бер очрашканда (Ә.Гаффарның әле Әлмәттә яшәгән чагы), үзенә дә сөйлисе иттем. Тик ул мондый шаяртуга бик үк разый булмады шикелле, әллә инде хәтере дә калды шунда. Әлеге пародиядә ниндидер челтәү-киная күрде булса кирәк. Югыйсә «әкият»емнең морале бик ачык һәм бик беркатлы иде...

Әхәт Гаффар әкиятләре иң элек тышкы кыяфәте белән җәлеп итә. Кыска, җыйнак; бизәкләре юк дәрәҗәсендә аз (җыелма, портатив әйберләр заманында яшибез бит!). Шуның өстенә алар бертөрлерәк тә («унификацияләнгән»): бер үк башлам — «яшәгән, ди» — һәм «шартлау» рәвешендәге бетем-йомгак. Тышкы гадилеге — «теләсә кем яза алыр иде» кебек алдаучан тәэсир калдырырлык дәрәҗәдә. Нәкъ шуңа да, авторның үз ихтыярыннан тыш, иҗатка ымсындыру-«котырту» көче бар бу гадилекнең. (Мин дә бит әнә шул «коткы»га бирелеп, бер тын белән әкият-пародия «иҗат итәргә» талпынып карадым.)

Әкиятләрнең эченәрәк керсәк, «катып калган» форма эчендә шактый катлаулы хәрәкәт барганлыгын күрербез. Монда нәни укучының колагын торгызырлык тамашалар бар: үз койрыгын үзе ашаган Шалкан гына да ни тора! (Нәкый ага Исәнбәт моны «сенсациячелек» дип атый бугай.) Тамашадан табышмакка бер адым: «Яшәгән, ди, бер Юл... Юл кая киткән?» Инде килеп, гыйбрәтле хәлләр дә җитәрлек: «кулы кычыткан» Пычакның ахырда үзен-үзе тураклавы — шактый нәсыйхәтле тарих түгелмени, йә?

Бөтен сорауларга җавапны, турыдан-туры гыйбрәтне әкияттән генә эзләү дөрес булмас, әлбәттә. Әмма ул — гаҗәп үзенчәлекле, авыр жанр. Монда дилбегәне нык тоту һәм кайсы тарафка, ни өчен баруыңны белү — аеруча мөһим.

«Ни өчен бару» җәһәтеннән, Әхәт Гаффар бер очракта да диярлек дидактик максатны күздән ычкындырмый (ә «дидактика» дигән сүздән оялмыйк). Бу аның әкиятләрен жанр үзенчәлеге ягыннан бигрәк тә мәсәлгә яисә хикмәткә (русның «притча»сына) якынайта. «Кыскартылган» әкият өлгесен махсус саклап, Ә.Гаффар әкияти фикерләүдәге әзер стереотипны җимерергә омтыла. Аның әкиятләренең чынлыкта... әкият булып ук чыкмаулары әнә шуннан килә. Бу яктан алар Рөстәм Мингалимнең балалар өчен язган шигырьләрен хәтерләтә. Тышкы охшашлык турында сүз булуы мөмкин түгел, әмма эзләнүләр юнәлеше бик якын, һәм иң мөһиме — никадәр генә бәхәс уятсалар да, һәр икесенең нәтиҗәләре кызыклы. Әлеге эзләнүләр замана баласының әзерлегенә нигезләнә, аны урап алган мохитнең катлаулылыгын истә тота һәм дөнья белән актив мөнәсәбәткә керү, фикерләү җегәрен көчәйтү максатын алга сөрә.

Сүз уңаенда: әдәби әкият традицияләребезнең ерак гасырлардан ук килүен истә тотсак, бүген шул кызыклы һәм четерекле жанрда эшләүчеләрнең иҗаты аерым игътибарга мохтаҗ, дип әйтәсе килә. Роза Хафизова, Фәнис Яруллин, Нурия Сәйяр, Роберт Батулланың «саф» әкиятләре, Шәүкәт Галиев, Марс Шабаев, Илдар Юзеев, Роберт Миңнуллин, Ләбиб Леронның шигырь-әкиятләре, Туфан

Миңнуллин, Ренат Харис, Юныс Сафиуллин, Зөлфәт, Рафис Корбановның пьеса-әкиятләре... Барлый башласаң, без алай ук ярлы түгелбез икән.

Тик шулай да кызганыч: бу исемлектә Ә.Гаффарның «хикмәт»-әкиятләре бер күренеп алды да бүтән күзгә чалынмады шикелле. Бардыр, билгеле, «тагын язар микән» дип көтүчеләр дә, «табылган форманы сарыф итеп бетерде» дигән нәтиҗәгә килүчеләр дә бардыр. Ә бәлки, ул әкиятләрне онытканнардыр да инде? Һәрхәлдә, автор үзе бу эшкә вакытлы мавыгу итеп кенә карамас, бигрәк тә «бер табылган алымны күпме эшкә җигәргә мөмкин» дип, туктап калмас ич? Чөнки әкият формуласын «сарыф итеп бетерү» мөмкин түгел. Аның чишмәсе бик көчле. Әле без ул чишмәдән асылда бер йотым гына татып өлгердек: никадәр генә төрле-төрле булып тоелмасын, әлеге әкиятләрнең күбесе уртак принципка — җисемнең бер сыйфаттан икенче сыйфатка күчүенә нигезләнгән бит. Иң күзгә ташланганы, мәсәлән, Түшәм белән Идәннең, Баскыч белән Ачкычның урыннарын алышуы булса, игътибар беләнрәк карауга, гадәти Баканың танымаслык Бакага, ә Туң Күчәннең Кәбестәгә әйләнүе күренә. Менә бу әкияттә дә нәкъ шундый әверелеш:

*Яшәгән, ди, бер Суалчан.*

*Яңгыр аны кунакка дәшкән. Бик озаклап җыенгач, киткән бу Яңгыр янына кунакка. Бик, би-и-к, би-и-ик озак барган, ди. Барган да барган. Бер дә ашыкмаган. Бер тамчы да ашыкмаган. Барып җитсә, ни күрсен: Яңгыр моны көтә-көтә Карга әйләнгән..*

Минемчә, әкиятнең шунда төгәлләнүе дә мөмкин иде.

Әмма автор сүзне алга таба дәвам итә, шулай булгач, без дә ахыргача тыңлап бетерик:

— *Кунакка кем янына барсаң да ярый. Кар, син мине кунак ит,— дигән Суалчан.*

*Ләкин Кар аңа ишеген ачмаган. Суалчан ач килеш кире үз өенә кайтып киткән.*

*Кунакка вакытында барырга кирәк. Югыйсә, көтә-көтә, хуҗаның ашы суынып бетә.*

Бу — арада миңа иң ошаган әкият, һәм ул югарыда әйтелгән фикерләрнең барысына да уртак дәлил булса кирәк. Бары тик йомгаклап куючы «нәсыйхәт» турында гына бәхәсләшәсе килә килүен... Хәлбуки, Шарль Перро шикелле атаклы әкиятченең дә үз әкиятләрен шигъри сөземтә-мораль белән төгәлләвен беләбез. Ул «мораль»ләрнең хәзерге басмалардан төшеп калуы да күпләргә мәгълүмдер.

Инде Перродан үзебезнең Гаффарга әйләнеп кайтсак, аның иҗатында да әкият жанрының «яшәве» очраклы хәл булмаска тиеш. Язучының, әйтик, зур прозада фикерне сөземтәләп бирү, контрастлы һәм оригиналь тасвирга омтылу кебек сыйфатлары нәкъ менә шушы «чыпчык борыны хәтле генә» әкиятләрендә кристаллаша.

Күп кенә проза әсәрләрендә алдан билгеле эз буйлап бару, бөтен хикмәтнең бик өстә ятуы шактый туйдыра башлаган иде инде. Ниндидер серлелеккә, кинаяле сурәтләргә, «подтекст»ка ихтыяҗ, сусау артканнан-арта барды. Соңгы елларда күпчелек әдипләребез менә шул ихтыяҗны нык сизеп иҗат итәләр шикелле.

Гомумән, ихласлык, хыялыйлык, ышану — бу төшенчәләрнең нинди киң мәгънәләргә ия икәнлеге барыбызга да яхшы билгеле. Әмма тормышта һәм әдәбиятта әнә шул мәгънәләрнең тараюы, хәтта җуела башлавы күңелне борчый. Тумас борын картайган, Кыш бабайның да артист кына икәнлеген белеп торган «сакаллы» сабыйлар кызганыч. Бу дөньяга да, тегесенә дә ышанмыйча, акча белән аракыга гына табынып тереклек итүче олылар кызганыч. Үткәнгә һәм киләчәккә, бүгенге чынбарлыкка һәм үз-үзенә ышанычын югалтса, адәм баласына ни кала?! Аны һәлакәттән аралап алырга, моның өчен тою һәм уйлау сәләтен уятырга, тормышка мөнәсәбәтен көчәйтергә кирәк! Бүгенге әдәбиятның төп көрәш мәйданы шундадыр. Дөньядагы хисапсыз әкиятләр дә ул тигезсез көрәш мәйданындагы гади сугышчылар булып күз алдына килә.

Язучы буларак Әхәт Гаффарның бу юлда үз эзләнүләре, үз табышлары бар. Аның әкиятләре — шул эзләнү агымының ярга ныграк кагылган мәле, ягъни барыбызга да тоемлы булып чайпалган бер дулкыны.

Ахыр килеп, әлеге тәҗрибәләрендә Ә.Гаффарның тел-стиль үзенчәлеге дә бүтән яктан ачылып ала. Әйтик, зур проза һәм сәхнә әсәрләрендә язучының сүз белән «дистанция»не саклый алмаган кебек тоелган урыннары очрый. Шундый чакта, фикерне, поэзияне кысрыклап, сүзләр артык тыгызлана — сулыш алулары кыенлаша, тын җитми башлый... Бу хәл рәссам полотносында «һава биреп» җиткермәүне, күзгә кереп торырлык җете төсләр белән генә мавыга төшүне хәтерләтә. Әллә автор моны юри, сүзләрне «үзләренең янәшә торуына гаҗәпләнерлек» итәсе килеп эшлиме? Шунысы

кызыклы: «һава биреп җиткермәү» хасияте әкиятләрдә алай ук күзгә бәрелеп тормый. Күрәсең, аларга әкият патшалыгының традицион, даһи гадилегеннән бер нур төшәдер...

Әхәт Гаффарның балалар өчен иҗат иткән хикәяләрендә дә сизелә ул яктылык. Соңгы елларда ул андый хикәяләрне байтак кына язып, алардан «Су астындагы чишмә» дигән бер җыентык туплады. Китапның исемендә зур мәгънә бар: чыганакларны саклау, киләчәкне кайгырту...

Чыннан да, балалар укысын дип язылган һәр яхшы әсәр — гомумән халыкның киләчәген кайгырту инде ул. Балалар өчен иҗат итү, бер изге чишмә булып, язучының үз Иделен дә туендырып тора!

...Пародиямне Ә.Гаффар бик үк ошатып бетермәде, дигән идем. Ул чакта мин аның әкиятләре турында «нәрсәдер» язу ниятем барлыгын да сиздердем.

— Тик... язарыма нокта куяр өчен бер әкият кирәк. Ул әкиятнең башын мин уйлап та куйдым инде,— дидем. Шартыма күнгән кебек булса да, байтак вакыт үтте — әкият язылмады; димәк, мәкаләнең бетем өлеше һаман юк иде.

Бетем димәктән, кайбер әкиятләрнең «шартларга» тиеш урында әллә ни шартлап чыкмавы хакында сөйләшеп алдык без ул көнне.

Бигрәк тә бер әкият кызганыч тоелды. Бөтенесе йоклагач, үзара кунакка йөрешүче йортлар турындагы әкият. Күпне вәгъдә итеп тә, шәп тәгәлләнә алмаган әкият. Язучы, һичшиксез, аның дәвамын яисә яңа вариантын язар кебек иде...

Аннан соң инде Ә.Гаффар прозада, драматургиядә бөтенләй үзгә әсәрләр бирде. Хәтта шигырьләр дә язып бастырды. Әкиятләргә әйләнеп кайтуы гына күренми. Шулай да, әкиятче автор турында соңгы фикерне әйтергә иртәрәк, дип уйладым мин. Һәм аның иҗатындагы бер «эксперименталь» якны күздән кичергән язмага «нокта» эзләп баш ватмаска булдым. Хәзергә Әхәт Гаффарның иске әкиятләрен дә укый торырга була ич!

Ә мин башлап биргәне менә болай иде:

*Булган, ди, бер Әкият. Ул бик бәләкәй булган. Бәләкәй булгач, аның үсәсе килгән...*

...Ишетәсезме, Әкиятнең үсәсе килә!..

1984

ЫШАНАСЫ КИЛӘ

Өмет бөресеннән шатлык яфрагы борын төртә: Җир шары кадәрле олы ак күмәч пешерәсе бар...

Рахмай Хисмәтуллин

Инде кайчан укылган кечкенә генә бер парча, ә күңелдән китми, күз алдына килә, тел очында тора: Сары Сагыш Йомгагы... Әлләкем дә түгел — сары суккан йөзе, якты дөньядан ваз кичкән кыяфәте өчен шундый кушаматка тап булган бер авыру... Тәрәзә төбенә песнәкләр килүен күргәннән соң бик тиз савыгып, шифаханәдән чыгып киткән бер агай... Бу хәл ышандырып та җиткерми. Ә ышанасы килә бит шуңа!

Рахмай Хисмәтуллин, ахрысы, шигырь язудан башлагандыр... Аның әсәрләренә — төрле көнкүреш хәлләре һәм эш-тормыш мәшәкатьләре белән тулы мәйдан өстеннән, шактый тыгыз саф булып баскан исемнәр аллеясы арасыннан — инде тын кысыла башлар, дип торганда гына, саф җил булып лирик агым ургылып керә. Шунда ук ул, гадәтилек болытларын бер читкә этәреп, шигъри образ яктысына коендыра...

«Сары Сагыш Йомгагы» дигән моңсу-шигъри исемдә дә язучыга иң хас үзенчәлекләрдән берсе — аның тормыш фактларыннан аерылырга теләмәве һәм шул ук вакытта алардагы гомуми, уртак сыйфат-мәгънәләргә генә таянуы, хис белән фикерне, сурәт белән фактны, кыскасы, конкретлык белән гомумиләштерүне кызыклы гына нисбәттә бергә куша алуы ачылып китә. Бу исә — язучы алдына тормыш үзе куйган авыр һәм катлаулы бурычның — кешедән Кешелеклелек үзәген табу һәм шул хакта дөресен сөйләү бурычының үтәлә башлавы дигән сүз.

Әйе... Сары Сагыш Йомгагы үзенең шигърилеге, көтелмәгәнлеге белән тансык, шуңа да күңелдән китми икән.

Язучы укучысы белән уртак тел таба белә, үзен гади тота, игътибарлы һәм ихлас булып кала. Әсәрләреннән күреп, аңлап торасың,— ул тормышның ачысын-төчесен шактый татыган: кыенлыкларның сәбәбенә төшенеп, каршылыклар белән тартыша-тартыша, дөньяда яктылык һәм яхшылыкның күбрәк булуына инанган. Шуңадыр да матурлыкны күрә, бәяли, аңлата белә: кеше матурлыгын, хезмәт һәм мәхәббәт матурлыгын.

Рахмай Хисмәтуллинның яраткан геройлары —хезмәт кешеләре. Алар — тормышта үзләрен эш белән раслаучылар. Бәлки, аларның һәркайсы да шәхси тормышта, шәхси мөнәсәбәтләрдә җайлашып бетә алмагандыр,— чөнки мохит һәрвакыт катлаулы, каршылыклы; гадел принципны өстен куйганда, әлеге чуар мохиттәге һәркем белән килешеп бетү мөмкин дә түгел... Алар —җиң сызганып яңаны төзүче, нык ихтыярлы, ике аягы белән дә җиргә басып торучы һәм күңелләре белән күктә гизүче, «акылга утырмас» романтиклар, шагыйрь җанлы кешеләр.

Рахмай Хисмәтуллин шигырь язудан башламадымы икән, дигән идек. Моңа бер нигез — аның әсәрләрендәге әлеге шул яхшы мәгънәсендәге бунтарьлар, исәп-хисаплы дөнья белән тигезсез көрәшкә чыккан хыялыйлар һәм альтруистлар. Шуның өстенә, әлбәттә, хикәяләүдә эмоциональ, образлы телгә, шигъри сурәт алымнарына омтылу... Хәтта үзенә күпмедер кыенлык китерсә дә, логикадан бигрәк, хискә таяна төшү, мавыгу... Шагыйрьлек — аның күпчелек әсәрләрендә. Тышкы хәрәкәттән күбрәк эчке хәрәкәт — кичереш, фикер хәрәкәте. Ләкин бу язучының иң төп һәм, ихтимал, иң кызыклы үзенчәлеге әле генә әйтелгәннәрдә түгел. Рахмай Хисмәтуллинның барлык әсәрләрендә дип әйтерлек, үрнәк һәм гыйбрәтле геройлары арасында тагын бер кеше йөри. «Лирик герой»мы ул? Әллә язучы үземе, дөресрәге, аның күңел күземе?.. Югыйсә ул бөтенесен күреп, аңлап һәм теркәп торучы «гамәл фәрештәсе» дә түгел, ул кайвакыт чишелеш юлын бик озак эзли, адаша һәм ялгышкалый, чын күңелдән көенә һәм сөенә, хәтта кайсыбер очракта, онытылып китеп, әдәби әсәр кысаларыннан чыга ук башлый... Р.Хисмәтуллинны укыганда сез моңа игътибар итегез әле! Авторның дилбегәне әледән-әле үз кулына алуы, вакыйгалар уртасына ташлануы, әлбәттә, иң әүвәл аның тынгысыз холкы, ташып торган җегәре турында сөйлидер. Шул ук вакытта бу — язучының тормыш һәм әдәбият каршындагы шәхси җаваплылык хисен тоюы да булып аңлашыла.

Әхлакый тойгының аеруча сизгерлеге, нечкәлеге — язучыны үз геройлары белән якынайта, туганлаштыра торган сыйфат. Бер очракта ул кеше рухының тазалыгына, кеше акылының мөмкинлекләренә соклана, адәм баласына матурлык чыганакларын табышып йөри. Икенче очракта, проза рентгены ярдәмендә, ул кеше күңеленең иң караңгы бүлмәләренә дә үтеп керергә, катлаулы психологик процессларны, рухи авыруларны, аларның шәхси һәм социаль сәбәпләрен ачып җибәрергә тырыша. Сорауларга җавап һәрвакытта да табылмый, андый чакта йөрәкләрне кысып алучы тойгы кала: әнә шулай укучыга әсәрдән язучының әрнүе, сыкрануы күчә. Барып чыкмаган язмышлар өчен, эшкә ашмаган мөмкинлекләр өчен... «Кеше була» бару баскычларыннан өскә күтәрелгән саен, рухи яктан түбәнгә, упкынга төшә баручылар өчен.

Рахмай Хисмәтуллин иҗатында без, әледән-әле, гадәти дөнья мәшәкатьләренә уралып, гаилә мөнәсәбәтләре эчендә югалып калган кеше, тип белән очрашабыз. Кайсыдыр яклары белән аның хәтта безнең танышларыбызга, күршеләребезгә, якыннарыбызга охшаган булуы мөмкин. Кыскасы, явыз-ялмавыз, бөтен дөньяга үче каткан бәндә димәссең. Була шундый вакытлар: башкалар алдында йөрәген ачып, аларның үзен аңлавына ирешергә тели ул, үзенең кирәкле зат булуын тоярга тырыша. Максатына ирешә алмаганда, аның әлеге талпынуы фаҗига дәрәҗәсенә күтәрелә. Андый герой тоташ газап эчендә кала. Башкалар инде аны бердәнбер сыйфатлары — кайчандыр үзе югалткан, әле онытып бетермәгән, әмма инде кире кайтарып ала алмый торган күңел гармониясенә ия булулары белән генә кызыксындырып куялар... Нәкъ шул ук сәбәпләр аркасында, аңарда көнләшү, чит итү, хәтта нәфрәт хисе уяталар... Чөнки ул — нәкъ менә башкаларга охшарга, «кеше кебек» булырга тырыша-тырыша, ахыр килеп, үз йөзен югалткан бәндә. Очраклы хәлмени, аның турында сүз барганда, нәсел-нәсәбе, ата-анасы йә бөтенләй искә алынмый, йә ул үзен тудырган-баккан кешеләрне оныткан, кире каккан икән...

Ул, әлбәттә, тамырдан өзелгәнен сизә, шул өзелүдән туган авырту тойгысы әле дә басылмаган бугай, һәм бу хәл бездә кечкенә генә булса да өмет чаткысы калдыра.

Нигә әле без бу типка болай озаклап, йөзенә текәлеп карыйбыз? Юкка гына түгел. Китапка ул бүгенге тормышыбыздан, югарыда әйтеп үтелгәнчә, гадәти таныш-белешләребез арасыннан килеп кергән.

Язучы бик нигезле раслаганча, үз гаиләсендәге гариплекләргә тормыш үзендәге үк саф-таза көчләр, уйлап чыгарылмаган геройлары белән каршы тора. Алар — кешелеклелек белән мәнсезлек, риясызлык белән исәп-хисапчыллык якага-яка килгән фронт сызыгында, матди көнкүрешебездә туган катлаулы коллизияләр эчендә. Шундый геройлар —замандашларыбыз образлары аша мәрхәмәтлелек һәм мәхәббәт утын, ата-баба йолаларын буыннан буынга күчерә килүнең мәгънәсе раслана.

Язучы белән бергә без кешеләрнең авыр хаталану вакытларын күзәтәбез, ләкин ул бәян иткән вакыйгалардан кырысланып, аның геройларыннан йөз чөереп чыкмыйбыз, ә сафлана һәм айный төшәбез. Моның хикмәте шунда: язучы, кемгәдер хөкем карарын чыгару белән шөгыльләнмичә, үзе сурәтләгәнне укучы белән бергә яңабаштан кичерешә. Ул бер очракта да әзер чишелешләр тәкъдим итми, ул тормышның без әле чиркәнчек алырга өлгермәгән тагын бер агымына алып керә,— конфликтлар, язмышлар, эшләр һәм фикерләр агымына.

Турысын әйтергә кирәк, Рахмай-Рәхмәтулла агай әсәрләрендә кызыклы, хәтта гадәти булмаган теге яки бу теманың да бөтен тирәнлеге, киңлеге белән ачылып бетми калган очраклары бар әле. Проза жанры тормыш материалын әзер кысаларга бөгәрләп салырга тырышуны, мавыгып китеп, комнан кала салуны кичерми... Шулай да, әлеге әсәрләрне укыганда, укучы күңелендә сораулар, борчылу һәм сөенү хисе, кеше һәм дөнья язмышы турында уй кузгалып кала. Күрәсең, андый сәхифәләрнең дә язучы иҗатында үз урыны булу белән килешергә туры киләдер.

Бөекләрдән берәү, эшкә тотынсаң, мәңге яшәрдәй булып зурдан кубарга, ә дога кылсаң —якаңнан әҗәл суырып алгандагы кебек, бөтен ихласыңны салырга кирәк, дигән. Шундый ярсулы омтылыш, күңелне кузгатырлык ихласлык бар, минемчә, Рахмай Хисмәтуллин иҗатында. Ә бу иң мөһиме түгелмени?

1984

## МӘҢГЕЛЕК ГАМЬ ТУФРАГЫННАН

Бөтен дөнья бәнем улса,
Гамем бетмәс,— нәдәндер бу?
Әзәлдә гамь торабилә
Яратылмыш бәдәндер бу!

Әбелмәних Каргалый

Ир-егетнең күңелендә иярле ат ятар, диләр. Әгәр шагыйрьнең җаны миһербанлылык, кешелеклелек белән тулы икән, шигырендә зәңгәр күзле мәхәббәт яисә бөек төзелеш хисләрен җырлыймы, уй-кичерешләре белән тирән тарихка яисә ерак галәмгә юл аламы,— ул һәрвакыт үзенең төп эшен башкара, изге ниятен гамәлгә ашыра.

Аның сүз киеменә төренгән кайнар йөрәк тибешен тою бүген безгә — исәп-хисап заманында яшәүчеләргә бик кирәк. Кешене рухи ялгызлыкта калдырырга ярамый бу заманда! Кешелекле әдәбият, тормышчан шигърият бүген, тыны кысылып дөнья иминлеген күзәтүче компьютер кебек, адәм баласының йөрәк тибеше сагында тора.

Менә шуңа күрә, бөтен вак-төяктән араланып, шигърияттә үзеннән-үзе аңлашылган кебек тоелган иң мөһим таләпләр турында сөйләшәсе иде. Шагыйрьнең үз сүзе өчен җаваплылыгы турында. Әлеге сүзнең җаныннан үткәреп, газап чигеп табылган булуы турында.

Артык сайланып тормастан, бер шигырьгә тукталыйк әле:

Хисләнә күңел, шомлана
Шаулы урманда йөреп:
Һәр имән әти кебек тә,
Һәр тирәк әни кебек.

Хушлана күңел, сафлана
Яшел урманда йөреп.
Үткәннәр белән күрешеп,
Серләшеп йөрдем кебек.

Җыйнак, гадәти, күзгә кереп тормаган сигез юл. Гадәтилеге, әйтик, кое авызы сыман: аның барлыгын да сизмисең. Ләкин коесы тирән! Аңа үрелепләр генә карасаң да, чиксезлектән башың әйләнеп китәрлек. Әгәр тышкы ялтыравы белән күз явын алса, ул болай ук чын булмас иде, табигый булмас иде, йөрәкне дерелдәтеп алмас иде. Безнең күз алдында — кеше язмышының, үзәк өзелүнең, күңел хатирәләренең шигырь булып яши башлавы. Әлеге шигырьнең чынлыгы фикер зурлыгында яисә сурәт тыгызлыгында гына түгел, ә иң беренче нәүбәттә — кеше яшәешенең олы, кайнар гәүдәләнеше булуында. Чиксезлеге — безне әнә шул рухи тормыш галәменә алып чыга алуында.

Шагыйрь (бу очракта ул — Гамил Афзал) тормышны шигырьгә салуның иң авыр юлыннан бара: дөнья бөтенлеген аңлаган, үзе шул гармониягә, камиллеккә омтылган халәттә... Капма-каршы күренешләрне, сурәтләрне, рифмалашырга торган сүзләрне бер-берсенә чагып очкын чыгару —аның юлы түгел. Ул үзе яна. Мәңгелек ташта сыны уелып калган күбәләк язмышын сайлый. Бу —чын шигъриятнең кәрван юлы сузылган юнәлеш.

Татар поэзиясенең нигезе йөрәк каны белән язылган шигырьләрдән тора. Ул — «олы юлның җилләренә» күкрәк куеп, тормыш «карурманнары» тирәнлеген яктыртып килгән шигърият. Тарихы бай: таза катламнарга таянып яңа нигезләр күтәрелә, яңа нигезнең ныклыгы аша аскы катламнарның куәте-җегәре сизелә.

Бик таныш мисалга әйләнеп карыйк: Муса Җәлилне һәм аның «Алтынчәч» поэма-либреттосын гына искә төшерик. Нигезендә — халкыбызның батырлык һәм мәхәббәт тантанасын җырлаган риваятьләре, әкиятләре, аларда гәүдәләнгән каһарманлык тарихы... Сизгер күңелле шагыйрь дөньясына, нидер әйтергә, кисәтергә теләгәндәй, тылсымлы алтын каурый сыман, халык иҗаты аһәңнәре агыла... («Алтынчәч»не Җәлил 1941 елда язып тәмамлый.) Ихтимал, Европадан исәргә торган сугыш җилләренә каршы күтәрелгәндер ул әкиятләр...

Зөлфәтнең «Йөрәкләрдә үлмәс дастан» поэмасына («Алтынчәч» белән ике арада — кырык ел!) каян килә икән ул әкиятләр рухы? Алар кешене тагын нинди афәтләрдән яклау өчен күтәрелделәр икән?..

Халыкның гыйбрәтле үткәненә, анык «саф вә раушан көзгесе»нә күз салу — тарихның тирән, караңгы коесы төбеннән су алу — җиңел түгел.

Заман тормышын тарих тирәнлеге аша аңлау һәм тарихның үзенә яңача караш аеручa житмешенче-сиксәненче еллар әдәбиятында яңа импульс алды, ул үткән белән бүгенгенең диалектикасын, кешелеклелек нисбәтен эзләү рәвешендә чагылды.

Бу елларда фронтовик әдипләргә генә түгел, соңрак туган буыннар иҗатына да сугыш хатирәсе яңа көч белән әйләнеп кайтты. Сугыш һәм иминлек турындагы иң яхшы әсәрләре аша татар әдипләре бөтен халык белән, ил әдәбияты белән тоташтылар.

Фронтовик шагыйрьләр иҗаты безнең поэзиябездәге хәтер һәм җаваплылык тойгысының көчәя төшүенә ярдәм итте. Укучысы алдында шигырь барча ишек-тәрәзәләрен ачты. Тормыш конфликтларын яхшылык белән явызлыкның тышкы бәрелеше буларак кына түгел, ә кеше күңелендә барган килешмәүчән көрәш нәтиҗәсе итеп сурәтләү өстенлек ала башлады. Бүгенге поэзиядә шул процессның сафландыргыч нәтиҗәсе ачык сизелә: кешене ыгы-зыгыдан аралап, табигать белән, тормыш асылы белән, ниһаять, үз-үзе белән күзгә-күз калдыру, мәңгелек сораулар хакында уйландыру омтылышы көчле булган әсәрләр иҗат ителә.

Хәтер көче безне дөнья бөтенлеген, тормыш гармониясен аңлауга алып чыга. Әнә шул гармонияне тоюдан, аңа омтылудан шигырьләрдә гамьлелек тойгысы көчәйде. Бөтенлеккә ирешергә омтылу теләге поэзиянең эчке төзелешен баетты, образлар мөнәсәбәтен катлауландырды. Ул үзгәрешләр «Дәверләр капкасы» (С.Хәким), «Рәссам» (Р.Харис), Ш.Галиев һәм Р.Мингалимнең балалар өчен язган яңа шигырьләре рәвешендә барлыкка килде. И.Юзеевның шигъри трагедияләрендәге жанрлар синтезы, катлаулы образлар системасы олы фикер биеклекләрен яулау максатына буйсына. Шагыйрь үткәнгә һәм киләчәккә, үзенә һәм кешеләргә мөрәҗәгать итә, вакыйга һәм ара ераклыгын кичәргә омтыла! М.Шабаев —ярлары һәм тирәнлеге үлчәнмәгән табигать агымына, Ш.Галиев — табигатьнең үзе кебек мәңге яңа, саф балачак дөньясына, фронтовик шагыйрьләребез — вакыт һәм мәгънә ягыннан чиксез сугыш хәтеренә төбәлгән...

Сибгат Хәкимнең моннан ун еллар элек тәнкыйтьче Тәлгат Галиуллин белән әңгәмәсе вакытында: «Узганнарыма мин бүгенге позициямне тагын бер ачыклау өчен генә кайтам»,— дигәне хәтердә. Бу сүзләр аның «Эзлиләр Европа буйлап» поэмасына да кагыла (1982 елда иҗат ителгән).

Инде шагыйрь сугыш эзләре буйлап «Үрләр аша» үткән иде, аннары «Дуга» поэмасын, яңа шигырь бәйләмнәрен иҗат итте. Ул әсәрләрдә бүгенге көнгә утлы еллар аша сынап карау, ә сугыш чорына һәм аның кешеләренә яңадан бер кайтып бәя бирү бар. Шулай да... «Эзлиләр Европа буйлап» — шагыйрьнең кабатлана башлавы түгелме бу? Күңел биографиясенә әверелгән материалга, яраткан темаларына, чынлап та, ул торган саен ешрак әйләнеп кайта, аларда озаграк туктала... Ә бит «Дуга» поэмасына кереш сүзендә үк әйтелгән: «Уттан бер чыкканнан соң икенче тапкыр керәсе килми. Әсәргә алыну минем өчен утка керү белән бер...» — дигән юлларын хәтерлибез. Бер алынган биеклекне кабат-кабат яулар өчен утка керер идемени шагыйрь?

Сугыш күренешен С.Хәким дөньяның чиксез бер халәте итеп ача, аның яңадан-яңа борылышларын, мәгънәләрен эзли. Ут эченә һәр керүендә шагыйрь үз алдына яңа, әлегәчә хәл итәргә алынмаган авыррак бурыч куя һәм аның чишелешен табарга омтыла.

Күрермен микән бу каты
Дөньяның йомшаруын,
Тоташ бер иген кырыннан
Торганын Җир шарының?

С.Хәкимнең фикер агышы укучыны һәрвакыт көтелмәгән ярга алып чыга. Сүзләре, сурәтләре гади-табигый, җирдән, халыктан. Аларда — гаҗәеп мәгънә аваздашлыгы. (С.Хәким рифмалары дигән феноменаль күренешне галимнәрнең өйрәнәсе бар әле.) Бу, бәлки, осталыкның үзедер?.. Шагыйрьнең инструменты, алымы сизелмәүдәдер, бәлки, бу осталык. Әлеге дүрт юлны кабат укып карагыз, тыңлап карагыз: «каты... дөнья», «иген кырыннан... торганын» дигән мәгънәви бөтен өлешләр, кинәт тын беткән кебек, урталай өзеп кенә калдырыла. Борчулы бу юлларның йөрәк тибеше — киеренкелекне

чак кына арттырсаң да, тын кысыла башлар төсле. Күз алдына офыктан офыкка җәелгән иген кыры килмәсә, күңелдә авыр тойгы калыр иде. Шагыйрь моны истә тоткан, күрәсең.

Поэзиябез соңгы егерме ел эчендә катлаулы тормыш белән яши. Аның тирән агымында — ургылып-ярсып алган борылмалар, шигъри сүзнең җегәрен сынаучы төрле бусагалар... Өлкән шагыйрь шул кайнап торган, вакыт-вакыт кирегә ургыла башлаган ташкында ничек итеп үз иманына хилафлык китермичә, яңадан-яңа дулкыннар алдында бер үк дәрәҗәдә абруйлы булып кала алган? Талант көче, үз-үзенә ышанычы беләнме? Янә — традицияләргә тугрылыгы — нык тамырлары беләнме? Мөгаен,  шулайдыр. Болар өстенә, шагыйрь үз иҗатында яңа юллар эзләүдән туктамаган, яңа чынбарлыкка алдан тамыр җибәреп килгән. Тарихта һәм бүгенге чынбарлыкта киләчәк яралгыларын күрү, фикерләүдә заманны тою, заман төсләрен, заман сурәтләрен аеру аша.

Димәк, бер яктан, талант көче һәм иҗади эзләнүләр, икенче яктан, әдәби-мәдәни традицияләрнең, халык тарихының зурлыгы, горурлыгы белән бергә, шагыйрьнең өченче таяну ноктасы да бар. Заман тойгысы... Шагыйрь дәверләр капкасына әнә шул ноктага таянып баса.

Шигърият тарихы катлам-катлам. Туган еллар аермасы булырга мөмкин, бер дулкын белән килүең яки яшьтәшләреңнән аерылыбрак калуың ихтимал, хәтта талант дәрәҗәләренә карамастан — шигырьгә, шагыйрьгә, поэзиягә Вакыт дигән көчнең тәэсире зур. Агачның ел боҗралары кебек, ул беренче карашка күренми, аны соңыннан, билгеле бер чикне үткәч кенә белеп була: корылыклы еллар, уңдырышлы еллар... Шул елларда —инде талант көченә, шәхес үзенчәлегенә карап —кем ничек тамырлана да, кем ничек үсеп китә...

Менә, мәсәлән, безнең әдәбияттагы кызыклы күренешләрнең берсе — «41 нче ел балалары» иҗаты. Мөхәммәт Мәһдиев һәм Нурихан Фәттах, Әхсән Баянов һәм Роберт Әхмәтҗанов, Фәнис Яруллин һәм Туфан Миңнуллин, Шәүкәт Галиев һәм Илдар Юзеев... Бу шәхесләрнең һәркайсы —күтелмәгән яктан ачыла баручы бер дөнья. Алар турында сүз күп булды, алга таба да булачак. Охшашлыкларыннан — үзенчәлек, үзгәлекләреннән уртаклык эзләячәкләр.

Сугыш вакытында малайлар күп туа, диләр. Булачак солдатлар туа, көрәшчеләр туа... Әтиләре урынына каласы малайлар... Сугыш утына каршы табигатьнең үзенчә көрәшүе микән бу?.. Сугыш вакытында шагыйрьләр дә күбрәк туадыр төсле. 43 тә — Равил Фәйзуллин, 42 дә — Кадыйр Сибгатуллин, 41 нең үзендә —берьюлы дүртәү. Гәрәй Рәхим сугыш башланып өч атна узгач туган — шук-җитди, моңлы-наян:

Сугыш җиле, әткәй, күкрәгемдә
Салкынаеп тора кар булып.

Кулъяулык чигеше сыман садә-самими һәм катмарлы Рәшит Әхмәтҗанов:

Җәрәхәтләр эзен тәннән
Көмеш сулар гына юмас.
Бәлки инде хәзер Җирдә
Миңа охшап беркем тумас?!

Бу ел балалары инде «гомер уртасыннан хатлар» яза. Рәдиф Гатауллинның ул хатларында — үткән белән бүгенгенең аерылгысыз берлеген тану, Вакыт бөтенлеген тою. Даимилек белән үсешүзгәрешнең, мизгел белән мәңгелекнең катлаулы бердәмлеген аңлау.

«Гомер уртасыннан хатлар» (сүз шул исемдәге әсәр турында гына бармый) — Р.Гатауллин иҗатындагы яңа әйләнеш. Ул үз хатларының адресатын ачык күрә, аның белән уртак тел табарга ашкына, шуңа күрә әлеге шигырьләрдә ихласлык, җылылык арта, алар бер-берсе белән тоташып китә, дәвамлы һәм бербөтен системага буйсына башлый. Бу хатларда — шагыйрь иҗатының төрле катламнары, төрле чорлары, аларның кызыклы аваздашлыгы. Арада көндәлек язмалары кебек үз эченә бикләнеп-йомылып торганнары да бар... Ләкин төп тенденция — шагыйрьнең эзлекле рәвештә әлеге боҗрадан чыгу юлын эзләве; ул, үзе дә ачыла бару исәбенә, дөньяның бөек серенә ирешергә, тормышның тирән агымына чыгарга, аның белән кушылырга омтыла. Шуңа күрә шагыйрьнең соңгы елларда язган, узып баручы гомер агышына каршы торырлык, мәхәббәт тугрылыгын җырлаучы әсәрләре борчылу, хәвефләнү дәрәҗәсенә җиткән тынгысызлык белән тетрәп тора.

Вакыт агышына, табигать һәм яшәеш ритмнарына үтә сизгерлек,— гомумән, әлеге буын шагыйрьләрен берләштерүче сыйфат. Аларның тынгысызлыгы, активлыгы, бер халәттән икенчесенә күчеп, үзгәреп һәм яңарып торуы, бер сүз белән әйткәндә, камиллеккә омтылу нәтиҗәсе булырга

тиеш. Шушы омтылыш «кырык беренче елгылар» иҗатына тынгысыз хәрәкәт, җегәр бирә. Тынгысызлык — аларның җитди эзләнүләрендә, рухи һәм әхлакый максимализмында, шигырь интонацияләрендә.

Р.Харис белән бергә, күренешләрне көтелмәгән янәшәлеккә куеп, аларның уртак нигезен эзлибез, тормыш каршылыкларының катлаулы бердәмлеген табарга тырышабыз.

Мин — йолдызның җанлы күмере —
Кабат кайтып яшим...
Әйләнештә
Хәтеремнең чиксез гомере!

Шагыйрь дөньясында — башка вакыт үлчәве. Яшәү һәм акыл билгеләгән кысалар хәтер чиксезлеге алдында көчсез. Кеше гомере вакыт һәм ара ераклыгында Мәңгелек белән тоташа...

Бөтен дөнья бәнем улса,
Гамем бетмәс,— нәдәндер бу?
Әзәлдә гамь торабилә
Яратылмыш бәдәндер бу!

«Әзәлдә гамь торабилә...» — «Мәңгелек гамь туфрагыннан!» Бу юлларны XVIII гасырда ук татар шагыйре Әбелмәних Каргалый язып калдырган. Заманының зур укымышлысы, зур шагыйре.

Арада ике йөз ел ята. Шигъриятнең кешене бөеклеккә һәм биеклеккә әйдәүче юлы дәвам итә...

Мондый шигырьләрдә шагыйрь шәхесенең зурлыгы, аның рухи галәме ачыла. Шәхес булу ул — эзләнүдән, үсүдән туктамау, яуланган биеклекләрдән ары — үзеңне дә узып үсү, башкаларга юл ачаача үсү дигән сүз икән...

Р.Харис, Р.Мингалимнәр буынындагы шагыйрьләрнең иҗади казанышлары нигезендә — әнә шул үсеш авырлыкларыннан курыкмау, фикергә судагы балык кебек иркен яшәеш бирергә омтылу.

Алтмышынчы еллар уртасында мәйданга чыккан һәм үзенең кыйбласына тугрылыклы калган бу шагыйрьләрнең көче — баштан ук яңалык өчен дауга, көрәш һәм гражданлык поэзиясе диңгезенә кушылуда, шул диңгезнең яңа күтәрелешендәге беренче һәм куәтле дулкын булуда.

Игътибар иткәнегез бардыр: ак ялларын ничек туздырып, нинди көч-гайрәт белән килә ул беренче дулкын! Аның ярда ярылып калган эзен инде башка дулкыннар күмә алмый, тирәнәйтә генә...

Безнең поэзиядә бүген дә әнә шул яңарыш процессы дәвам итә. Әлеге процесста үзенчә ачылып киткән төрле буын шагыйрьләрнең әсәрләрен укыганда күңелдә бер сөземтә кала: гомумкешелек идеалларын җырлау һәм башың белән йолдызларга орыну өчен татар шигъриятенең туфрагын тоймас хәлгә җитү кирәк түгел; киресенчә, туган тел ачкычларын табып, халыкчан фикерләү рәвешенә таянып, дөньяның яңа багланышларына, көтелмәгән масштабларына үтеп керү юлларын эзләргә кирәк. Шигъри ачышлар табигатьне, кешене бербөтен яшәешеннән аермый караучыларның юлында күбрәк очрый.

Мондый шигырьләрнең көче-җегәре — укучыны хис чынлыгы һәм фикернең күз алдында тамырланып, үсеп, яфрак яруы белән әсәрләндерүдә. Аларның катлаулылыгы — нигездә тормыш һәм кеше язмышының катлаулы булуыннан. Хис һәм фикер җәһәтеннән бербөтен булып, эзлекле үсеш хәрәкәте аларда тышкы билгеләрнең гадиләшүе, конкретлыкка, табигыйлеккә, нәфислеккә таба юл алуы рәвешендә чагыла.

Шагыйрьләрне, бигрәк тә аларның төрле буыннарын, бер-берсенә каршы куярга ярамый, әлбәттә. Шулай булса да, чагыштырып карыйсы килә... Бүгенге яшьләрдә тормыштан шигърият табу ничегрәк бара? Табигатьне, дөньяны һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне аңлаудан сурәт яңалыгына, фикер яңалыгына таба юлны ничек үтәләр алар?.. Тасвирланган вакыйгасы белән берберсенә шактый якын ике мисал алыйк әле.

Беренчесе. Өлкән шагыйрь кызын җитәкләп мәктәпкә бара. Ләкин аны үз балачагы турындагы уйлар били:

Минем язым койды үз гөлләрен.
Кайда минем шаулы урамым?

Баласы язмышында — аның өчен үз тормышының дәвамы, үз намусының пакьлеге. Утлар-сулар кичкән шагыйрьнең сүзе кырыс, таләпчән. Аның үз-үзенә таләпчәнлеге баласына, кешеләргә күчә.

Икенче мисал — яшь шагыйрьдән:

Бир кулыңны, кызым!
Чәчәк кебек
нәни кулың бераз җылынсын! —

дип, җайсыз гына сүз башлый ул, әмма шул гади тойгы-хәрәкәтләрдән көтелмәгән җитди нәтиҗәгә алып килә:

...Мин икенче кулда тоям һаман
Әтиемнең кулы җылысын.

Яшь авторда хис җылырак, йомшаграк. Ул үзен һәм баласын буыннарны ялгап торучы, үткән белән киләчәкне тоташтыручы бер бөҗра итеп, шул вазифада бертигез җаваплылыкта күрә.

Бер-берсенә охшамаган ике авторны берләштерүче нигез — югалтулар ачысын кичерүдән тормыш тулылыгына ашкыну тойгысы, киләчәк турында гамь уртаклыгы.

Гади генә тормыш күренешләренең гади күз белән күреп булмаслык эчке бәйләнешен, тылсымлы төшен табып килүче бу шигырьләргә поэзиябезнең кешелекле традицияләре яктысы төшә. Әнә шундый ихласлыкның, күнел җылысының яшьләр иҗатында да ныклы урын били баруы — икеләтә сөенечле күренеш.

Соңгы елларда гына гөлт итеп берничә исем кабынды: Ркаил Зәйдуллин, Ләис Зөлкарнәев, Ләбиб Леронов, Газинур Моратов... Арадан Ркаил Зәйдуллин иҗатын аеруча кызыксынып күзәтәм. Аңардан алдарак килгәннәр дә билгеле бер бөҗра эченнән чыга алмый торганда, ул, үсү авырлыкларын җиңә-җиңә, шагыйрь буларак ачыла бара. Иң мөһиме: ачыла-үсә барган саен, тамырга ныграк таяна. Туфрак белән бәйләп торучы хисләр Ркаилдән «Ишек ясый Гали-баба» кебек чын шигырьләр яздырта. Кайчакта ул, давыллы диңгез белән алышуның дәһшәтен белгән хәлдә, бүтәннәр яр буенда таптанып торганда, кемнедер үзенә таныш түгел берәүне коткару өчен ярсулы стихия эченә кереп киткән егет булып күз алдына баса. Дулкыннар белән тигезсез көрәшендә аның өчен ут йотып, аңа ярдәмгә ташланасы килә...

Яшь шагыйрь иҗатында, әнә шулай, эзлекле һәм җегәрле төстә, дөнья гамьнәренә шәхси катнашлык, шәхси мөнәсәбәт көчәеп бара:

Җан дигән сүз — матдә түгел, әмма
беләм: ул да иңә бара җиргә.

Кайбер күренешләрне бәяләгәндә шагыйрь  кайнарлана кебек, ашыга төшә, хикмәтен табып өлгерә алмый сыман. Ләкин бу — әлегә аның кимчелеге түгел, бу — аның иҗади кыюлыгы турында сөйләүче билге, ягъни Р.Зәйдуллинның тормыш катламнарына шагыйрь буларак үз кордашларыннан алдарак, тирәнрәк үтеп керүе нәтиҗәсе.

Беренче китапларны, көндәлек матбугатта басылган шигырьләрне укыганда, безнең яшьләр иҗатында әле  кешегә тереклек суы кебек, саф һава кебек кирәкле әсәрләр җитми, дип уйлыйсың. Дөрес, бүгенге яшь шагыйрьләрнең күбесе туган ил, туган як кебек төшенчәләрне шигырьдән шигырьгә йөртеп, аларның изгелеген җуюдан саклана. Авылны сагыну мотивларын да бер көйгә генә сузу басылды диярлек. Ләкин хәзер инде яшь шагыйрьләр авылны сагынып, боегып утырмыйлар, ниндидер сәбәп белән кайтып төшәләр дә «шау уятып бөтен урамны» нидер искәртәселәре килә; «Мине онытмагансың икән әле!» —дип, туган авылларының «җилкәсеннән кагалар». Шигырьгә, май табы булып, үз-үзеңә соклану билгеләре җәелә.

Укучыга шактый танылган шагыйрьләрнең дә кайбер язмаларында йөрәкне май баса башлау, «рухи комфорт» галәмәтләре сизелә: шәхси үпкәләр, көнкүреш вак-төякләре зур проблема дәрәҗәсенә кабартыла. «Надан тәнкыйтькә» каршы ук ату (тел төбендә, әлбәттә, үзеңне тәнкыйтьтән аралап, котылгысыз булуыңны гарантияләп куярга азаплану), шәхси дошманнар белән исәп-хисапны өзү мотивлары шигырь бәйләмнәренең, китапларның «күркенә» әйләнеп бара. Вак мәнфәгатьләр, үз «мин»ең белән генә бәйле хисләр күзне — күңел күзен томалый, ил-дөнья гаменә урын калмый, изге төшенчәләр тирәсендә гомуми сүз боткасы куера башлый.

Шактый оста эшләнгән юллар, кызыклы гына детальләр күзгә чалына, ә аларга тукталып, җентекләбрәк карасаң...— ул сак, шома фикер, очраклы табылган метафора артында кеше җаны юк икән ләбаса! Шигырь күп сүзле, ул бер тере организм булып кабул ителми, аны ничек башланган булса шулай дәвам итәргә мөмкин. Үз-үзеңнән ифрат канәгать булу аркасында, кайбер мәхәббәт шигырьләренә дә күңел киңлеге, мәрхәмәтлелек җитми, зурлык җитми...

Чорның иңенә кул салып, шаулы декларацияләр белән чыгуны шыпырт кына күкрәк сугулар, үз-үзеңне җаваплылыктан аралап куюу рәвешендәге «мыштым» өндәү билгеләре алыштыра бара кебек:

Мин — елга. Тик кая агасымны
Әйтә алмыйм әле үзем дә!

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә болай дип билгеләнгән: «Елга — башланган урыннан алып койган җиренә чаклы *үзе салган* үзәнлек буенча табигый рәвештә агып торган су». Кая коясыңны да белмисең икән, димәк, әле син елга түгел, ди китап...

Яшьләр иҗатына халыкчан сурәтлелек бары тик туган туфрак төшенчәсе белән бергә килеп керә һәм яңа шигърилеге белән ачыла ала.

Заман гаме белән типкән йөрәкләр аша халык рухыннан, әдәби традицияләрдән килгән кан үтә. Тамырларга, шәҗәрәгә, ил тарихына ихтирамлы мөнәсәбәт көчәйгәннән-көчәя бара. Яшьрәк буын шагыйрьләр иҗатында да — тирән хәтерле геройлар дәвере.

М.Әгъләмов һәм Х.Әюпов, Р.Миңнуллин һәм З.Мансуров, Г.Садә һәм М.Мирза, Ф.Тарханова һәм Н.Измайлова шигырьләрендә кеше күңеле һәм аңы — заман билгеләре генә түгел, вакыт җилләре кисешкән нокта. Миңа бу шагыйрьләрнең гадәти тормышта әлегәчә беркем дә абайламаган матурлык һәм гариплекне күреп, шуны хәленнән килгәнчә әйтеп бирүе кыйммәт. Үз учында пешә-пешә алып килгән ут белән үрләтеп җибәргәндә генә аның шигырь учагы укучыны җылыта.

Вакыт агышын җиңү, киләчәккә өмет тойгысы кеше тормышының да мәгънәсен билгели. Чик-сезлекне тою көче гомер чикләрен үтеп чыгарга сәләтле. Н.Измайлованың «Нәнәем трагедиясе» дигән җыйнак кына шигыре әнә шул турыда:

Ах, ник ышандырдык икән:
«Берни юк,— дип,— тегендә?!»

Һай, дөреслек! Нәнәемнең
Очар күңелен урладың!..
Нинди бөек ялган белән
Күзләренә нур салыйм?!

Рухи яшәеш мөмкинлегенә — мәңгелеккә ышануын җимерү, күңел әкиятеннән мәхрүм итү адәм баласының калган гомерен дә мәгънәсезләндерә.

Ә бит тормышта һәркемнең үз әкияте бар**.** Берәүләрнең ул — үткәнендә: алар кайчандыр кылган һәм кылмаган гамәлләрен әкият итеп сөйлиләр; икенчеләренең ул — киләчәгендә: алар гомер буе килер көнгә өметләнеп яшиләр. Ә иң бәхетлеләр — өченчеләре: аларның күңел әкияте — бүген, үзләре белән; ул — аларның якты хәтере дә, олы чынбарлыгы да, сүнмәс өмете дә. Тик ул әкиятне гомер буе югалтмый узулары авыр!

Әкияти хисең саумы жанда?
Җуймадыңмы җирдән күчкән
                    тылсым көчен?
Әкиятне жую — кешелекне жую.
Әфсен-төфсен!

Зөлфәтнең алда әйтелгән поэмасы кеше һәм Җир язмышы хакында тирән борчылу белән тулы. Әсәрдә әкият темасы бик күп каршылыклы күренешләр һәм төенләнгән образлар аша үтә. Шагыйрь ул каршылыкларны бер селтәнүдә хәл итәргә, бөтен төеннәрне әфсен өреп чишәргә алынмый. Чөнки Җир үзе — «Әкият янар учак сыман»...

Әкият — бәлки, ул Табигатьнең үз асылын саклау инстинктыдыр? Әллә ул — Рухи биеклеккә омтылу көчеме? Яисә халыкның бәхет турындагы хыялымы? Боларның барысын да берләштергәндәй, киләчәк сагында торучы Әкият ул — кешенең кешелеклелеге, дип раслый шагыйрь. Ул үзенең изге бурычы итеп намусны уяту, хәтерне терелтү, хыял-өметләргә җан өрүне саный. Кешегә ышану,

кешене яклау — поэманың әнә шундый гуманистик идеясе — тәгәри киткән йомгак кебек җисемле төс ала, укучы күз алдында тормыш һәм әкият чынбарлыгын тергезә. Бирeдә романтик ачкыч, символик сурәтләр җирдән аерылып китү түгел, ә тормыштагы катлаулы бәйләнешләрнең җеп очын табарга һәм тасвирларга омтылу булып аңлашыла. Кичерешләр давылы, фикер җегәре укучыны үзенә бөтереп ала, заман һәм кеше турында тирән уй чоңгылларына алып керә.

«Кош булуың хәтта шомлы чакта җинаятьтер — кеше булуың...» дип сискәндергән шагыйрь кеше табигатен саклау, кешелеклелекне җуймау өчен көрәштә иҗатының төп мотивын күрә. Булмышыңа канәгатьлек кылып яшәүгә, гадәтилек тузанына батуга буйсынмыйча, тормышның фаҗигале агышына кыю каршы чыгып: «Һаман яратам!» — дип, үз иманын яклау бу әсәрнең дә кайнар темпераментын билгели.

«Йөрәкләрдә үлмәс дастан» поэмасының образлар системасы, композицион төзелеше турында әле сүз булыр. Кайберәүләрнең аны цикл дип билгеләүләре дә ихтимал. Формаль яктан моңа нигез юк түгел. Шулай да, шигырьләр циклы булганда, бер таудан башланып төрле тарафка агучы, үзләренә төрле язмыш сайлый алган елгаларны күз алдына китерәбез. Ә бу очракта, төрле елгалар буйлап килеп, бер максатка — бер диңгезгә кою өстенлек ала. Зөлфәт әсәре үзенең колачы, фикерләү рәвеше белән — поэма. Аны тормышның үзе кебек төрле чишмәләр туендыра. Дөрес, кайбер «инеш»ләр, һәр-кайсы үзалдына әйбәт кенә агып ятса да, бу «диңгез»гә булып чыкмаган, ә кайсыберләре, ахыр максатка ашкыныбрак килү җитмәгәнлектән, коясы төшенә барып ирешми бөялеп тора...

Без биеклек тойгысына, буяулар җетелегенә, дәрт-хисләр давылына сусаган идек. Хис-фикердә киеренкелек, кыюлык, аныклык, ихтыяр көче һәм колач, укучы белән тормыш турында югары дәрәҗәдә сөйләшү сагындыра башлаган иде. Зөлфәт поэмасын шушы давыллы-кайнар омтылыш күтәрә. Аның геройлары дөньяның, тормышның, кеше табигатенең камиллеген, бөтенлеген яклап көрәшкә керәләр. Тигезсез көрәш, фаҗига төсмере әсәрнең эчке киеренкелеген арттыра, аның аша оптимизм һәм яктылык саркылып чыга.

Шагыйрь тау башындагы иң биек Ташка сүз бирә:

«...Миндә Җирнең
Һәм Галәмнең бердәм, зур көче бар...
Мәңге ялгызлыкның җиңеп булмый,
Аңлап булмый торган зур үче бар!»

Кеше шушы көч-дәһшәтне буйсындыра, табигатьнең бөек гармониясенә үзе кушыла. Яшәү мәгъ-нәсе һәм кеше рухының биектә калуы турында уйланырга мәҗбүр итә бу юллар.

Мөгаен, иң кызыклы күзәтүләр бүгенге татар шигырен интонация үзенчәлекләре буенча өйрәнгәндә килеп чыгар иде. Шагыйрьнең генә түгел, чорның тавышы, сулышы «оеп калган», йөрәк тибеше язылган интонация-«кардиограмма»лар буенча.

Яңгырларда кичке кошлар кайта.
Кичке кошлар —
бу тормышка сабый чактан
җыелган сорауларым...
*(Роберт Әхмәтҗанов)*

Дулкын өстенә дулкын булып килүче «кичке кошлар»да — шигырьнең йөрәк тибеше: кул сузы-мыдай озын сызык белән ул күзгә төшеп торган эңгерне сөртеп ала кебек... Шагыйрь гади күренешнең катлаулы табигатен тоя, катлаулы чынбарлыкның гади хакыйкатен ача.

Шигырь үзенең төзелеше белән үк күңелдәге сагышны, гамь-борчуларны кузгата. Ул үз дулкы-нында тормыш ваклыкларын юып ярга ташлый, яңадан бер көч алып, битараф йокымсыраган кыяларга килеп бәрелә. Димәк, шагыйрь тормышның тирән агымнарын тоя, вакыт-заман агышын аңлый, аның нигезендәге гармонияне күрә. Поэзиянең асылында, гомумән, гармониягә омтылу ята. Шул омтылышның, заман тойгысының зурлыгы нәтиҗәсендә килә ул әсәрләргә проблема мөһимлеге, гамь тирәнлеге.

Татар поэзиясе — үзенең табигате белән һәрвакыт уйлы-гамьле поэзия. Халыкның иң гади җыру-такмазаларында ук — дөнья гаме, тормыш уе. Хәтта туй-мәҗлес җырларына кадәр басынкы, озын,

моңлы. Эченә ут йотса да сөремен тышка чыгармый торган сабыр халык сагышын-күңелен җырлап бушаткан. Шуңа күрә дә «моңлы ул, шагыйрь ул»...

Бүгенге татар шигъриятенең дә йөзен чын кичерешләр, зур уйлар, Ватан, милләт, намус, тугрылык турында мәңгелек гамь билгели. «Һәрбер йөрәк үзенчә яңартканга» күрә генә яши бит ул мәңгелек темалар!

Бу әсәрләрдә татар шагыйрьләренең шәхес буларак җирлеге, күңел биографиясе ачыла. Сугыш кичкән буын һәм аның балалары, оныклары... Хис ягыннан авылча самимилек, фикер ягыннан — җиргә, туфракка якынлык. Аларның әсәрләрендә тормыш чынбарлыгын гадиләштермичә һәм катлауландырмыйча — үз барлыгында, үз төсләре белән аңлау. Шуның белән аларның язган сүзе җиргә, укучыга якын. Татарның укучысы да авылдан. Китапка изге итеп карау аның канына сеңгән.

Безнең бабайлар өчен китап сүзеннән дә зур сүз булмаган. Янгын чыкса, мал-җиһаздан әүвәл, китапны саклаганнар, яу килсә, китапны җиргә яшергәннәр. Билгесез солдат каберләре кебек, күпме китапны куенына алды икән бу җир!

Китап сүзенә хөрмәт традиция-йола буенча гына түгел. Китап кешене үз-үзенә — зурлыгына, көченә, матурлыгына  ышандырып килгән, шул ышаныч ярдәмендә аны сират күперләреннән алып чыккан. Китап сүзе адәм баласын түбәнлектән, рәхимсезлектән, ваклыктан аралаган. Гасырлар буена шулай. Әле дә шулай.

Кешенең шәфкатьсезлеген күрсәң, балачагында ул әкият тыңлап үсмәгәндер, дип уйла.

Кешенең күңел күзләре сукыр икәнлеген абайласаң, аның үз гомерендә шигырь укып әсәрләнгәне юктыр, дип кызган.

Дөньяда иң бәхетсез җан иясе — үз халкының рухи-мәдәни хәзинәсенә тамыры белән ялгана алмаган кеше. Ул — хәтерсез кеше. Өметсез кеше. Имансыз кеше. Чөнки әдәби-мәдәни мирас ул — буыннар хәтере, халык хәтере, ул — кешелекнең гасырлардан килгән хыял-өмете, ул — кешегә, илкөнгә, иң мөкатдәс идеалларга ышаныч гәүдәләнеше.

Менә шуңа күрә бүгенге шигырьләрне укыганда иңгә олы җаваплылык тойгысы баса, күңелгә Шагыйрьнең мәгълүм юллары килә:

Күкрәгемдә минем шигырь утым саумы?!

1983

## ШАГЫЙРЬЛӘР НИГӘ КАРТАЙМЫЙ?

...Дөнья уе башында.
Асыл кошлар затыннан ул,
Сандугачлар яшендә.
Илдар Юзеев

Бу җыр аккан бозлар кебек шаулап-гөрләп үтә дә якты бер моңсулык тарата. Ачык тәрәзәләрдән яз җиле сыман ургылып керә дә күңел гөлләрен уята:

Язгы ташуларда,
Аккан бозга басып,
Икәү килә елга буйлатып,
Берсе җырлый шашып,
Изүләрен ачып,
Икенчесе килә уйнатып:
— Сау булыгыз, кызлар,
Сагынырсыз, кызлар...

Шигъри сүзнең чынын, асылын халык үзе сайлап ала. Сайлап ала, җыр итә, мәңгеләштерә. Күрәсең, шагыйрьнең халыкчанлыгына иң беренче үлчәү шулдыр.

Илдар Юзеев иҗатында көе-моңы саркылып торган, җыр булып канат чыгарган юллар аз түгел.

Димәк, башыннан ахырына чаклы «яшьлек турында» җырлап мәйданга кергән шагыйрь бүген дә яшьлек җырчысы булып кала? Әгәр «яшьлек җыры» дигәнебез киң мәгънәсендә кешегә һәм тормышка мәхәббәт турында икән, бу — чыннан да шулай. Тирәннән, үзәктән килүче әлеге хис әсәрдән әсәргә үсә, яктырак, катлаулырак булып ачыла бара.

*— Соңгы елларда Сез көтелмәгән борылышлары, иҗади табышлары белән күп бәхәсләр уяткан әсәрләр яздыгыз, Илдар абый. «Өзелмәс кыллар» һәм бигрәк тә «Мәхәббәт китабы» поэмалары Сезнең иҗатның,— һәм, ихтимал, татар поэзиясенең дә,— тагын бер яңа кырын ачып җибәрде...*

*— Мәхәббәт китабы»н ни өчен яздым?*

*Мәхәббәт — кешелекнең гомер буе җырлаган җыры. Әмма аны «һәрбер йөрәк үзенчә яңарта», дибез. Бу хакта яңа сүз әйтүе мөмкин дә түгелдер кук. Шагыйрь — мәхәббәт белгече түгел. Ул хөкем итми, канун чыгармый, бары үз карашын, үз мөнәсәбәтен белдерә. Мин мәхәббәт хисен зур төшенчәләр җирлегенә куеп, катлаулырак категорияләр биеклегенә күтәреп карарга омтылдым. Тарих. Кеше язмышы. Дөнья. Илләр, шәхесләр. Бурыч, вөҗдан, яшәеш. Кеше хисләренең, рухи дөньябызның кыйммәте дә шул җирлектә ачыграк күренгән төсле булды.*

*«Мәхәббәт китабы» — дөресен әйткәндә, гомерем буе хыялланган әсәр ул. Кәгазьгә ике ел эчендә төшсә дә, йөрәк белән гомер буе язылган, бөртекләп-тамчылап җыелган.*

Ни өчен «Мәхәббәт китабы» шагыйрьнең «икенче сулышы ачылу» рәвешендәрәк күз алдына килә? Моның сәбәбе — әсәрнең яңа табышлары булуында гына түгел. Бу «китап» Юзеев иҗатының «гомер бөҗралары»н ачыграк күзалларга мөмкинлек бирә һәм аның, асылда, ябалдашка түгел, тамырга үсүе, ныгуы турында сөйли.

«Мәхәббәт китабы»нда чынлап торып «таныш моңнар» ишетелеп китә. Нәрсә бу — шагыйрьнең кабатлануымы, әллә диалектик үсешнең яңа баскычында беренчел нигезләргә кайтуымы? Соңгы фараз дөреслеккә якынрак булыр: беренче чор поэмаларындагы романтик биеклек бүген яңа яуланган фәлсәфи тирәнлекләр хисабына үстерелә.

Искә төшерик: Илдар Юзеев шагыйрь буларак «Таныш моңнар» поэмасы белән танылган иде. «Таныш моңнар»ның аерым юллары яшьләр арасында җыр булып таралды. Укучыларының яшьлеге — шагыйрьнең яшьлеге! Әлеге әсәр таралган чорда Зөфәр, Резидә дигән исемнәрнең ешаеп китүе бер дә юкка түгел. Аннан соң язылган «Фәрит — Фәридә», «Әнкәй», «Миләүшә» поэмаларында да яшьлек рухы саклана. Ләкин...

*— ...Сез «тынлык белән сөйләшә» башлагач, әсәрләрегезгә үзеннән-үзе шартлы күренешләр, бик нык гомумиләштерелгән образлар килеп керде. Бу хәл кайбер югалтулар бәрабәренә дә булды шикелле. Гомумән, беренче чорда язылган поэмаларга үзегезнең мөнәсәбәтне белү кызыклы булыр иде.*

*— «Миләүшә»ләрдән соң минем өчен уйлану чоры булды. Тормыш тәҗрибәсе һәм зәвыклар үзгәрү дә тәэсир итми калмагандыр. Күзгә-күз карап сөйләшерлек, өлгергән, зуррак проблемаларны уртага аласы, тормышның тирәнрәк катламнарын күтәрәсе, уй-фикерләрне колачлырак, саллырак итеп белдерәсе килде. Заман да, укучы да тиз үзгәрә бит. «Таныш моңнар» дәрәҗәсендә калсам, үсә барган укучым мине узып китәчәк, дип уйладым. Билгеле, сез хаклы, кайберәүләрдән шунда ук: «Катлаулырак яза башладыгыз»,— дигән сүзләр ишетергә туры килде. Хискә генә корылган тар сулышлы лирикага күнеккән кешеләр, димәк. Мин аларга гадәттә: «Әгәр шагыйрь бер урында таптанып торса, үзегез дә аны гафу итмәс идегез»,— дип җавап бирәм...*

Шагыйрьнең җырына күчкән дөньяны шүрлекләргә аерып, кысаларга тутырып булмый. Әйе, И.Юзеев иҗаты,— асылда, яшьлек һәм тормыш-яшәеш, ватандарлык һәм тынычлык турында. Әмма бу темалар арасында кискен чикләрне аеру мөмкин түгел. Иң мөһиме, шигырен саегудан, вакланудан саклый шагыйрь, нинди генә дулкында язмасын, үзәккә кеше язмышын, табигать баласы язмышын куя.

Юзеевның лирик герое тормышның төрле өлкәләренә үтеп керергә, аны бөтен катлаулылыгы белән аңлатырга омтыла. Шагыйрь күңеле заманның җиде җиленә, барча үзгәрешләренә ачык. Аңа тарихның мәңгелек мизгелендә үз урынын билгеләргә, үз максатын һәм таяну ноктасын табарга кирәк.

Бу уңайдан, И.Юзеевның табигать, заман һәм кеше мөнәсәбәтләрен калку итеп куйган «Моң турында баллада», «Карурман» кебек әсәрләре аеруча игътибарны җәлеп итә. Табигатьне аңлау һәм саклау дигән зур проблема — дулкынландыра һәм борчый торган проблема бар, әлбәттә. Әмма шагыйрь цивилизация белән табигать арасындагы каршылыклар турында бәхәсләшү өчен генә сүз алмый. Аның шигъри уйланулары нигезе — кешенең рухи тамырлары туган җирдә, дигән фикердән башлап ил-көн, халык язмышы турында гамьгә кадәр. Бит «дөньяның гамьнән башка яме юк». Ул гамьне ике генә юл белән:

...Мине елга иткән чишмәләрдән
Калмадыммы икән аерылып?..—

дип тә белдерергә мөмкин.

Аңлашыла: чишмә яисә карурман — табигать байрагындагы традицион галәмәт-символика гына түгел. Шигъри контекстта бу төшенчәләр гаять киң мәгънәгә ия. Халыкның күңел хатирәсе, рухи хәзинәсе, мәңгелек идеаллары — менә ул тормыш һәм иҗатның даими яңарыш чишмәсе, дип раслый шагыйрь. Һәм шул чишмәләр сау булганда гына «мең һәм миллион кыллы зур тормышның» симфониясен «күммәс башка көйләр дулкыны».

Табигать — ул әле туган тел стихиясе дә. Халык иҗатының бәрәкәтле чишмәсеннән игелекле рәвештә файдаланучы шагыйрь тулысы белән шушы хакыйкатькә тугрылыгын дәлилли. Әнә шуңа да аның күп кенә шигырьләрендә әллә кайдан кычкырып торган декларатив-кызыл кабыклы гражданлыкны күрмисең. Туган ил, тынычлык, табигать турында язганда да, мәхәббәт, бәхет һәм моң-сагыштан торган юлларда да гражданлык хисе тирән катлам булып ята.

*— Илдар абый, иҗатыгызны өйрәнүчеләр драматик поэмаларыгыз белән Такташның «Җир уллары» трагедиясе арасында ниндидер эчке бер бәйләныш күрәләр. Мөгаен, аны рухи туганлык дип тә әйтергә ярыйдыр... Юк, сүз тышкы охшашлык, гадәти йогынты турында бармый. Чын шигърият гөлeнең йогынты-тәэсирләрдән шытып түгел, ә шагыйрьнең шәхесе, дөньяга карашы җирлегендә үсеп чыгуы мәгълүм. Бәлки Сезнең Такташ иҗаты белән очрашуыгыз әнә шул рух-яшәеш тәҗрибәсенә кушылгандыр?..*

*— Минем өчен әдәбият үзе Тукай белән Такташ иҗатыннан башланды. Бала чакта ук, әле бөтен тулылыгы белән аңлап бетермәгән килеш, тылсымлы-сихри бер тәэсир булгандыр инде ул. Хәтеремдә, миңа инде ун-унбер яшьләр иде, кулыма Һади Такташ китабы эләкте. Шигырьләрдән аерыла алмыйча караңгы төшкәнче утырдым. Кышкы кич, сугыш вакыты, керосины бетеп лампа сүнгән. «Җир уллары» трагедиясен дөрләп янган мич авызы каршында, мичтән төшкән кайнар яктылыкта укыдым.*

И.Юзеевның шигырь һәм поэмаларына хас сыйфатлар — моң тирәнлеге, фикер һәм хис ачыклыгы, халык иҗатындагы образ һәм мотивларны яңа яктан ачу — аның җырларында аеруча ачык чагыла. Аның һәр җыры диярлек моң чишмәсе булып тибә һәм безнең күңелләргә юл таба. Чөнки аларда заман рухы, чордашларыбызның бай һәм катлаулы эчке дөньясы ачыла. Шагыйрь тормышның үзе кебек үк гади дә, катлаулы да булган табигыйлеккә ирешә. Әле «Таныш моңнар»га кадәр үк, педагогия институты студентлары Илдар Юзеев белән Ләбиб Айтугановның «Төнбоек» һәм «Карлыганым, бөрлегәнем» исемле ике җыры яшьләр арасында киң таралып өлгерә. Шуннан бирле, гәрчә көй өчен текст язу белән махсус шөгыльләнмәсә дә, кабатланмас үзенчәлекле җырлары шагыйрьне бөтен иҗаты буена озата килә.

Җыр язмышы — кош язмышы сыман: канатлану белән ерак юлларга чыга, илләр урап кайта ул.

Сагындырды Агыйделнең камышы,
Челтерәп аккан чишмәләрнең
тавышы.
Сагындырды сызылып таңнар атуы,
Әнкәемнең иркәләп уятуы...

«Алтын балачагы узган» болыннарны сагынуын шигырь юлларына сала шагыйрь. Аңа көй язганда, Сара Садыйкова да, ихтимал, челтерәп аккан чишмә кебек яшьлек елларының кайтавазын ишеткәндер. Шуңа күрә, Финляндия татарларының «Ватан гимны»на әверелгән дә ул җыр!

Әйе, җыр юлы — катлаулы юл. Тулысынча халыклашкан хәлдә үзенең авторына — Сибгат Хәкимгә әйләнеп кайкан «Юксыну»ны, Әхмәт Фәйзинең вафатыннан соң җыр булып калыккан «Умырзая»ны искә төшерик. И.Юзеев сүзләренә җырлана торган «Яшь наратлар» көе дә әнә шуларга охшаш катлаулы юл уза. Юзеев сүзләренә дип басым ясау һич тә очраклы түгел. «Мин бу җырның текстын әзер көйгә яздым,— дип искә ала шагыйрь.— Әмма аның тарихы җырчы репертуарыннан башланды. Ул чакта Илһам Шакиров халыктан яңа бер көй отып кайткан иде, тик сүзләрен ничектер ошатып бетермәвен әйтте. Аңа ике вариантта махсус җыр тексты язып бирдем. Илһам аларның берсен сайлап алды. Шулай итеп, әлеге көй Мирсәет Яруллин эшкәртүендә, яңа сүзләр белән җырчылар репертуарына керде, халыкка кире кайтты. Аны, әлбәттә, Җәүдәт Фәйзи дә ишеткән һәм: «Бу бит — минем сугышка кадәр үк иҗат иткән көем. Сүзләре генә Фатих Кәрим язганча түгел!» — дип гаҗәпкә калган. Төрле сәбәпләр аркасында җырның Фатих Кәрим язган тексты онытылган да, матур көйне югалтасы килмәгән һәвәскәрләр аны үз сүзләре белән җырлап йөри башлаганнар икән...» Көй агышына гаҗәп тиң килеп торган яңа сүзләр кушылмаган булса, бу җыр, бәлки, тора-бара бөтенләй онытылып калган булыр иде. И.Юзеевның «Яшь наратлар» шигырен Фатих Кәрим истәлегенә багышлавы да менә шул тарих белән бәйле.

...Урман буендагы яшь наратлар
Син калдырган көйне җырлыйлар.

И.Юзеев шигырьләренә, гомумән, музыкаль бөтенлек хас. Аның «Өчәү чыктык ерак юлга», «Таныш моңнар» кебек әсәрләрен һич икеләнүсез музыкаль поэмалар дип билгеләргә мөмкин. Шагыйрьнең сәхнә әсәрләрендәге җырлары да бик үзенчәлекле. Бер яктан, алар драматургия материалының шигъри аһәңен көчәйтәләр, шул ук вакытта мөстәкыйль яшәүгә дә хокук алдылар. «Янар чәчәк» пьесасындагы җырлар (М.Яруллин музыкасы), «Бөркетләр кыяга оялый» водевиленнән «Бөркет турында баллада» (С.Садыйкова музыкасы) әнә шундый озын гомерле, матур язмышлы булып чыктылар. «Кыр казлары артыннан» драмасындагы Ясминә җыры да (М.Имашев музыкасы) халыкчан моңы, тирән драматизмы һәм гомумиләштерү көче белән безгә тәэсир итә.

*— Сез — шагыйрь һәм драматург. Бу ике жанр арасындагы бәйләнешләргә, берьюлы ике юнәлештә иҗат итү үзенчәлекләренә тукталу кызыклы булыр дип уйлыйм. Ләкин шигъриятегезне яратучыларның бер өлеше, гомумән, Сезнең театр белән иҗади хезмәттәшлегегезгә гаҗәпләнебрәк карый кебек. Шуңа күрә иҗатыгыз бөреләнгән еллар турында сөйләшүне дәвам итик әле. Сезне бит сәхнә әсәрләре язудан башлагансыз, диләр...*

*— Беренче әсәрем, чыннан да, пьеса иде. «Алсу гөлләр» исемле. Мин аны... икенче класста укыганда яздым. Шул заманнарда бик таралган сюжетларга ияреләгән инде, билгеле. Балалар бер шикле кешене тотып кайталар, һәм ул шпион булып чыга. Шунысы кызык: җәй көне класска җыелышып, укытучыларыбыздан башка гына куйган идек әлеге спектакльне.*

*Өченче класста укыганда Яңавыл район газетасында бер бит тулы шигырьләр басылып чыкты... «Нил һәм Илдар Юзеевлар иҗаты» дип куйганнар. Нил инде бишенчедә укый, шигырьләр яза, аның шигырьләре бик күп иде, шулар арасына минем дә «Дошман җиңелә» исемле бер шигырем эләккән. Шушы газетаны күреп, безгә күрше Тәтешле районыннан бер пионервожатый килде. Кызыл галстугы әле дә күз алдымда тора. Ул үзләрендә Һади Такташ исемендәге әдәби түгәрәк төзегән икән, безне дә шунда язылырга өндәде. Безгә әлеге түгәрәкнең тәэсире шактый булгандыр дип уйлыйм. Чөнки вожатый дигәнебез — хәзер инде танылган башкорт шагыйре Әнгам Атнабаев булып чыкты...*

*Бераздан тагын пьеса язу белән мавыга башладым. Ике пьеса, икесе дә үзебез күргән-белгәнне түгел, сугыш кырындагы каһарманлыкларны тасвирлый. Күрәсең, иҗатның башлангыч чорында «романтик темалар» эзләү чире дә була торгандыр. «Моңлы җыр тавышы» дип аталганын мәктәп сәхнәсендә куйдык, шунда төп рольдә —батырларча һәлак булган пионер малай булып үзем уйнадым.*

Моннан унбиш еллар элек Язучылар союзына — И.Юзеев янына Сәгыйт Таҗетдинев исемле отставкадагы офицер килеп керә.

«Мин Дахау концлагере крематориендә яндырылган татар шагыйре полковник Хәйретдин Мөҗәйнең васыятен алып кайттым,— ди ул.—«Исән-сау илгә кайтсаң, безнең ничек көрәшкәнебезне халыкка җиткер»,—дигән иде Хәйретдин. Мин инде күпме генә кешегә сөйләп өлгерәм, менә шул хакта сез язып чыксагыз иде»,— ди Сәгыйт ага. Билгеле, ул чакта Илдар Юзеевның үзендә нәрсәдер язу уе тумый, тик әлеге очрашу турында каләмдәшләренә сөйли.

Шулай да, ут эченә кергәндә әйтелгән васыять сүзләре күңелдән китми, уйландыра, күз алдына килә. «Ул да безнең Башкортстан ягыннан... Безнең шикелле үк авыл чирәмендә тәгәрәп үскән. Җәйге тын кичләрдә гармун моңына ияреп урам әйләнгәндер. Егет чагында нинди җырлар җырлады икән?» — дип уйлый шагыйрь. Үзенең яшьлегендәге җырларны искә төшерә.

Биек тауның башларына
Менәселәр бар әле,
Дөрләп янган ут эченә
Керәселәр бар әле...

Бу җырда ир-егетнең гаярьлеге-кыюлыгы да, алдагы язмышын сизенүе дә бар төсле...

Шагыйрь өчен Хәйретдин Мөҗәй, һичшиксез, шушы җырда «терелә». Образ менә шулай табыла.

И.Юзеев һәр әдәби очрашуда дип әйтерлек сүзен «Язылмаган поэма» әсәреннән башлый — Хәйретдин Мөҗәй васыятен үтәп йөри. Аның йөзендәге, тавышындагы чиксез дулкынлану, тетрәнү залга күчә. «Барысын да өр-яңадан кичерәм, бер сулышта укыйм, күңелдән шул поэманы гына беләм бугай...» — ди ул үзе.

...Зинһар өчен,
Дөрләп ут янганда,
Мине уйлаганда,
Кышкы кичтә мичкә карама!

«Язылмаган поэма» — драматик киеренкелеге һәм масштаблы сурәтләргә омтылуы ягыннан бик үзенчәлекле әсәр. Ул елап-сыктап күңел бушату рәвешендә түгел, тез чүкмәскә, баш имәскә рухландырып торучы җан әрнүе булып туды һәм шагыйрь иҗатындагы тирән драматизм катламнары ачылуның башы булды. «Тынлык белән сөйләшү», «Соңгы сынау», алардан соң — «Таш диварлар авазы», «Очты дөнья читлегеннән»... Тарихилык шагыйрь иҗатының мөһим сыйфатына, аның илһамын канатландыручы, каләмен шомартучы көчкә әйләнде. Юзеев поэзиясе заманча яңгырашка менә шундый киңлекне һәм тирәнлекне яулау нәтиҗәсендә иреште.

*— Форма өлкәсендәге төрле эзләнүләр, аерым алганда, шартлылык мәсьәләләре турында төрле бәхәсләр бара. Күпмедер дәрәҗәдә уйлап чыгарылган бу бәхәскә катышмастан, сәнгатьнең яшәешенигезе генә түгел, гомумән, дөнья, тарих, үсеш-үзгәреш турында безнең күзаллавыбыз шартлы булуын танырга мәҗбүрбез. Шуңа күрә Сезнең әсәрләрегездә үткәннән бүгенгегә яки шартлы киләчәккә җиңел күчү, беренче карашка ерак торган күренешләрне янәшә кую һәр яктан да аклана. Шулай да үз фикерегезне ишетү кызыклы булыр иде: әлеге чараларны, фәнни фантастикадагы сыман, аерым күренешләргә, мәсьәләләргә көтелмәгән яктан карау, укучының игътибарын үткенәйтү максатында гына кулланмыйсыз микән Сез?*

*— Әсәргә символик образлар килеп керү шагыйрьнең максатына һәм язу алымына бәйләнгән. Реалистик җирлектән аерылмаганда, алар фикернең җегәрен, тәэсирен арттыралар. Ләкин шартлылык белән ясалмалык арасында — җир белән күк аермасы. Шартлы алымнар әсәр тукымасында бүселеп тормаска тиеш. Мин үзем —шигырьдә генә түгел, сәхнә әсәрләрендә дә чамасын белеп символика уенына таяну ягында. Мәсәлән, «Сандугачлар килгән безгә» исемле моңсу комедиядә «Тимер кеше»не сәхнәгә чыгару минем өчен зарури булды. Урман каравылчысы Хәмзиннең салкын җанлы кешеләргә каршы көрәшен аңлатырга кирәк иде... Кыскасы, әсәрнең эмоциональ-мәгънәви тәэсирен көчәйтү өчен кирәк булганда, шартлылык табигый чарага әверелә һәм гади укучыга (тамашачыга) да бик яхшы аңлашыла.*

Катлаулы күренешләрне катлаулы формалар аша ачарга омтылу — И.Юзеев иҗатының бер сыйфаты, дип билгеләп үткән идек инде. Шагыйрь, үзе үк әйткәнчә, укучы җаена гына бармый, мәгәр аның поэмаларында киң аудитория белән турыдан-туры багланышка керү, күзгә-күз калып сөйләшергә теләү бар. Шигъри сүзнең мөстәкыйль яшәешен күрү омтылышы элек-электән шагыйрьләрне сәхнәгә, театрга чакырган. Шагыйрь Юзеевның драматург Юзеев белән килешеп яшәве, мөгаен, шуның белән аңлатыла торгандыр. Сәхнә әсәрләре язу аңа поэмаларында да драматик формалардан оста файдаланырга ярдәм итә.

*— Иҗатыгызның сәхнә әсәрләреннән башлануы бәхетле һәм мәгънәле фал булган икән. Театр белән иҗади элемтәнең шигырьләрегезгә дә бик кызыклы тәэсире сизелә. Гомумән, Сез укучыларыгызның поэмаларны кабул итү психологиясен үзгәртүдә катнашмыйсыз микән?*

*— Театрның файдасы да, күпмедер зыяны да булды, ахрысы. Баштарак шигъри уйлау-фикерләү рәвеше сәхнә әсәрләре иҗат итүдә нык комачаулый — тизлекне, киеренкелекне киметә, хәрәкәт азлыгына китерә иде. Шуңа күрә хәтта бермәл шигърилектән кача башладым. Драматург дуслар: «Ялгышасың, шигърият сәхнә әсәрен көчлерәк итәргә сәләтле»,— диделәр. Уйлап карасаң, безнең күпчелек поэмалар нигезендә монолог ята бит. Ә монолог үзе сәхнә сөйләменнән килә. Драматик уйлау поэмаларда композицион бөтенлеккә, драматик киеренкелеккә ирешүне җиңеләйтә.*

Әлбәттә, бу мөнәсәбәтләрнең ачыктан-ачык күренеп тормый торган бүтән тәэсирләре дә бардыр... Бер генә герой да әдәби әсәрдә тормыштагы сурәтенчә үк яши алмый. Хәтерлисездер, И. Юзеевның бер пьесасындагы рәссам егет Айтуар да: «Художник һәр образында үзен иҗат итә»,— ди бит...

Мең авазлы шигъри «карурман». И.Юзеев иҗаты, тулаем алганда, әнә шундый булып күз алдына килә. Бу «карурман» аша челтерәп торган «таныш моңнар» үтә. Ягъни шигърият үсешендә туган яңа күренешләр тәэсирендә, үз тәҗрибәсе һәм эзләнүләре юлында шагыйрьнең тавышы ныгыса-көчәйсә дә, ул төп темасына, төп принципларына тугрылыклы булып кала. Шагыйрьнең әле дә яшьлек һәм мәхәббәт җырчысы булып, рухы белән яшь калуы — «болай да кыска гомерне мәгънәле итү» уе белән янып яшәү нәтиҗәсе. Ул үзенең бөтен иҗаты белән, Зур Хакыйкать — мәхәббәт һәм тормыш фәлсәфәсе дигән ике «кыл»ның яңгырашы бергә кушылган төштә, дип раслый:

Җанга керим дисәң,
Нык тарттырма,
Бушатма да — тап кыл уртасын,
Шул чагында табарсың син көйнең
Илаһи бер бөек ноктасын...

1980

## ДӨНЬЯНЫҢ КЫЛ УРТАСЫНДА...

Мин еллардан гомер дигән
Бер челтәр үреп барам...

Гәрәй Рәхим

Аларның бәрәңге бакчаларыннан
ук Урал таулары башланып китә...

Башта кечкенә генә, тәбәнәк кенә калкулыклар рәвешендә пәйда булалар да, аннары, тора-бара, әкренләп-әкренләп, сокландыргыч тауга әйләнәләр алар. Шулай итеп, бәрәңге бакчасы артындагы кылганлы калкулыклар бөек Уралга барып тоташа.

Кеше күңелендә шигърият туу да әнә шулайрак бара кебек. Анда да башта мәхәббәт һәм нәфрәтнең сизелер-сизелмәс, йомшак кына авазлары ишетелеп китәдер, кылганнарны кузгатып искән җил төсле, әлегә түбәннән генә аккан фикер агышы тоела башлыйдыр. Аннары инде бу агым зурая, көчәя; әлеге калкулыклар тауга әверелгән сыман үсә-үсә, әкренләп, кеше рухының олы биеклекләре — Урал кебек буй җитмәслек мәгърур шигъри ил барлыкка киләдер... Хис-кичерешләр тау кыялары кебек биеклеккә һәм тау упкыннарыдай тирәнлеккә ирешәдер.

Безнең алда — шагыйрь Гәрәй Рәхимнең туган ягы.

Безнең алда — аның күңел җимешләре, иҗаты...

Гәрәй Рәхим — бәхетле шагыйрь. Аның егерме биш яшьтә язган «Әниләр зары» исемле шигыре «Советский Союз» журналы аша Европа телләрендә яңгырады.

Г.Рәхим — алтмышынчы еллар уртасында исеме күренә башлап, бүген шагыйрь буларак кына түгел, проза һәм сәхнә әсәрләре белән дә үз укучысын тапкан язучы.

Ул — тормышта һәм иҗатта максималистик карашлары белән аерылып торган буын вәкиле. Аның асылда төрле характердагы каләмдәшләрен ачык гражданлык поэзиясе, актив көрәш рухы берләштерә иде. Алар үз алларына әдәбиятның олылыгын, иҗат эшенең җаваплылыгын аңлаудан туган зур һәм катлаулы бурыч куеп килделәр. Әлеге бурычны үтәү өчен аларга «халыкның гасырлар буена... моң һәм хис белән өретелеп килгән күңел авазы һәм ритмына сизгеррәк булырга» (Р.Фәйзуллин) кирәк иде.

Дөньядагы барлык үзгәрешләрне күңелгә үтә якын алып, катлаулы заманда кеше матурлыгын раслау теләге белән янганлыктан, җаны-тәне белән гармониягә ашкынганлыктан, киеренке кичерешләр давылы булып танылды бу поэзия. Аның йөрәк тибешендәге аритмия дә әлеге шул дулкынлану яки борчылудан, соклану яки нәфрәтләнүдән иде.

Г.Рәхим башта ук талантлы хорда үз тавышын ишеттерә алды. Халыкның күңел авазына һәм ритмына сизгерлекне, мәсәлән, бер-береңне кабатламыйча, менә ничек әйтеп була икән:

Тир тәмен тойган халыктан
хикмәтле сүзләр сөзәм,
күңелемдә кайнатам да
аларга тылсым өрәм.... *(Р.Фәйзуллин)*

Дөньядан ничә мизгелгә
Әҗәткә алган көем!
Китәсең кире дөньяга,
Сүзләрдән киеп кием... *(Г.Рәхим)*

Игътибар итик: беренчесендә — хәрәкәтнең максатчанлыгы, активлыгы; икенчесендә күпмедер үз ихтыярына куелуы, табигыйлеге сиздереп тора. Әмма бу аерма — килешмәүчән каршылык түгел, алар бер-берсен тулыландырып яшиләр. Шуңа күрә дә, үзенчәлекле авазларын саклап килү өстенә, бер-берсен дәвам итеп, ачып җибәрүләре белән әлеге буын шагыйрьләренең иҗаты әдәбиятыбызда кабатланмас бер күренеш булып танылды.

Г.Рәхимнәр буынының шул рәвешле — тормышның яңа катламнарын ачарга омтылып мәйданга килүе — күптәнге хакыйкатьнең тагын бер кабат раслануы иде: шигърияте яңалыкка омтылу тойгысы яшәтә.

Көндәлек тормышыбызда да шулай бит... Ибе-җебе китереп эшләнгән фабричный паласлар, уңмый торган буяу төшерелгән ашъяулыклар берзаман туйдыра башлый, алардан күңел кайта, җан бизә. Әнә шул вакытта әбиләр сандыгында үз сәгатен көтеп яткан чүпләмле сөлгеләр, йон җебеннән сугылган паласлар дөньяга чыга. Адәм баласы үз кул җылысы кермәгән әйберләрне нигәдер ятсынып куя, үзе бәйли, үзе тегә, үзе чиккән кульяулыклар белән мавыга. Бу, кайберәүләр уйлавынча, иң соңгы мода, «ретро», тагын әллә нәрсәкәй... Чынлыкта исә гадилеккә, табигыйлеккә сусау актарып чыгара ул сөлге-эскәтерләрне сандык төбеннән.

Менә шундый тансык үзгәрешләр әдәбиятта да төрле юл белән бара. Күнегелгән, туйдыра башлаган бертөрлелектән качу берәүләрне, әйтик, ирекле үлчәмнәргә, шаккаткыч метафоралар парадына чакыра. Ягъни алар көтелмәгәнлек, гайре табигыйлек белән укучыны җәлеп итәргә омтылалар. Икенчеләре исә моның киресен — нәкъ менә җиргә, табигый яшәешкә якынайтучы юлны сайлыйлар... Беренче юнәлеш буйлап китсәң, шигырьнең эчке төзелешен катлауландыру, эстетик информация күләмен арттыру мөмкинлекләре ачыла бара: аннары инде, бәлки, санның сыйфатка күчүенә дә өметләнеп буладыр... Икенчесе буйлап барганда — материал каршылыгын җиңеп, тормыштан шигърият эзләү, аның үзенә генә ятышлы көен табу...

Г.Рәхим иҗатын карап-күзәтеп барган укучылар белә: шагыйрьгә бу юлларның икесе дә якын.

Без килгәндә сыйлар әйбәт иде —
Табын саен алма туралды.
Без килдек тә, бу да бар бит диеп,
Табыннарга аттык торманы.

Күрәсең, шундый юлларны укып микән, Г.Рәхим шигырьләре турында сүз чыкканда, аларның төп үзенчәлеген — гадилек дип билгеләү гадәткә кергән. Имештер, аңа форма өлкәсендә эзләнүләр чире кагылмаган, аның стиле сөйләп чыгуга гына корылган...

Ә тел очында һаман шул көй тора:

«Зирекләрнең кара бөдрәләре...
Зир-рекләр-рнең кар-ра бөд-рәләр-ре...»

Бу көй-моң төгәл һәм нәфис тәкрарланып килгән «р» авазына да бәйле түгелме?.. Шулай ук башка шигырьләрдәге аерым юлларның, сүзләрнең музыкаль ачкыч булып кабатлануын хәтерлик. Г. Рәхимнең мәгънәви кайтавазларга омтылуы шактый эзлекле күренеш икән ләбаса!

Бер очракта ул дулкын-дулкын булып килгән кабатланулар рәвешен ала, әлеге дулкынның һәр кагуы сиңа нәрсәдер алып килә, шул дулкын белән синнән нәрсәдер китә, аны берничек тә тотып, туктатып калып булмый:

...Озын төннәрдә мин,
Ялгыз чыгып кухня ягына,
Төне буе шигырь язып чыгам —
Ялгыз әниемне сагынам.

Икенче очракта шигырь юллары, Идел ярындагы текә Тәтеш басмалары кебек, кискен генә өскә күтәрә башлый — башлар әйләнерлек!.. («Әниләр зары»н гына искә төшерик.)

Яңа бизәкләрне сабыр гына өсти-өсти, инде ясый башлаган картинасын тулыландыра барырга ярата шагыйрь. Мондый очраклар күбрәк. Шуңа күрә теләсә кайсы шигыреннән һәр строфаның беренче юлларын гына алып карарга мөмкин: «Яшь кызлар июньдәй көләчләр...», «Чирәмдә чал чәчле бер бабай...», «Аранда яшь колын... тибенә...». Якыннан карасаң, картинадан бигрәк, шигырьнең «киндере» күренә башлый, «буяулары» сылаштырып кына барган кебек. Сырлап, чәчәкле-чуклы итәргә тырышу юк. Чү әле, форма гадилеге дигәннәре шушымы соң әллә?.. Ләкин шагыйрь-рәссамның төп үзенчәлеген, ул иҗат иткән дөньядагы тирәнрәк һәм олырак багланышларны күрү өчен, «картина»ны, читкәрәк китеп, ерактанрак карарга кирәктер... Тулаем шигъри панорама итеп күрерлек ераклыктан, һәм, әлбәттә, вакыт ераклыгыннан.

Г.Рәхимнең баштагы чор иҗатында төрле күренешләр янәшәлегеннән яки капма-каршылыгыннан шигъри сөземтә чыгару өстенлек ала иде шикелле («Буыннар елъязмасы», «Әниләр зары»).

Хәзер исә шагыйрь аерым детальләр, метафораларны чәкәләштерүдән бигрәк, нигез ташы булып ятарлык зур-зур кисәкләр, кантарлар «күтәреп килә» шикелле. Аларда фикер, тау башыннан тәгәрәп төшүче кар йомарламы төсле, беренче юлларда ук зур тизлек ала, шигырь юлларын үзенә укмаштыра-укмаштыра, күләмлерәк, көчлерәк була бара. Кеше күңелендә барган вакыйгаларның көтелмәгән катламнары ачылып, хис сурәтен яңа төсмерләргә баета. Җан хәрәкәтенең юнәлеше кискен үзгәрә, бу инде узгынчы тәэсирләр, бер минутлык хисләр генә түгел, бәлки, тамчылап җыелган һәм бөялеп торган ихлас кичерешләрнең яшәү рәвешен үзгәртерлек дәрәҗәдә көч-җегәр алуы:

Мин авылга кайткач, ялгыз гына
Чыгамын да ындыр артына,
Каралтылар ышыгына кереп,
Тынып калам...

Һәм елыйм мин, ялгыз рәхәтлектән...

Эчке тетрәнүләр белән телгәләнгән җан ачысы. Картинаның тышкы бөтенлеге әнә шул парә-парә килүне тагын да кискенрәк аерып күрсәтә. «Гади» шигырьләрнең тәэсир көче менә шушы ике нокта — Дөнья һәм Кеше дигән полюслар арасында барлыкка килүче куәтле «магнит кыры»на бәйле булырга тиеш. Бер яктан, бу — Г.Рәхим поэзиясендә баштан ук күренгән сыйфатның — конкрет сурәттән күпмәгънәлелеккә һәм гомумиләштерүгә чыгу, үзеңне мәңгелек чылбырның бер буыны итеп тою, әлеге сыйфатларның алга таба ныгый, тамырлана төшүе. Икенче яктан, күпчелек шигырьләрендә аны үзенчәлекле шагыйрь итеп танытучы эстетик үзәк абайлана башлый. Инде ул «кантарлар»дан башка ташларны да үз урынына куеп бара: бусы нигез салырга булса, икенчесе —дивар өяргә, ә менә бусы, нәфисрәге,— тышлау өчен, ягъни «облицовкага»...

«Табылдыклар өстәлә» циклы, шулай ук шагыйрьнең, «тар шигырьләр үлчәве»н җимереп, кыска пьесалар, операга либретто, нәсер-«каргышнамәләр», хикәяләр һәм повестьлар иҗат итүе әнә шул хакта сөйли. Сибгат ага Хәким әйтмешли, прозасы — күңелендә шигырь күплектән...

Гәрәй Рәхим бу тормыш-яшәешнең иң асыл, беренчел нигезләрен табарга омтыла:

Мин еллардан гомер дигән
Бер челтәр үреп барам;
Матур һәм ямьсез үрелгән
Төшләрен күреп барам.

Халык көнкүреше бизәкләреннән, туган як табигате төсләреннән, онытылмас хатирәләр һәм тормышның һәрдаим туып торган сорауларыннан үрелгән күзгә күренмәс моң челтәре. Аның бер җебе — тел һәм күңел паклыген саклап кала алган әби-бабалары язмышы. Икенче җебе —бил сынардай чакларда да илне ятларга бирмәгән әти-әниләренең көчле рухы. Ә җирлегендә — «утыз яшьтә икенче кат чәч агартучы» кордашларының якты эшләре, җитди омтылышлары. Аларга да гомер челтәрен үрү һәм матур итеп үрү җиңел түгел. Һәр буынга тормыш үз табышмакларын, киртәләрен әзерләп тора, олы юлга һәр буын үз хаталары белән көрәшә-көрәшә чыга. Шуңа күрә дә бу иҗат — үзенең асылы белән драматик. Сабыр, җитди драматизм тормыш мәгънәсен, дөнья ямен нечкәрәк тоярга булыша.

Катлаулы бу тормышта, кайберәүләр хәтта үзләренең чын асылыннан ераклаша, кача барган бер вакытта, хисләр табигыйлеген, принциплар ныклыгын саклап калу җиңел түгел. Шагыйрь әйткәнчә, күбрәк «без әдәпле генә яшибез, бер-беребезгә каты дәшмибез»...

Бу иҗади проблема шагыйрь шәхесенең бөтенлеге, шагыйрь «мин»енең зурлыгы хакында да уйландыра.

Бервакыт үзе үк, уйнап-көлеп: «Эш җайланды, тәнкыйтьчеләр уйлап тапкач яңа термин. Миндә хәзер ике мин бар: берсе — үзем, берсе — лирик мин»,— дип язса да, Г. Рәхим тормышта һәм шигырьдә туры сүзле, нык вәгъдәле булып кала. Язмыш сынауларында калган чордашларыннан ул

бары игелекле һәм кешелекле сыйфатлар гына эзли. Чит-ят күзләрдән ачык йөз, үткен сүз белән яшерелгән моңлы күңеле ак кәгазьгә ачыла...

Шагыйрьнең мондый холкы, тормышта һәм иҗатта эзлеклелеге туган җире һәм үзенең якташлары белән бәйле булырга тиеш. Бик күп сыйфатлар аңа «Көннәр язга авышкач» повестендагы Ычтуп дәдәй кебек җор телле, шаян һәм мут ил картларыннан, әсәрләнүчән, йомшак күңелле әнисе Фәкилә ападан киләдер. Бу иҗатның чишмә башы — шагыйрьнең туган төбәгендә: аның һәр шигыре үз авылдашларының «үзгә бер моңы, үтә гади, ләкин гаять шигъри сүзләре булган җырларына» тартым. Опера өчен язган либреттосында исә («Каһәрләнгән мәхәббәт», Б.Мулюков музыкасы) шагыйрьнең туган як тауларындагы Агин, Мамин чишмәләре бергә кушылып җырлаган кебек: аңа бөтен поэзиясе, рухы, сулышы белән шагыйрьне үстергән халык стихиясе шаулап керә. Шуңа күрә аның төп ориентиры һәрчак үзгәрешсез кала: ул — тормыш, кешеләр, кешелеклелек. Шуңа күрә вак-төяк борчулар, көндәлек мәшәкатьләр генә шагыйрьнең башын идерергә сәләтсез, алар аның күңелен тарайта, язмышын каралта алмый.

Үзен бәхетле шагыйрь итеп тоя Гәрәй Рәхим. Сугыш белән яшьтәш булып та, аннан озынрак гомерле булганга күрә бәхетле ул.

Канлы-яшьле еллар әчесе ана сөте белән кергәнгә күрәдер, ахрысы, аның иҗатында Бөек Ватан сугышын кичкән шагыйрьләр — Сибгат Хәким, Хисам Камал, Әнвәр Давыдовларга якынлык та сизелә. Бу уртаклыкның нигезендә — гаҗәеп түземлелек («Мин яратам, ахры, бу дөньяны, җанда матур яра булганга...»), язмышка каршы бару («Кил, минем күрәчәгем!»), дөреслекнең күзенә туры карау («Барган саен минем юл өстемә әткәй кабере калкып чыга һаман...»).

Иҗатында ныклы җирлеккә басарга, крестьянча җитди исәп-гамь белән яшәргә шагыйрь бала чагыннан ук әзер: «Уенчыклар алып тормадык, Җир туфрагы белән уйнадык...» Иген кыры аны каударланмаска һәм вакланмаска өйрәткән, кичерүчән һәм кеше хәленә керүчән итеп үстергән. Шул сыйфатлары, шифалы дым туфракны сугарган кебек, шигыренә дә күчә, аның җирлеген — ышанычлы, формасын — табигый, эчтәлеген тормышчан итә:

Миңа монда җайлы сезнең белән,
Карт авылым монда, үз күгем,
Бер ялгызым гына, яшеренеп,
Бер елармын, ахры, мин бүген...

Тормышны туган йорт тәрәзәсеннән яхшырак күрә шагыйрь, үзенең туган авылына да читкә китеп, тыныч кына карый алмый, сагышлы-моңлы чакларында төп нигезенә «кайтып елый».

Безнең шагыйрьләрнең барысы да диярлек авыл баласы,— «игеннәр иленнән». Безнең җыр буразналары ерак гасырларда да таныш ызаннарга алып чыга. «Игенченең галәмара изге аты!» — урта гасырларда яшәгән хикмәт иясе әнә шулай дип язган һәм тагын: «...Әйтелде шәһри Болгар кәндләрендә» (ягъни бистәләрендә),— дип калдырган. Тормышны тук башаклы арыш теземнәрендә, хисапсыз күп ашлык көшелләрендә күргән бүгенге шагыйрь исә: «Дөньяның кыл уртасында язылды... бу җыр»,— дип белдерә.

Юк, болай диюенә карап без аны дөнья уртасына чыгып баскан бер тәкәббер затка тиңләргә ашыкмыйк! Бу җырның мәгънәви төше анык, конкрет. Туфрагы конкрет. Шунлыктан аның эчтәлегендә «дөнья» төшенчәсе яңарак, киңрәк мәгънәләре белән ачыла. Ул — безнең сөенечләребез һәм көенечләребезне, мәхәббәт һәм нәфрәтебезне бергә туплаган даирә. Шагыйрьнең күңел башкаласы, өе исә менә шул дөньяның кыл уртасында: «Зур дөньяның йөзен шушы нәни өйдән күзәтәм. Дөнья матурлыгын сезгә — кешеләргә күрсәтәм...»

Дөнья уртасына нинди сүз әйтергә дип чыккан соң шагыйрь? Аның миссиясе нидән гыйбарәт?

Г.Рәхим иҗатында сафлыкны һәм табигыйлекне сагыну хисе өстенлек итә, дигән идек... Сагыну хисе үсә-үсә дә Борчылуга әверелә икән ул. Ә бу Борчылу дигәнебез — үзәгендә «йөгәне-ияре белән аргамак тупырдап торган» хис, хәрәкәткә чакыручы хис. Ил-җир, Кеше язмышы өчен җаваплылык хисе нәкъ менә шул Борчылуга нигезләнә: «Ә бүгенгә — аз да, күп тә түгел — без җаваплы бугай дөньяга». Ул, сугыш кузгалган елны туган ир-егет, илләр йөзен сагыш-хәсрәт саргайтканын онытмаска өнди («сугыш булган җирдә сагыш бар»). Һәм, әлеге дә баягы, моңарчы аның шигырьләрендә күренгәләгән таш образы — нигез яки дивар коруга гына түгел: «Бу таш белән бер-

кемгә дә сукмадым мин, әмма кулга алдым»,— дип, явызларны кисәтү өчен дә кирәк икән. Шулай итеп шагыйрьнең әсәрләрендә публицистик ачыклык белән фәлсәфи тирәнлек табигый кушыла, шәхси һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең бөтенлеге раслана. Дөнья, ил образы, кеше алдындагы бурыч төшенчәсе дә ачыклана, конкретлаша төшә.

Шагыйрь тук чырай астындагы рухи хәерчелекне, күңел китеклеген дә күрә, адәми затлар арасындагы мөнәсәбәтләрнең каршылыклы асылына игътибар иттерә: «Утызга да тулмый яшибез, шул кадәрле төгәл яшибез, әллә артык кызык кеше без, әллә бер дә кызык түгелбез...» Гражданлык җаваплылыгы аның үзен дә зур таләпләр куеп яшәргә, үтемле темалар артына яшеренмәскә, бөртек авырлыгын тойган башак кебек, сүз кыйммәтен тоярга өйрәтә.

Заман һәм аның өчен җаваплылык турында сүз иң югары дәрәҗәдә алып барылырга тиеш. Г.Рәхимнең, әнә шул җаваплылыкны истә тотып, бервакыт: «Халтурачылардан көн кадагына суккан темаларны тартып алырга кирәк!» — дип чакыруы хәтердә. Ә чын поэзиядә, гомумән, вак темалар, кечкенә төшенчәләр юк. Шагыйрьнең ирләрчә җитди һәм саллы фикерләү җирлегендә туган ил, халык, заман кебек гадәти, күнегелгән төшенчәләр яңа, конкрет мәгънәләре белән ачыла: «Заманага лаек җырлар эзләп, йөрәкләрдән кайчак каннар тама...»

Шагыйрьнең тоткан юлы — олы максатлар хакына янып яшәү, югары эстетик зәвыкка, киң идея карашына ия булу, халыкның рухи һәм әхлакый нигезләренә таяну. Шуңа күрә дөнья уртасына басып сүз әйтерлеге бар шагыйрьнең: аның шәхси кичерешләре, шигырендәге лирик башлангыч «дөнья» һәм «заман» масштабларына үрелеп үсә.

«Масштаблы» дигәннән, без ул сүзне, «киң колачлы», хәтта «зур күләмле» мәгънәсендә генә аңларга күнегеп киттек. Аның беренче нигезен — шартлы нисбәтне белдерүен бик искә алмыйбыз бугай. Ә бит, мәсәлән, болай да фараз итәргә була: масштаблырак булган саен, шигырьнең төше кечерәя һәм тыгызлана барырга тиеш. Гәрәй Рәхим менә шулайрак уйлый төсле. «Шигырь — нокта... Шул ноктага сыйган Галәмемнең бөтен җисеме...» — ди бит ул. Һәр шигырьне бер «төш» тирәсенә тупларга! Аңардагы масштабның зурлыгы дөньяга караш бөтенлеге, тормышка мөнәсәбәт җитлеккәнлеге белән билгеләнергә тиеш! Шагыйрь үз иҗатында шушы кыйблага йөз тота һәм аның бу юнәлештә һәрвакыттагыча эзлекле булуы күренә.

Яшәү мәгънәсен аңлау, сүз кадерен белү җәһәтеннән Г.Рәхим поэзиясенең фронтовик шагыйрьләр иҗаты белән аваздашлыгына игътибар иткән идек инде. Бу — очраклы бер күзәтү генә түгел.

Әйдәгез әле, чагыштырып карыйк:

Белсәң, әнкәй, дошман тылларына
Разведкага барган чакларым,
Мин куркудан доганң гел укыдым,
Җаным саклап кеше сатмадым.

*(Х.Камал)*

Мин әнкәйгә үкси-үкси сөйлим
Шәһәрдәге дуслар турында:
— Алар, әнкәй, шундый әйбәтләр,—
дим,—
Кечесе дә,— димен,— зуры да. *(Г.Рәхим)*

Биредә уртаклык бармы? Бар. Фәлсәфи конфликт уртаклыгы. Бер якта — һәр күренештән гүзәллек, тигезлек эзләү һәм гармониягә омтылу, икенче якта — тормышның күптөрле, катлаулы, ә кайчакта рәхимсез чынбарлыгы. Бу ике зур көчнең килешмәүчән көрәше бик күп төсмерләрдән хасил була. Нәкъ менә шул каршылыклар кисешкән ноктада Г.Рәхимне үз буыны белән берләштерүче сыйфатлар, аның шәхес үзенчәлеге, үз сүзе һәм шул сүзне әйтү рәвеше — кыскасы, әнә шул дүрт төрле хасияте бербөтен яшәеш ала төсле.

Нәтиҗә ясауны укучы ихтыярына калдырып, аның уйлануларына бер этәргеч бирү өчен, шагыйрьнең иҗат үзенчәлеге турындагы тагын кайбер күзәтүләребез белән уртаклашыйк.

Беренче күзәтү: «Сары төс төяп көз килгән мәлдә күңелне сагыш биләргә тиеш. Ләкин, яз төяп кошлар кайтыр дип, сагышны шатлык җиңәргә тиеш».— Тормыш каршылыкларын гадиләштеребрәк күзаллау, җиңел, хәтта ваемсызрак оптимизм.

Икенче күзәтү: «Күпме көннәр үткәч, ярсу күңелем сыкрап куйды, сагынып яз шигырен... Мин «Яшьлек» дип шигырь язган урында көне буе сары яфрак коела».— Аек акыл хәрәкәте, күренешләр арасындагы катлаулы багланышларга игътибар итү сизелә, әмма әлегә бу мөнәсәбәт сүлпән, шунлыктан киләчәккә ышанычның беркадәр күңел төшенкелеге белән алмашынуы бар кебек.

Өченче күзәтү:

Гомер дигән пар ат һаман чаба,
Кабатланмый ни дә, бар да таман.
Барган саен ләкин юл өстенә
Әткәй кабере калкып чыга һаман...

Бу — тормышны үз төсендә күрүдән курыкмау, каршылыкларның бердәмлеген тану. Биредә инде кирәк икән көчсезне яклау, ышанычын югалтканга терәк булу, конфликтның уртасына ташлану теләге өстенлек ала башлый...

Бу юллар арасында еллар ята.

Шигырь юллары гына түгел, дөньяны аңлау баскычларыдыр төсле алар. Тик ул баскычлардан өскә таба атларга да, кире төшәргә дә мөмкин...

Шулай, шагыйрь, тормышның үзе кебек, беренче карашка гына гади тоела. Һәм бу «гадилек» иҗат мәйданына аяк баскан елларындагы туры, кискен, дөресен әйткәндә, өстәрәк яткан фәлсәфи сөземтәләргә, логик нәтиҗәләргә охшамаган.

Бүгенге укучы шигырьдән вәгазь көтми, ул катлаулы бу заманда үзенә теләктәш эзли, шагыйрь күңелендә йөргән иң яшерен серне белергә омтыла.

Әлбәттә, шагыйрьнең иҗади үсеше — катлаулы күренеш, анда җиңелрәк юлдан чалулап китүләр дә, текә үткелләрдән каерылып төшүләр дә юк түгел. Ләкин анда олы юл, төп тенденция ачык төсмерләнә. Ул тенденция үзеңне аңлаудан — дөньяны аңлауга таба, һәм, тышкы тәэсирләрдән бигрәк, эчке тетрәнүләр нәтиҗәсендә кабынып китүгә таба бара. Шул юнәлештә тамырлары тирәнгәрәк үтәр төсле аның!

Гәрәй Рәхим күңел биографиясен гел кояшлы көннәрдән генә төзи ала. Бу дөнья нинди генә кырыс булмасын, шагыйрь-улының аңа мәхәббәте тугрылыклы, даими.

Юнәлешләр еш алышынып торган мәлләрдә дә күңеленә хыянәт итмәү, һәрчак үзең булып калу өчен адәм баласына еш кына әнә шундый тотрыклы, җитди хис җитми.

«...Минем күңелемдә олы бер Мәхәббәт туды... Мин шул Мәхәббәтне югалтмасам, дөньядагы бер генә кара көчкә дә бирешмәячәкмен»,— ди «Көннәр язга авышкач» повестеның герое.

Мәхәббәт — Гәрәй Рәхим иҗатының туфрагы, суты һәм һавасы. Шуңа күрә дә «сүз башласа, телләреннән җыр булып моң түгелә» аның.

Дөньяга булган сөюем
шушы нәни җыр булыр,—

ди шагыйрь. Ә дөньяның камиллеге өчен көрәшүче, кеше рухының илаһи бөеклеген яклаган җыр —«нәни» була алмый!

1981

## ЮЛЫ ҖИҢЕЛЛӘРДӘН КӨНЛӘШМИК

...Әй сез, яшәү баскычлары!
Һәр адымда
Кирәк икән ачкычлары!
Рәдиф Гаташ

Юк, иҗатында җиңел язмыш эзләмәде ул. Башта ук: «Әнкәй, җибәр мине сәяхәткә — күңел диңгезләрен күрим...» — дип ашкына башлаган иде. Әле үзенә дә аңлашылып җитмәгән күңел алгысуы тора-бара гына аныграк төсмерләнде: кешенең бу китүе, бу сәфәре — үз асылына әйләнеп кайту өчен икән! Рухи асылына, рухи тамырларына.

Гомер чишмәсеннән ерак китеп,
якынайган саен диңгезгә,
ешрак сагынам һаман әнкәм өен,
ныграк табынам туган нигезгә.

Иҗатында үткән юлдан, тирәннән килә бу сүзләр... Аларга беренче адымны сәях җанлы үсмер малай ясый. Ул үзенең киләчәгенә илтәсе юлларны әле «туган йорт тәрәзәсеннән» генә күрә. Икенче адымда — инде шактый озын юллар узарга өлгергән ир-егет, аның дөньяны «халык урамыннан» күрергә омтылуы. Өченче адым — Эйфель манарасыннан яңгыраган сагышлы һәм горур җыр: «Бүген — минем сагыну көнем. Бүген — ераклардан күренә миңа илем, туган җирем, әнием!» Әйе, бу —үз башыңнан кичереп, үз җаныңнан үткәреп табылган хакыйкать. Шуңа күрә шагыйрьгә дә, аның укучысына да бердәй аңлаешлы, бердәй кадерле ул.

Минемчә, шагыйрь шәхесенең зурлыгы, фидакарьлеге — мәхәббәт шигырьләрендә. Мәхәббәт шигырьләренең дәртендә һәм дәрманында...

Изге хисләрне вакламау, кадерле кешеңне рәнҗетмәү, сөю-сәгадәтне шик-күләгәләрдән аралап, пакь көе саклау... Аның иҗатын шул саф, садә нур яктырта.

...Бөреләрнең
тик ачылган чагын, саф чагын,
каеннарның суты ташыган мәлен
күзләреңнең язы сакласын.

Рәдиф Гатауллинның иҗади эзләнүләре алга таба, нигездә, ике юнәлештә барды. Бер яктан, шагыйрь сүз тылсымы һәм хыял көче белән тормышка, чынбарлыкка тәэсир итеп, аны үзгәртергә, матурларга омтыла: «Эретәсе иде туңган җирне, терелтәсе иде гөлләрне...» Икенче яктан, шул тормыш-чынбарлык поэзиягә үзе килеп керә, аның туфрагына һәм һавасына әверелә: «Арыш дулкынлана: күңелемә бәреп керә музыкасы...» Шуңа нисбәтле рәвештә Р.Гатауллинның бөтен шигъри системасы тирән үзгәрешләр кичерә. Ул үзе дә моны сүз арасында гына: «Сизәм: проза хәзер аралаша сиңа атап язган шигырьдә»,— дип искәртеп куя. «Проза» бу шигъриятнең «төшен» эрерәк, тазарак итте, аны җиргә якынайтты.

«Иске китапка зимагур бабайлар язган җыр»га гына колак салыйк! Төенләнгән көе калган бер сорау бугай ул, ерак еллардан килеп җитә алмаган билгесез хат бугай: «Үткән гомер — туган җир, гөлбакча. Кайтасы иде...»

Сагышлы җырлар юлыннан якты сәхифәләр эзли шагыйрь, үзенең иҗат-хыял кодрәте белән әлеге сәхифәләрне аяз күккә күтәрә. Алар, бәлки, очар кошка әйләнерләр, йә шифалы яңгыр болыты булып калырлар, әмма моңга сусап ачылган жаннарны боз булып сукмаслар! Чөнки шагыйрьнең күңеле изгелектә, һәм шул изгелектән аның һәр сүзе хәерле эшкә фатиха, яман уйны кисәтү сурәтенә керә.

Тасвир шигырьләр урынын инде шигырь-мөнәсәбәт, шигырь-хат били: күңел серен сөйләүче, илтифатка һәм аңлауга өмет итүче, чакыру-өндәү яисә кисәтү булып яңгыраучы хат... («Хат язам — җыр язам...») Шәкли үзенчәлек кенә микән бу?! Шигырьнең эчке үсеше лирик монолог рәвешен ала.

Мондый ихласлыкның нигезендә — фикер җитлеккәнлеге һәм кичерешләр аныклыгы. Шуның өстенә — шигъри юлларда «оеп» калган автор тавышы, табигый интонация.

Әйе, сүз, асылда, кабатланмас яңгырашы белән дә истә калучан әсәрләр турында бара. Китап бит-ләрендәге «оя»ларында вакытлыча гына тынып торалардыр күк алар. Партитурадан күтәрелеп очарга сәләтле көйне хәтерләтәләр. Күңелнең билгеле бер халәтен таләп итүче, гадәтләнгән сүз-сурәт бәйләнешләрен җимерергә тырышучы һәм үзенең әнә шундый «капризлары» белән кызыклы да булган шигъри система. Менә ни өчен кайчакта Рәдиф Гатауллинны, ул тәкъдим иткән тонны кабул итүе җиңел түгел.

Ак кәгазьгә мин шатланып яздым  ласа!..

Шигырь дөм караңгы төнне телеп үткән яшен яктысы кебек башлана. Ак кәгазьгә һәм укучы-сының ак  күңеленә өмет белән баккан шагыйрь — беренче юлда. Шигырь безнең күз алдында ярала. Сүз-сурәтләр гаҗәеп бер эзлеклелектә бер-берсен эзләп килә. Әлеге чиратлашу шулкадәр иркен, табигый: хәтта күренешләрнең очраклы гына янәшәлеге дип тә уйларлык. Хәлбуки, бу — образлы фикернең үзенчәлекле хәрәкәте, лирик геройның күңел халәте белән бәйләнгән.

Р.Гатауллин стиленең янә бер үзенчәлегенә игътибар итми мөмкин түгел. Аның һәр шигырендә диярлек килешмәүчән ике башлангыч бәхәсләшә. Бер яктан, ихлас кичерешләр, ургып торган хис булса, икенче яктан, исәпчел символика, ялангачрак конструкцияләр үзара тыныша алмый. Хис детальләрен шагыйрь көчәйтеп, зурайтып тасвирларга ярата: сөйгәне киткәндә «аяк астында тетрәп җир шуыша»; сөенгән чагы булса, канында елга агышын сизә... Шул ук вакытта хәтта табигать күренешләренең дә (бер шигырендәге пластмасса торна шикелле) бары символ-төшенчә генә булып калуына рәнҗеп куясың. Төсләр тыйнаклыгы өстенә, сурәт-сынның бөтенләй диярлек тасвирланмавы да әлеге системадан килеп чыга. Ул моны үзе дә аңлый: «Минем шушы сурәт — күңелеңнең тик шәүләсе. Җырның меңнән бер авазы... *Кайтавазы*...»

Табигатьне генә түгел, укучыга таныш образларны да символ-төшенчә хәлендә калдыру, мәгълүм исемнәрне, китап сүзләрен «ярату» күзгә ташлана. Заман үзгәрешләренә тарихтан һәм әдәбияттан гыйбрәт эзләгән булып, үткән көнне яктыга алып чыгарга тырыша шагыйрь. Иҗатының беренче чорыннан башлап («Һейне тауларда») хәзергесенә кадәр («Әбелхарис һәм Әбүгалисина турында») шундый юнәлештәге хәрәкәт сизелә. Лирик герой үзенең идеалын дәверләр, каһарманнар фонына куеп сыный. «Тик һәркемнең үз Парижы!» кебек көтелмәгән ракурс-янәшәлекләр, «Орлеан кызлары», «Феникс — үлемсез кош» шигырьләрендәге таныш образларның яңа бәйләнешләре... Алар яшәү мәгънәсе, дәвамлылык, тугрылык турында уйлануларның җирлеген киңәйтә.

Кичәге көн — китапка әверелгән тарих кына түгел. Ул — үз иҗатыңның иң биек нокталары да. Шигырьләрнең зурлыгы һәм тәэсир көче шагыйрь узган юллар озынлыгы, ул кичергән хисләр кайнарлыгы белән үлчәнә.

Бу уңайдан «Җилкән» һәм «Нигез сагындырса» яки «Әтиемне юксынам» һәм «Әткәй яшендә» дигән шигырьләрен искә төшерү урынлы булыр. Язылу аралары — тугыз-ун ел, тематик якынлыкла-ры исемнәреннән үк сизелеп тора. Ләкин тышкы охшашлык әлеге шигырьләрдәге эчке үсешне һәм бер үк вакытта фәлсәфи каршылыкны тагын да ачыграк, җетерәк күрсәтеп тора. Бер мәлгә артка чиге-неп алган фикер, яңа көч белән ыргылып, ныграк катламга ябыша, биегрәк үргә күтәрелә. Аннан ары текәрәк биеклекләр — «Ерак Марс авылы», «Тел ачкычлары», «Алибилар булмас» һәм башкалар күренә...

Инде Рәдиф Гатауллин тагын бер — «Европада татар шагыйрьләре»ннән башланган әйләнешне тәгәлләде шикелле. Алдагысы нинди булыр? Ирешелгәннәрне ныгыту рәвешен алырмы ул, әллә яңа — көтелмәгән ачышлар юлыннан китәрме?.. Күрәзәлек итәргә ашыкмыйк. Сораулар, шагыйрь үзе үк әйтмешли, «төенләнгән килеш калсын». Һәрдаим камиллеккә омтылуы, өметләндереп һәм киләчәккә чакырып торуы белән гүзәл ләбаса ул шигърият!

Р.Гатауллинның соңгы еллардагы әсәрләре әнә шул үсеш бөҗраларын, үсеш контрастларын күр-сәтүе белән гыйбрәтле. Беренче тәҗрибәләреннән алып, эзләнүләре, табышлары һәм югалтулары белән шагыйрьнең тулаем үзенчәлекле иҗаты күз алдыннан кичә. Әмма бу үткәнгә әйләнеп карау — киләчәк хакына: «Акылны без хаклы яклый белдек, тыймадыкмы хисне?.. Тыныч, тын булганга әйбәт, дидек түгелме шигырьне?»

Һәрхәлдә, шагыйрьне алга таба да җиңел юллар көтми.

Көнләшмибез юлы җиңелләрдән —

Һаман максат кушкан юлдан йөрик...
Юлда каршы алыйк Кояш-киләчәкне!..

Җырдан өч кенә юл. Көләч җырдан. Ашкынулы җырдан. Ул безне олы идеаллар, якты максатлар иленә чакыра.

1980

## БАЛАЧАККА ЕШРАК КАЙТЫГЫЗ!

Сабый вактын сагынмакта һәр шагыйрь дә...
Габдулла Тукай.

Табигать безнең һәркайсыбызга тәпи йөри башлаганчы ук искиткеч күркәм сыйфатлар бүләк итә: самимилек һәм зирәклек, чын күңелдән соклана һәм сөенә белү, теләсә нинди җисемгә «җан өрү» һәм үз-үзеңә читтән карый алу сәләте... Бу сыйфатлар, терекөмеш сыман, тормышның теләсә нинди буасын ерып ташларга да, күз ачып йомганчы исраф ителергә дә мөмкин. Шагыйрь җаннар гына шушы хәзинәнең чын бәһасен белә, шуңа да аны берьюлы суга салмыйлар. Алар, үз өлешләрен дә бәрәкәтле тотып, аны дөньяның бүтән балаларына һәм, әйтергә кирәк, өлкән яшьтәгеләренә дә бөртекләп өләшәләр: саф-таза асылыңны саклау — өзлексез көрәш-хәрәкәттә булу нәтиҗәсе ул, дип искәртәләр.

Үзебезгә дә бик кадерле булган әлеге «терекөмеш бөртеге»н без балаларыбыз учына салабыз. Бу мирас аларга, бәлки, татлы күз яше яисә язгы кояш тамчысы булып күренер. Алар аңа соклану бәхетен һәм аны югалту нәүмизлеген кичерерләр. Шушы тойгы күңелләрендә гомер буена сакланып калыр һәм «терекөмеш тамчысы кебек, тормыш учыннан тәгәрәп төшә күрмәгез!» дип, һәрвакыт кисәтеп торыр.

Балалар өчен язылган һәр шигырьгә әнә шул терекөмеш бөртеге түгел микән дип карыйсы килә...

Сабый чак бәхетен ятимлек белән кыерсыткан язмыш Роберт Миңнуллинга әҗәтен соңлап булса да түләргә уйлагандыр, күрәсең... Университет тәмамлагач, ул очраклы рәвештә генә диярлек балалар матбугатында эшли башлады. Нәниләр өчен язылган беренче шигырьләре дә баштарак әле шундый бер очраклылык булып кына тоелды бугай. Табигать этюдлары... Пират исемле маэмай белән шигъри телдә сөйләшүләр... Яшь автор әйтерсең өлкәннәр өчен дигән дәфтәреннән кайбер парчаларны нәниләргә дә укып күрсәтергә карар кылган иде.

Тора-бара бу «шаярулар»ның яхшы мәгънәдәге «кәсеп» булып калуы, язмышка әверелүе күренде.

Балалар өчен язган шигырьләре Роберт Миңнуллин иҗатын көтелмәгән яктан ачып җибәрде. Андагы моңсулык, сабыр-салмак агыш та заман тизлекләренә битарафлык һәм шәхси кичерешләр утында гына яну түгел икән, киресенчә, бу — мода җилләренә баш бирмичә, шигъриятнең асылына тугры калу, хисләрнең табигый сафлыгына омтылу, дөньяны яңабаштан ачу шатлыгы кичерү икән. Менә ни өчен аның шигъри сүзе «махсус» атап язмаганда да балаларныкы булып китә алган! Менә ни өчен аның балаларга дигән шигыре олылар укыганда да мәгънәсен югалтмый! Безгә бу иҗат тылсымы үткән заманда (үз балачагыбызда), хәзерге һәм киләчәк заманнарда (балаларыбыз белән бергә) яшәү мөмкинлеге бирә. Балачак һәм табигатьнең үлемсезлеге тормышның чиксез дәвамын тоярга, аның мәңгелек сорауларын аңларга ярдәм итә.

Табигать берәүләргә, балалар шагыйре булырсың, дип, аерым сәләт бирәме? Балалар поэзиясе — кайберәүләр өчен генә бүлеп куелган кишәрлекме? Ул бит, асылда, шигъри тоемлау, фикерләү рәвеше, дөньяга мөнәсәбәт стиле белән бәйләнгән. Димәк, Роберт Миңнуллинның да иҗади кыйбласы беренче карашка гына очраклы тоелган. Шигырьдән шигырьгә, китаптан китапка үсеп, ул балалар әдәбиятының зурлыгына, изге вазифасына инануын һәм аңа мавыгып хезмәт итүен раслый. Бу өлкәдәге барча уңышлары шагыйрьнең гражданлык активлыгы, иҗатта зур җаваплылык тоюы нигезендә күтәрелә.

Активлык һәм җаваплылыкның бер мисалы итеп, телевидениедә Р.Миңнуллин алып барган «Шигъри тәлгәшләр» тапшыруын гына да искә алырга мөмкин. Бу инде — шагыйрьнең фидаилеге, тәрбия һәм мәгърифәтчелек белән турыдан-туры шөгыльләнүе, шигырьләрендә башлаган сүзен бүтән формада дәвам итүе, иҗатының бер тармагы. Әйтерсең ул җаны-тәне белән уенга бирелгән сабыйлар арасында: менә ул аларны бүлдерми генә яңа уен башлап җибәрә, балалар, үзләре дә сизмәстән, шул

уенга кушылалар. Аларга ул үзләре уйлап тапкан булып тоела. Уен өзелми, аңа яңа буыннар өстәлеп китә.

Гомумән, Р.Миңнуллинның балаларга багышланган иҗаты кайдадыр өзелеп торган мөһим җепне ялгау, бер мизгелгә генә туктап торган мәңгелек двигательне хәрәкәткә китерү кебек тәэсир калдыра.

...Өлкәннәрнең тай җигә алмауларын күреп торган кыю малайны ул:

Җәфа чиксәм
Чигәр идем,
Мин ул тайны
Җигәр идем...—

дип ашкындыра.

«Әни эштән кайтканчы...» дигән шигырьнең булдыклы герое да игелек эшләү уе белән янган үз ишләрен матур үрнәгенә ияртеп китәрлек. «Елмаючы бүреләр» белән «Куян йөрәкле Бүре» турында укыгач, бик теләгәндә явызлыкны да йөгәнләргә була икән, дип ышанасың.

Хәрәкәткә чакыру, аңа дөрес юнәлеш бирү — игелекле һәм бәрәкәтле эш. «Урман аша үткәндә», «Акбай шулай ди...» кебек аз гына хәйләкәр шигырьләре шагыйрьнең тиешле нәсыйхәтне җайлы гына, киная белән генә бүтәннәргә җиткерә алу осталыгын күрсәтте. Ул «уйнап кына» җитди мәгънәгә алып килә, намус, тугрылык, хезмәт сөю кебек олы төшенчәләрнең асылын аңлата. Биредә аңа табигый кече күңеллелек һәм шаянлык, бала җанын аңларга тырышу сыйфатлары, шуның өстенә беркадәр артистлык та ярдәмгә килә.

Белгәнебезчә, һәр сабый үзе дә тумыштан «артист». Шагыйрь исә аны партнерлыкка чакыра, аның фантазиясен очкынландырып җибәрә, аңа «рольгә керергә» булыша. Бу — әлеге дә баягы, «мәңгелек двигатель»не хәрәкәткә китерү, уенга җәлеп итү, эшкә-иҗатка рухландыру, дөньяның искитмәле күренешләрен үзең табарга һәм аңларга өйрәтү. Шушы хәрәкәтнең беренчел этәргече, «әлифба»сы сүз уйнатулардан башлана.

Нәни укучыга шигырь иң әүвәл гаҗәеп яңгырашлар, сүз фокуслары булып килә. Бер мәлгә үзеңне циркта утыргандай хис итәсең. Р.Миңнуллинның «Акбай цирк карый» дигән беренче җыентыгында, «Урамнан фил китеп бара» кебек, турыдан-туры тамашага нигезләнгән шигырьләр дә байтак. Дөрес, бөтен «йөк»не цирк маҗаралары җилкәсенә салган очракларда авторның үз табышлары югалыбрак кала, аның үзенә генә хас тавышын аеруы шактый кыенлаша иде. Шулай да бу цикл бала күңеленә беренче адым, дөньяга сабый күзләре белән карарга тырышу булып хәтердә калды.

«Җиде абый тай җигә» исемле китабында инде табышлар өстенлек итә. Тамашаларда бала үзе катнаша. Серле сүзләр урманында ул «юлбАРЫСлан, мәЧЕлән, төлКЕрпе» дигән җанварларны күреп гаҗәпкә кала. АвтоБусның автоДуска әверелүенә сөенә. Сүз, бишектәге сабый төсле, елмаеп кына яткан чакларында да сокландыра.

Без токкан йолдызлар белән
Зу-ур чиләк тулган иде,
Чиләгебез йолдыз белән
Чүмәкәй булган иде.

Бу шигырьләр — шактый тыныч-тигез агышлы. Аларны укыганда, капылт кына борылышлар булыр да, көтелмәгән хәлләргә юлыгырсың дигән уй гадәттә күңелгә килми. Шулай да уяу-аң булырга кирәк! ...Әнә малайлар үзләре ясаган ракета эченә кереп утырганнар да: «Ни дисәң дә кораб бит. Очып китсә әгәр дә, безнең эшләр харап бит»,— дип шүрләп калганнар. Алга таба шигырьне, билгеле, колак торгызыбрак тыңларга мәҗбүрсең.

Әлеге шигырьләрдә куз буу юк, алар сере менә-менә ачылыр кебек тоелган һәм шунлыктан бигрәк тә кызыктырып торган фокусларга тартым. Бәләкәй геройның булыр кебек көттереп тә булмый калучан маҗараларда сыналуын, «алдануын», шуннан ипле генә итеп гыйбрәт чыгаруны Р.Миңнуллин аеруча яратып куллана. Һәм, яшерен-батырын түгел, бу аңа бик килешеп тора. Качкын кәҗәнең кыр кәҗәсенә әверелүен, елгада балык урынына йолдыз каптыруларны искә төшерик...

Әлбәттә, чынбарлык тыштан караганда гына бер күзәнәкле булып күренгән икән. Сабыйның күңел дөньясын тулырак, тирәнрәк аңларга омтылганда, шигырьләр дә катлаулырак, нечкәрәк төсмерләргә байый бара. Шагыйрь өчен иң төп максат — «уеннан уймак» чыгару, ягъни укучының игътибарын туплау һәм аны уйга калдырырлык сүз әйтү. «Акбай цирк карый» җыентыгында ук:

Гөрләвекләр гөрләмәгәч,

Яз була алмас инде...—

дип кайгыручы яки пешереп алгач юашланып киткән кычыткан турында уйланучы нәни геройлар белән танышканда, күңелдә шагыйрьнең зур киләчәгенә өмет хисе туган, шул юнәлештә ай үсәсен көн үсүен күрәсе килгән иде. «Сүз тыңлый», «Әни эштән кайтканчы», «Бүтәннәр күрмәсә дә» кебек шигырьләр әлеге юнәлешнең дәвамы булып кабул ителә. Р.Миңнуллин иҗатының бик үзенчәлекле һәм мөһим принципка — күңелле мотивлардан җитди сөземтәгә ирешү принцибына нигезләнүе вакыт үткән саен ачыграк беленә бара.

Гомумән, Р.Миңнуллинның һәр ике китабын һич сагаюсыз янәшә куеп карарга һәм кистереп әйтергә мөмкин: соңгысы — үзеннән алданрак чыкканы белән игезәк түгел, ягъни ике арадагы үсеш-аерма күзгә ташланып торырлык. Бу үзгәрешнең уңай якка булуына ким дигәндә ике зур дәлил бар.

Беренчесе — шагыйрьнең иҗади мөстәкыйльлеккә ирешә баруы.

Роберт Миңнуллин иҗаты хаклы рәвештә безнең бай традицияле балалар поэзиясе мәктәбеннән дип танылды. Шул ук вакытта аның «өйрәнчек» булып йөргән чоры истә калмаган. Билгеле, үз-үзеңә ташлама ясыйсы килү тойгысы бар әле дөньяда, әнә шул тойгы җиңел юлдан китәргә «котыртып» тора... Әмма шагыйрьнең берәүне дә кабатламаган үз табышлары өстенлек ала. Әйтик, Ш.Галиев безне нигездә җете, контраст буяулары белән җәлеп итсә («...Керпе һаман йөрәгемне чәнчеп тора...», «Йөзә белмәсәң, чәйгә сикермә!»), Р.Миңнуллин йомшаграк, сизелмичә диярлек күчеш ясаучы тоннар сайлый һәм уңышка үзенчә ирешә. Гомумән, Р.Миңнуллин үзен балалар язучысы дип санаган күпләрнең балалар турында... өлкәннәргә һәм өлкәннәрчә фикерләп язуы кебек хатаны кабатламаска тырыша.

Шагыйрьнең үсешенә икенче дәлил — табигыйлекне саклаган хәлдә, шигъри сүзнең мәгънәви тыгызлыгына йөз тотуы.

Кызганыч, күп сүзлелек — балалар поэзиясенең «нәсел чире». Иҗатының башлангыч чорында Р.Миңнуллин да «Елның дүрт төсе» дигән циклы белән әлеге «тел тегермәне»нә бер чүмеч су салган иде. Ләкин шигъри бәйләмнәр белән мавыгуы тикмәгә булмаган икән: ул киңрәк картиналарны, зуррак гомумиләштерүләрне күздә тоткан. Әмма әлегә колачы иңләп бетерә алмаган.

Инде менә «Җиде абый тай җигә» һәм «Айга очтык!» җыентыкларындагы, шулай ук алардан соң басылган күпчелек әсәрләр бер фикергә алып килә: Роберт Миңнуллин үз сүзен шигырьдән шигырьгә саллырак итеп әйтә ала торган шагыйрь булып формалаша.

Бүген ул дүрт шигырьдән торган цикл күләмен дүрт строфалы бер шигырьгә берләштерә, иртәгә исә шул дүрт строфаны дүрт юлга сыйдыра алыр дип өметләнергә кирәк. Юк, бу үзмаксат түгел, бу — укучы таләбе: балалар өчен язылган шигырьнең бер сүзе дә куыш эчле булмаска, һәр юлыннан җегәр ташып торырга тиеш. Аның һәр юлын тормышның тирән катламнарына алып керүче, Балалыктан Олылыкка илтүче гаҗәеп спиральнең бер буыны итәсе иде! Шул чакта гына шигырь салават күпере кебек катлаулы һәм табигый күренеш булып калачак.

Иҗатта табигыйлеккә ирешү — балачакка кире кайту кебек үк мәңгелек сәфәр. Яңа әсәргә керешкән саен өр-яңадан кичелә торган сират күпере. Әмма, никадәр генә авыр булмасын, шагыйрь аны урау юллар белән алыштыра алмый.

*1981*

P. S. 1982 елда балалар өчен язылган шигырь китаплары һәм телевидениедә алып бара торган «Шигъри тәлгәшләр» исемле тапшырулар циклы өчен Роберт Миңнуллин Муса Җәлил исемендәге республика премиясе белән бүләкләнде. Бу — аның балалар әдәбиятын үстерүдәге хезмәтен югары бәяләү, иҗатына ышаныч билгесе иде. Бу — татар балалар поэзиясендә үзенчәлекле шагыйрь тууын икърар итүче таныклама иде.

Әдәбиятыбызның уңдырышлы туфрагында, көчле традицияләрдән сут алып үскәнлектән, татар балалар поэзиясенең турыдан-туры варисы булганлыктан, аның иҗатында аеруча табигый яңгыраган таныш аһәңнәр, күрәсең, әлегә кадәр кайберәүләребезне сагайтып килде... Шул сорауларга җавап биргән төсле, «Роберт Миңнуллин кемгә охшаган?» дигән мәкаләсендә Шәүкәт ага Галиев та: «Минемчә, ул барыннан бигрәк... үзенә охшаган!» — дип язган иде.

Әйе, гомумән алганда бер-берсенә бик охшаган кебек тоелган балалар дөньясы да үзенең асылын-да кабатланмас йөзләр, характерлар, сыйфатларның гаҗәеп гармониясеннән гыйбарәт шул. Балалар

белән бергә әлеге сыйфатларның бер-берсеннән аерылып торган яклары да үсә, көчәя төшә, алар кабатланмас төс һәм төсмерләре белән тармаклана, бер-берсеннән аерыла баралар... Роберт Миңнуллинның балалар шигъриятендәге үзенчәлекле йөзен танып алу баштарак читен иде. Читен иде, ләкин бу аның үз йөзе булмау турында сөйләми, киресенчә, әле генә әйтелгәнчә, без үзебез аны танымый тордык, ахрысы. Ә шагыйрь үзе «Бишектәге бишкә төрләнә» дигән хакыйкатьне һичкайчан истән чыгармаган һәм киләчәктә укучылары белән бергә үсеп китүе ихтимал сыйфатларын алдан күргән! Беренче шигырьләреннән башлап инде ул әйбәт сыйфатларны үстерешә, кимчелекләрнең тамырында ук дәвалануына булыша икән.

Роберт Миңнуллинның төп максаты-юлы да шунда: баланың иртәгәсе көнен истә тотып, «үсә төшкәч тә кияргә яраулы» кием алган кебек, ул тәэсир-тәрбия көче белән киләчәккә төбәлгән шигырьләр иҗат итә. Җырлары, лирикасы белән халыкта танылып өлгергән шагыйрьнең олылар өчен иҗатының да киләчәге әле алдадыр: әлеге шигырьләре, җырлары аның бүгенге балалар —бүгенге укучыларына зур үскәч кирәге булыр дигән ният белән, перспективаны күздә тотып языла кебек.

Балалар шагыйре — икеләтә җаваплы һәм икеләтә бәхетле язмыш иясе: аның иҗаты һәр яңа буын белән яңара, һәр яңа дулкын белән яңа биеклеккә күтәрелә бара. Шагыйрь үз укучыларының бүгенгесендә яши, алар белән киләчәккә таба атлый һәм алар белән яңадан балачак дөньясына әйләнеп кайта. Ә бит кеше гомеренең матурлыгы — балачакка ешрак кайта белүдә дә.

*1983*

## ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР

Мәскәү күз яшьләренә ышанмый.
Рус әйтеме

Көннәрнең берендә мин Николай Иванович Рыжков булып уяндым. Соңгы араларда төрле-төрле сурәткә кереп алулар табигый хәлгә әйләнә башлаган иде инде. Табигый дигәч тә... дөнья үзе шуңа мәҗбүр итә икән ул. Әрсезенә, мәнсезенә шулай юлыга торгач, кайчагында бүре булып улардай хәлгә килсәң дә гаҗәп түгел...

Әмма СССР премьер-министры кабыгына кереп карарга туры килгәне юк иде әле.

Барысына да ерак Казакъстан якларында яшәп ятучы бер милләттәшебез сәбәпче булды. Пенсиядәге мөгаллим Мөхәммәтдин агайны татар китабының СССРдагы татар халкы яшәгән төбәкләргә барып җитмәве бик борчыган. Борчылып кына калмаган ул, кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә карар кылган. Тик ничек итеп, нинди юллар белән?..

Аңлашылса кирәк, вакыйга безнең көннәрдә —әле дә булса, әкияттәге кебек, ак патшага, акыл иясе баш вәзиргә ышаныч бетмәгән шартларда бара... Рәсәй күләмендә мәгариф отличнигы, «илле еллык пропагандист», кулына каләм алып, Мәскәүгә хат язган. Әйе, әйе, СССР министрларының башлыгына — Николай Ивановичның үзенә. Хәзерге Татарстан җирендә халкыбызның миллион ярымы гына калды, янә биш миллионы мәмләкәтнең сиксән төбәгендә яши; мең еллык тарихыбыз, телебез вә әдәбиятыбыз бар, басма сүзгә ия булу ягыннан империядә рустан гына калышканбыз, дигән Мөхәммәтдин агай. Бүген исә татар матбагачыларының милләт алдындагы олы бурычларын үтәп җиткерә алмавыннан зарланган, моның төп сәбәпләреннән берсен әйтеп тә биргән: «Казандагы бердәнбер нәшриятыбыз хәлсез, фәкыйрь шул,— дигән.— Күрәсең, Мәркәз аны шул төбәктә яшәгән халык микъдарынча гына кәгазь белән тәэмин итәдер...»

Милләттәшебез, шулай Мәскәүнең үзенә сүз катып, Татарстаннан читтә яшәсәк тә, без дә бит хак-хокуктан мәхрүм ителгәннәрдән түгел, без дә дәреслеккә, туган телебездәге бүтән төрле китапка мохтаҗ, дигән. Гаделлекне торгызырга өндәп, илнең башка төбәкләрендә көн итүче милләттәшләр өчен дә китап бастырырлык кәгазьне Казанга бирүне сораган Мөхәммәтдин агай.

СССР Министрлар Советы Рәисенә турыдан-туры мөрәҗәгать иткән икән, Мөхәммәтдин агайның моңа үзенчә сәбәбе-сылтавы да юк түгел. Николай Иванович Рыжков белән земляклар лабаса; шул Пермь якларында утыз җиде ел буена сабыйларны укыткан.

Юк, олы яшьтәге мөгаллим, сугыш ветераны үзенә нииндидер майлы калҗа сорап язмый. «Знакум»лыгын да ул халкына китап сүзе басарлык кәгазь алу өчен файдаланып булмасмы дип кенә өметләнә.

Ул заманда әле Татарстаныбыз суверен дәүләт түгел (хат 1990 елга аяк баскан көннәрдә язылган); «Совет халыкларына —дан!» дигән кайгыртучан сүзләр урынына «Көчле Үзәк — көчле республикалар!» дигән чираттагы канатлы тәгъбирне һавага чөйгән вакытлар... Үзәккә таба суыру инерциясе хәтта Рәсәйнең үзендә дә: «Нинди көчләр, нинди упкын тарта безне җан сорап?!» — дип әйтерлек тойгы-настроениеләр кузгаткан мәл. Үзәктән этелү көче исә милли аһ-зарларны, элеккечә үк шактый җилле генә итеп, читкә куып-себереп торуын белә... Балтыйк буе, Молдова илләренең хәле: койрыгын алса — башы ябыша, башын алса — койрыгы, дигәндәй; Кыргыз, Әрмән, Азәрбайҗан, Кырым — гражданнар сугышы чигендә: анда кан түгелә, яшь коела.

Ә Мәскәү, күрәсең, гадәтенчә, күз яшьләренә ышанырга ашыкмый. Аның тәрәзәсендәге «дворник»лар, уңга-сулга җитез генә селтәнеп, куа-себерә тамчыларны, куа-себерә... Яңадан-яңа хасбулатовларга эш арткан вакыт...

«Москва. Совет Министров СССР. Рыжкову Н. И.» дигән хат менә шундый җилләр белән килеп төште дә инде... минем өстәлгә.

Мәскәүләрдән урап килгән хатны кулыма алганда дулкынландыммы икән, әллә аптырадыммы — хәтерләмим. Конвертыннан ук Кремль исе килгәндәй тоелды.

Без бит инде,— җитмеш ел буе, Мәскәүнең төчкергәненә бәрәкалла дип, һәртөрле указны Ходайдан килмеш вәхи белән бер күргән халык...

Татар түбәтәен кыңгыр салып, кишер чәе эчкәндә, даһи юлбашчыбыз, рәхмәт төшкере: «Теге, мулла малае...» — дип, Тукайны телгә алган, имеш.

Халыклар атасы, «Язгы җилләр»неме, «Намус»ныммы укып чыккач, тәэсирләренә чыдаша алмый, җиде төн уртасында Казанга шылтыраткан, дип тел шартлаталар.

Заманының иң күренекле халыкара эшлеклесе «Кече җир» дигән үлемсез китабында безнең милләт кешесен дә искә алгач, ничек куанган идек...

Кыскасы, «Әби патша»дан алып «Рәйсә Мәгъсүмовна»га кадәр, татарның патшалар белән «әшнәлеге»нә мөнәсәбәтле әллә нихәтле риваять иҗат ителгән.

Әлеге хат аркасында Николай Ивановичка да шундый легенда каһарманы булу мөмкинлеге ачылган иде... дип әйтергә теләмим. Ул кадәресе бик яхшы аңлашыла. Республикалар союзы премьер-министры, үзе теләгән җәһәттә дә, һәр хатка җавап язып утыра алмый. Мөгаллим-ветеран да аны гына аңламаслык беркатлы агай түгелдер. Әмма ул, мәсьәләнең никадәр зурлыгын белгәнгә күрә, шул дәрәҗәдән торып,— чишелүен үк, димим...— игътибарга алынуын булса да өмет итә ләбаса.

Миңа нишләргә? Хатны озата килгән баскыч-баскыч кәгазь кисәкләрендә (аны, әлбәттә, Казан Кремлендә дә аягөсте басып укыганнар) «авторга җавап язарга» дип күрсәтмә бирелгән. Кем исеменнән язарга? СССР Министрлар Советы Рәисе булыпмы?.. Дөрес, зур-зур түрәләр өчен, хат кынамы, әллә нинди җаваплы чыгышлар, китаплар иҗат ителгән мохиттә яшибез. Тик, андый эшләрне тапшырганда, фикер сөрешен кайсы якка таба агызырга кирәклеген алдан әйтеп куялар иде. Ә монда — шактый ук четерекле хәл бит: автор дигәнебез хатка каршы хат түгел, конкрет ярдәм көтә!..

«Хөрмәтле...» дип, беренче юлны гына башлаган идем дә шундый икеләнүләр уртасында тукталып-төртелеп калдым.

Аннары, ни булса шул дип, яңадан кулга каләм алдым,—җанны кыйнаган уйларның бер өлеше чайпалып кәгазьгә түгелде.

Беренче хат

Хөрмәтле Мөхәммәтдин ага!

Милли китапчылык юлындагы кыенлыкларга игътибарны юнәлтеп аваз салгансыз — рәхмәт яусын.

Бер караганда, кәгазьгә кытлык — ил белән. Нәшриятларның тулаем матди хәле кыенлашу, тормышыбызның бүтән яклары кебек үк, үзен көннән-көн ныграк сиздерә башлады. Бай чимал чыганагы сыйфатында кырын ятып яшәүгә җайлашып килгәндә генә, СССР дигән мамонтны әле теге, әле бу яктан проблемалар борчасы тешли. Һәм сәяси-политик, һәм икътисади-экономик кыенлыклар уртасында калдык шул. Күз ачып йомган арада илдәге барча сабын заводлары һәм тәмәке фабрикалары берьюлы тузып эштән чыккан, имеш. Кәгазь комбинатларында да «кинәт кенә» чимал җитми, аларга ремонт кирәк булып чыкты. Яңа кануннар кабул ителгән саен куллары ныграк бәйләнә барган дәүләт нәшриятларының хәле тәмам мөшкелләнде. Комбинатлар белән килешү җепләре бушаганнан-бушый, кәгазь алу һәм китап бастыру хакы кыйммәтләнә бара. Бәяләр һәм принциплар шактый ук болганган әлеге «базар»да милли нәшриятка икеләтә, өчләтә авыр булачак.

Чын мәгънәсендә акча басар өчен мәйданга чыккан кооперативлар кәгазьне генә түгел, полиграфия базасын да сатып-тартып алырлык көчкә иреште. «Приватизация» кебек ялтыравыклы төшенчәләр күзне камаштырган, учны кычыттырган бер заманда кайберәүләр, җиңел генә кубып, «хосусый матбага», «конкуренция» дип авыз суын корыта башлады. Шагыйрь әйткәндәй, сөйләве яхшы, күңелле...

Ким дигәндә җитмеш елга артка калганыбызны гына онытабыз. Иске гадәт буенча, тагын да тулы бер дәверне «сикереп үтү» өянәге кузгала.

Җенси яки сәяси порнография бастырып көн күрүдән башлаган «хосусый» матбагалар милли мәдәниятне үстерү кебек авыр йөкне үз җилкәләренә алырлармы?.. Ә бит безне бу юлы да, нәкъ үзебезгә хас, урак-чүкечле хаталар һәм бәлаләр көтеп тора: булганны нигезенә хәтле җимерәбез дә, яңаны күтәрмәгән көе, түбә ябарга маташабыз...

Менә шундый шартларда милли китап үзенең йөзен саклап кала алырмы, туры мәгънәсендә базары төшмәсме аның?..— Сезнең хатка җавапны әлеге шул сорау билгесе белән төгәлләргә мәҗбүрбез.

Әйе, Николай Иванович «исеменнән» менә шундыйрак хат язарга туры килде. Язуын яздым, әмма иңгә басып торган бер эшне, бурычны үтәү тойгысы тумады. Киресенчә, күңелдә ниндидер канәгатьсезлек хисе төенләнде һәм көчәя генә барды. Мөхәммәтдин агай да мондый җавапка, хәтта ул премьер-министрның үзеннән килсә дә, риза булмас иде, мөгаен.

Юк шул, кәгазь хәлләре читен, дип, җае чыккан саен зарланудан гына файда юк. «Планнан тыш» кәгазьне рәхим итеп базардан сатып ал, диярләр: хакы дәүләтнекеннән ун мәртәбәгә кыйммәтрәк булса ни, аның каравы — полный хөррият...

Ә дәүләт? Ә Мәскәү?.. «Ходай Тәгалә дә сораучыга мохтаҗ»,— диләр, анысы. Чынлап торып сорасаң, сукыр бер тиенне дә «конвертлы рубль»гә әйләндереп була, имеш... Әмма безме соң ул — «имчәк сорап еламаган»? Әнә бервакыт... «Җиде миллионлы халыкка китап чыгарырга тиеш бит без, нигә шуны белмәмешкә салышасыз?» — дип ишекләрне шакый торгач, Мәскәү агай кечелекле мөнәсәбәтен күрсәтеп алды. Көннәрнең берендә «өстәмә фонд» дигән кәгазь килеп төшмәсенме. Кәгазь дип, китап баса торганы ук түгел әле, аны алырга мөмкин, дигән язу гына. «2 нче номерлы» дигәннәр (саргылт, сыйфатсыз кәгазь инде; булсын — артыгына өмет иткән дә юк), «национальный, ягъни милли китап бастыру өчен» дип аерып күрсәтелгән (һай, рәхмәт төшкерләре!). Җәмгысы 10 (ун) тонна... Күпме бу? Күз алдына китерү өчен шундый чагыштыру: бүген «Казан утлары»ның бер санын бастырырга 25 ләп тонна кәгазь китә. Ә безнең нәшриятка бер ел эшләү өчен 1800 тонна кәгазь кирәк... «Милли китапка» дигәннәренең хикмәте соңрак ачылды: Казан полиграфкомбинатында бүтән республикалар өчен басылгалап килгән дәреслекләр өчен «өстәмә фонд» булып чыкты...

Мәскәүдән кәгазь сорау эпопеясы менә шулайрак төгәлләнде.

Әйе, «икенче сорт» дигән стереотипны, «тулып җитмәү» комплексын табигый хәл дип кабул иттерү өчен, безнең башкайларга шактый озак тукыдылар. Халыкның зурлыгын да, илдә сибелеп

яшәү шартларын да күрмәмешкә салыштылар. Милли мәдәниятне өстән — басып, астан кисеп килделәр.

Чагыштырып карыйсыздыр: Татарстан нәшрияты чыгарган күп кенә басмаларның «авызын ачса — үпкәсе күренеп тора». Кәгазе саргылт, рәсемнәренең төсе яңгыр юган сыман уңган, тышлыгы кыек-мыек ябыштырылган, җилемгә батып беткән. Нәшрият, бер очтан, типография оятын да күтәрә.

Миңа инде Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты хуҗаларының күңеленә май булып ятмаслык сүзләрне еш әйтергә туры килә. Хезмәттәш-партнерларны үпкәләтмисе иде, әмма ни хәл итәсең — заманында көн саен газета, журналлар, ел саен меңгә якын исемдә китап бастырып килгән комбинат хәзер, тупасрак итеп әйткәндә, «күтәрәмгә калган»: кайбер басмалар икешәр-өчәр ел чыга алмый интегә, аларның сыйфаты да яхшыруга таба бармый. Сыйфатына күз йомган тәкъдирдә дә, полиграфкомбинатка гына ышанып торсаң, татар баласына йөзәр меңләгән данә белән күптөсле, рәсемле китаплар чыгарып булмас иде.

Бу бәлаләрнең иң төп сәбәбе — техник җиһазлануда артта калганлык, шуның өстенә әзерлекле белгечләр һәм эшчеләр җитешмәү булса, әлеге сәбәпләрнең (яки нәтиҗәләрнең) чыганагы эшне оештырудагы җитешсезлекләргә һәм озак еллар дәвамында тиешле дәүләт оешмалары тарафыннан игътибар күрмәүгә барып тоташа.

Ләкин безне иң борчыганы: хәлне төзәтү юнәлешендә сизелерлек бер генә адымның да ясалмавы. Турысын әйткәндә, Татарстанның төп дәүләт типографиясе хәзер татар китабын бастырудан баш тарту дәрәҗәсенә җитеп килә. Нәшрият, ниһаять, яшәвенең җитмеш икенче елында беренче тапкыр, «үзенең» китабын бастыру өчен, район газетасы типографияләренә сүз катып карый. Шулай итеп, үзебез, үз кулыбыз белән, милли китап санын кыскартуга мәҗбүр ителәбез...

Хәер, Госкомиздат дигән мәшһүр системада татар халкының бердәнбер китап нәшрияты, русның провинциаль яки ведомство нәшриятларыннан да мескенрәк хәлгә төшерелеп, район газеталары белән бер тактага куелган иде инде. Әле соңгы елларга кадәр, тематик пландагы берәр өтерне үзгәртү дә Мәскәү рөхсәте белән генә эшләнде. Телеңне белмәгән, әдәбиятыңнан хәбәре булмаган чиновниклар кайсы китапны кайчан, нинди кыяфәттә, нинди күләм белән чыгарырга икәнен хәл итеп килделәр.

Шул чорда кучер дәрәҗәсендә дилбегә тотарга өйрәнеп калган кайбер үз түрәләребез бүген дә әле шул иске гадәтне куарга азаплана. Ә нәшриятка ярдәм кирәксә, күзеңә туп-туры карап, авыз ералар: «Үз җаегызны үзегез карагыз, сез бит хәзер мөстәкыйль түгелме соң»,— дигән булалар.

Хәтерлисездер: Союзда да, Россия Федерациясендә дә министрларны раслау теге яки бу өлкәдәге авыр бурычларны барлау, искә төшерү рәвешендә барды. Тимер юлчылар яки күмер чабучылар министры буласы килгән кешегә нык кына тирләргә туры килде. Ә менә матбугат министрларының ничек билгеләнгәнен күреп калдыгыз микән? Мин моны махсус күзәттем: депутатларыбыз китап матбагасына кайсы яктан килеп кагылырлар да, министр дигәнебез әлеге проблемага нindiрәк мөнәсәбәт белдерер?

Көтүем бушка булды: ике Югары Советта да китап язмышы турында җитди сүз кузгатылмады. Ике якның да битарафлык күрсәтүе идеме бу, әллә компетенция җитмәвеме? Һәм инде шуннан соң да нәшрият хезмәтендә берәр үзгәреш, яңарыш көтәргә мөмкинме?..

Ә бит ул чакта ук илдәге һәр ике китапның берсе «зыянлы» булуы билгеле иде. Инде быел Татарстан китап нәшриятында басыласы китапларның уннан тугызы үзен үзе аклый алмый. Бу исә безне шактый четерекле хәлгә куя: милли китапны саклап калу өчен, аңа дип, мең бәла белән эзләп алынган кәгазьнең күпмедер өлешен «килешү бәясе» белән чыга торган, ягъни үтемле русча китапларга сарыф итәргә мәҗбүр булабыз . Хуҗалык исәбендәге милли нәшрият хәлләре... Шул шартларда да татар китабының тиражы үсә бару — гайре табигый хәл. 1987 елда әлеге сан 1,924 миллион данә булса, 1988 елда ул —2,295 миллион, 1989 елда — 4,334 миллион, ә 1990 елда, план буенча, тагын да үсеш булырга тиеш иде...

«План буенча», «тиеш иде» дип икеле-микеле әйтүем шуңа: беренчедән, бу мәкаләне тапшырганда әле ел төгәлләнергә ике-өч ай вакыт бар; икенчедән, 1990 елның әлегә кадәрге тугыз-ун ае һәртөрле планнарны һәм өметләрне чәлпәрәмә китергән дәвер булды. (Бу хакта «Социалистик Татарстан»да басылган интервьюда киңрәк, тәфсиллерәк сөйләнде инде.)

Шул җәһәттән, Казанда яшәүче рус язучысы Лев Кожевниковның «Ищу мецената» дигән чыгышы искә төшә. «Советская Татария» газетасында (30 декабрь, 1989 ел) басылган ул мәкалә нәшриятка

үпкә генә түгел, дәгъва белдерүе белән дә рус телендә укучыларның бер өлешен җәлеп итәргә, ышандырырга мөмкин иде. Үз вакытында аңа игътибар бирүне кирәксенмичә, без ялгышмадык микән әле?

Л. Кожевников мәкаләсенең беренче җөмләсе үк моңа кадәр мин язып килгәннәрне сызып ташлый.

СССР матбугат министры (ягъни Госкомпечать рәисе) Югары Советның әлеге дә баягы (үзен раслаган) сессиясендә шундыйрак саннар китергән иде... Безнең илдә нәшрият эшчәнлегенә бер сум акча тотсаң, ул 8—10 тәңкә табыш булып кайта; бу — гаҗәеп күрсәткеч, хәтта алтын чыгаруның да файдасы 3 сум тирәсеннән узмый, имеш. Шуңа таянып, Л. Кожевников әлеге табыштан үзе мәхрүм калган кыяфәт ясый: янчыгына миллионнар тутырган «номенклатур» әдипләрне, язучыны талау юлы белән череп баючы нәширләрне сүгә.

Әле генә, «һәр ике китапның берсе...», хәтта «ун китапның тугызы...» исрафчыл, дип әйткән идек. СССРның матбугат министры берне таратып унны җыеп алу серен ачканмы соң әллә?

Юк шул. Пәри — башка, җен — башка, дигәндәй, янә шул «уртача» сан күрсәтеп хәрәмләшү... Әмма Л. Кожевниковның телен кычыттырып торган сүз төптәрәк ята. Элек тә миндәй талантлы әдипләр кысыла иде, дигән фикерен дәвам итеп, ул болай ди: «...произвол творится и ныне, втихую..., под трескучими перестроечными лозунгами, скажем, «издательского хозрасчета» или *национального самоопределения* и т. д.» (Аерым сүзләргә мин басым ясадым.)

«Астыртын башбаштаклык, золым...» — җиңел генә кизәнеп, зур гаеп ташлый бит автор. Хуҗалык исәбе белән бәйле матди хәлебез инде аңлаган кешегә аңлашылгандыр, өстәп әйтергә мөмкин булган бер генә сан: 1991 елда безнең нәшриятның китап чыгарудан 1,5 миллион сум зыян күрүе көтелә... Моның шапырынулы лозунгмы, әллә бөтенләй бүтән нәрсәме икәнен, шәт, шуннан чамалап буладыр. «Милли үзбилгеләнү дигән лозунг-шигарь астында золымлыклар эшләнүе» — хәер, бу гаепләү дә яңалык түгел инде.

Шулай да, үз-үземне кабатлап булса да, тагын бер сан белән җавап бирү кирәктер: җитмеш ел эчендә Татарстан китап нәшрияты бастырган һәр 6 китапның берсе татарча булса, бишесе —рус телендә. Золым турында сөйләргә, чыннан да, нигез бирә бугай бу сан, әмма ләкин мәкалә авторы уйлаганның киресе килеп чыга түгелме соң?..

Без инде, ниһаять, һәр дүрт китапның өчесе татар телендә басыла башлавын искә алып үттек. Бер караганда, игътибарга лаек казаныш. Әмма шул хәлендә дә нәшриятыбыз милли китапка булган ихтыяҗның... яртысын канәгатьләндерә ала. Ул ихтыяҗ дигәнебез, дөрес, әле тиешенчә өйрәнелмәгән; сүз бары тик сәүдә оешмалары биргән заказ турында гына бара. Татар китабы белән СССР күләмендә сәүдә итүнең үз кыенлыклары мәгълүм, һәм ул аерым сөйләшү темасы булып кала.

Җыеп кына әйткәндә, татар китабын чыгару полиграфкомбинатка да «зыян» сала, татар китабын ил буенча тарату китап сәүдәгәрләрен дә бөлдерә. Һәрхәлдә, алар шундый шартларга куелган.

Күрәсез, хикмәт кәгазь җитмәүдә генә түгел, һәм, шагыйрь әйтмешли, «мәсьәлә бик зур, сыйдырмый тар шигырьләр үлчәве». Әлеге «мәсьәлә»не хәл итү өчен безгә Мәскәүдән килмәсләре дә мәгълүм...

Мөхәммәтдин агайның хаты менә шундый каршылыклы уйлар кузгатты. Һәм әлеге уйларны беренче хатта әйтеп бетерә алмаганымны аңлап, өстәвенә зарланып кына әллә ни майтарып булмасын да белгәнгә, кулыма тагын каләм алдым...

## Икенче хат

Хөрмәтле Мөхәммәтдин ага!

Татар китабына гадел мөнәсәбәт күрсәтүне үтенеп язган хатыгыз бик урынлы булса да, күрәсең, хәзерге көндә безгә «Үзәк»тән ярдәм көтеп тору гына — хилаф бер эштер. Әлбәттә, «уртак мал»да халкыбызның мәгълүм бер өлеше бар, һәм ул өлешне сорап түгел, даулап алырга туры килмәгәе әле.

Татарстан сәяси һәм икътисади-экономик мөстәкыйльлеккә чын-чынлап ирешә икән, тормышның бүтән проблемалары никадәр күп һәм никадәр катлаулы, җитди булмасын, безнең Югары Совет һәм Хөкүмәт милли мәдәният, милли нәшрият мәсьәләсен озын чиратның койрыгына куя алмас. Хәзер һәр

көн, һәр сәгать исәптә. Без инде җитмеш ел вакытны югалттык. Таралган авылларыбызны җыю гына да әнә ничек кыен!

Телен югалткан миллионлаган милләттәшебезне кайтару — тагын да авыррак. Милли китап учагының куз-күмерләре тәмам сүнгәнче, ашыгыч чарасын күрергә иде.

Соңгы елларда әдәбиятка, журналистикага килүче агым бик саекса да, әлегә иҗади көчләр бар. Беренче чиратта — нәшриятның полиграфия базасын аякка бастыру, моның өчен Татарстан хөкүмәтеннән матди ярдәм алу, кадрлар белән эшләүне үзгәртеп кору һәм, әлбәттә, дәүләт карамагындагы басмаханәне милли китап мәнфәгатьләре белән турыдан-туры бәйләү таләп ителә.

Нәшриятта да кадрлар мәсьәләсе белән ныклап шөгыльләнәсе бар әле... Нәшрият редакторы булу — авыр иҗат һәм казна хезмәте; ул теләсә кемнең хәленнән килми. Кызганыч, буыннар алышыну үзен бик сиздерә... Әмма бу да — күп сәбәпләрнең берсе генә. Соңгы вакытка кадәр журналистлар арасында иң түбән хезмәт хакы китап нәшриятында булды, һәм әле дә ул чагыштырмача түбән булып кала. Нәшрият, бик авырлык белән генә, елына бер квартира ала; вуз бетереп бирегә эшкә килгән кеше, фаразан, 120 елдан соң гына баш өстендә түбә булуына исәп тотарга мөмкин.

Хатның шул төшендә бүленеп, нәшриятка эшкә килгән көннәремне хәтергә төшердем. Нинди уйлар, хыяллар иде бу башта! Әле ике ел да узмаган, әмма кырыс чынбарлык ул планнарның бер өлешен сытып ташларга өлгерде инде.

Җөмләдән, шигырь китапларын гына алыйк. Күрәсең, алар һәрвакыт нәшриятның сызлап-сыкрап торган төше булгандыр... Берничә ел элек, әдәби тәнкыйтьче белән әңгәмә корганда, нәшриятның шул замандагы баш редакторы шигырьнең гонорар җәһәтеннән кыйммәткә төшүе хакында бик уф орган иде. Шагыйрь кесәсендәге тиеннәрне санау...— шәхсән мин монысын хуплый алмыйм. Әмма эт теле кебек юка-юка җыентыкларның, зур газаплар белән 1—2 мең данә генә басылып та, кибет шүрлекләрендә тузан эчеп ятуы кемнең эчен пошырмый икән? Шагыйрьләрнең дә затлы тыш кигезгән, рәсемнәр белән бизәлгән, һәр китапханәнең күрке булырлык китап чыгарасы киләдер дип уйлыйм. Ә кем комачаулый соң шундый басмага ия булырга?! Һәрхәлдә, чын шигырь китабын затлы итеп чыгару фарыз.

Сүз уңаеннан, тормышка ашмас икенче бер хыялымны да әйтим әле.

Мәктәп балаларының букчасын күтәреп караганыгыз бардыр,— бигрәк тә башлангыч сыйныфта укучыларныкын. Ни өчен таш төягән кебек авыр соң алар? Дәресләр күп булгангамы? Әллә инде уку әсбаплары калын булган өченме? Кайбер дәреслекләр икешәр, хәтта өчәр класска исәпләнгән бит. Бала ничә ел буе һаман шул бер кирпеч-китапны күтәреп йөри-йөри туеп бетә. Миңа калса, җиденче класска кадәр һәр дәреслекне ярты еллыкка бүлеп чыгару балалар өчен бик уңайлы булыр иде. Әлеге китапларны тулы көенчә алып килү ихтыяҗы кабатлау дәресләрендә генә туачак. Әмма... колхоз басуын әзмәвердәй тракторлар белән издерә генә белгәнебез кебек, супер-дәреслекләргә җайлашкан шул без. Әле бер уку әсбабын чыгару мең бәла булганда, аны икегә, өчкә, дүрткә бүлеп аерым китаплар итү — кая ул, авызымнан җил алсын!

Һәм башкалар, һәм башкалар...

Әлбәттә, болары — «кычытмаганны кашу» сериясеннән... Ә бит, мәсьәләгә җитдирәк карасак, нәшриятның уңай традицияләрен саклаган һәм үстергән хәлдә, аның җитмеш ел эчендә деформацияләнеп каткан структурасы тамырдан үзгәртеп коруга мохтаҗ.

Бу — редакцияләрдә, бүлекләрдә хезмәтне оештыру рәвешенә дә, тематик планның эчтәлегенә дә, күпме мыләргә кереп оялаган стереотипларга да кагыла. Безнең «эчке» эшләр булып тоелса да, боларны уңышлы хәл итү, нәшрият хезмәткәрләренә генә түгел, авторларыбызга, укучыларыбызга да бик бәйле.

Эчке эшләр димәктән, Мөхәммәтдин ага әнә, кәгазь табу — нәшриятның үз кайгысы, дип тормаган... Аңа һәм, аның кебек, чит җирләрдә яшәп тә халкыннан аерылмаган затларга ихтирам хисен хат аша гына җиткереп булса икән...

Икенче хатның дәвамы

...Сездәй милләт хадимнәре күбрәк булса иде, Мөхәммәтдин ага. Инде бит заман шундый: милли китапны Татарстаннан гына көтеп ятар чак узып бара. Мәктәп дәреслекләрен җибәрүне, мәсәлән, бездән, сары томшыклы карлыгач балалары кебек, утыз биш — кырык өлкә көтеп тора. Уку әсбапларына ихтыяҗ бер ел эчендә генә дә бермә-бер диярлек артты (72 мең сумнан 136 мең сумга җитте). Якын елларда әле бу санның үсү тенденциясе сакланыр дип уйлыйм. Казанны рухи мәркәзебез дисәк тә, бөтен авырлыкны ул гына күтәреп бетерә алмас бит?! Һич югы, дәреслекнең өлгесен бездә әзерләп, бастыру эшен урыннарда (бигрәк тә союздаш республикаларда) — җирле типографияләрдә җайга салырга кирәк. Заманында Казан, үз өлешенә кертеп булса да, кардәш халыкларга һәм дәреслеген, һәм уку әсбабын басып биргән ич. Әле соңгы елларда да кайсыбер Урта Азия, Алтай халыклары китапны Казанда бастыра иде. Халыклар тулай торагында хокуксыз өйдәш булып җитмеш еллап тереклек итә торгач, күрәсез, инде үзебез ярдәмгә мохтаҗ булып калдык...

Тарих хәтерли: заманында татар китабы Россиянең байтак шәһәрләрендә басылган. Димәк, аңа ул чакта ихтыяҗ да, мөмкинлек тә булган. Хәзер ул ихтыяҗлар һәм мөмкинлекләрне яңабаштан өйрәнәсе, чарасына ныклабрак керешәсе бар.

Аңлашыла ки, татар китабын бастыру, тарату мәсьәләсе безне илнең (СССРның) төрле төбәкләре белән эшлекле бәйләнешләр урнаштырырга чакыра. Шуңа күрә ул Союз дәрәҗәсендә дә һәм аерым республикалар, шул җөмләдән Россия белән дә махсус килешүләр төзүне ашыктырачак...

Икенче хат шулай, күпнокталар белән өзелгән килеш, язу өстәлендә калды, миңа ашыгыч эш белән Мәскәүгә китәргә туры килде. Аннан әйләнеп кайтуга, көндәлек мәшәкатьләр үз эченә суырып алды. Хатка нокта куярга җай чыкмады да чыкмады. Аннары, күңелдәге уй-фикерләрне бер Мөхәммәтдин агай белән генә түгел, татар китабына битараф булмаган бүтән милләттәшләр белән дә уртаклашасы иде, дигән теләк туды. Бәлки, без аерым-аерым шул турыда уйлап йөрибездер, фикернең уртак булганы да, бәхәскә керердәе дә бардыр. Һәрхәлдә, бу юнәлештә җәмәгатьчелекнең мөнәсәбәте ачыкланырга, сүздән эшкә күчү тизләнергә тиеш бит. Нәшриятның эченнән торып әле бик аз вакыт кына шул хәлләрне күзәтү дә бер нәтиҗәгә килергә мөмкинлек бирә: без пружина кебек тыгызланган көннәр кичерәбез, һәм һәр бирмеш көн йә —татар китабы файдасына, йә аңа каршы эшли. Йә татар... файдасына, йә аңа каршы...

Кайчандыр күкрәгенә «әллә нинди кара көчләр» басып торганга гына уяна алмаган халык өстенә янә җитмеш кат вәгъдәләр юрганы ябылган. Россиядә сан ягыннан икенче булган милләт — Урал, Казакъстан, Урта Азиягә яңа дәвер мәдәниятеннән ут алып биргән милләт — чыра яктысы кебек бердәнбер нәшриятка карап калды. Дөнья базарына «кара алтын», мех чыгарган, автомобиль, очкычлар төзү, химия, хәрби комплекс гигантларын иңендә күтәргән Татарстан җире бүген «эштән чыгарылган татар кызы» хәлендә... Ә шул ук вакытта, үзен милләт хадиме дип санаган агай-эне (ни аяныч!) өч хәрефкә койрык ялгамакчы булып мәш килә, «татармы без, болгармы?» дип дөнья болгата, дини китапчыклар белән спекуляция ясый...

Берсе тора да кычкыра: «Ниткән эш ул кәгазь булмау? Бер «КамАЗ»га бер вагон кәгазь бирәләр!» — ди. Икенчесе: «Нишләп әле нефть саткан акчага алмыйсыз ул кәгазьне?!» — дип, четерекле мәсьәләне чишә дә бирә. Шул юл белән кәгазьле булу өчен бер генә нәрсә җитми: китап нәшриятының әлегә ни «КамАЗ» җитештерү, ни нефть чыгару мөмкинлеге юк... Инде артык та беркатлысы: «Таләп итәргә кирәк, бугаздан алып сорарга, фәлән-фәсхет!» — дип кыюлана. Әйтерсең лә... Әйтерсең лә...

Әйе, килер бер көн: матбагачылык та аерым ширкәтләр кулына калыр. Ихтимал, китап басу эшенә спекуляциянең бер рәвеше дип түгел, ә милләткә хезмәт итү мөмкинлеге дип караучы зыялы кооператорлар заманы булыр ул. Кулны һәм зиһенне богаулап торган «планлы-команда» системасы җимерелер. Ул чагында инде бер дивизия зурлыгындагы совет язучылары гаскәре, хисапсыз фән кандидатлары, истәлекләр язып интегүче ветераннар (һәм аеруча — графоманнар чирүе!) китапны партия комитетлары яисә министрлыклар ярдәменнән башка гына чыгару мөмкинлегенә ирешерләр... Әмма, вакыйгаларны никадәр ашыктырсак та, бүгенге мәсьәләләр иртәгәсе көн хисабына чишелә алмый. Хәзерге шартларда Татарстан җирендәге полиграфия базасын ныгытуга керешмәсәң, дәүләт

типографияләрен, ниһаять, татар халкы мәнфәгатьләрен дә санга сугарга мәҗбүр итмәсәң, алга китеш булмасы ап-ачык. Икенче адым,— әлбәттә, кәгазь һәм башка материаллар проблемасын хөкүмәт дәрәҗәсендә хәл итү, нәшрият-полиграфия системасы өчен кадрлар әзерләү һәм аларга тиешле шартлар тудыру, татар китабын СССРда һәм чит илләрдә тарату юлларын табу... Санап китүе генә җиңел, боларның берсен дә көмеш табакларга салып китермәсләре шулай ук мәгълүм...

Беләм, Мөхәммәтдин агай да хәзер Мәскәүдән пилмән яумасын яхшы чамалыйдыр, Николай Ивановичтан җавап та көтмидер. Мин генә уңайсыз хәлдә калдым: үзем язган хатларның астына Н. И. Рыжковның имзасын салып җибәрә алмыйм ич инде. Күз алдыгызга киләме, йә:

Өченче хат

(Проекты)

Хөрмәтле Мөхәммәтдин Гарифуллович!

Сезгә язган ике хатымны берьюлы җибәрергә булдым.

Озак хәбәрсез торуыма үпкәләмәгез, якташ.

*Сәлам белән, Николай Иванович...*

Яисә менә болайрак өстәп куйсаң, күңелгә тагы да хуш килер иде:

Өченче хатның дәвамы

(Хыял)

...Халкыгызның ил хәзинәсенә керткән өлешен исәпкә алып һәм аңа карата күп еллар буе эшләнеп килгән гаделсезлекне бетерү өчен, Татарстанны кәгазь белән тәэмин итү, Союз хисабына Казанда яңа полиграфия комплексы салып бирү мәсьәләләре хәл ителәчәк.

*Сәлам белән...*

*1991*

## СӨЕНСЕННӘР ӘЛЕ САБЫЙЛАР!

Мәгариф — азатлык юлында беренче адым.

Гаяз Исхакый

Әле күптәнме генә теге яки бу шәхес хакында истәлекләр тупланган җыентыкның кибет киштәсендә боегып, алынмыйча яту ихтималы бик зур иде. Ул заманда чыккан шундый басмаларның кайберсе әле дә кайдадыр тузан эчеп ятадыр. Ә менә соңгы бер-ике елда гаҗәп хәл: нәкъ шул рухтагы китаплар, басылып чыгу белән, комга сеңгән су тамчысы кебек тарала да бетә. Татарстан китап нәшрияты, мәсәлән, үткән ел дәвамында гына «Туфан», «Такташ», «Сибгат Хәким» дигән, исеменнән үк эчтәлеге аңлашылып торган бик үзенчәлекле өч том чыгарды. «Мәгариф» нәшриятының Абдулла Алиш һәм Габдрахман Әпсәләмовка багышланган китаплары елның күркәм вакыйгасына әверелде. Бу басмалар уңаеннан үткәрелгән кичәләр, бигрәк тә балалар белән очрашулар укучы күңелен кузгаткан мәгънәле китап бәйрәмнәренә нигез салды.

Гомумән, соңгы елларда күренекле әдипләребезнең гомер һәм иҗат бәйрәмнәре матур, ихлас итеп үткәрелүе күңелне сөендерә. Исәннәренә, ниһаять, күптән әйтеләсе җылы сүзләр килеп ирешә. Хәлбуки, әлеге кадер-хөрмәтнең дәрәҗәсен һич кенә дә киметмәстән, юбилейга мөнәсәбәтле мәҗлесләргә һәм «ияр-камыт баулары»на каршы куймастан, чын каләм әһеле өчен барыбер иң олы бүләк — аның китабы басылып чыгудыр, дип расларга батырчылык итәм. Беренчедән, андый вакыйга (ягъни китабы басылу) юбилей җиткәч кенә булырга тиешлеләрдән түгел. Икенчедән, ни кызганыч, бу кытлык заманында хәтта түгәрәк туган көненә дә һәр әдип үз китабының чыгып җиткәнен күрмидер...

Шулай да бәхетлеләрдән көнләшмик. Халык шагыйре Шәүкәт ага Галиев, мәсәлән, үзенең җитмеше тулган көндә, Сабан туе мәйданының уртасына чыккан кебек, Камал театры сәхнәсенә басып, әле генә нәшриятлар «табасыннан төшкән» ике җыентыгын берьюлы кулына алган иде. «Көләч көзге» исемлесен мин, уенын-чынын бергә кушып: «Сезгә хөкүмәтебез бүләген тапшырабыз, аксакал»,— дип бирдем. Һәм бу сүзләрдә шаяртудан бигрәк хаклык күбрәк иде. Бәйрәм табынына «Мәгариф» нәшрияты тырышлыгы белән куелса да, чын мәгънәсендә «хөкүмәт бүләге» булды ул китап.

Яшерен-батырын түгел, моннан берничә ел гына элек «Мәгариф»тә (химаяче-спонсор ярдәме яисә махсус заказ белән!) берәр балалар китапчыгы дөнья күрсә, шуннан зур гаеп эзлиләр, ул чактагы мәгариф түрәләре, нәшрият өстеннән шикаять язып, безне генә түгел, ревизорларны да айлар буе тинтерәтәләр иде.

Хөкүмәттән һәртөрле пособиеләр теләнеп, хәтта кайбер чакта андый «хәер-сәдака»ны алып та, язучы үзенең хәлен чын-чынлап яхшы якка үзгәртүгә ирешмәячәк. Язучыга иң лаеклы, иң нәтиҗәле һәм иң тотрыклы ярдәм хезмәтенең таҗы булган яңа китабын (яки сайланма әсәрләрен) дөньяга чыгаруда булышлык күрсәтү рәвешендә булырга тиеш.

Әлбәттә, һәр мөмкинлекнең чиге бар, һәм каләм ияләренең күпчелеге хәлне аңлый: иҗатын укучыга җиткерү хәстәрен нәшрият белән бергәләп кайгырта. Гамьле әдип ничек борчылмасын: иҗтиһад итмәгән (әйе, акча җитмәгәннән генә түгел!) авыл һәм мәктәп китапханәләрендә татар әдәбияты — ялан тәпие бозга ябышып каткан Апуш хәлендә... Милли китап сәүдәсе дә, һәр авылда аракы кибете ачуны мәҗбүри итеп куйган кебек, дилбегә какканны көтә...

Әнә шул хәлләрне күздә тотып, берничә ел элек, язучыларыбыз республика җитәкчеләренә махсус мөрәҗәгать кабул иткәннәр иде. Ул чакта әллә ни нәтиҗәсе күренмәсә дә (гадәтебезчә, бик зур эш кырдыкка санап, мөрәҗәгатьне баш астына салып, мич башына менеп ятканбыздыр), «Балалар әдәбияты яклауга мохтаҗ!» дип аталган әлеге хат әле дә актуальлеген югалтмады.

Ниһаять, соңгы өч-дүрт елда хәл уңай якка үзгәрә башлады. Мөрәҗәгать тәэсиреннән бигрәк, мәсьәлә үзе өлгереп җитте шикелле... Әдип һәм дәүләт эшлеклесе булуны бербөтен олы вазифа итеп аңлаган Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Туфан Миңнуллин һәм башка язучы-депутатларыбызның

милли китапны, бигрәк тә балалар китабын яклап дәлилле сүз әйтүе «бозны кузгатты». Китап нәшер итү хөкүмәт карары белән башкарыласы мөһим гамәл итеп канунлаштырылды.

Нәшрият өлкәсендә дәүләт сәясәтенең шундый эшлекле һәм эзлекле төс алуы, билгеле, матур нәтиҗәләр бирә башлады.

«Мәгариф» нәшриятының да милли әдәбиятыбыз җәүһәрләрен бала күңеленә түкми-чәчми җиткерергә омтылуы яңа көч белән дөрләп китте. Яңа буын дәреслекләр һәм әдәби хрестоматияләр рәвешен дә алды ул, махсус басмалар итеп тә күзалланды. Мәсәлән, «Хәзинә» дигән гомуми исемдә, татар әдәбиятының борынгы дәверләреннән алып бүгенгәчә үткән юлын иңләүче, аның иң асыл үрнәкләрен туплаган 15 томлык сериягә нигез салынды. Әлеге хезмәтнең беренче китабы Әмирхан ага Еники фатихасы белән укучы кулына кергән иде. Аннан соңгы томнарга Р.Фәйзуллин, Н.Хисамов, М.Госманов, М.Хәсәнов, Ф.Мусин һ. б. күренекле шәхесләребез кереш сүз-аңлатма яздылар. Бу сериянең һәр китабын, галим һәм язучы А.Яхин җитәкчелегендә, «Мәгариф» нәшрияты хезмәткәрләре төзи. Г.Ибраһимов исемендәге институтның танылган галимнәре тарафыннан халкыбыз иҗатының барча жанрдагы әсәрләрен сайлап, тәфсилле аңлатмалар белән, яңа концепция нигезендә нәшер ителә торган 12 томлык «Энҗе чәчтем — энҗе җыям» сериясе (баш редакторы К.Миңнуллин) балаларга шулай ук игелекле хезмәт күрсәтер дип ышанабыз. «Раушан көзге» һәм «Иң матур сүз» (балалар бакчалары өчен антология-хрестоматияләр), мәктәп программасына нигезләнеп, «Милли әдәбият китапханәсе» дигән исем белән өр-яңа сериядән чыга башлаган классик әсәрләр...— шундый тыйнак китапларыбызга күпме хәзинә сыйган.

«Мәгариф» нәшрияты ни өчен балалар китабын зәвыклы гөләндәм-букетларга туплап, эзлекле цәм максатчан рәвештә чыгарып барырга тырыша соң? Моның чын сәбәп-омтылышлары аңлашыладыр. Без — бөек халык, дип күкрәк кагу бер хәл, чынлыкта кемлегебезне үзебезнекеләр дә, башка милләт балалары да китапларыбыз аша төшенсен һәм кабул итсен дип көч куябыз. «Без тарихта эзлебез!» сериясеннән басылып килүче, дәүләтчелегебезнең төрле дәверләрен иңләгән «Кубрат хан» (М.Хәбибуллин), «Хыянәт» (Ф.Латыйфи) кебек әдәби әсәрләргә балалар һәм яшүсмерләр зиһенен ачу, аларның күңелләрен агарту вазифасы йөкләнә. Язучы ачып җибәргәнче тирән катламнарда яткан тарихи-мәдәни мәгълүмат, шахта субайлары кебек, танылган галимнәрнең фәнни-популяр тәфсире белән ныгытып барыла.

Гасыр башында калган юл башчыбыз — «Мәгариф» нәшриятының «Балалар күңеле» дигән мәшһүр сериясен (Г.Тукайның «Энҗе бөртекләре» белән башлап!) тергезүнең дә максаты — милли тәрбия традицияләрен яңарту. Бу сериянең затлы басмаларын, Шәүкәт ага Галиевка кушылып, «Сөенсеннәр әле сабыйлар!» дип чыгарабыз. Шуңа күрәдер, Ә.Баянның «Җил яратучы күркә», Т.Миңнуллинның «Авыл эте Акбай», Р.Харисның «Әбәк», И.Юзеевның «Аю сатам, кем ала?», Р.Миңнуллинның «Алма бабай», Р.Вәлиевнең «Кайтаваз кайда яши?» һ. б. китапларны сабыйлар үзләре генә түгел, аларның әти-әниләре һәм тәрбиячеләре дә куанып кабул иттеләр шикелле.

«Бишек җырлары» җыентыгы белән дөньяга аваз салган нәшриятыбыз «Күгәрченем, син дә гөрлә...», «Сайра, сандугач!» кебек балалар җыр китапларын чыгаруны шулай ук изге эш итеп саный. Бу юнәлештә безнең белән хезмәттәшлек иткән Мәдәният министрлыгына һәм Президент каршындагы Мәдәнияткә булышлык итү фондына рәхмәт яусын!

Г.Тукай һәм А.Пушкинның татар һәм рус телләрендәге бүләк басмалары (төзүче-редакторы Х.Фәйзрахманова), М.Җәлил, Ф.Кәрим, А.Алиш, Н.Баян һәм Г.Кутуй иҗатыннан бер сәлам-китапчык, Ә.Еники, Ф.Хөсни, Г.Сабитов, Ф.Шәфигуллин, Ф.Яруллин, Л.Ихсанова хикәяләре (төзүче-редакторы Н.Нотфуллина), Л.Толстойның «Хаҗи Морат»ы (Л.Гыйззәтуллина тәрҗемәсе), А.Сент-Экзюперинең «Нәни принц»ы (Р.Вәлиев тәрҗемәсе) — болар барысы да «Мәгариф» китапханәсе» сериясеннән. «Нәни принц»ның «Мәгариф» басмасын сорап Франциядән, Канададан, Япониядән, Бельгиядән, Израильдән хатлар килә... Гомумән, дөнья классикасын туган телебездә «сөйләтү» традициясен тергезү — инде гамәлгә ашырыла башлаган ниятләребездән. «Том Сойер...» һәм «Белмәмеш маҗаралары»ннан соң (С.Ибраһимова, К.Миңлебаев тәрҗемәләре) яңалары булачак...

«Хәзинә», «Энҗе чәчтем — энҗе җыям», «Балалар күңеле» серияләрендә басылып чыга торган әдәби җыентыклар мәктәп һәм гаилә китапханәләренең күркенә, яшь буын рухын баетучы кыйммәтле хәзинәгә әверелде. «Бу китапларның тирән эчтәлекле, яхшы бизәлешле булуына ирешү өчен, нәшрият хезмәткәрләреннән зур белем, зәвык, һөнәри әзерлек һәм иҗади осталык таләп ителә»,— дип,

«Мәгариф» нәшриятының хезмәтләренә Президентыбыз биргән югары бәя безне фидакарьлеккә рухландыра.

Билгеле, «Мәгариф»нең төп вазифасы уку-укыту әсбаплары әзерләп бастыру булганлыктан, эшебезне хәтта күләм-нисбәт җәһәтеннән дә бәяләү четерекле: бер вагон кәгазьгә, мәсәлән, егермеләп әдәби китап чыгарып була, шул ук микъдар ике дәреслеккә дә сыеп бетәргә мөмкин... Мәгәр балалар китабын — зиһен һәм күңел үстерүче тормыш дәреслеген нәшер итү, янә дә Шәүкәт ага Галиев шигырен файдаланып әйткәндә, «төп эштән соң башкарыла торган төп эшебез» булып кала.

Китап басылып чыгу куанычын безнең белән бергә кичергән дистәләгән язучы арасында Р.Фәйзуллин, Р.Мингалим, Р.Гаташ, Т.Галиуллин, Р.Мөхәммәдиев, Ш.Маннапов, М.Насыйбуллин, Д.Салихов, Р.Гыйззәтуллин, С.Шәмси, Р.Рахман,  А.Хәлим, Л.Янсуар, Г.Рәхим, Җ.Сөләйман, Ә.Мушинский, Р.Бәшәр һәм башкалар бар. (Сүз уңаеннан әйтеп үтү артык булмас: Р.Миңнуллин һәм Роберт Әхмәтҗанов «Мәгариф» нәшриятында басылган китаплары белән Тукай исемендәге Дәүләт премиясен алдылар. 2003 елда берьюлы дүрт автор — прозаик М.Хәбибуллин, шагыйрьләр З.Мансуров, Р.Бохараев һәм рәссам Ф.Хәсьянова, шул ук нәшрияттагы басмаларга нигезләнеп, Тукай бүләгенә тәкъдим ителделәр.)

Ә.Гаффар, Р.Корбан, Н.Каштанов, Р.Кутуйның ике дәүләт телендә берьюлы басылган җыентыклары, шулай ук татар һәм рус әкиятләреннән төзелгән «Куян күчтәнәче — Заюшкина избушка» китабы (төзүчесе Л.Гыйззәтуллина) «тел ачкычы» төсендә, гамәли яктан да файдалы бер күренеш булды.

Ихтимал, язучыга, каләм хакы алу җәһәтеннән, әсәрен бүтән нәшриятта бастыру файдалырактыр... Бездә нәшер ителгән хезмәтнең төп өстенлеге — конкрет укучыны күздә тотып, аңа атап чыгарылуы гына, ягъни ул адреслы («киләчәккә хат») һәм шуңа күрә нәтиҗәлерәк тә. Чын китапны таныган кеше редакторларыбыз, рәссамнарыбыз һәм техник хезмәткәрләребезнең югары һөнәри осталыкка ия булуын раслар. Без каләм әһелләре белән үзара ихтирамлы мөнәсәбәтне сакларга, үз хисабына китап чыгару җае булса — «йомшаграк» шартлар тудырырга тырышабыз. Хезмәтебезнең асыл мәгънәсен белү, аны башкаларның да күрүе һәм аңлавы — иң зур юанычыбыз. Милләт баласының күңел киштәсендә «Мәгариф» нәшриятының бер генә китабы булса да бар икән,— димәк, безнең көнебез бушка үтми.

Татарстан Милли китапханәсе үткәрә торган, инде традициягә әйләнеп килүче «Ел китабы» дигән бәйге-ярыш, баштагырак елларда, кайбер журналистлар сүз уйнатканча, «ша-ярыш» кына ахрысы дип, әлләни җитди кабул ителмидер кебек иде. Янәсе, китапның кыйммәтен китапханәчеләр түгел, әдәбият белгечләре бәяләргә тиеш... Шулай да, ахыр чиктә, китапның җәмгыяви әһәмияте укучыга ясаган тәэсире белән, ә инде шул ук «урамның каршы ягына» чыгып караганда — аңа укучының мөнәсәбәте белән билгеләнә. Китап сүзенең көндәлек яшәешебездәге урыны әнә шул гапгади төшенчәдән —«әйләнеш»тән гыйбарәт булып чыга. (Китапханәдәге бер нөсхәне уртача ничә кеше укыганлыгын теркәүче сан икән ул — «китап әйләнеше».) Бу бит үзенә күрә бер «референдум», һичшиксез дикъкатькә лаеклы әдәби-социологик тикшеренү! Форсаттан файдаланып, Зәйнәп Әбүгали кызы Җамалиева кебек фидакяр китапханәчеләребезгә ихлас күңелдән рәхмәт әйтәсе килә.

«Ел китабы» бәйгесенә минем дә нәшрият манарасыннан гына торып карамавым аңлашыладыр. Чөнки безнең «Мәгариф»нең төп икмәге —дәреслек, сүзлек, фәнни-популяр әдәбият кебек, балаларга бик кирәкле булса да, мондый конкурс кысаларыннан читтә кала торган хезмәтләр. (Иписез аш үтмәсә дә, табынга кунак ризыгы итеп «кызыл билле перәннек» куела.) Соңгы бәйгеләрнең берсендә, мәсәлән, татар телендә басылган 63 китап катнашкан булса, шуларның нибары 8 е генә «Мәгариф»неке иде. Төрле номинацияләр буенча беренче — өченче урыннарга лаек дип табылган басмалар — 11. Һәм... әлеге бәхетле китапларның 5 есе — «Мәгариф»тә басылган булып чыкты. Ягъни мәйданга чыккан 8 китабыбызның 5 есе «батыр калган»!.. Очраклы хәл түгелдер: 1997 елда ук беренче урынны Фәнис Яруллинның «Мәгариф»тә басылган «Биюче бака» дигән җыентыгы алган иде, 1998 елда — Әхәт Гаффарның «Әкәмәт»е, 1999 елда Шәүкәт Галиевнең «Көләч көзге»се беренче булды. 2000 елда балалар әдәбияты буенча «баш батыр» —Илдар Юзеевнең «Аю сатам, кем ала?» дигән китабы. 2001 елда бу бәхет Рөстәм Кутуй белән Разил Вәлиевнең «Купшы әтәч»енә дә елмайды.

«Сан сыйфатка күчә» һәм «аз булсын — яхшы булсын» дигән, тыштан капма-каршы тоелган, әмма асылы уртак ике формула билгеле. Нәшрият хезмәтендә дә, сыйфат өчен көрәшү белән бергә, укучының күптөрле ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен, сан ягын да онытмаска кирәк була.

Әйтик, бүген Русия китап чыгару индустриясе Мәскәүдә һәм Питерда тупланган. Рус китап сәясәтен нигездә биш-алты нәшрият-монстр билгели. Шул ук вакытта Русиянең иң эре 25—30 нәшрияты исәбенә милли «Мәгариф» тә керә икән, бу инде бөтенләй үк әһәмиятсез күрсәткеч түгел.

Беренче карашка, әнә рус телендәге басмаларга һич кытлык юк кебек тоела. Кибетләрне генә түгел, Казан урамнарын да язгы ташу сыман китап баскан!.. Шул уңайдан кәмит тә, гыйбрәтле дә бер хәл искә төшә. Халыкның башын Кашпировскийлар әйләндергәнче үк әле, ниндидер шабашник-күзбуар безнең авыл клубларында гипноз сеансы үткәреп йөри икән. Тамашасының «кендеге» булырлык күренеш — ...залны судан бастыру. Моның: «Су баса!» — диюенә, куркаграк ирләр эскәмияләргә менеп кунаклый, хатын-кыз җәмәгате исә, чыланмасын диптер инде, итәк-чабуын күтәрә, имеш... Без күзәтә торган китап «ташуы» — рус телендәге басмаларның әнә шулай «итәк күтәреп маташуы» ул. Күп булып тоелуы шуннан гына: юньлерәк китапларның бәясе «тешли», ә «чүбек тутырган»нарына кызыгу хәзер шактый сүрелде. Асылда, Русия Китап палатасы мәгълүматларына караганда, нәфис әдәбият бастыру, шулай ук балалар китабы чыгару соңгы ун ел эчендә 6—7 тапкыр кимегән, һәм бу тенденция әле дә дәвам итә икән.

Бу саннарны искә алуым — Мәскәү нәшриятлары өчен кара кайгыга батуымнан түгел, үзебездәге хәлләрне чамалап-чагыштырып карау өчен кирәк. Бит моннан ун еллар элек, хәлләр шактый мөшкелләнеп, рәхимсез һәм кагыйдәләрсез көрәш мәйданында яклаучысыз калган татар китабы бөтенләй «нокаут» алмасмы дигән шомлы уйлар килә башлаган иде күңелгә... Һәм шундый мәдәни-икътисади-сәяси ситуациядә «Мәгариф» нәшриятын төзү турында махсус карар кабул ителүнең никадәр үз вакытында булуы еллар үткән саен ныграк ачыла, аңлашыла бара.

Яңа туган «Мәгариф»не бишеккә салып тирбәтмәсәләр дә, кырыс һәм кысыр заманда нәшрият кадәр нәшрият ачуга батырчылык иткән хөкүмәт безне үз канаты астына алды. Бу гамәлнең иң югары дәрәҗәдәге гаранты бар иде. Кремльдә бер төркем язучылар белән очрашуы вакытында (әле яңа нәшрияттә эшкә керешкән генә чорым иде) Минтимер Шәрипович кыска һәм ачык итеп: «Мәгариф» нәшриятын ярдәмнән ташламабыз»,— диде. Бу сүзләр менә ничә еллар инде конкрет эш белән расланып килә. Кайгыртучанлыкның нәтиҗәсе дә күз алдында.

Хәзер, мәсәлән, Русиядә китап чыгаруның 80 нче еллар уртасындагы биек ноктасына кире кайту турында хыялланалар. Бездәге хәлне күзаллау өчен бер генә мисал: «золотой застойный» дәвердә басылган дәреслекләребез ел саен 500—600 мең тирәсе булса, хәзер әлеге сан 1 миллион данәдән артык.

«Суверенитет безгә ни бирде?» дип сораучыларга, Тукай әйтмешли, «сүздә түгел, басмада» бер җавап инде бу.

Ә ун гына ел элек дөнья бөтенләй башка кебек иде... Билгеле, без дә күктән пилмән яуганын көтеп ятмадык, кытлык чорында дөньяга килүебезне аңлап, тырыштык, тырмаштык. Авырлыкларны җиңеп, юлда калыккан киртәләрне ишә баруның файдалы яклары да күп икән. Акчаны кысып тоту зарурлыгы иң элек нәшриятлар темпланыннан беркемгә кирәкмәгән чүп-чарны чыгарып ташлауга булышты. Дөрес, акчасы табылгач,  шундый басмаларны чыгару белән «тавык фермалары» да шөгыльләнә башлады. Кайдан килсен ул «табылдык» акча,— барыбер халык кесәсеннән алына. Хөкүмәт структуралары да, «ни сәбәптәндер», дәүләт нәшриятларын өнәмичә, китапка охшаган нәрсәләрне «әштер-өштер» китерүчеләр файдасына юмартлана. Тарих өчен теркәп калдырыйк: әллә гафиллек, әллә хөсетлек аркасында, бу елларда галимнәргә, һөнәрлеләргә (профессионалларга) түгел, китап битен акча кәгазедәй санаучы һөнәрчеләргә («ремесленник»ларга), үз мәнфәгатен генә кайгыртучы «Озын Ибрай»ларга юл ачыла.

Әйе, насыйбына ирешү максатында һәркем үзенчә кәсеп итә. Моннан җиде-сигез еллар элек шактый четерекле хәл туды: Кулланучылар җәмгыяте (потребсоюз) «кинәт кенә», авыл халкына татар китабын сатуга караганда, «рус» аракысын сату файдалырак икәнен аңлап алды. Моңа шул чактагы район башлыкларының гаме китаптан ераклаша башлавы да ярдәм итте... Иң аянычы шунда: әлеге башбаштаклык авыл баласын милли китаптан аерды... Күрәсең, әлегедәй сынауларны да үтәргә кирәк булгандыр. Аның каравы, Татарстан башкаласында татар баласына туган телендә китап сату белән

махсус шөгыльләнергә тиешле беренче сәүдә ноктасы — «Мәгариф» нәшриятының «фирменный кибете» барлыкка килде.

Шул ук дәвердә республикадан читтә яшәүче милләттәшләр белән дә элемтә өзелде. Милләт яңадан уянып, Русия төбәкләрендә татар мәктәпләре һәм класслары ачыла гына башлаганда, бу — кислородны ябып кую белән бер иде. Диаспора исеменнән бик гайрәт чәчеп йөрүче милли оешмаларның да бу хәлне төзәтүгә әллә дәртләре, әллә дәрманнары җитмәде... Турыдан-туры килешүләр төзи башладык, бигрәк тә Башкортстан, Пермь өлкәсе белән элемтәләр элеккеге елларга караганда да уңышлырак эшләп китте. Мәсәлән, өч ел рәттән, Башкортстан Халык мәгарифе министрлыгы заказы буенча, төбәк үзенчәлекләрен исәпкә алган махсус әлифбаны җәһәт кенә эшләп, барлыгы 28 мең данә бастырып җибәрдек. Ягъни бүген чит төбәкләрдә дә милли мәгариф өлкәсендә кул кушырып утыручыларга, дәреслек, балалар китабы юк, дип аклануы кыенрак. Андый мохтаҗлыгы булган һәр төбәк, хәтта аерым мәктәп тә нәшриятка турыдан-туры мөрәҗәгать итеп, бу мәсьәләне чишә ала. Дөрес, «Мәгариф»нең китап туплау һәм саклау урыны булмаганлыктан, һәр китапны үз вакытында соратып, чыккан берен ала барырга туры килә. Моның уңайсызлыклары аңлашыла, мәгәр шул ягы әйбәт —«әрдәнәләп өеп куярга» эшләмибез, ягъни һәр китап ихтыяҗны исәпкә алып кына планлаштырыла. Элек андый заказлар ким дигәндә бер ел алдан җыелса һәм аны үзгәртү, киметү яки өстәү мөмкин булмаса, без хәзер ихтыяҗ үзгәрүгә бик сизгер һәм тиз реакция ясыйбыз. Китап басыла башларга хәтта бер генә көн калганда да, заказ кабул ителә.

Кызганыч, балалар китабына ихтыяҗны алдан белү, тиражны төгәл билгеләү бик кыен. Сарыф ителгән көч һәм чыгымнар акланып бетми. Бу игелекле эшкә мәктәп һәм авыл китапханәләре кушыла алса, балалар китабының иң хаҗәтен кирәкле санда нәшер итүне җайга сала алыр идек. Әйтик, «Мәгариф» нәшриятының уникаль китап программалары — алда телгә алынган «Хәзинә», «Энҗе чәчтем — энҗе җыям» серияләрен һәр мәктәп һәм авыл китапханәсе берәр генә данә булса да алдырырга тиештер бит инде?!

Китапханәләр соңгы ике-өч елда иркенрәк сулыш ала башладылар. Президентыбызның турыдан-туры ярдәме белән, аларга китап фондын тулыландыру мөмкинлеге тудырылды. Үзенә күрә, «тузган китапны яңарту программасы» эшли башлады. Моның өчен китап укучылар бик рәхмәтле. Булган кадәресе чынлап та шактый таушалган, яңалары «килеп җитми», шунлыктан бүгенге буын авыл балаларына үз заманының әдәбиятын укудан мәхрүм булып үсү яный башлаган иде...

Соңгы унъеллыкта Татарстан Милли китапханәсе дә укучылар белән яңа китапларны «кавыштыру» кебек игелекле вазифаны үз өстенә алды. Әлеге «Ел китабы» конкурсы да — татар китабының хәлен чагылдыручы көзге сыман: республика китапханәләре хәзинәсенә байтак кына яңа басмалар 1000 һәм аннан күбрәк данәдә барып кушылган. Китапханәнең төп укучысы балалар һәм яшүсмерләр булуын исәпкә алсак, дымга сусаган басуга төшкән бәрәкәтле яңгыр кебек булган ул китаплар! Мәсәлән, Татарстан китап нәшриятында басылган татарча бер калын роман китабын ел дәвамында уртача 42 кеше укып өлгергән. Чират торып укыганнар. Моннан берничә ел гына элек кер порошогына торган чиратлар, әнә шулай, күңелне сөендереп, китапханәләрдә һәм китап кибетләрендә генә калсын иде!

Хәтергә төшерик: моннан ун гына ел элек әле Казан урамына чыксаң, кеше алдында татарча сөйләшергә ярамый, дип кисәтү ясыйлар иде. Туган телебездәге балалар китабы, милли дәреслек арзанлы ямьсез тышлык кигән, 2 нче сортлы дип атала торган саргылт кәгазьдә басылган булыр иде. Ул китаплар татар баласына «икенче сортлы халык икәнегезне белеп үс!» дип тукып торалар иде сыман.

Бүген исә балаларыбыз кулында — якты чырайлы татар китаплары. Алар яхшы кәгазьгә, сыйфатлы итеп бастырылган.

Юк, бернинди дә могҗиза булмады: шушы еллар эчендә, алда әйтелгән үзгәрешләргә өстәлеп, хөкүмәтебез ярдәме белән, газета-журналлар («Идел-пресс») нәшриятына заманча китап бастыру техникасы алынды. Милли дәреслек һәм балалар китабы бастыруның зур йөген тартып баручы полиграфкомбинатның да техник куәте артты. Ә бит «Мәгариф» нәшрияты чыгара торган продукция эчтәлеге белән генә түгел, технологик яктан да шактый катлаулы. Аның һәр «өтере» махсус стандартларга җавап бирергә тиеш, катлаулы формулалар, таблицалар, рәсем-иллюстрацияләр, корректура ягыннан искиткеч җаваплылык таләп итә торган зур күләмле текстлар... «Мәгариф»нең бөтен китаплары энәсеннән җебенә кадәр — оригинал-макет дәрәҗәсенә җиткәнче, нәшриятның үз

эчендә, үз белгечләре көче белән эшләнә. Күрәсез, соңгы елларда Казан-башкаланың йөзе матурайган кебек, китапларыбызның да тышкы кыяфәте көләчләнде. Баланың зәвыгын тәрбияләүдә китап үзенең килеш-килбәте белән үк катнашырга тиеш, әлбәттә!

Ун ел элек чиратлар һәм китап тышлыклары гына түгел, фикерләвебез дә башка иде шул безнең.

Гомуми тиражы 15 миллион данәгә җиткән 1000 китап — әлегәчә башкарылган хезмәтнең нәтиҗәсе әнә шундый. Күпме бу, азмы? Балалар белән очрашканда, шундый чагыштыру китерәбез: әгәр без чыгарган китапларны «гыйлем сукмагы» итеп салсаң, ул сукмакның бер башы Казанда булса, икенче очы... Берлинга барып җитәр иде, дибез. Милли китапка шундый кайгыртучан мөнәсәбәт булганда, «Мәгариф» нәшрияты Берлинны гына «алып» калмас әле, шаять.

Алда әйтелгәнчә, сан артыннан куу үзмаксат булмаса да, узганга карап шөкер итмәсәң, алга карап фикер йөртүе кыен...

Ниһаять, без эш һәм иҗат кешесен ымсындырып торучы көч, алга куалаучы «таяк»-стимулга ихтыяҗ барлыгын искә төшерә башладык. Инде искәртеп кителгәнчә, соңгы елларда төрле һөнәр ияләренең уңыш бәйрәмнәрен уздыру кебек, язучыларның да хезмәтен зурлау актив төс ала. Әдәбият өлкәсендә бер-ике рәсми премиягә куш булып, төрле конкурслар үткәрелә, бүләкләр бирелә башлады. Кемнеңдер моңа эче дә поша шикелле, әмма, минемчә, ул хәтле премияләр күбәйде дип кайгырмыйк, аларның гаделлеген, дәрәҗәсен сакларга гына кирәк... Әлбәттә, барыбер, язучыга иң олы бүләк — аның китабы дөнья күрү, дибез. Әлеге китабы уңышлы саналып, бүләк тә бирелсә — нур өстенә нур булыр. Тик менә китабы чыкмаса... язучы тегесеннән дә, бусыннан да мәхрүм кала. Бигрәк тә беренче китабын бастыру алдында торган талантлы яшьләр ярдәмгә, яклауга мохтаҗ. Татарстан хөкүмәте вице-премьеры Зилә Рәхимьян кызы Вәлиева хуплавы белән, «Мәгариф» нәшрияты яшь авторларга йөз тоткан махсус әдәби бүләк булдыру тәкъдимен кертте. «Тургай чәчәге» дип исемләнгән бу бүләк бүтән премияләрдән бөтенләй аерылып торачак. Ул әле китабы басылып чыкмаган, әмма басылып чыгарга лаек дип табылган яшь талантка грант рәвешендә бирелә, һәм бәхетле авторның хезмәте шул ук елны «Мәгариф» нәшриятының махсус сериясендә басылып чыга. Бу бүләкнең әнә шундый максатчан булуы әдәбиятыбызны үстерүгә билгеле бер өлеш кертер дип өметләнәбез. Сүз уңаеннан искәртү кирәктер: талантлы яшьләребез инде «Мәгариф»тә чыккан беренче җыентыклары белән Язучылар берлегенә кабул ителә башлады (Сөмбел Гаффарова, Лиана Әмирханова, Рәмис Аймәт, Нурзидә Нотфуллина...— бу исемлек дәвамлы булыр, иншалла!).

Нәкъ менә Яшьләр елында сәләтле яшь каләмнәр иҗатына юл ачкан «Җәйнең җиде төсе» җыентыгы, «Сабантуй» газетасы, «Ялкын» журналы авторларының «Безнең йолдызлар яктырак» һәм «Җилләрдә чәчәк исе» исемле тупланмалары — чын мәгънәсендә яңа гасырга атлаучы бәхетле китаплар!

Китапка гаять җаваплы вазифа йөкләнә — аны кулына алып укыган баланың зиһенен баету, рухын ныгыту, күңелен үстерү. Китапның үзенең дә бәхете — укучыдан. Балаларыбызның күңел пайтәхетенә күтәрелгән «Мәгариф» китаплары нәкъ шуны раслый.

2002

## ИСКЕ СӘГАТЬ ДӨРЕС ЙӨРИ

Һәр халык үзенең Китабы янына чакырып китерелер.

Коръән сүзе

Чынлап та, әйләнә торган һәр нәрсә хәйләгә корылган.

Сәгатьне генә алыйк. Кабат-кабат «яңадан яши башларга» өмет һәм ышаныч бирү өчендер, бәлки, безнең бабайлар вакыт агышын бер урында бөтерелгәндәй, боҗра буйлап агарлык иткәннәр. Һәр сәгатьне — яңа әйләнештән, һәр тәүлекне — яңабаштан, һәр айны беренче числодан санаганнар. Яңа елларны кабаттан туган кебек башларга күнеккәннәр. «Өзелеп калган» көннәр, гүяки кәлтә койрыгыдай, яңадан үсеп чыга барган.

Шушы өзек-өзек мизгелләр бары тик Вакыт «туктап» калгач кына бербөтен булып тоташа — аларны кабер ташына уелган саннар арасына куелган сызык ялгый...

Хәер, «түгәрәк» даталар якынлашканда да Вакыт елгасының агышын ныграк тоя башлагандай буласың бит. Кеше гомеренең генә түгел, олуг гамәлләрнең һәм вакыйгаларның дәвер йомгагы да шундый хисләр кузгата, дулкынлануга сәбәпче була.

Бер караганда, юбилей дип шауламаслык, хәтта күпләр ишетми-белми калса да, әллә ни югалтмаслык дата: моннан 280 ел элек — 1722 елның 15 июлендә (иске стиль белән) Әстерханда су өстендәге күчмә типографиядә Петр Беренченең «Манифест»ы татар телендә басылган. Татар басма китабының «Мәскәү вакыты белән» тарихын галимнәр шул көннән башлап саныйлар. «Манифест» рус патшасының Фарсы иленә яу чабуын — аклап, хәзергечә әйтсәк, «террорчыларга каршы» көрәш итеп аңлатырга тиеш булган. Шунысын да искә төшереп узыйк: галимнәргә билгеле булган беренче татар китабы Лейпциг шәһәрендә 1612 елда, ягъни «Европа вакыты белән» моннан 390 ел элек басыла. Ул — татарча-латинча һәм латинча-татарча сүзлек белән татар теле грамматикасы. Әлеге мисалдан чыгып әйтә алабыз: татар телендәге беренче китап — уку әсбабы булган, татарның үзенә генә түгел, Европага гыйлем-мәгърифәт тараткан! Хәтта сугыш көймәсендә басылган «Манифест» та патша хезмәтенә җәлеп ителгән татар теленең яулап алучылар коралы түгел, дипломатия теле булуын күрсәтә.

Шөкер, милли китабыбыз, үткәндә — ят дин корымын сылау пумаласы, хәзерге көндә — фәхешкә димләүче азгын сурәт түгел, һәр заманда күңелгә, зиһенгә пакьлек һәм тәүфыйк иңдерүче якты кыйсса булып килде. Кыйблалар буталган, адәми затның нәфес колына әверелү ихтималы көчәйгән чорда да зыялы наширләр шул саф рухны сакларга, үстерергә омтылалар.

Татар басма китабының зур һәм катлаулы тарихында, бигрәк тә рухи-мәдәни тормышыбызның соңгы 70—80 елында, әлбәттә, Татарстан китап нәшрияты мөһим катламны тәшкил итә. Халкыбызның рухын баетуга гаять күп көч салган, үзе дә традиция-тәҗрибә («культуралы катлам») туплану хисабына байый баручы «төп йорт»ыбыз ул. Узган гасырның «ком сәгате» әвеш-тәвеш килгән саен, төрле җилләре-давыллары һәм сөенечле мәлләре аңа да кагылмый калмаган. Дошман эзләү бизгәге кеше гомеренә янаган чорларда иң хәтәр сызык матбугат — нәшрият — китап аша узган.

Билгеле, һәр заман үз мәшәкать-проблемалары белән килә, үз кыенлыкларын тудыра. Идеология кылычы баш өстеннән читкәрәк тайпылгач та, китапчылар ил белән бергә мәгълүм тетрәнүләр кичерде. «Лимитлы» хуҗалык итү тышавыннан котылу белән, акча муенчагына бәйләнеп калу бигрәк тә милли китапка авырлык китерде. Нәшриятның шул дәверендә эшләп алу миңа бу халәтне кичерү ҹәм аннан чыгу юлларын эзләүдә катнашу форсаты бирде. Кайбер чоңгылларына «пәриләр оялаган» агымны сафландырырга керешү шактый ук четерекле гамәл иде. Шул ук вакытта буыннар алышыну хафага салды. Яхъя Халитов, Рәис Даутов, Кыям Миңлебаев, Таһир Нурмөхәмммәтов, Адлер Тимергалин һәм башка агайларның дәррәү пенсиягә чыгуы — «соңгы могикан»нарның безне калдырып

китүе булып тоелды, алардан башка нәшрият яшәвен дәвам итә алмас сыман иде... Татарстан китап нәшриятының легендар бер чоры төгәлләнү шаһиты булганмын икән.

Шул тетрәнү күңелдә әле һаман да сүнеп бетмәгәндер кебек.

Акыллы кешеләр узган көн белән елмаеп саубуллашканнар. Без шул вата-җимерә, селкереп түгә генә беләбез бугай. Берара матбугат битләрендә, халык җыелган мәйданнарда, гомумән, җае чыккан саен кичәге көнне сүгү шаукымы кузгалып алды. Бигрәк тә әлләни эш кырмыйча күпне дәгъва итүче, «иртә дә уңмас, кич тә уңмас» кавем үч алырга тырышты. Югыйсә нәкъ менә «торгынлык» чорында башкарылган тау хәтле хезмәт — мирасыбызны торгызуда, халык иҗатын барлауда оештырылган, заман әдәбиятына юл ачуда кылынган эзлекле фидакяр гамәлләр — аннан соңгы дистә ел дәвамында да үрнәк, гыйбрәт, ирешәсе үр булып калды. Үткәнне, үзеңнән элгәреләрне сүгәргә түгел, алар белән ярышырга кирәк иде — изге эшләрне күбрәк эшләүдә, җәмгыять тәгәрмәчен алга таба җәһәтрәк әйләндерүдә. «Нигезенә кадәр» җимереп, аннары җимерекләр өстендә туй итәргә түгел,— ныгытырга, корырга, төзергә! Бүген менә шул хакыйкатьне аңлау әйләнеп кайта сыман.

Тормышта мәшәкатьләр бетмәгән кебек, китап чыгару хезмәтенең дә үз четерекләкләре бетмәячәк. Әмма бүген куанып әйтә алабыз: безнең республикада милли нәшрият эшчәнлеге тотрыклы, стабиль хәлгә кайтты. Соңгы дүрт-биш елда хөкүмәтнең махсус карарлары кабул ителеп, халыкка кирәкле китапларны эзлекле, максатчан рәвештә чыгару җайга салынды. Бу эшнең нәтиҗәләре дә күз алдында. Булганына канәгать итмәүчеләр табылыр, әмма төрле буын әдипләребезнең укучы көткән әсәрләре, «Казан утлары» дигән затлы журналыбызда чыгып өлгерер-өлгермәстә үк, аерым китап рәвешендә дә дөнья күрә. Балалар әдәбияты һәм яшь язучылар иҗаты да игътибардан читтә калмый.

Язучылар союзындагы бер очрашу вакытында Әгъзам Самат улы Гобәйдуллин, Президентыбыз исеменнән, күптомлыклар чыгаруны җайга салырга вәгъдә иткән иде. Нәтиҗәдә, быелдан башлап Татарстан китап нәшриятында күренекле язучыларыбызның сайланма әсәрләрен бастыру эше хөкүмәт дәрәҗәсендә хәл ителде.

Гаяз Исхакый, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев мирасы белән бергә, Туфан Миңнуллин, Нурихан Фәттах, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Әхсән Баян һәм башка замандашларыбызның саллы иҗатлары белән танышу мөмкинлеге туды.

Такташ, Туфан, Сибгат Хәким кебек классикларыбызга китап-һәйкәлләр куйды нәшрият. Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре», ифрат күркәм басма булып, кабат «әйләнеп кайтты».

Әлифба алышыну сәбәпле генә түгел, идеологик «уяулык» аркасында да күпме буыннар укудан мәхрүм ителгән гаять бай әдәби-рухи мирасыбыз да онытылмый.

Аерым программалар (бигрәк тә татар телен гамәлгә кую программасы) буенча тарихыбызга, тел һәм мәдәниятькә багышланган җитди фәнни хезмәтләр, сүзлекләр дөнья күрә.

Билгеле, милли китап программасын төптән уйлап, эзлекле рәвештә, чорлар һәм жанрлар нисбәтен исәпкә алып гамәлгә ашыру өчен, һәрхәлдә бүгенге шартларда, нәшрият хөкүмәт канаты астына сыенырга мәҗбүр. Түләүле хезмәт күрсәтү юлы белән — заказ буенча теләсә нәрсә бастырып, шуннан килгән табышка балалар китабы яки фәнни хезмәт чыгару хәзергә очраклы бер күренеш кенә була ала.

Кыргый базарга керә башлаган елларда ук мин милли китап бастыру эшен җил тегермәне белән чагыштырган идем. Акча җиле исми торса, ул туктап калырга мөмкин. Хәер, түләүле хезмәт күрсәтүче, ягъни коммерция нәшриятлары да шул ук шартларда көн итәләр. Аларның тегермәне дә җилсез әйләнми. Шушы еллар эчендә алар, нигездә, нәшрият эшенең бер «сер»ен үзләштерделәр — «җилне урларга», үз тарафларына истерергә өйрәнделәр. Ягъни аларга да аерым сәбәпләр аркасында һәм мәгълүм мәгънәдә хөкүмәт ярдәм итә. Күбесенең дәүләт нәшриятыннан аермасы да юк кебек, бары тик шул гына: ак он тартса ни дә әрем тартса ни. Тегермәнченең кесәсе барыбер акка буяла. Җил истерүченең дә.

Шул ук вакытта нефтьчеләр химаясендәге «Рухият» нәшрияты кебек ширкәтләрнең үз киштәләрен, үз йөзләрен таба баруын уңай яктан билгеләп үтәргә кирәк. Алар, умарта балын урлаучы аю кәсебенә керешмичә, халкыбызга хәл кадәри хезмәт күрсәтәләр. Язучыларга һәм язу чире йоккан акчалы кешеләргә дә файдалы эш башкарыла: соңгылары дәүләт нәшриятындагы чиратка тыгылып, чын китапларга тиешле урынны биләмиләр...

Соңгы елларда, нәшрият эшенең тернәкләнүе, китаплар активрак басыла башлавы белән, гонорарлар азлыгы турында сүз ныграк куера башлады. Әлбәттә, әдәби әсәр иҗат иткән язучыга, дәреслек

язган галимгә каләм хакын хезмәтенә күрә лаеклы итеп, үз вакытында түләү тиеш. Һәм гонорар түләрлек кенә акча табылыр да... Әмма, «тавык алдан булганмы, әллә йомыркамы» дигәндәй, никадәр баналь булып тоелмасын, иң әүвәл, гомумән, китапның үзен бастырырга кирәк бит әле. Гонорар белән чагыштырганда, бу эш күп тапкыр зуррак чыгым сорый. Аннары инде... 1 мең данә булып чыккан шигырь җыентыгы, 3 мең данә проза китабы дистә еллар дәвамында таралып бетә алмаган очраклар турында сөйләргә кала. Чөнки китап, басылып чыгу белән, нәшриятның «баш авыртуы»на әверелә.

Бер уйлаганда, татар китабы, ким дигәндә 10 мең булып — «Казан утлары» журналын укучы зыялы милләттәшләр санынча чыгарга тиеш кебек. Дәүләт ярдәме булганлыктан, безнең китаплар үзкыйммәтеннән түбән хакка сатыла бит әле. «Урыс баеса — чиркәү сала (ягъни рухи ихтыяҗын үти), татар баеса — хатын ала (димәк, бүтән ихтыяҗларын алга куя)» дигән мәкальдәгечә яшибезме? Төп укучысы авылда яшәгәнлектән, татар китабын илтеп җиткерү дә четереклерәк. Чөнки авыл сәүдәсендә китап кибете дигән төшенчә инде бүген үк онытылды («кит әле, авылда китап кибете буламыни?!»). Татар китабы белән сату итү бу елларда сәүдә өчен зыянлы хәлгә әйләнгән икән бит. Быел халыкка аракы шешәсе санынча китап сатылды, дип, кайсы район мактана алыр икән?

Укучы ихтыяҗын өйрәнеп, аны чын мәгънәсендә социаль заказ буларак кабул итү һәм эчтәлек ягыннан кирәкле китапны җитәрлек санда чыгару әлеге шартларда буш хыял гына булып кала. Үз илеңдә татар китабына шундый мөнәсәбәт булса, читтә яшәүче милләттәшләрне туган телдәге әдәбият, милли дәреслек белән ничек тәэмин итәргә? Кирәксенүче, килүче, алучы булмаса, чишмә суы да тәмсезләнә, хәтта тамыры корый бит.

Бүген Татарстан китап нәшрияты укучыга үзе барырга мәҗбүр: китапларын Башкортстанга, Пермь, Чиләбе, Төмән, Свердлау һәм башка тарафларга үзе илтеп таратырга омтыла, китапханәләрне һәм хосусый китап сатучыларны шул эшкә җәлеп итә. Язучыларның иҗат союзы каршындагы әдәбиятны пропагандалау бүлеге дә укучы белән китап арасын якынайтуга үз өлешен кертә башлар дип ышанасы килә. Соңгы елларда Татарстан Милли китапханәсе һәм урыннардагы китапханәчеләр дә татар китабын таратуда сизелерлек ярдәм күрсәтәләр. Президент М.Ш.Шәймиев ихтыяры белән, республика китапханәләре (ягъни укучыларыбыз) миллионнарча сумлык китапка баеды.

Билгеле, нәшрият эшендә алга таба хәл итәсе җитди проблемалар байтак. Уфа язучыларыннан көнләшеп (һаман да шул беркатлылык — «Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер бирәләр», имеш), зарланышып кына утырсак, ерак китеп булмас. (Сүз уңаеннан әйткәндә, былтыр мари телендә барлыгы дүрт китап чыга алган, әлеге дүрт мари китабының берсе Казанда — «Мәгариф» нәшриятында басылды.)

Проблемаларның берсе — балалар өчен туган телдә китап бастыруны ныклы эзгә салу. Язучылар съездында, аннан соңгы җыелышларда да: «Балалар китабы чыгаруны бары тик махсус нәшрият ачу юлы белән генә җайга салырга мөмкин»,— диючеләр булды. Ләкин мәсьәләнең асылы һаман да акчага (аның җитмәвенә) барып терәлә. Рәссам хезмәтенең шактый кыйммәт торуы, яхшырак кәгазьдә һәм күп төсле итеп бастыру чыгымнары аркасында, балалар китабы шактый кыйммәткә төшә. Алда әйтелгәннәрдән аңлашылганча, ул чыгымнарның бер өлеше булса да әйләнеп кайтасына өмет-ышаныч аз...

Кыскасы, балалар китабының чыгуын кирәксенү җитсә, аның әһәмиятен аңлау җитсә, бу эшнең җайга салынуына өмет итәргә була. Дәүләтнең ике нәшриятында да чын мәгънәсендә балалар китабы дип әйтерлек оригиналь басмалар дөнья күреп килә. Димәк, сыйфатның санга да йогынты ясавын теләргә генә кала.

Заманында, әле үзем Татарстан китап нәшриятында эшләгәндә, нәшриятның иң кыен чорында, мин аны иске сәгать белән чагыштырган идем. Яныннан китүгә туктап калырга мөмкин, янәсе. Һәр чагыштыру үзенчә аксый, диләр. Чагыштырулар искерә дә, бүтән мәгънә алырга да мөмкин икән... Хәзер, мәсәлән, миңа «Иске сәгать дөрес йөри» дигән канатлы сүз хакыйкатькә якынрак кебек тоела. Яңа «сәгать»ләр, такси хисаплагычы кебек, вакытны үз файдаларына гына бора, бертуктаусыз кесәңне

капшый, әле алдарга да маташа. Ә «иске сәгать» — иске дус сыман, сине ташламый, гадел хезмәт итә, ышанычлы — аңа карап адымыңны дөресли аласың.

Татар китабының чын йөзен, вакытын билгеләүче Татарстан китап нәшриятына карата әлеге чагыштыру ҹич тә «аксамый», минемчә.

Ә инде, бу юлларның авторы «Мәгариф» нәшриятында эшли ләбаса, татар китабының «түгәрәк» даталары унаеннан күңеленә килгән сүзен ни өчен Татарстан китап нәшрияты мисалында әйтергә уйлады икән, дигән сорау туса...

Иң әүвәле бу — татар китабының авыр йөген катлаулы, каршылыклы XX гасырның буеннан буена диярлек үзенең иңендә күтәреп барган мәшһүр Фидакарь. Аннары ике нәшриятыбызны бер үк сәгатьнең ике угы итеп күз алдында китерегез. Кайсы зуррак, кайсы кечерәк булуына карамастан, алар бер-берсенә каршы юнәлгән уклар түгел. Шунысы да мөһим: алар икесе бергә булганда гына Вакытны дөрес күрсәтә алалар. Ә Татар вакыты бүген аеруча бердәмлеккә мохтаж.

2002

## БЕРЕНЧЕСЕ — СОҢГЫСЫ?

Әкрен киткән куян артыннан җиткән.

Мәкаль

...Беренче китабына шактый озын юл үтеп килә шагыйрь. Аңа бу юлда уйланырга, язганнарын кайта-кайта барларга вакыт һәм мөмкинлек җитәрлек булгандыр. Шул ук вакытта, яшерен-батырын түгел, әлеге юл озынлыгы, вакыт дигән нәрсә безне дә уйга калырга мәҗбүр итә. Күпне күргән, күпне кичерергә өлгергән авторның дөньяны беренчел сафлыгында, садәлегендә кабул итү тойгысы тупасланып өлгермәгәнме? Безнең тын урамнарны уятып, җилбәгәйгә, ялкынланып-дөрләп үтә алырмы ул?

Юк, бу — мин уйлап чыгарган сораулар түгел. Алар соңлап чыккан беренче китапларның титул битенә үк язып куелган кебек һәм иң ахыргы сәхифәне ачканчы сине эзәрлекләп баралар.

...Тормышта ничегрәк килеп чыга соң әле ул — соңару дигән нәрсә? Шул хакта уйлану рәвешендә, сүзне чак кынаерактанрак алып китәсе килә. Хәер, әллә ниерактан да түгел — үзебезнең әниләрдән генә. Әниләрнең — бигрәк тә, яшьли ир-канатлары сынып, тол калганнарыннан.

...Төшкә кер идең дә
Бәхет көен, әни,
Әйтеп бир идең лә... *(Я.Игәнәй)*

Бүген инде үсеп җиткән, яңа оя корган балалары, сез игътибар итәсезме икән олыгая баручы әниләрегезнең үз-үзләрен тотышына? Үткән елларына, «казага калган» гомерләренә кабат кайталар кебек тоелмыймы алар? Бәлки, бу — кире кайту да түгелдер әле... Беркайчан да шаулап уза алмаган яшьлекләрен, чигүле кульяулык сыман, сандык төбеннән генә чыгаруларыдыр? Яшь көе күмерләнеп калган күңелләрендәге ут шушылай тереләдер, бәлки... Кызлары, киленнәре белән ничек тә пардан киенергә кызыгулары, яшьләрчә ачык-җете төсләргә уралырга яратулары да шуннан түгелме икән? Мөгаен, шуннандыр. «Карале, бу төс яшьләргә генә килешә бит»,—дип, хәтерләрен калдыра күрмик әниләрнең. Белмиме соң алар күпме сулар акканын, аңламыймы соң алар яшьлекнең кабат кайтмаска узганын! Ничектер хәлләренә керәсе, ниндидер юаткыч сүз әйтәсе иде үзләренә... Ләкин бу — мескенлек белән түгел, балаларга багышланган гомер һәм ифрат зур фидакарьлек, олы күңеллелек белән очрашу. Бу — рухны сафландыра, миһербанлыкка өнди торган фидакарьлек.

Шактый соңлап дөнья күргән беренче китапларда да әнә шундый язмыш кабатлана төсле. Ягъни әлегәчә тамчысы да исраф ителмәгән яшьлеккә, сафлыкка ирек бирү ихтыяҗы... Күңел түрендә бик озак яшеренеп яткан эчке мөмкинлекләрнең, ниһаять, гамәлгә ашырылуы...

Әлеге хәл күз ачып йомган арада булмаган. Бөртекләп тупланган, тамчылап җыелган һәм бөялеп торган көч-егәр көннәрнең берендә үзенә юл ачарга мәҗбүр иткән. Инде без әнә шул эшнең нәтиҗәсе — беренче китап белән таныша алабыз. Хәзер безне иң борчыганы, иң кызыксындырганы: ни дәрәҗәдә килеп чыккан ул нәтиҗә? Аның дәвамы нинди булыр?

Бу хакта фикер йөртү, гөман кылу өчен, без инде алдарак китерелгән өземтәнең авторы — Ямаш Игәнәй китабы буйлап барырбыз. Фәһемле укучы аңлар: нәкъ менә шул китапка һәм аның авторына игътибар һич тә очраклы түгел. Сайлап-нитеп тормастан, бер мисал алыйк:

Әти яраланды, дигән хәбәр килде:
Күктә канлы болыт ага шуннан
бирле...

Шигырь менә шушы ике юлдан тора. Ямаш Игәнәйнең бүтән шигырьләре дә күләм ягыннан шул чамадарак. Әмма кыскалык биредә, форма үзенчәлеге булудан да бигрәк, бу иҗатның гомуми омтылышын билгеләп килә кебек. Бер шигырендә — борынлап чыгарга гына торган үсентегә тамчы булып тамарга тели лирик герой. Ул йә сүрелебрәк киткән хисне очкынландырып җибәрә, йә безнең дә тел очында гына торган фикерне күтәреп ала.

Фикерен әйтеп өлгерә шагыйрь — мәгәр соңгы сүзен әйтеп туктамый. Чөнки хакыйкать шундый: соңгы сүзе әйтеп бетерелгән шигырь булмый дөньяда; шигырь ул — юл: башы да, ахыры да күренмәгән олы юл. Ул юлдан барырга да барырга гына мөмкин...

Безнең байтак шигырьләр шундый схема буенча языла: табигатьтәге үзгәрешләр аша шигъри геройның үз күңелен аңларга омтылуы яисә үз күңелендәге хәрәкәткә табигатьтән охшашлык эзләве (өлгесе: «Ай да ялгыз, мин дә ялгыз»). Бу — бик табигый күренеш, еш кына гаҗәеп багланышларны тоярга ярдәм итүче алым, әмма бу — әле берьяклы хәрәкәт.

Шигырьне юл белән чагыштыруны дәвам итәбез икән, ул юлдагы хәрәкәтнең дә, нигездә, ике яклы булуын күрәсе килә.

«Ике яклы хәрәкәт» дигәнебез — дөньяның бөтенлеген чарпаландырмыйча, катлаулылыгы, каршылыклары белән аңлау цәм кабул итү. Минемчә, бары шундый әсәрләр генә һәр заманда да җырланасы җыр, үтәсе юл булып калачак...

Ауган агач агып бара елгадан.<br>
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . ..<br>
Су өстенә күтәргән тамырына<br>
Бер йомарлам туфракны кысып<br>
тоткан...

Билгеле, бу — әле иң югары нокта түгел, абайланып килә торган ым-ишарәләр генә. Алга таба шушы хәрәкәтнең көчәюен күрәсе килә. Авторның гадәти җисемнәрдән, җирдән шигърият табарга ашкынуы, әйтик, яңгыр тамган тавышта туй кыңгыравы чыңын ишетә алуы безне күпкә өметләндерә. Хәзергә әле аның, чыннан да, юл башындарак торуы сизелә. Икеләнебрәк тора кебек. Каршылыкларны җиңеп чыгасына, үзен аңлаячакларына бик үк ышанып җитми төсле.

Кызганыч ки, кайчакта без күңелдәге ихлас уйны да гади генә итеп аңлата алмыйча каушап-икеләнеп калабыз. «Вакыт — ач упкын, язмыш —кыя» кебек юлларда шигырь орлыгы, булган тәкъдирдә дә, коры катламга эләгеп, шытмый кала.

Әнә шулай, игътибар беләнрәк караганда, катлам-катлам булып аерыла башлый еллар, стильләр, әдәби модалар, хәтта нәшрият редакторлары... Ул катламнарда — төрле каршылыклар аша үтү, табышлар һәм югалтулар. Шул ягы белән мондый җыентык, беренче булса да, күпмедер дәрәҗәдә — сайланма; анда — вакыт һәм зәвык сынавын нигездә уза алган шигырьләр; әмма кистереп кенә әйтүе кыен: бу «сайланма әсәрләр» шагыйрьнең үз йөзен, чын халәтен чагылдырамы? Аның, төрле иләкләрдән иләнә торгач, ахырда калган көрпәсе генә түгелме?

Ә бит беренче җыентыкларына һәм җәмәгатьчелектә танылуга чагыштырмача озынрак юл үтеп килгән авторларның барысында да диярлек шундый каршылыкка тап буласың. Уйландыра торган хәл!

Бер яктан, бу — әдәбиятка инде дистә еллар дәвамында хезмәттә һәм шигырь язуда тәҗрибә туплаган кешеләр килә, дигән сүз... Аларның беренче китабы — инде шактый битләре язып тутырылган хезмәт кенәгәсе. «Китап сүзе»ннән килү көчәйгән, икенчел әсәрләрнең күбәюе борчый башлаган чорда, «ашыкмыйча» килүчеләр үзгә бер өмет хисе уята. Хезмәт һәм көнкүреш тәҗрибәсе булган буын, бәлки, әдәбиятны җиргә, заман сулышына якынайтыр? Ә бәлки, яшьлек җүләрлекләре белән мавыкмыйча, җитлеккәнрәк, акыллырак сүзне нәкъ менә алар әйтер?..

Икенче яктан караганда, поэзиягә шул рәвешле тыныч, хәтта салкынчарак агымның килеп керүе алдагы елларда күпмедер дәрәҗәдә «климат үзгәрүгә» дә сәбәпче булыр дип уйлыйм... Чөнки, хосусән, бу күренеш үзе гадәттән тыш хәл түгел, ул — мәгълүм хакыйкатьнең тагын бер кат раслануы гына: канаты булганнарның һәркайсы оча алмаска да мөмкин, әмма, очарга дип туганнар, иртәмесоңмы,— очарга тиеш!

...Беренче җыентыгына яшь автор озын юл үтеп килә, шунлыктан ул, асылда, аның бер томлык «сайланма әсәрләре» булып чыга, дидек. Әмма бу күренешнең сәер ягы шунда: соңгы елларда беренче басмаларга ышаныч күзгә күренеп кими. Язучылар союзына, ким дигәндә, икенче китап белән алу турында сүзләр йөри...

Моның хикмәте нәрсәдә? Шундый авырлык белән чыккан беренче китап ни өчен бик үк ныклы ышаныч уятмый?

*...Әүвәлдә яшәгән бер әүлия, инде телдән калгач, үзенең шәкертләренә ике бармагын күтәреп күрсәткән, ди. Нәрсә әйтергә теләде икән, дип, гасырлар буе баш ватканнар кешеләр. Әле дә төрлечә юрыйлар, имеш... Кем белә, бәлки, ул әүлия, ике бармагын өскә күтәреп:*

*— Икенче китабыгыз бармы?! — дип сорагандыр...*

Хәер, сүзне шаяртуга бормыйк. Икенче китап — бу инде тагын да җитдирәк проблема!

Шушы еллар эчендә без Ямаш Игәнәйнең дә, «соңлап килүче»ләрдән бүтән байтак исемнәрнең дә бер-бер артлы тезелеп чыккан яңа китапларын күрдек. Юл ачылды! Теге, беренче китаплар онытыла ук башлады, артта калды кебек... Артта калды микән?!

Ни өчен теге яки бу авторның икенче китабы чыгу белән «икенче сулышы ачылды» дип әйтүе кыен? Моның хикмәтен һаман да шул Беренче китапка кайтып эзләми кайдан эзлисең?

«Сайланма» җыентык — авыр бирелгән, аеруча җаваплы булган адым, дисәк тә, Беренче китап — ким дигәндә, инде кайчандыр башланган юлның яисә сукмакның дәвамы бит ул! Ә юл хәле — киң мәгънәсендә алганда, шагыйрьнең иҗатта табигый халәте, яшәеш рәвеше. Кыскасы, җиңел тормыш түгел!

Әлеге сүзләр «сәфәр чыккан» Ямаш Игәнәйгә ни дәрәҗәдә кагыла торгандыр, мәгәр чорлар, язмышлар бергә төенләнгән Чаллы — КамАЗ төбәгендә яшәве аңа бу юлны үзенчә баетырга мөмкинлек бирергә тиеш. Әлбәттә, бу теләк темаларга гына кагылмый. Сүз — кеше күңеленең тирәндә яткан хәзинәләрен ачу, тормышның яңа катламнарына үтеп керү турында бара.

Аннары, КамАЗ яклары дип телгә алганбыз икән, моның хәзер тагын бер төшенчә — «юл» төшенчәсе белән дә баглы булуын искә төшерәсе, шунда матур бер фал күрәсе килә. «КамАЗ», үз бишегеннән Казан каласына кадәр юлны салып, йомылып кына утырган авылларга да гөрелтесен ишеттереп, үзенең барлыгын сиздереп узды. Без, билгеле, аны башка юлларда да таный идек, ләкин ул юлларның берсе дә «КамАЗ» юлы» түгел иде!

Шагыйрьгә дә шундый юл кирәк. Кыен булса да, озаккарак сузылса да,— үзе салган юл.

1978

## КӨНДӘЛЕКТӘН СӘХИФӘЛӘР

### Беренче сәхифә: 1978 ел

Рубенсның бер картинасында һәр ике тарафка төшкән агач күләгәләрен хәтерлисездер. Тәэсирле күренеш. Сәнгатьнең тылсымлы көчен тоярга мөмкинлек бирә торган мизгел.

Ренат Харис шигырьләре, аерым алганда, аның «Уйлы туйра» дигән китабы белән танышканда, иң әүвәл сәнгатьнең әнә шул могҗизасы хакында уйланасың. «Сүз белән сурәт ясау» диләр икән, бу, мөгаен, беренче нәүбәттә, әлеге шагыйрь иҗатына туры киләдер. Мәгәр чын шигърият өчен «рәсем ясау» осталыгы гына аз әле. Ренат Харис төсләрне һәм төсмерләрне үзенчә зәвык белән төшергән сурәт-рәсемнәренә «җан өрә», ул гына да түгел, аларны кискен бәрелешләргә кертә. Шул сәбәпле аның шигырьләре тормышчан, күп бизәкле, җанлы хәрәкәт булып кабул ителә.

Шигырендәге контрастлар төенен шагыйрь фәлсәфи гармония рәвешендә чишә. Зур полотнода,— мәсәлән, «Рәссам» поэмасында,— бу аеруча ачык чагыла.

«Рәссам»дагы «гүзәл тән», «сугым сарае» һәм «яңгыр боткасы» метафора дәрәҗәсендә генә калмаган, алар — бер энә күзеннән үткәрелеп, яңа масштабларда «чигелгән»-сурәтләнгән дөнья сурәтләре. Кыю образ бәйләнешләре, тирән гомумиләштерүләре белән укучыга көчле тәэсир ясый бу поэма. Шуңа күрә җыентыктагы әсәрләрнең генә түгел, тулаем шагыйрь иҗатының иң югары нокталарыннан берсе дип саналырга хаклыдыр ул. Бу поэмада Ренат Харис иҗатының үзәк лейтмотивын күрергә мөмкин. Ул — олы мәгънәсендә сафлыкка, пакьлеккә өндәү.

...Яудырам яңгыр
ал нурдан,
Зәңгәр нурдан, яшел нурдан, күксел
нурдан —
Юынсын кеше,
Юынсын кош-корт,
Юынсын үлән!

Туасы көнгә якты ышаныч белән тулы уйлануларның шигъри кысасы нинди генә булмасын —кош теле кебек җыйнак әсәрме яки киң сулышлы, күп авазлы поэмамы — аларда бер мөһер ачык беленә: шагыйрьнең үзенә генә хас фикерләү рәвеше.

Берише шигырьләрендә, мәсәлән, ул дөньяга табигать «күзе белән» карый, тормышка мөнәсәбәтен табигатьнең кинаяле «телендә» белдерә. (Шуңа күрә хәтта традицион «сары яфраклар» да яңа мәгънә төсмерләре белән җәлеп итә, күңелдә кала.) Яисә шагыйрь, мәңгелек төшенчәләрнең асылына төшенү максаты белән, ерак тарихка киткән була, ә үзе киләчәктән урап кайтып килә... («Кеше» либреттосы).

Шигъри сүзнең мәгънәви сыйдырышлылыгын арттыру юнәлешендә Р.Харис буяулар җетелегенә, нәфислегенә ирешеп кенә калмый, фикернең тирән тамырлы һәм киң колачлы булуына да җирлек әзерли. Аның әсәрләрендәге ритм-аһәң дә хис-кичерешләр табигатен ачуда турыдан-туры катнаша. Бер үк вакытта шагыйрь төрле йогынтыларны җиңә һәм үз иҗади шәхесен формалаштыра бара. Бу исә, хәрәкәттәге һәр әдәби күренеш сыман,— тәмамланмаган процесс:

— Ишек ачтым,
Кар, кер,
Сөйләшеп утырыйк бер.
— Йә сөйләрсең моң-зар,
Кеше түгел бит мин, кар —
Давылга әйләнермен...

Икенче сәхифә: 1979 ел

Бәхәскә урын калдыра торган фикер-эпиграф: кыска шигырьне «япан кырда утка кергән ялгыз солдат»ка охшата шагыйрь.

Һәр халыкның әдәби хәзинәсендә булган кыска формаларның, билгеле, шигъри сурәт тудыруда үз мөмкинлекләре бар. Равил Фәйзуллин иҗатына да үзәктән, төеннән генә торган шигырьләр, «нюанслар» элек-электән ят түгел, аларның күбесе укучы күңеленә дә хуш килде кебек.

Гомумән, Равил Фәйзуллинны кайта-кайта уку кызыклы. Таныш юллар, таныш сурәтләр һәр очрашуда диярлек яңа мәгънәләре, яңа төсмерләре белән кабул ителә. Бүген, әйтик, аларның ялтырабрак торганнары, «терсәклерәк»ләре тәэсир итә, иртәгә — хискә, моңга бай, кешелеклерәк шигырьләр җанны һәм аңны кузгата... Солдатларча кырыс-пөхтә шигырьнең дә бу системада үз урыны бар.

Әмма ул, кайчакта хәтта шигъри ым, ишарә генә булып калса да, «ялгыз солдат» түгел (шагыйрь белән менә шунда бәхәсләшәсе килә дә!). Ул — хис-фикер ташкынын үзенә ияртеп, шушы ташкынга юл ача-ача, «гадәтилек амбразурасы»на кыю ташланган солдатларның берсе! Аның тылында — катлаулы мөнәсәбәтләр үрелешеннән, төсмерләр балкышыннан торган тулы бер дөнья.

Шагыйрь менә шул дөньяның бөтенлеген яклый:

Мин зур түгел. Мин —
үзем кадәр генә.
Тезләнмә!
Бәләкәй түгел мин. Мин —
үзем кадәр әле.
Кизәнмә!

Беренче юл шигырьнең яңгырашын билгели — алга таба үстереләчәк фикергә җирлек-плацдарм хезмәтен үти. Ул вазифа күпчелек парчаларның исеменә яисә эпиграфына ук йөкләнгән. Хәтта аерым сүзнең үзаллы яшәве, зур нагрузка күтәрүе шагыйрьнең күләмлерәк әсәрләренә дә хас, һәм бу — аның иҗат үзенчәлеген билгеләүче сыйфатлардан берсе. Асылда, Р.Фәйзуллинның шигыре беренче юлдан да иртәрәк башланучан: тормышның үзеннән җыелып килә ул; һәм соңгы юл белән төгәлләнми — аны укучы үз аңында, күңелендә дәвам итә. Ягъни кыскалык — боз тавының су өстендәге өлеше сыман, шигырьнең... күзгә күренгән «сыны» гына булып чыга!

«Кыска шигырьләр»нең эчке диапазонына игътибар итик. Ым-репликадан — монологка. Сызмалардан — картинага. Фикри сөземтәдән —драматик төенгә, һәм киресенчә... Кеше күңелендәге кичерешләр белән тормыш-табигать күренешләре арасындагы үзе генә белгән мөһим бер ноктага баса шагыйрь. Ул — тирән эчке мәгънә җегәренә һәм көчле киеренкелеккә ия булган бер мизгел, дөньяның олы эчтәлекле кисәген сурәтләргә мөмкинлек бирүче Таяну ноктасы.

*Үрмә гөл*
Читән башына җителде.
Кош канатларына уралсаң иде!

Равил Фәйзуллинның шагыйрь буларак яңалыгы, әлбәттә, фикерләү рәвешендә. Кайберәүләр, аңлашылмый, катлаулы яза, дип санарга тырышкан шагыйрь гап-гади күренештә тормышның поэтик очкынын күрә:

*Туган йорттан аерылгач*
Тамчылы гөл — нәкъ әнием!..

Килешәбез: Фәйзуллин — катлаулы шагыйрь. Әмма аның катлаулылыгы — безне үзе белән иҗат итешергә өндәвендә, күңелне эшкә җәлеп итүендә. Ул ил-көн, чор куйган, һәр уяу җанны борчыган сорау хакында уйланырга чакыра, укучыны, вөҗданы белән күзгә-күз калганда, дөреслекнең күзенә туры карарга өйрәтә. Шуңа күрә ул үз-үзенә дә таләпне зурдан куя:

Шагыйрь булсаң, дөнья өчен
давың, януың кирәк.
Януыңны халыкларның

күмәк тануы кирәк.

## Өченче сәхифә: 1984 ел

Яшерен-батырын түгел: Фәннур Сафин иҗатын күптәннән, аерым бер игътибар белән күзәтә киләм, әмма аның хакында күңелдә йөргән уйны әйтергә форсаты чыкканы юк иде...

Фәннур Сафинның иҗаттагы гомере миңа өч үзенчәлектән гыйбарәт булып тоела. Бәлки, ул үзенчәлекләрне бер сүз белән — егетлек дип кенә атау дөресрәк булыр.

Аның беренче егетлеге шул... Кордашларының һәм аннан соңрак килүче яшьләрнең бер өлеше (сүз уңаеннан әйтик: әле дә булса, янәсе, үз принциплары, үз фикерләре, характерлары бар, дигән эффект тудыра алучылар), «кирәкле кешеләргә» сыенып үсә-үсә, дүрт тарафны да кыйбла итеп танырга өлгергәндә, әлеге мохиттә иң йомшак күңеллесе булган, ихтимал, иң йомшак холыклысы да булып күренгән бу шагыйрь күптән инде үз тавышын җуярга, «син үзеңне безнеңчә тот, безнеңчә йөрт» диючеләрне канәгатьләндерә торган шигырь язучыга әйләнергә тиеш иде.

Ләкин, юк! — гаҗәп үҗәт егет булып чыкты бу Ф.Сафин: үзенчә, үз тавышы белән җырларга хокукын яклап кына калмады, башкаларны да шушы җырны тыңларга, танырга мәҗбүр итте. «Айлы төндә», «Ике учак», «Сүз әйтмәгез» кебек нык үзәкле әсәрләр язып, боларда үзенең төп иҗат юнәлеше булуын раслады.

Шагыйрьнең икенче мөһим сыйфаты: иҗатының иң югары нокталарында ул шигъри фикеренә, чын поэзиягә хас булганча, табигый яшәеш бирүгә ирешә. Аның иң уңышлы әсәрләре — билгесезлектән, борынгылар әйтмешли, «гаип хәзинәдән» калкып чыккан төсле, ничек яралуы сер булып калган затлар... Сүз-сурәтнең «якалары җилбәгәйгә ачык»; шигырь юлының сулышы иркен; ритмаһәң — йөрәк тибеше кебек табигый. Шул табигыйлектән көй саркыла башлый, саф тавышлы, моңлы җырлар туа... «Гомер буе ярсу йөрәк Сине сагынып сулкылдар...» («Хушлашырга ашыкма»).

Фәннур Сафин иҗатының өченче хасияте баштагы икесеннән аерылгысыз, аларның асылын билгеләүче сыйфат — кешелеклелек.

Бу иҗат эчендә хөсетлек, дөньяга үч-үпкә, үз «мин»еңтирәсендә бөтерелү ише (ни кызганыч: заман шигыренең атрибутына әйләнеп килүче) нәрсәләргә урын юк. Икенче чиккә ташлану —тормышның катлаулы күренешләрен гадиләштерергә маташу, өндәү билгеләре белән генә сөйләшү яисә көләч, җилбәзәк булып кылану да шагыйрьне бизәмәс иде.

Ф.Сафинның байтак шигырьләрендә, нигездә, яманаты чыккан «лирик мин» түгел, ә сулкылдап торган кеше җаны сүз ала. Ул безнең күбебезне тышаулап торган, канәгатьләндереп яшәгән чикләрне узып китәрлек көч таба, үз «мин»е белән бүтән «мин»нәргә — кеше язмышларына барып тоташа,— территориаль сулардан әледән-әле ачык диңгезгә килеп чыга төсле. Аның «душа»сы —кырыс дөньяның каралтуыннан, җәрәхәтләвеннән сакланып, әлегә нindидер калкан белән капланырга мәҗбүр булган җаны — торган саен ныграк ачыла бара. Ул безнең барыбызны да җир белән тоташтырып торучы ялангач тамырларга кагыла!

«Югары көчәнешле ток» астында калдырган мондый мизгелләр адәм баласын гамьсезлек џәм нәфес күлдәвегендә чупырдап-юанып яткан җиреннән суырып ала, аңа сынын турайтырга булыша һәм авырлыкларны җиңә-җиңә алга атларга әмер бирә.

Шагыйрь, әнә шулай, дөнья белән адәм баласы арасындагы өзелмәс җепне, элемтәне тоя, аны ныгытуда үзе дә катнашырга омтыла. Шунлыктан аның «лирик без» исеменнән сүз алгалавы да гомуми, абстракт сүз булып яңгырамый:

Сафлык яклы идек без,
Шулай булып калыйкчы?!
— Тол тарихы — Ил тарихы...—
дияр бер көн тарихчы...

Миһербанлы шигырьләр.

Бу сүзләрне язганда мин, әлбәттә, шагыйрьнең иң биек (ягъни мөмкинлекләрен билгеләп торучы) «пик»ларын күздә тотам. Шушы мөмкинлекләрен тулырак эшкә җиккәндә, бу иҗат тулы куәтенә яңгырар, күләгәдә калмас иде, дим. Бит, Фәннурның үз сүзләре белән әйткәндә, «без чорны узарга, вакытны узып яшәргә тиеш!»

Тагын бер сәхифә:
Төрле еллар, төрле уйлар

Зиннур Мансуровның беренче китабыннан кайтаваз булып яңгырап торганы: «Ил чирәмен кочып елар идек, ак күлмәкләр яшел булганчы!» Аннан соң шагыйрьнең яңа табышлары булды, югалтулары да бардыр. Әмма үзгәрешсез калган бер үзенчәлеге бар: З.Мансуров шигырьләренең таяну ноктасы, гадирәк итеп әйткәндә — «язылу сәбәбе» кызыклы. Гадәттә, ул өстә генә ята. Хәйретдин Мөҗәйнең сугыш көндәлекләре. Энциклопедиядәге «галифе» сүзе. Мамадыш юлында чәнечкеле чыбык белән әйләндереп алынган зират... Зиннур Мансуров әлеге күренешләрнең һәркайсын үз күңелендәге вакыйгага, халәткә әйләндерә. Аларга үзендә яшәеш бирә, аларны алга таба үстерә һәм укучыларга әнә шул үсешне күрсәтеп бирә. Шагыйрьнең теге яки бу күренеш, фактка бәйле фикере, тойгысы да кызыксындырыр иде укучыны. Тик ул күренешне Зиннур Мансуров белән бергәләп «үстерү» тагын да кызыклырак түгелмени?

Әнә шуңа күрәдер, Зиннурның шигырьләрендә эчке хәрәкәт, тормышның сәламәт агышы нык сизелә. Анда, бөтен ваклыкларны таратып, саф җил исеп тора кебек.

...Халыкта күз карасын «күзнең кешесе» дип атау бар. Якынрак килеп карасаң, чыннан да, сәламәт күзнең «кеше»сен күрәсең. Шигырьнең дә менә шундый «кеше»се булганда гына укучы анда үзен күрә, үзен һәм дөньяны таный ала... Зиннур шигырьләрен укыганда да, әнә шулай, үзеңне таныйсың.

Ә бит шундый авторлар да байтак: шигырьләрендә тема — актуаль, техника — шәп; бер генә кимчелек — «кеше»се күренми. Ягъни кешелекле тойгы дефициты нык сизелә, кешене аңлау һәм яклау җылысын неон уты төсле салкын яктылык кысрыклап чыгара.

Ул шигырьләрнең, халыкча әйткәндә, «кешесе үлгән».

«Әнкәйнең, күңелең ак икән, улым, дигән сүзләре бик нык хәтердә калган. Башта ул сүзләрнең мәгънәсенә артык игътибар итеп бетермәдем. Ул сүзләр әкренләп, озаклап яттылар күңелгә. Кешенең күңеле ак булырга тиеш. Шагыйрьгә бу бигрәк тә кирәктер».

Сибгат Хәким иҗаты күңелгә әнә шундый табигыйлеге, җылылыгы белән килеп керде. Колачының киңлеген күбрәк күргән саен, уй-гаменең тирәнлеген ныграк тойган саен, бер сорау көчәя барды: шагыйрь дөньясындагы муллыкның, юмартлыкның чыганаклары нидә икән?..

Сибгат ага үзе дә, шул кызыксынуны белеп, тормыш-иҗат юлыннан бер сөземтә чыгаргандай: «Дөнья хәтле материал читтә өелеп кала, әрәм кала... Шагыйрьгә прозаның кирәклеген аңладым»,— дип язган иде. «Халык язмышы —шагыйрь язмышы» дип исемләнгән китабының Габдулла Тукайдан эпиграф белән ачылуы да шушы фикерне куәтли: «...Мәсьәлә бик зур, сыйдырмый тар шигырьләр үлчәве».

Бу мәкаләләр — язылачак шигъри әсәрләргә сызмалар сыман... Аларда — шигъри моң-интонация, хис тыйнаклыгы, гади һәм нәфис композиция-сурәтләү алымнары. С.Хәкимгә генә хас образ-мотивлар, кабынып-балкып китүче ассоциацияләр, яңа борылыш саен ачылган маяклар кебек, фикер агышының төп юнәлешен күрсәтеп торалар. Мәгънәне ача-киңәйтә-тирәнәйтә баручы кабатлаулар да, аерым детальдән гомумиләштерүгә чыгу да — шигырьдән.

Солдат хаты турында уйлануларын гына алыйк. «Өч почмаклы хат. Өч почмаклы җир... Кишәрлек кенә үзе. Ләкин җирнең бер кисәге. Батырлык ул шул өч почмаклы хат рәвешендәге бер кисәк җирдән, туган җирдән, солдат хаты кадәрле генә җаннан күзгә күренмичә калкып чыга кебек». Гадәти генә мәкалә югыйсә, ә шагыйрьнең шәхесен, дөньясын шигъри сүзгә караганда да тулырак һәм тирәнрәк итеп ачып сала. Әнә шулай, «шагыйрь прозасы»ннан шигърият дөньясына аяк басасың... Беренче аккордлар монда ишетелә башлый...

«Язылмый калган җыр сагышы» да шагыйрь күңелендә йөргән зур әсәрнең увертюрасы булган. Ул, җыйнаклана-тыгызлана төшеп, поэманың кереш өлешенә әверелгән. «Дуга» поэмасы да авторның шундыйрак кереш-хикәяте белән башлана. Бу — бер форма-алым яисә гадәти мәгънәсендәге кереш сүз түгел, юк, бу — әсәрнең табигый башламы.

Димәк, әлеге очракта да шигырьгә «күңелдән юылмаган эзләр-уйланулар» алып чыккандыр? Язылган көннәрен генә чагыштырып карыйсың: чыннан да, шулай! — «шагыйрьгә проза кирәк икән».

Шуңа күрә шагыйрь ачкан дөньяның бөтенлеге, камиллеге, зурлыгы лирик «мин» белән турыдан-туры бәйләнгән. Аның ышанычлы тавышы, гомумиләштерү көче — «гомеренең ахырына чаклы җитәрлек тормыш биографиясе»ндә.

Төрле уңайдан әйтелгән сүзләр, төрле сәхифәләргә сибелгән фикерләр зур шәхеснең тормышы һәм дөньяга карашы җирлегендә берләшә. Нәтиҗәдә, «үзе турындагы» китап заман һәм шигърият хакында уйланулар китабына, эзләнүләр һәм ачышлар китабына әверелә; шагыйрь безгә яшәвенең һәм иҗатының асылы турында  сөйли. Шул мәгънәдә «Халык язмышы — шагыйрь язмышы» — аның төп китабы. Эдуардас Межелайтисның «Төнге күбәләкләр»е, Рәсүл Гамзатовның «Минем Дагстаным» әсәре кебек...

«Шагыйрь сабаны белән сөрелгән проза». Заманында бер бөек шагыйрьгә карата әйтелгән бу сүзләр Сибгат Хәким прозасын укыганда да күңелгә килә. Әлеге шигърият — хакыйкатьнең үзе кебек гади. Аның ышандыру көче әнә шунда.

Һәм... инде Сибгат абыйдан башка еллар үткән саен көчәя генә барган бер сагыш та яши бу китапта. Язылмый калган җыр сагышы...

1980

# ЧЫНЛАП ТА ШУЛАЙМЫ СОҢ?

Тәнкыйтьченең эчендә
тагын бер тәнкыйтьче утыра

...Бу язмаларны, шигырь китапларының ак калган төшләренә язылган сүзләр, дип атап булыр иде, бәлки...

Китапка кечкенә кәгазь кисәкләре кыстырып, фикереңне юл уңаенда, кайнар көе язып бару —тәнкыйтьче халкының профессиональ гадәте. Соңыннан ул язмаларның күбесе мәкаләләргә керми дә калучан. Бигрәк тә кимчелекләргә төртелеп узган урыннары. Аларны еш кына мәкаләнең тоны, төзелеше, максаты сыйдырмый: фикер сөрешен чарпаландырыр, читкә алып китәр, дип, вак-төяккә бәйләнү булып аңлашылыр, дип уйлыйсың...

Әйе шул, һәр тәнкыйтьченең эчендә тагын бер тәнкыйтьче утыра бит әле. «Личный», «лирик» тәнкыйтьче дигәндәй... Язганда, ул сине кисәткәли тора: фикереңне ипләбрәк әйт, тамырына балта чабу булмасын, төп тонны берүк басып китмәсен! Алга таба сүзләр «түгәрәкләнә», шомара, димәк, тагын бераз йомшара... Укучыга тәкъдим ителгәндә инде мәкалә кулдан тере балык кебек шуып чыга. Тәнкыйтьче үзе дә аптырап кала. Юк, һәр ноктасы үзенеке, сүз сөреше нәкъ аныңча, фикеренең дөреслегенә шикләнми. Әмма... Шагыйрь иҗатына тулаем бәя биргәндә «баштан сыйпап», җитешсез якларны «түгәрәк» сүзләр белән генә әйтеп китү... Бу —укучыны гына түгел, авторның үзен дә саташтырмасмы, шагыйрьнең үз-үзенә хилаф мөнәсәбәт тудырмасмы?.. Чынлап та шулаймы соң барысы да? Аерым очрак, хәтта бер карашка вак деталь булып тоелса да, асылда җитди һәм каршылыклы хәлләргә күз йомып килү тора-бара зуррак, катлаулырак хәлләр, кимчелекләр булып җыелмасмы?

Яисә шулай да була... Игътибар итә киләсең: берәү артык күзгә чалынмыйча гына шигырь язып маташа, ара-тирә басылгалый да. Язганнарының төп өлеше — балаларның кибеттән «Конструктор» тартмасын сатып алып, әзер детальләрдән уенчык җыюы шикелле үк — яңа сүз түгел... Җитдигә санамыйсың: андый әйберләр басылгалый инде, мондый шаярулар поэзиядән ерак тора, кыскасы,— гөнаһсыз мавыгу... Гөнаһсыз мавыгу гынамы?! Җитә бер вакыт,— әзер өлге-конструкцияләр белән эш итәргә остарып килүче автор инде үз юлында бернинди тоткарлык күрми кебек. Әдәбиятта вакыйгага булырдай күренешләр турында сүз әйтелми тора, ә аны мактап язылган «тәнкыйть» күзгә керә. Хөрмәтле генә агайлар гаҗәп җиңеллек белән зур-зур сүзләр ычкындыралар. Яңа исем, диләр, табыш, ачыш, диләр. Аптырап каласың: чынлап та шулаймы соң?!

Әлбәттә, поэзия күренешләренә карата абсолют фикер була алмый, ул һәр заманда төрле карашлар, зәвыклар бәрелешенең кайнар ноктасы булган. Соңгы елларда беркадәр сүрелү-тынычлану, академик тонга күчү — әйбәт фал, дип раслаучылар да күп. Һәрвакытта да шулаймы икән? Безнең шигъри цех тоташтан сыйфат билгесе куярлык продукция генә бирә башладымы, әллә соң, уртакул гәҗит мәкаләсе кебек, укысаң-укымасаң да ярарга әйләнеп барамы? Поэзия уңаеннан әлләни искитмичәрәк сөйләшү җәмәгатьчелекнең аңа игътибары кимү турында кисәтмиме? Ниһаять, шигырь җыентыкларының тиражы төшә бару аларның сыйфатына гына бәйлеме? Шундый сораулар күңелгә килгәндә, мин кулыма шигырь китабы алам...

«Китап читендәге язулар» — укучының шигырьгә беренче, турыдан-туры мөнәсәбәте. Әмма... ни өчен анда да бөтенләй ак калган (димәк, «сөт»кә киткән) битләр ешрак күзгә чалына?..

Шигырь белән укучы арасындагы бәйләнешләрнең өзелгән яисә урнаша алмый калган очраклары түгелме соң алар?

Әйе, авырткан җирдән кул китми, дигәндәй, бүгенге поэзиядәге дулкынланып укырлык әсәрләргә ихлас сөенгән хәлдә, бу юлы мин үземне (һәм, ихтимал, ниндидер дәрәҗәдә башка укучыларны да) борчып йөргән мәсьәләләргә тагын бер кат әйләнеп кайтасым килә. Аларга якынрак килеп карыйсы иде! Якыннан караганда алар, шәт, алай ук вак булып тоелмас.

*P. S.* ...Бу язмаларны әзерләп бетергәч (әлеге дә баягы «личный» тәнкыйтьче килеп кысыла!), кинәт уйланып-икеләнеп куйдым: фәлән шигырьләр уңаеннан күңелгә килгәч тә, әлеге фикерләр бары тик аларга гына кагыламыни?

Әгәр дә, әйтик, теге яки бу шигырь басылып чыкмаган булса? Каты куллы, нечкә зәвыклы редакторга тап булып?..

Аңлыйм, бармак белән төртеп күрсәтмичә сөйләшүнең дә уңайсыз хәлгә куюын бик аңлыйм! Бу инде — үз исеменә тәнкыйть сүзе ишеткәч, серкәсе су күтәрми торган ике-өч автор белән әчелешле булу гына түгел... Монда сине әллә нинди гөнаһларда гаепләргә урын кала! Бигрәк тә кыюлыкны исемнәр чәкештерүдә генә күрүче, моннан илле ел элеккечә, «ахырына кадәр фаш итүле» мәкалә тирәсендә җылынырга теләүче агай-энеләр үпкәләр...

Юк! Фәлән әсәрләрне исемләп «фаш итү» яисә ул мисалларны әдәбияттан сызып ташлау белән генә беркайчан да, бер мәсьәлә дә хәл ителмәгән. Шигъриятнең бүгенге торышын белгән укучы моңы аңлар, кирәк булса, мисалларны да исенә төшерә барыр, дип уйлыйм. Ә инде... үзенә түгел, бүтәннәргә бармак төртеп күрсәткәнне көтүчеләр шулай да табыла икән, бу юлы аларның өметен аклап булмады, бигайбә!

Күңелне кузгатмый,
ә тәнне дерелдәтә...

Ничегрәк аңлатып булыр икән бу халәтне... «АН-2» самолетына утырып очкандагы кебегрәк, дипме соң?..

Ару-талуны белмәс мәшһүр «кукурузник» болай чагыштыруга үпкәләмәс. Чыннан да, әлеге шигырьләрне кулга алганда, самолетка утыру кебек үк, матавыклы әзерлек эшләре үтәргә кирәк. Монда да тавыш җитәрлек, «һава упкыннары» көтеп тора, өстәвенә күтәрелә һәм төшә алмый интегү... Самолетта очуның тагын бер җайсыз ягы бар — үзеңне иркле хис итә алмау: бәйлелек — «хәвефсезлек каешы»на, һава шартларына, тагын әллә ниләргә... Менә шул хәлләргә һәрвакыт шактый авырсынып кына риза булган шикелле, ул шигырьләрне укыганда даниндидер мәҗбүриятне тоясың; бу мәҗбүриятнең вакытлы булуын белү генә шул шартларга түзәргә, хәтта, шулай тиештер дип, эчтән тынарга күндерә. Әлеге биеклекнең һәрвакыт җиргә бәйлелеген, җиргә нисбәтле булуын тоеп барасың. Җирнең кадере арта, җәяү йөрисе килү теләге көчәя...

Юк, канатларны кисеп, җирдән мүкәләп барырга чакырмыйм. Шигырьдә канатланып очу, баш әйләнерлек тизлекләр дә булырга тиеш. Шуңа сусау бар адәм баласында! Көчле тойгылар —тизлек һәм биеклек халәтен кичерәсе килү дә, тынычлык, тотрыклылык, җиргә нык басып торуны теләү дә — һәркайсы вакыт, кәеф, зәвык һ. б. шартлар белән бәйләнгән. «АН-2»дә дә, бәлки, бик күпләр җылы ваннада яткан кебек рәхәтлек кичерәләрдер. Сүз — күңелнең чын тизлек, чын биеклек һәм табигый киеренкелеккә сусавы, нәкъ әнә шундый очракта ниндидер таяну ноктасы, ныклык, җирне тоясы килү халәте уянуы турында.

Адәм баласы әнә шулай ике арада талпына, каршылыклы кичерешләр утында яна инде ул... Укыйсың, аңлый барасың — күге биек әсәрләр җирне нык тою аркасында гына иҗат ителә. Җир хәлләренә, кеше язмышына якынрак булган саен, тормышны — ямьлерәк, кешене матуррак, бөегрәк итүче әсәрләр языла.

Кеше күңеленең яңа тирәнлекләрен ачу, заман проблемаларын күтәрү өчен яңа мөмкинлекләр эзли шагыйрь. Шул юлда кайчак укучыны бик күп киртәләр, шартлылыклар аша үтәргә мәҗбүр итә. Әмма ни өчен әле без шушы «бәла-казаларны» кичеп тә гүләүдән башка берни дә ишетмибез, тимер салкыныннан кала берни дә тоя алмыйбыз? Җирдән күтәрелеп, укучыны да үзенә ияртергә көче җитми бу шигырьнең. Ә бит үзе шатыр-шотыр итә, әллә кайсы төшләре кубып төшәрдәй булып калтырый, шау-шуы колакны саңгыраулата...

Шигъри иҗат, үзенең асыл үрнәкләре белән, без еш кына истән чыгара торган хакыйкатьне кабат-кабат раслап яши: зурдан кубып, тавышны «бөердән» чыгару — иң мөһиме түгел. Үзенә якын күренешләр һәм кичерешләр турында язганда, күңелендә бөялеп торган чын хисләренә юл ачканда, төрле буын шагыйрьләр ихлас һәм табигый булып калалар. Бәлки, күбәләк кебек кенәдер ул: канат җилпенеше дә зәгыйфьрәк тоеладыр, «түшәме» дә үзенә тиң-таман, ди, хәтта күбәләк кебек кыска гомерле булуы мөмкин...Әмма шул гомер эчендә әлеге шигырь безнең тормышны аз гына булса да

ямьлерәк итәргә, табигый кичерешләр белән янып алырга, ниһаять, таш күңелләрдә дә үзенең җылы сурәтен — эзен калдырып китәргә сәләтле!

Тыштан һичнинди хәйләсез, самими генә кайбер әсәрләрнең җисемендә, тукымасында беленеп-тоелып торган шундый табигыйлек күңелнең әллә нинди тирәнлекләрен айкап ала, җырлыйсы да килә, елыйсы да килә... Андый шигырьләрне укыганнан соң дөньяның бөтенлегенә, кешенең матурлыгына ышаныч арта, шул бөтенлекне, матурлыкны үзеңнең дә арттырасы килү теләге уяна!

## Ни өчен уртакулның базары югары?

Шундый бер риваять бар...

...Имештер, көннәрнең берендә булачак пәйгамбәрне агасы базарга агач пот (мәҗүси тәңре сыны) сатарга җибәрә... Дөресен әйтергә кирәк, товар бик үтемле түгел. Шунлыктан Мөхәммәт ибн Мостафаның да күңеле тартмый: көнозын базарда утырасы, ә соңыннан сатылмаган товарны кире күтәреп кайтасы... Ләкин абзый сүзеннән дә узып булмый. Иң соңгы юлны сайлый — хәйләгә керешә малай. Иртән бер кочак «тәңре»не бау белән аркылыга бәйли дә, җирдән сөйрәп, тузан туздырып, базарга чыгып китә. Үзе юл уңаенда ук сөрән салып бара: «Пот сатам! Алып калыгыз! Һич югы яксагыз — мичегезне җылытыр,— агачы бик шәп бит!» — дип кычкыра икән. Мәҗүсиләр, әлеге тамашаны күреп: «Бу ни хәл, нинди башбаштаклык бу?! Безнең тәңрене мыскыл итә ич бу малай актыгы!» — диешәләр һәм, әлбәттә, шушы хәлдән чыгуның бердәнбер юлын табалар: базарга барып җиткәнче үк зирәк Мөхәммәтнең бөтен товарын сатып алып бетерәләр...

Малай чакта колакка кереп калган бу риватьнең сөземтәсе, гыйбрәте — ачыклап торуга, тәфсиргә мохтаҗ түгел. Булган байлыгыңны тәкъдим итә белү дә зур сәнгать, ди ул. Синең алтын кулыңнан үтеп, көмеш тир тамчыларың белән сугарылган җитди хезмәтең икенче берәүнең һәйбәт кәгазьгә төрелгән түбән сыйфатлы «товары» янында югалып калса — бусы тагын да үкенечлерәк, оттырышлырак.

Бәлки, кайвакыт әнә шул күрсәтеп җиткерә белмәү дә безнең эшне, дәрәҗәне,— әйтик, поэзиябез ирешкән чын биеклекләрне, аларның зурысын еpактан ук танырлык-күрерлек итә алмыйдыр әлегә?

Бәлки, гомумән, җитди, тирән шигырьгә караганда буш ритмнар, затлы эчемлек этикеткалары һәм ыштан «фирма»ларының күбрәк игътибар үзәгендә булуы шуннан килә торгандыр?

Аннары шунысы да яшерен-батырын түгел, этикеткага, ярлыкка кайсыбер шигырьләргә караганда күбрәк мәгълүмат салынган була! Алар, бүгенге көн тизлекләреннән калышмаска тырышып, дөнья куучы кешегә ныграк кирәк булып чыга! Ә безнең җир гаменнән аерылган фикер-фаразлар, әзер детальләрдән җыелган кайбер шигырьләргә «мич кабызырга ярар әле» дип тә күз салучы табылмый...

Киресенчә дә булырга мөмкин. Синең шигыреңдә, ихтимал, дәрьяларның агышын кирегә борырлык фикер оеп ятадыр. Ләкин... иң әүвәл аны әле һич югы укырга кирәк. Ара-тирә роман хәтле романны «укый алмадым» дигән сүзләр дә ишетелеп китә. Ә бит ул «укый алмаган» әсәрдә кызыклы образлар, фикерләр, язмышлар, әлегәчә берәү дә күтәрмәгән катлам бар. Шулай дип әйтеп карагыз — ышанмый. «Мин аны укый алмадым. Мин ни өчен азапланырга тиеш?» — ди.

Мондый очракларда иң җиңеле — укучыны гаепләү: үшәнлектә, тармаңгайлыкта, тагын әллә нинди гөнаһларда... Ә бит тел көрмәкләндерүдән, ясалма катлауландыру-боргалаудан талантлы автор гына оттыра. Көнлекче автор шулай «бөгештерү»ләр артына үзенең бушлыгын яшерергә азаплана. Тыштан — бер үк нәтиҗә. Мондый очракта талымсыз, әмма борыны сизгеррәк «уртакул» отучы булып чыга. Ул җиңел укылыш, вакыйга-интрига кору исәбенә укучыны яулап бара. Укучыларның бер өлеше шундый җимгә каба, шул рухта тәрбияләнә. Әлеге очракта талантлы әсәрне артык катлаулы, «аңлаешсыз» булганы өчен чат саен сүксәләр, фикер һәм образ яңалыгы булмаган, әмма су кебек агып торган әйберләр чыгып җиткәнче үк «укыла бит...» дип яклау сүзләре ишетелә, ни арададыр һәртөрле тәнкыйтьтән аралап өлгерәләр. Шулай итеп, Мөхәммәт турындагы риваятьтәге кебек, аларның товары үтә — базар алар куйган бәяне таный... Менә шундый чакларда, без инде яхшы белән яманны аера алмый торган хәлгә килеп җиттек, кебек тәэсир кала башлый.

Тәрәзәсез-ишексез өй...

Бу табышмакның җавабы билгеле инде. Ә поэзия яңа табышмаклар тәкъдим итәргә ашыкмый. Мөгез чыгарудан курка бугай...

Куркуның сәбәпләрен эзли китсәң, аны бүгенге поэзиядәге «тигезлек», «алтын урталык»тан да күрә башлыйсың. Юк, төрле стильләр, төрле буын әдипләренең янәшә торып, кулга-кул тотынышып эшләве мәгънәсендә түгел бу «тигезлек». Бериш, ягъни уртача әсәрләр, уртача геройлар, ниһаять, уртача тел булуы мәгънәсендә ул. Уртакул әсәрдән чын ачышны аера алмый торган уртача тәнкыйть, кемнәрнедер даими исемлек белән аерып куя, дип яманаты чыккан «обойма» да шушы шартларда бөтенесен соры төскә буяу белән алдыра башлады: хәзер «обойма»га бөтенләй билгесез исемнәрне дә кушып җибәрү яңалык һәм кыюлык дип санала, имеш...

Алтмышынчы-җитмешенче елларда поэзиядә зур давыллар уйнап узуы мәгълүм. Гомум яңарыш дулкынында аеруча шул чактагы яшьләр күтәрелде. Бу — өлкән әдипләр иҗатында да тирән үзгәрешләр булып чагылды. Алар өчен әлеге хәлләр бигрәк тә тәэсирле булды — шигырьнең базары бер яктан төште, икенче яктан күтәрелде. Тышкы билгеләренә карап кына да бу үзгәрешләргә табынуы яки аларны себереп түгүе җиңел иде. Кайберәүләр шулай эшләделәр дә.

Тасвир-хикәяләүдә тәрбияләнгән, дөнья әдәбиятыннан хәбәре аз укучылар катламы бу хәлне шактый авырсынып кабул итте шикелле. «Чәйнәп салу»ның, киң тасвир өлешенең кыскаруы, нигездә, әнә шундый укучылар арасыннан бер өлешнең «кыскаруы»на да сәбәпче булгандыр.

Шигырь төшенең тыгызлануы аның эчке җегәрен, сыйдырышлылыгын арттырды. Ә кайбер очракта — андый парчаларны да чыра яндырып эзлисе юк — шигырь дигәнебез тәрәзә-ишек уярга онытып салынган өйне хәтерләтә башлады. Менә шундый вакытта әдәбиятка аяк баскан яшь шагыйрьләргә уңышлары һәм каршылыклары яхшук бергә буталган, кискен аерылып тормаган шартлар белән очрашырга туры килә. Алар мондый очракта нинди юлны сайлыйлар соң?

Тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе җитмәү үзен сиздерә: кызганыч ки, әлегә безнең күбебездә иң соңгы әдәби агымнарның көчле йогынтысын җиңә алмау, хәтта аларны күпмедер дәрәҗәдә канунлаштыру өстенлек ала шикелле. Гомуми хорда үз тавышыңны ишеттерүдән шикләнү, «башлап биргән җыр»ны гына дәвам итү, шуңа канәгать булу поэзиядә якты исем-йолдызларның шактый аз кабынуы булып чагыла.

Бермәл шул болгавырда аптырашып калган авторларның кайсыдыр өлеше, ниһаять, ис-акыл алып, «ничек язарга икәнен» (?!) чамалап, берәм-берәм мәйданга чыга башладылар төсле. Ботак-чатаксыз, багана кебек юнган дөрес-шома шигырьләр күбәйде. Шигырьләрдә икенчеллек, «китап сүзе» көчәю күзгә ешрак ташлана. Шигырь халык тормышыннан, җанлы телдән аерыла бармыймы, дигән шөбһәле сорау күңелгә килә. Моңа җирлек бар. Бүген цитата, исемнәр, астөшермәләр поэзиясе дип әйтерлек язмаларны шактый күп укырга туры килә, алардагы эстетик информациянең кайчак эпиграф итеп китерелгән газета хәбәреннән генә гыйбарәт булуы — борчый торган хәл.

Кайбер шигырьләргә әле болай гына якын килеп тә булмый: аларны уку төрле исемнәрдән торган кроссвордны чишү, еш кына уртачадан түбән дәрәҗәдә эрудицияне тикшерү булып тоела башлый. Ә кроссвордның язмышы һәрвакыт бер үк финал белән төгәлләнә: шакмаклары тулуга, ул кирәксез бер нәрсә булып кала, бүтән кызыксыну уятмый.

Ясалма катлауландыру һ. б. төрле эстетик кыланулар кайбер яшь, җегәрле прозаиклар өчен дә «әйбәт тон» булып санала башлады бугай. Тәмәке тартканда төтенне боҗраландырып чыгарудан тәм табучы малайлар кебек, без хәзер тәкәббер геройлар, «интеллектуаллар», аларның көяз сөйләшүе, «даһи» парадокслары белән мавыга төшәбез. Тормыш проблемалары, конфликтлары урынына ясалма фәлсәфи бәрелешләр күпертелгән саен, әсәрләрдәге геройлар күзгә күренеп кечерәя. Шул ук вакытта без бу «төтенне боҗраландырып чыгару»га сокланган кебек тә булабыз. «Аһ, образ! Аһ, метафора!...» дигән нәтиҗәләр ясарга ашыгабыз. Чынлап та шулаймы? Үзебез дә сизмәстән, җисемне — шәүләсеннән, форманы эчтәлектән аермыйбызмы?

Форма димәктән, шагыйрьләр болай ук «ваклану»ны яратмасалар да, шигырьдә шапшаклык көчәя башлавына күз йомарга мөмкин түгел. Әйтик, чын рифма — сүзне сүзгә чагып ут үрләтү, фикер-мәгънә учагын дөрләтү — «искелек калдыгы»на әйләнеп бара түгелме? Ник дисәң, шигырь үрә генә башлаган, әле шигырь кануннарын яхшылап белеп бетерми торган өйрәнчекләрдәге кебек, ярым-

йорты яңгырашка корылган сүз кайтавазларына таяну — «ялкау рифмалар» — торган саен күбрәк күзгә ташлана.

Мәгълүм ки, шигырь — гармония баласы. Анда гармония эзләү, тормыштагы кебек үк, көрәш аша бара. Әсәрнең төзелешендә үк — шул көрәшнең чагылышы. Шигырь — тыелгысыз омтылыш. Шигырь — көтү. Авазның, сүзнең, образның мәгънәсен, кайтавазын көтү. Асылда, аның көтелмәгән булуы!

Без, шигырь акмы, «кара»мы — аның әйтергә теләгән сүзе мөһим, дияргә яратабыз. Әмма укучының көткәне акланмау — нинди дер ачышка алып килердәй булып талпынып та, «авыз эчендә ботка пешерү»дән ары уза алмый калу — шигърият кораллары белән эш итә белмәүдән башлана.

Шушы җәһәттән, яшь язучының үсү юлында «мөгез чыгарып» каравын да хуплыйсы килә. Без соңгы унбиш-егерме елда, икенче чиккә ташланып, артыгын «кайгыртып», кайчакта бераз тар күңеллелек тә күрсәтеп булса кирәк, экспериментлар ясаучы, үзен авыррак жанрларда сынаучы, кыскасы, үз мөмкинлекләреннән зуррак йөк күтәреп караучы (яшьлеге аркасында!) авторларны бер чыбыктан сөрдек, әдәбият бакчасына мөгезсезләрне, ботак-чатаксызларны гына үткәреп җибәрергә тырыштык шикелле. Әдәбиятта мөгезсезләр, мүкләкләр, шомалар күбәю кем өчендер файдалы иде. (Кызганыч, бу юлы «төртеп күрсәтмәскә» сүз куештык.)

«Алтын урталык»ны чамалап алган авторларга «яшел дулкын» ачу, эстетик яктан куәтсез, эчтәлек ягыннан җитди булмаган әйберләрнең зур тираж белән пропагандалануы, тәнкыйтьтә һәм чыгышларда өстән-өстән генә: йә тема уңаеннан, йә фамилия-сан өчен, йә болай, җае килгәнгә генә сыйпап-мактап үтелүе чын шигырьне авыр хәлгә куйды. Бу — җәмәгатьчелектә хата фикер формалашуга, яшь һәм башлап язучыларга ялгыш юнәлеш бирелүгә дә нигез тудырды, минемчә.

Шундый мөмкинлекләр булганда, бер яктан, сөякчел язмалар — әзер идея кабыргасына ит кундыра алмый азапланучы авторлар иҗаты үзен яхшы хис итә. Икенче яктан, «теше чыкмаган» яки «төшкән» шигырьләр: беренче тәэсирне суырып-әвәләп тә «чәйнәп йота» алмаган, проблеманың төшенә «теш үтмәгән» очраклар ишәя.

Һәр ике төрдә дә — кеше язмышына чыга алмау, тоташып яна алмау.

## Шигырьнең дәрәҗәсен төшерүче сәбәпләр күп

Без, ихтимал, ул сәбәпләрнең кайберләрен — иң өстә ятканнарын гына күрәбездер әле. Чынлап та, тулы бер китаптан, зур шигырь бәйләменнән ни өчен санаулысына, аерым юлларга гына тукталасың, игътибар итәсең, тәэсирләнәсең, истә калдырасың? Күңел халәте, вакыт, әзерлек, зәвык һ. б. нәрсәләр бар — алары мәгълүм... Ләкин бер үк шигырь күпләрнең күңелен били ала икән, димәк, анда «программаланган» да нидер бар?! Җыр — сер, ди халык, һәм һәр шагыйрь ул сергә үз ачкычын эзли. Шигырь басуында үзенә бер кишәрлек алып калу турында гына кайгырткан авторга серне ачарлык ачкыч кирәк түгел. Аның шигыре, каккан казык кебек, нык тырпаеп тора. Әмма... Укучыга коры казык түгел, күз алдында тамырлану, үсү, яфрак яру кирәк...

Без прозадан да хисләр чынлыгы, хәрәкәтләр чынлыгы эзлибез. Документаль әсәрләрнең көтебрәк алынуы, кулдан кулга йөртеп укылуы тикмәгә генә түгелдер.

Галәм язмышы өчен шәхси җаваплылык турында чиләк төбе кагу төсендәге купшы юлларга кем мохтаҗ?

Штамп әнә шулай формадан эчтәлеккә үтеп керә: темада яңа чишелеш тәкъдим итмәү, фикер очкынының бик тиз сүнеп калуы рәвешендә чагыла. Изге темаларны да үтемле товар итеп ваклау, бер өлгә буенча «тиражлау» очраклары эчне пошыра. «Гөнаһысын кая куярбыз, егетләр?» — дип әйтәсе килә башлый.

Шигырь арты шигырь укыйсың: барысы да дөрес, барысы да мәгълүм... Һич аңлашылмый: нинди максат белән әле Кояш системасы өчен кайгыртучы «фәйләсуф» булып күренергә тырышабыз? Газета хәбәрләрен нигә дип рифмалаштырабыз? Модасы шулмы, заман гаме белән янган булып күренәсебез киләме? Авторның чын йөзе, тормыш позициясе урынын тышкы кыяфәт — поза ала бара. Бер табылган алымнар, темалар, образларны ахыргача сыгу хәтта иҗатлары белән танылып өлгергән шагыйрьләрнең дә кызыклы дөньясын кызганыч хәлгә китерә — ахыр чиктә бер даирә эченә бикли

бара. Аларда шигырь — тәкә мөгезе шикелле — үз эченә бөтерелеп, башына кайтарылып үсә башлый: гамәлгә яраксыз, гарип бер нәрсәгә әйләнә.

Бәлки, поэзиядә... юк, поэзиядә генә түгел — прозада, драматургиядә һәм тәнкыйтьтә дә дөнья-күләм әйберләр турында сүз куертып, аяк астындагы туфракны онытып җибәргәләү, җирдән аерылу, нindидер бер божрага бикләнү, йомылу менә шундый — тормышның үзендәге сәер хәлләргә иш булып чыкмыймы икән?..

Әнә сәхнәдә нидер хәл итәләр, шаулашалар, гөж киләләр,— тик әйтерсең лә башка телдә сөйләшәләр...— тамаша залына «ут» күчми. Бу хәлне кайбер авторлар һәм артистлар үзләренчә аңлыйлар: кинәт сәхнәдә арзанлы трюк, кылану, тамашачыны көлдерергә тырышу башлана. Ләкин, кем әйтмешли, «егылып көлә халык... автордан һәм актерлардан көлә!» Сәхнәдәге вакыйга, хәтта үзалдына яшәгән кебек тоелганда да, нәкъ менә тамашачының килеп кушылуына, аның бер почмактан килеп күтәрешүенә мохтаҗ! Әҗәлдән улын саклап калганда, Әлмәндәр картның ихласлыгын һәм гаҗизлеген тоюдан елап утырабыз бит әле...

Минемчә, кайчакта шигырьгә дә әнә шундый гаҗизлек, укучыны үзе дә сизмәстән катнашып китәргә «котырту» хикмәте җитеп бетми!

Югарыда искәртеп үтелгән хәлдән — бер божрага бикләнү, йомылудан чыгу юлын әдәбият үзе үк эзли. Игътибар итәсездер, соңгы еллар поэзиясендә, көчле бер агым булып, сурәт, проблема һәм фикер колачы ягыннан прозага һәм драматургиягә тартылу бара. Проза һәм драматургиядә исә лирик башлангыч, моң, укучы-тамашачы белән эчкерсез бәйләнешкә омтылу, ачылу тенденциясе көчәя. Замандашның күңел төпкеленә карау, аңа турыдан-туры мөрәҗәгать итү, укучыны хәтта кайсыдыр чаты белән бераз эләктереп алу — битарафлыктан уяту, эшкә-хәрәкәткә чакыру... Шигырь тәэсир итсен өчен — җиңел укылмаска тиеш!

*Янә бер P. S.* «...Җиңел укылмаска тиеш!» дигән җөмлә ташка басылып чыккач, кайберәүләр моны, ким дигәндә, изге кануннарга кул күтәрү дип аңлаганнар, имеш. Аларны тынычландырырга мәҗбүрмен: соң, әлбәттә, шигырьдә фикер буталчыклыгына яисә тел кытыршылыгына, ритм чатаклыгына өндәргә мөмкинме! Шөкер, арабызда үзләрен иректә шигырь язам дип белүчеләр болай да бар. Чын шигырь — «иректә»ме, «ак»мы ул яисә традиционмы — һәрвакыт үз калыбында туа. Көе-авазлары белән колакны иркәләсә дә, кабат-кабат уйландырырлык, бәлки, төн йокыларын алырлык дәрәҗәдә «авыр укылышлы» шигырьләр яши дөньяда. Шулардан беренче булып күңелгә килгәне, әйтик: «Гариб моң бар өнендә җил-җиләснең — Туган илләрдән искән җил димәссең...». Бу ике юлдан соң инде күпме шигырьләр бер балкып сүнгән һәм сүнәчәк, ә болар утлы күмер кебек гел көйрәп тора, аз гына җил исеп кую белән, бәгырьгә төшеп, яна башлыйлар...

Юк, җиңел укылмаска тиеш шигырь!

## Тәнкыйть — кемгә кирәкле шәй?

Сорау беренче карашка гына сәер тоела. Поэзия һәм укучы, шигырьнең замандаш күңеленә юл эзләве мәсьәләләренә кагылганда, «әзерлекле укучы» дип аты чыккан тәнкыйтьчене, тәнкыйть базарындагы бәяләрне читләтеп үтеп булмый. Соңгы елларда гына да татар поэзиясенең үсеш тенденцияләрен күзаллаган байтак хезмәтләр дөнья күрде. «Дежур» рецензентлар һәм кайбер шагыйрьләрнең үзара макташу рухындагы язмаларына юл шактый чикләнгән кебек булды. Шулай да баштан ук таныырга кирәк: киң катлам укучыга чын поэзияне аеру мәсьәләсендә һәрвакытта да ныклы юнәлеш бирә алганыбыз юк әле. Бездә ни язылса — шул әйбәт, дигән рецензияләр һаман да күп басылып тора. Рецензия, билгеле булганча,— киң катлам укучыга тиз барып ирешә торган, укучы фикерен һәм ихтыяҗын формалаштыру көче зур булган өлгер, сугышчан жанр. Без исә еш кына, шушы гади хакыйкатьне онытып, рецензияне китап пропагандасы белән бутауга юл куябыз. Профессиональ тәнкыйтьнең сүлпәнлегеннән һәм «вакланмавыннан» файдаланып, бер төркем кәсепчеләр бу эшне тәмам үз кулларына алдылар шикелле. Газета-журналлардагы шундый төр язмалар буенча хөкем йөрткәндә, ниһаять, безнең поэзия тулысы белән үзенчәлекле, «кабатланмас йөзе булган» шагыйрьләрдән һәм «коеп куйган» шигырьләрдән генә тора башлады.

Чынлап та шулаймыни соң?..

Икенче яктан, шагыйрьләрнең соңгы еллардагы төрле чыгышларына, шул исәптән тәнкыйтьчеләргә «багышлап» язылган рифмалы парчаларына карасаң, поэзиянең уңышларын һаман да күрми икән әле безнең тәнкыйть, һәм аның бөтен гөнаһларында, кимчелекләрендә торганы шул тәнкыйтьчеләр генә гаепле икән. Тәнкыйть белән тарткалашучы шигырьләр антологиясе төзесәң, шәт, күләм ягыннан кулга тотарлык бер китап килеп чыгар иде. Әлеге шигырь авторларына тәнкыйть тирәсендә чуалучы кәсепчеләр ныграк ошый шикелле. Аларның яшәү рәвеше нигездә мактаудан гыйбарәт — кирәк урында җәмәгатьчелек фикере, дип күрсәтә аласың; ә инде кимчелек таба башласалар — «профессиональ тәнкыйтьче түгел шул, аңламаган инде, бичара», янәсе... Янә классиклар тарафына бармак төртеп күрсәтүчеләр дә күбәя: әнә бит алар да... Булган, тупас тәнкыйтьнең тыелган алымнар кулланулы да, «ахыргача фаш итү» (Алла сакласын!) џәм үпкәләшүләр дә байтак булган. Әмма шунысы да бар: әүвәлгеләр, бөекләр «тәнкыйть — кирәкле шәйдер» дигән принциптан чыгып, аны вульгарлаштыруга каршы торганнар. «Рецензия оештыру» хәстәре дә аларны борчымаган булса кирәк. Аннары тарих шаһит: тәнкыйтьчеләр өстеннән язу урынына, әдәби-эстетик фикер үсешенә үзләре җиң сызганып өлеш керткән шагыйрьләр һәр заманда булган. Әле дә юк түгел...

Әйе, поэзияне бәяләүдә мәгълүм штамп яши, һәм ул, миңа калса, өлешчә, поэзиянең үзеннән дә килә — бумеранг булып, игезәк образлы, «дөрес» фикерле төссез шигырьләрнең кайтавазы булып. Шигърият һәм укучы файдасына тәнкыйтьнең беркадәр «тенденциоз» булуыннан, ягъни күңелендәген уеп әйтүеннән (скальпель белән!) шифасы гына тияр иде. Бу сүзләр беренче тапкыр яңгырамый, ләкин...

Бер яктан, теге яки бу шагыйрьнең тәнкыйтькә, «минем уңышларымны гына, ә башкаларның кимчелекләрен генә күрсен иде» дигән кебек, үпкәләп яшәве, икенче яктан, «тигезләүче» тәнкыйтьченең һәм һәвәскәр тәнкыйтьләүчеләрнең җавапсыз чыгышлары укучыда, бигрәк тә яшь авторларда ялгыш фикер тудыра, поэзиянең дә, тәнкыйтьче сүзенең дә абруен төшерә. Һәрхәлдә бүгенге шигырьләрдәге аерым кимчелекле яклар вакыт-вакыт — өстенлек, ә ким дигәндә  табигый хәл дип кабул ителә икән, бу хәлләрнең тагын да тирәнрәк тамыр җәюенә юл ачыла гына бара.

Сер түгел, җитешсезлекләр турында сүз чыкса, һәркайсыбыз күбрәк яшьләрне генә телгә алырга тырышабыз. Беренчедән, яшьләр иҗатында чор әдәбиятының төп эзләнүләре һәм төп «авырткан» төшләре ярылып», ачык булып ятканга күрә. Икенчедән, яшьләребез әле эзләнү чорында, тәнкыйть сүзенең аларга файдасы ныграк тияр, дип. Ләкин әсәрне кешесенә (ягъни ул биләгән урындыкка) карап бәяләү, өлкәннәргә хөрмәтне, ә яшьләр турында кайгыртуны ташламалар ясау белән алыштыру гаделме?

## Язылган кадәресенә нокта куйгач...

Хәер, «сорау билгесеннән соң» дип әйтү дөресрәк булыр иде. Чөнки нәкъ менә якты исемнәре, биек орбитасы, кабатланмас дөньясы булганлыктан, поэзиябезнең сораулары, проблемалары да шактый. Җитди, зур проблемалар үзләре янындагы кечерәк мәсьәләләрдән җыела-укмашалар.

Укучы белән багланышка керү — үзеннән-үзе аңлашылган кебек тоелучы шундый «гадәти» мәсьәләләрнең берсе. Әлбәттә, укучы күп төрле — аңа шигырьләрнең дә төрлесе кирәк. Әлбәттә, сүз ерак йолдызлардагы җан ияләре, хәтта Яңа Гвинеядәге «куку-куку» кабиләләре белән контактка керү турында да бармый. Ләкин, укучы үзебезнеке — ул гаеп итмәс, дип, артык җиңел уйламыйбызмы? Ул — җитәрлек дәрәҗәдә әзерлекле, үзе аралап укыр әле, дип, ачыктан-ачык халтура тәкъдим иткәләү — бер-беребезгә илтифатсызлык күрсәтү түгелме?

Нишләп әле без һәрвакыт җиңел юлга исәп тотабыз: «талантлы укучы»га, «үз укучыбыз»га гына өметләнеп язабыз? Файдасы тиярдәй булганда, «гади укучы»дан килгән хатны калкан итеп күтәрү, турысын әйткән тәнкыйть фикерен исә ерактан ук күреп селтәнә башлау — иҗатыбызны, әдәбиятыбызны кая алып барыр? Зур традицияләре булган әдәбият инерция буенча үсүен дәвам итәр, дип ышанабыз шикелле. Чынлыкта шулаймы соң?

Әдәбиятның үсеше дә, тормышка тәэсире дә укучы-замандаш күңеле аша бара. Шигырьне укучы хөкеменә, кеше арасына чыгарып җибәргәндә, аның өчен җаваплылык хисе дә зур булырга тиеш.

1987

## АЧКЫЧ ЭЗЛӘДЕМ...

...Сүз әйтмәүдән дә әчерәк тәнкыйть юк.
Әхсән Баян

Бер танышым шәһәребезнең яңа микрорайонында яши, һәркөн иртән эшкә ташпулатлар белән кысрыкланган сала урамнарыннан килергә ярата. Авыллыгын инде җуеп баручы, әмма әле кала булып җитә алмаган урамнарданниләр уйлап үтә икән ул?

Хәер, эшкә килеп җитү белән, башкаларга да йоктырырга теләгәндәй, ул үзенең тәэсирләрен ачылып сөйләргә ярата. Аның хезмәттәшләре-дуслары — байтак китап укыган егетләр-кызлар, җае чыкса-чыкмаса, югары материяләр тирәсендә фәлсәфә куертырга теләүчеләр дә бар арада. Ә танышымның хикәяте гади нәрсәләрдән, җир хәлләреннән башлана. Мәсәлән, менә болайрак:

— Бүген ишегалдында Караборын елап калды әле, егетләр...— ди ул.— Каяндыр килеп, ияләнеп калган иде, ничәнче ел инде безнең подъездда яши. Бала китергәндә генә югалып тора да ияртеп кайтып керә үзләрен... Матур була аның көчекләре! Тик, күзләре елтырый башлауга, әнкәләре каядыр чыккан арада, урлап бетерәләр үзләрен берәм-берәм. Шуннан соң шыңшып йөрүенә тәкать юк...

Нидер әйтеп бетерми, барысы да шуны көтеп тора. Бу тынлык — аның файдасына.

— Көчекләргә, бәлки, безнең подъездга кереп-чыгып йөрүче күршеләр үк кул суза торгандыр. Караборын — юаш, ышанучан, аларга игътибар да итми... Тик үз ишләре өчен мондый көннәрдә аннан да усалрак җанвар юк: ишегалдыннан узып баручы бер кәкрекойрыкка да көн күрсәтми. Аларны күрү белән зур тавыш чыгара, пыр туздырып, әллә кая хәтле куып китә. Күрәсең, караклыкны үз ишләреннән күрә, бәбкәләрен шул «сабакы»лар ияртеп киткән дип белә...

Тыңлап торучылар әкрен генә таралышалар. Әллә чынлап та шушы хикәят тәэсир итте инде аларга?.. Бөтен бәлане үз ишләреннән күрә, башкача булуын башына да китерә алмый торган җан ияләре турында уйландыргандыр, бәлки, ул аларны?

Тәнкыйтьче дустымның әдәбият хакында түгел, ә подъезд этен кайгыртып сөйләгәнен искә төшерүем белән, сүземдә шәхсилек төсмере куерып киткәндер. Әмма шул очраклы гына мисалда, минемчә, катлаулы мөнәсәбәтләр һәм бәйләнешләрне гадиләштереп аңлаудан, сәбәп белән нәтиҗәне бутаудан кисәтеп тору да бар кебек!..

Әдәбиятның тәнкыйть дигән бер йөген тартып-тартышып баручылар хезмәтен мин, авыл баласы, үзебезчә — авылчарак итеп күз алдыма китерәм. Әйтик, басу белән, иген игү белән чагыштырып карау җайлырак та, аңлаешлырак та тоела.

Әдәби тәнкыйтьнең бөтен сөрүлек җире ул — китаплар, матбугат басмалары, ягъни аны башкалар инде әзерләп куйган, дип карау гадәткә кергән. Культуралы, эшкәртелгән басу, янәсе,— чирәм күтәрәсе түгел. Ләкин, һәркайсыбыз белгәнчә, «эшкәртелгән туфрак», әдәби туфрак — ул әле өске катлам гына; тәнкыйтьчегә исә шул туфракка җегәр бирүче, аны яңартучы тирәнлекләр белән эш итәргә кирәк... Шул ук вакытта ул, «тормыштан килүче әсәр, тормыштан килүче автор» кебек мактау сүзләрен урынлы-урынсыз сибәргә ашыкмыйк, дип искәртә: чөнки тирән катламнардан ут (чүп үлән) тамыры да күтәрелә; әдәбиятта чүп үләне белән көрәшүнең исә үз авырлыклары бар — бередә гербицидлар кулланырга ярамый. Һәм тәнкыйтьнең төп максаты, төп бурычы — утау түгел; чүп үләнгә дә ул, тамыры нинди нык, ничекләр ирешә соң бу моңа, дип карый, шул ныклыкны сау үсентеләргә күчереп булса икән, дип уйлана!

Бу четерекле хезмәткә алынган каләмдәшләрем иҗаты шул рәвешле тормышка якыная, безгә якыная бара, барыбызга да кирәгрәк була бара. Аларның язганнарында тормыш, тирән катлам импульслары көннән-көн ачыграк чагыла. Бу шулай булырга тиеш тә: тәнкыйть, тормыш һәм әдәбиятның тетрәнүләрен алдан сизеп торганда гына, әдәби хәрәкәткә һәм укучыга тәэсир итә, тиешле нәтиҗәгә ирешә ала.

Тәнкыйтьче Мансур Вәлиев, мәсәлән, үзенең кордашлары Марсель Галиев һәм Мөдәррис Әгъләмов иҗатына әнә шул юл белән килгән иде. Әлеге хезмәтләрендә ул аерым язучының аерым әсәрен

генә түгел, бөтен бер әдәби буынның язмышын күрә, тормыш һәм культура традицияләре белән бәйләнешен, иҗтимагый тамырын билгели, әдипне аңлау тормышны аңлаудан, заманны аңлаудан, шәхесне аңлаудан башлана, дигән мәгълүм хакыйкатькә тагын бер кат ышандыра.

Мансур Вәлиев, бүгенге яшьләр иҗатының йомшак якларын күргән һәм күрсәткән хәлдә, аның үсеп китәр өчен җирлеге, нигезе булуын раслый, бигрәк тә 70 нче елларда яшьләр поэзиясенә ышанычның какшый башлавы сәбәпләрен аңлатып, аның яңа юллардан үсүен яклый. Шулай да аның «яшьләр шигърияте ндәге тынлык чоры бетте» дигән фикеренә ышанырга бер факт комачаулый: мәкаләләрендә телгә алынган Р.Хәлиуллина һәм Ф.Гыйззәтуллиналарны, хәтта Зөлфәт белән М.Әгъләмовны да 70 нче еллар уртасындагы яшьләр поэзиясенә кертү килешеп бетмәс иде. Дөрес, ул буыннан «яшь шагыйрьнең беренче китабы» финишына килеп җитүчеләр һаман да кимеми — әлеге серияне дәгъва кылучы яшь авторлар инде «алтын» юбилеен билгеләп үтәргә җыена... Аларда дуамаллык юк дәрәҗәсендә, «вулкан» сүнеп килә, аларда акыл тәлинкәсе баса төшә. Әлеге агым, ихтимал, безнең поэзиягә, аның гомум атмосферасына да тәэсир итми калмас...

Бу — каләмдәшемнең фикерен дәвам итү, аңа ялгап әйтү, юл уңаендагы бер күзәтү, әлеге нәтиҗәләрнең Вакыт сынавын ничек үтүе турында уйлану гына. Һәм шундый ук — «юл уңаендагы» нәтиҗә: мавыгып китү, теләгәнне бар итеп күрә башлау, кечкенә генә табыш, һич югы отышлы тема өчен булса да мактау тәнкыйтьченең үзен ялгыш аңларга урын калдыра.

Ә инде аерым әсәргә, аерым язучы иҗатына яисә әдәбияттагы мәгълүм тенденциягә тискәре мөнәсәбәтеңне ачыктан-ачык белдерәсең икән... Бер мәлгә тирә-ягыңда «дошман»нар һәм ачыгавыз тамашачылар гына калгандай була. Менә шул «тамаша»да тәнкыйтьчебез, кылыч уйнату белән мавыгып, тышкы билгеләре буенча гына, әдәби хәрәкәтнең тулы бер буынын «шигъри бушлык» дип кырып ташламасмы?

Ниһаять, барыбызга да теге яки бу дәрәҗәдә хас булган әлеге кимчелекләр кайбер укучыларның гомумән тәнкыйтькә ышанычын киметмәсме?..

Укучы дигәннән, инде без укучы исеменнән үзебезнең сүзне әйтергә гадәтләнеп киләбез бугай. «Укучы таләп итә»,— дип кенә җибәрәбез. Әле генә, бәлки, мин дә шулай мавыгыбрак киткәнмендер. Ләкин мине авыл китапханәсендәге укый-укый таушалган китап эчлегендәге «бу китап — бик кызыклы, сез дә укыгыз!» дигән эчкерсез «кыска рецензияләр» ныграк ышандыра. Тәнкыйтьче — югары әзерлекле укучы ул, дип кабатларга яратабыз икән, аны шәхси мөнәсәбәттән мәхрүм итү, тыю дөрес булмас. Мәшһүр Белинскийның бер хатыннан мондый сүзләр хәтергә килә: «...бәләм,— дигән ул,— минем көчем — зур сәләттә түгел, ә дәртләнеп эшләүдә, холкым-табигатем белән һәм кеше буларак субъективлыгымда, язган сүзем белән үземнең һич тә бүленми торган бернәрсә булуымда...»

Яшь тәнкыйтьченең «ташка басылган» сүзләрен укыганда да, без аның үзен күрергә, ихласлык дәрәҗәсен тоярга тырышмыйбызмыни? Мәсәлән, шул ук Мансур Вәлиев иҗатының иң көчле ягы — хис-пафос белән, кайнарлык белән алдыруда, дип дөрес әйтәләр. Кызыклы фикерләр, нечкә күзәтүләр белән бергә, аның чыгышларына йөрәк кайнарлыгы, изүләрне чишеп сөйләшү рухы салынган. Минемчә, бу — безнең соңгы еллар тәнкыйтендә яңа тенденция. Ул көннән-көн көчлерәк юл ала торган, перспективалы юнәлеш булыр, дип өметләнергә батырчылык итәм.

Фикерләү рәвеше-стиле белән бөтенләй үзгә булса да, темпераменты белән М.Вәлиев иҗаты урта буын тәнкыйтьчеләрдән бигрәк тә Рафаэль Мостафин, чордашларыннан — Ринат Мөхәммәдиев әсәрләренә тартыла. Үзеңне иркен тотып, тугарыла төшеп язу, шул ук вакытта дәлиллеккә, җитдилеккә хилафлык китермәү... Конкрет әсәрләргә нигезләнеп, концептуаль, мөһим бер юнәлешкә буйсындырылган әлеге хезмәтләр — акрынлап җыела-көч ала килгән язгы ташу сыман. Әнә шул бер актарылып агуында юлны бүлеп торучы берничә олы буаны алып китәргә өлгерә ул...

Яисә менә әдәби тәнкыйтькә М.Вәлиевтән чак кына соңрак килгән Равил Кукушкин. Аның балалар әдәбиятына багышланган күпчелек хезмәтләрендә фикер «мускуллары»ның уйнавы ничек сокландыра. Аларда ачык белдерелгән мәхәббәт һәм нәфрәт тә, полемик рух та үсә барсын иде... Чыннан да, югары дәрәҗәле тәнкыйть әсәре шәп шигырь кебек — аның соңгы юлы гына, аерым фикере-бәясе генә түгел, бөтен яшәеше киеренке, җәя җебедәй тартылган хәлгә килергә тиеш түгелмени? Фикер җисемле булырга — аның җылысы, массасы тоелырга тиеш түгелмени?

Тәнкыйтьнең фәнме, әдәбиятмы булуы турында бәхәсләрнең дулкын-дулкын булып кабынып торган чагы. Медицинадагы кебек, күпләр тәнкыйтьтә үзен белгеч дип саный. Ә шул арада тәнкыйть үзенең сүзен әйтү рәвеше белән прозага тартыла бара. Кайчакта аңа шагыйрьләр көнләшеп карарлык

образлар, чагыштырулар килеп керә. Фикерне сурәтле, җисемле итеп бирергә омтылу — бик табигый хәл, минемчә. Бер яшь тәнкыйтьченең Роберт Миңнуллин иҗатын шагыйрьнең туган ягындагы Сөн суына охшатуы хәтердә калган. Башта ясалмарак чагыштыру, турыдан юл салу кебегрәк тоелган иде ул. Ә хикмәт шул охшашлыкның төрле яклы анализ нәтиҗәсе булуында икән: яшь тәнкыйтьче бу иҗатның чишмәләрен, аккан юлындагы борылмаларын, тирән һәм саегып киткән төшләрен һәм, ниһаять, әлеге елганың кая коюын өйрәнә, шагыйрь дөньясындагы шул тормышны үзенчә, ышандырырлык итеп тасвирлап-күрсәтеп бирә.

Сибгат Хәким шигъриятенең кешелекле яктысын һәм җылысын ачу өчен, Мансур Вәлиевкә Аккош күлендәге караңгы төндә шагыйрь шәменнән яктырган дача өе ярдәм итә. «Учагың сүнмәсен» исемле китабында аның тәнкыйди образлылыкка таяну, тәнкыйди прозага омтылу тенденциясе аеруча ачык күренде.

Кемнәргәдер бу ошамый — алар шунда ук чуарлау, төчеләнүгә каршы сугыш игълан итәләр. Әлбәттә, чама тойгысын югалта башлаган очракларда андый кисәтү бик урынлы. Тик юган суы белән бергә баланы да чыгарып түкмик,— бөтен хикмәт образлы фикердә яисә шәхси мөнәсәбәтне ачыктан-ачык белдерүдәмени?! Күренеш һәм аның образлы гәүдәләнеше арасындагы нисбәт кенә югалмасын. Купшылык бездә әнә шул нисбәтне саклау осталыгы җитенкерәмәгәндә, тай өйрәтергә алынган кыю, әмма тәҗрибәсез малай кебек мавыгып китеп, шул тайны җиңә алмаганда килеп чыга. Ә ул мавыгу дигән нәрсәдән тәнкыйтьтә ат уйнаткан агайлар да азат түгел. «Фәлән шагыйрь өчен халык иҗаты җәүһәрләре Галәветдин лампасы (?!) ролен уйный»,— дип алар да язгалый ич...

Күпләр игътибар итә булыр: Мансур Вәлиев катлаулы метафоралар белән мавыкмый, парадокслар ясап, мөһим нәрсәләрдән күзне адаштырып калдырмый. Сурәт, чагыштыру аңа мәгънә тирәнлеген яктыртып җибәрү өчен бер очкын буларак кына кирәк. Төгәл һәм мәгънәле исемнәр табуына ук игътибар итәрлек. Беренче китабы — «Яшьләр мәйданга чыга» — әдәбиятка үз буынының килүен хәбәр итү. Икенчесе — «Табарга һәм югалтмаска». Биредә ул, минемчә, кешенең рухи кыйбласын табу авырлыкларын, югалтулар аша килгән табышларның кадерен искәртә. Шуннан соңгы китабы — «Күңелнең көткәне». Анда тәнкыйтьченең бүгенге әдәбият турында фикерләре, бүгенге шатлыклары һәм борчулары, киләчәк — күңелнең көткәне — турында ихлас уйлануы...

Сүземнең башында ук тәнкыйтьче танышымның шәһәр эчендә калган авыл урамнары буйлап килүен болай гына искә төшермәгән идем мин. Соңгы еллардагы әдәби тәнкыйть үзенчәлекләренә, аерым алганда, яшь каләмдәшләрем иҗатына шулай ачкыч эзләдем. Башта тышкы билгеләр — мәкалә исемнәре буйлап үттем: «Авыл урамнары буйлап», «Авылыбыз моңын югалтсак», «Авыл кешесенең матурлыгы»... Тышкы билгеләр генә микән бу?! Мондый аваздашлык һич тә тормышның канунлашкан күренешләрен теркәп баруга охшамаган; минемчә, ул әлеге тышкы билгеләрдә генә абайлана башлаган үзгәрешләрнең нинди эчке үзгәрешләр китереп чыгарасы турында уйлану, әдәбияттагы һәм тормыштагы юнәлеш-ориентирлар турында уйлану. Әдәбият урамнары буйлап үткәндә, тәнкыйтьче үзенең су астында калган туган авылын — Идел төбендәге чишмә кебек, яшәү суты биреп торган төбәген дә күз алдыннан кичерәдер, адәм баласының күңел төпкелендә яткан кешелеклелек чыганакларын күрергә омтыладыр кебек.

М.Вәлиевнең һәр тәнкыйть чыгышы диярлек әсәрнең әхлакый-фәлсәфи төшен ачуга юнәлгән була. Әгәр әдәби әсәрнең төше, җаны, шигърияте язучы шәхесенең тормышны тирәннән тоюы, тулы аңлавында икән, ул әнә шул шигъриятнең бүлгәләнмәвенә ышана, шуңа күрә үзен теләсә нинди жанр әсәрен анализлаганда бердәй вәкаләтле хис итә. Аның иҗатында аерым сүз-төшенчәләр баскычыннан күтәрелеп, кешенең рухи җегәрен күрсәтүче эш-гамәл, күңел хәрәкәтләре яссылыгында фикерләү көчәя бара. Бу — карашның киләчәккә төбәлгән булуын янә бер кат раслый.

Ләкин бу комплиментарлык түгел, бу — әсәргә һәм бигрәк тә аның авторына перспектива калдыру, үсү өчен түшәмне биегәйтә төшү! Яшьтәшләре иҗатына игътибары һәм кирәк чакта үсендерү сүзе әйтә килүе (М.Әгъләмов турында — «Киләчәккә кайту», Ф.Сафин турында — «Рәхмәт сезгә, шагыйрь!», Р.Зәйдуллин һәм Л.Зөлкарнәев турында — «Егермедәгеләр») шул сыйфат белән бәйләнгәндер дип уйлыйм.

Яңа, күпләргә «таныш булмаган буын»ны — аның проблемалары, үсеш каршылыклары, үзенчәлеге белән тәкъдим итү, аңлату — авыр бурыч, әмма яшьләр прозасына һәм поэзиясенә иң якын торганы — яшьләр тәнкыйте; яңа күренешләргә бәя биргәндә шушы якынлык та ярдәм итәдер аңа.

Яңа буын дигәннән, сүз, әлбәттә, әдәби тәнкыйть сафларын тулыландырырга омтылучы яшьләр турында да барырга тиеш. Ни көтелә алардан? Мин, шул сорауга җавап эзләп, М.Вәлиевнең моннан байтак еллар элек дөнья күргән беренче китабын кабат укып чыктым. Арада аеруча җәлеп иткәне — танылган язучы белән яшь тәнкыйтьченең «бүгенге герой проблемасы»на багышланган әңгәмәсе («Мәйданга — бүгенге көчләрне!»). Ул әңгәмәдә — әдәбиятның эченнән килү. Әдәбиятны үстерешә торган, «эчендә җаны булган» тәнкыйть. Менә бу сыйфат яңа буын тәнкыйтьчеләргә дә чит булмасын иде.

Фәиз Зөлкарнәев, Әхмәт Сәхапов... Яңа исемнәр күп түгел. Әмма һәркайсының эзләнүләре, табышлары бар. Тәнкыйтькә яңа көчләр, авырлык белән булса да, килә тора. Шул ук вакытта әдәби тәнкыйтьне үзләренең иҗатын дан биеклегенә тартып менешүче итеп күрергә теләгән һәм, әлбәттә, еш кына аннан канәгатьсез булган кайбер иптәшләр, тәнкыйтьчеләр ишәя, дип юкка хафаланалар.

Әдәби тәнкыйтьнең әдәбияттагы бүтән тармаклардан үзгә бер сыйфаты билгеле: ул — аның өлкәннәр тәнкыйтенә һәм яшьләр тәнкыйтенә бүленмәве. Башлап язучы тәнкыйть, яшь-яшел тәнкыйть булуы мөмкин түгел. Тәнкыйть — җитлеккән яисә җитлекмәгән генә була ала.

Татар әдәби тәнкыйте хәзер (бәлки, башка беркайчан да булмаганчадыр) исемнәргә бай. Шулай да өлкән буын Җ.Вәлиди, Г.Гали, Г.Нигъмәтиләр заманын сагынып искә төшерә. Без исә М.Гайнуллин, Х.Госман, Г.Кашшаф, И.Нуруллин һәм Н.Юзиев хезмәтләрен яхшы хәтерлибез, Р.Мостафин, Ф.Мусин, Т.Галиуллин, А.Яхин, А.Әхмәдуллин, Н.Хисамов, Х.Миңнегулов, Ф.Галимуллин, Д.Заһидуллина һ. б.ларның гыйльми-тәнкыйди иҗаты әдәбиятыбыз үсешендә нинди урын билгәгәнен беләбез... Шуңа да карамастан, соңгы елларда әдәби тәнкыйтькә кагылышлы дәгъваларның бер өлеше бик тә урынлы булуын танырга кирәк.

Әдәбиятның «кара эш»ен тартып баручы рецензияләр белән, мәсәлән, эшнең бик шәптән тормавы билгеле. Шигырь юлыннан яисә проза биргән материалдан күтәрелеп, тормыш-яшәеш белән бәйле киң гомумиләштерүләргә чыгу ук димик, күп хезмәт куеп, шагыйрьнең иҗади йөзен ачуга ирешү дә аз рецензия авторларының гына бәхетенә тия. «Универсал», дөресрәге, очраклы кешеләр язган рецензияләр газета битләрендә саргая. Шаблон буенча эшләнгән ул язмаларда ялтырап ятучы исемнәрнең шактые күз алдында ук үзен акламый, ә укучыны юлдан яздырырга мөмкин. Бу — рецензиягә бер күзәнәкле жанр итеп каравыбыз нәтиҗәсе.

Рецензия — тормыш һәм әдәбиятның иң көчле агымы туры килгән үзән. Кулына каләм алганда максаты ачык булмаган, көче җитмәгән кешене ул әллә кая агызып китәргә мөмкин.

Безне әлеге агымда төрле бусагалар сагалап тора. Әйтик, тәнкыйть формулаларының көчле инерциясе — әзер калып буенча «кирпеч сугып» утыра башлау ихтималы. Яисә шаблонның нечкәрәк, яшеренрәк формасы — әдәбият белеме салган баганалы юл буйлап бару, теориядән чыгып, «шулай булырга тиеш» дип, әсәрне сүтәргә керешү. Бу — әдәби әсәрнең, язучы шәхесенең үзенә генә яраклы ачкычны эзләүдән котылырга маташу. Шуңа күрә тәнкыйть формулаларын мин купшы образлылыктан да хәтәррәк нәрсә дип саныйм. Аларның төп чыганагы — еш кына тәнкыйтькә яңалык тойгысы җитмәүдә: әдәбияттагы яңа күренешләрне үз вакытында тану, бәяләү, талантның табигатен аңлау күңел һәм зиһен хезмәтен сорый, әзерлек таләп итә.

Турысын әйтергә кирәк, соңгы елларда прозаиклар һәм шагыйрьләр авызыннан еш кына «тәнкыйть фәнни булырга тиеш» дигән сүзләр ишетелә, ә күңелгә вәсвәсәле уй керә: «тәнкыйть минем иҗатымны тиешенчә күрми, күтәрми» дигән киная-дәгъва түгелме соң бу? Үзе әдәби хәрәкәт турында актив фикер йөртеп, каләмдәшләре иҗаты турында саллы-саллы мәкаләләр язган әдипләр болай эшләми. Чөнки алар тәнкыйтьне — әдәбият белеменнән, ә чын тәнкыйтьне ялган тәнкыйтьтән аера белә.

Тәнкыйть мәкаләсенең фәннилеген терминнарга карап билгеләүчеләр, әлбәттә, шундый «атрибутлар» булмаган һәр очракны гадиләштерү, җиңелләштерү, фәнни булмау дип бәяләргә кыенсынмыйлар. Ләкин нәкъ менә шул терминнарны күп очракта без үзебезнең эшне җиңеләйтү өчен уйлап чыгарабыз, аннары, аларга таянып, әсәрне гадиләштерәбез, «соңгы нульгә хәтле» түгәрәклибез, схема буенча аңлатабыз лабаса! Әдәбият белеме тирән йокыга талган чорда бу бигрәк тә күңелсез нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Мансур Вәлиев, шундый ихтималны күздә тотып, бер мәкаләсендә болай ди: «Кешенең рухи яшәеше өлкәсендә конкрет сүз, атама эзләү ул — физика дөньясында моңарчы билгеле булмаган күренешне иске прибор белән аңларга, шуның аша күреп бетерергә теләү кебек тоела».

Сүз, әлбәттә, әдәби тәнкыйтьнең методологик нигезләре турында бармый. Һәм хикмәт терминнарның үзләрендә түгел, ә аларга мөнәсәбәттә — аларны хезмәт иттерүдә яисә аларга табынуда. Менә шул җәһәттән инде яшь иҗатчы шәхесенең көче сынала. Тәнкыйть әсәре тормышка һәм әдәбиятка карата «икенчел», күләгә булып кала икән, бу — аның авторының тормышта һәм әдәби процесста үз позициясе юклыгы билгесе. Күңелендә кешеләргә әйтер ниндидер җитди, мөһим сүз булмавы галәмәте. Аны инде дәрәҗә-титул белән дә, «фәнни» терминология белән дә яшереп кала алмыйсың.

Тәнкыйтьченең дәрәҗәсен, зәвыгын хәтта ул мисал итеп китергән өземтәләргә карап та белеп була...

Әдәби процессның, аерым әсәрнең артыннан ияреп барганда бәхәс куерта башлавыбыз, көн тәртибеннән төшеп барган мәсьәләләр тирә-сендә кылыч уйнаткан булулар да әлеге — үз сүзең, үз мөнәсәбәтең өлгермәгәнлекне фаш итә.

Шул уңайдан, тормыш гыйбрәте итеп, берничә ел элек булган бер вакыйганы сөйләп үтәсе килә.

Ул җәйне, давыл көченә каршы тора алмыйчамы, тамырларының куәте бетепме, йөзьяшәр бер тал ауган иде. Авыл читендә, су буенда, бик күптән корыган иде инде — башта аңа игътибар итүче дә булмады шикелле. Утынга дисәң, кытлык юк: авыл өстенә үк урманы ишелеп тора. Шулай да, теш ярып керәсе мал бит, дип, ахрысы, авылның ике башыннан ике йорт кешеләре бу тал янына йөгерешеп килгән: икесе дә, безнең бабайның бабасы утырткан тал булырга тиеш бу, дип тарткалаша... Кыскасы, ике баштан төшеп, ай буе утынга турадылар әлеге талны. Тимер кебек харап каты кәүсәле икән. Кара тир агызып эшләделәр. Ул арада халык печәнгә төште,— «Ходай биргән» утынны, кискән төшендә генә, ашык-пошык өеп калдырырга туры килде. Шул көнне, үч иткәндәй, кичкә таба дүрт яктан кара болыт килеп, авыл өстендә янә давыл уйнады. Мунчаларга тикле су күтәрелде, буалар ерылды, буалар белән бергә шикәр шакмагы кебек туралган тал — ике әрдәнәсе дә тиң агып киткән булып чыкты...

Моннан, табигать үзе биргәнне үзе алган, дигән киная генә килеп чыкмасын өчен, өстәп әйтим: безнең тәнкыйтьтә дә шундыйрак хәлләр булгалый тора. Без, теге яки бу проблема үзе алдыбызга килеп аугач кына, аны үзләштерергә — тарткаларга, таркатырга, «кисәргә» керешәбез,— ә шул арада ул... агып киткән була.

Әдәби тәнкыйть кайнар эздән барырга тиеш, аңа көрәш рухы хас, дибез икән, аның ачышлары — мөһер сугу түгел, иң беренче чиратта, әсәрнең табигатен, язучы шәхесен аңлау, әдәбияттагы һәм тормыштагы яңарыш белән җитәкләшеп бару икән,— бу юлда тузан утырганын көтеп тору мөмкин түгел!

Кызганыч ки, прозадагы шартлылык, поэзиядәге «интеллектуальлек» һәм башка шундый «сакаллы» мәсьәләләр буенча бәхәсләшергә без шактый нык соңладык: андый шау-шуның үзәк матбугатта басылып өлгерүе бер хәл, иң мөһиме — ул «проблемалар»ны әдәбият үзе чишә бара. Гомумән, кайбер тәнкыйтьчеләребезнең илкүләм дискуссияләр белән татарча полемикасы, сүз көрәштерүе, кайчакта кечкенә генә мәсьәләне зур каланчага күтәреп менү яисә башка әдәбият җирлегендәге бәхәсне үзебезгә өстерәп кайтулар мәгълүм мәзәкне хәтерләтә башлый.

Хәтерлисездер, рус күршесенең ел саен игене ишелеп уңуын күргәч, үз уңышсызлыкларыннан гаҗиз булып, «урысча чәчәргә» мәтәшеп караган бер агай турында ул мәзәк...

Әйе, әдәби тәнкыйтьнең мәшәкатьләре, проблемалары күп. Алар, әлбәттә, тәнкыйтьнең «ияртеп килгән балалары» түгел, алар — гомум әдәби процессның үз карынында яралган проблемалар.

Һәммәбез тоеп-аңлап яшибез: безнең әдәбиятта «Әйтелмәгән васыять»ләрдән, «Туган ягым — яшел бишек» ҫәм «Әтил суы ака торур»лардан башланган бер зур хәрәкәт бара. Безгә менә шул яңалыкның укучы күңелендә, зиһенендә дәвам итәчәк перспективасын ачасы бар.

Әлегә без бу юлны кире яктан үтә башламыйбызмы — тышкы билгеләр белән күбрәк мавыкмыйбызмы (бигрәк тә поэзия тәнкыйтендә)? Яңа, үзенчәлекле әсәрләр шуңа күрә дә каты чикләвек булып чыкмыймы, тәнкыйть игътибарыннан читтә калмыймы?

Әдәби әсәрне канунлашкан кысаларда гына тикшергәндә, әлеге сорауларга җавап табуы кыен. Тәнкыйтьнең, анализ принципларын инкяр итмәгән хәлдә, әсәрне һәм аның геройларын тулаем заман тормышы белән бәйләп, андагы катлаулы процессларның табигый чагылышы итеп каравы — нәкъ менә шул сорауларга җавап эзләү, яшәеш һәм иҗат серләренә ачкыч эзләү ул, минемчә.

1988

# Багышлау

Гомеремнең күбрәк өлешен ту-
ган туфрактан, туганнардан аерылып яшәргә туры килгәнлектән, күңелемә сагыну хисе иртәрәк оя коргандыр кебек.

Мин әле дә сагынып яшим: бала чагымның моңсу рәхәтен һәм авылымның якты күңелле кешеләрен; мәктәп елларын һәм студент хөрриятен; хезмәт һәм иҗат юлындагы кыен да, бәхетле дә мизгелләрне...…

Кемгә ничек туры киләдер, ә миңа гомер юлымда гел генә мәрхәмәтле кешеләр очрады. Кардәшләрем һәм авылдашларым, сабакташларым һәм остазларым... Яраткан кешеләрем һәм фикердәшләрем... Кайда гына эшләсәм дә, хезмәттәшләремнән цәм җитәкчеләрдән уңдым шикелле. Һәммәсенең исемнәрен атау өчен, мөгаен, шушы китап битләре җитмәс иде. Фани дөньядан кичкәннәренең урыны җәннәттә булсын, исәннәрнең изгелегенә игелекле гамәл белән җавап кайтарып өлгерергә язсын, дим.

Борынгы хатлар шәкелендә, «һичберегезне аермаенча» рәхмәт укыйм һәм бу китабымны сезгә багышлыйм.


«ҮЗ АВЫЛЫМДА ТУГАН ИКӘН...»
*Нәби Дәүли*

«БЕЗ АНЫ КӨТӘ ИДЕК...»
*Аяз Гыйләҗев*

ЙӨРӘК ҖЫЛЫСЫ БЕЛӘН
*Рафаэль Мостафин*

ТИРӘНЛЕКНЕ ТОЮ
*Нажар Нәҗми*

«ТӘРҖЕМӘ ӨЛКӘСЕНДӘ ЯҢА ИСЕМ»
*Кыям Миңлебаев*

«ЯШЬЛЕКТӘН ХАТ»
*Мансур Вәлиев*

КАЙТУ
*Равил Фәйзуллин*

«КИТАП» ЭЧЛӘРЕНДӘ КИТАП
*Гарәф Шәрәфетдинов*

ЗНАТОК КНИГИ И ДЕТСКОЙ ДУШИ

РОЖДЕННЫЙ ПОД СОЗВЕЗДИЕМ БЛИЗНЕЦОВ
*Равиль Бухараев*

МӨДӘРРИС ВӘЛИЕВ (САЛИХ МАННАПОВ)
*Рәис Даутов*

## «Үз авылымда туган икән...»

*Нәби Дәүли хатларыннан*

Мөдәррис туганым!

Хатымны ничек башларга да белмичә аптырап утырам әле. Бик тә кызыклы хәл килеп чыкты. Үзең дә беләсеңдер, минем иҗатым турында бу озын һәм зур гомердә әллә ни күп язмадылар. Минем исемем күбрәк очракта «һ. б.»лар дигән исемлектә йөрде. Мин беләм, кайберәүләр үзләре турында бик әйбәт рекламалар оештыралар, һәм бу аларда шактый уңышлы чыга. Аларның әсәрләреннән элегрәк исемнәре телгә керә. Мин мондый юл белән барырга теләмәдем, теләмим, теләмәячәкмен.

Мин үз «шеф»ымны түземле рәвештә көттем. Кайчан да булса, кемнеңдер минем иҗатыма да күзе төшәр, кем дә булса минем язмышым турында да үзенең туры сүзен әйтер әле, дидем.

Күп еллар узды. Ләкин андый «шеф» тиз генә күренмәде. Ә мин һаман көттем... озак-озак өметләнеп яшәдем.

Ә карасаң-торсаң, андый кеше минем үз авылымда туган икән. Әйтерсең лә, Язмыш, көтмә син ул Казаннан андый яхшы кешеләрне, менә мин сиңа үз туган авылыңда андый кешене дөньяга китердем, ул үсеп җитәр, Казанга барыр, сине очратыр, дип әйткән сыман. Бу — минем өчен чыннан да олы бәхет булды. Рәхмәт, туганым Мөдәррис! Ярый әле мин исән чакта очрадың... Синең «Казан утлары»нда чыккан мәкаләң мине бер дә булмаган олы шатлык белән тетрәтте. Бу — минем иҗатым турында беренче олы сүз...

Н.Дәүли
*4 июль, 1980*

## «Без аны көтә идек...»

*Беренче китапка*
*һәм Язучылар союзына*
*тәкъдим хатыннан*

Салих Маннапов (Мөдәррис Вәлиев) нәшриятка тәкъдим иткән җыентыгын «Хәтер» исемле эссе белән ача. Мәгънәле адым!..

Яшь тәнкыйтьченең бүгенге көнебезнең иң авыр һәм иң катлаулы «ХӘТЕР» мәсьәләсенә шулай тере образлар аша игътибар итүе, татар әдәбияты хәзинәсеннән иң көчле әсәрләрне төпле итеп сайлап ала белүе аның җитлеккәнлеген, җитдилеген, сугышчан характерга ия икәнлеген берсүзсез раслый.

Китапта мөхтәрәм әдипләребез Г.Бәширов, С.Хәким, Ә.Еники, М.Мәһдиев, ни өчендер коралларыбызны барлаганда еш кына хаксызга онытып җибәргәли торган якты шәхес Х.Камал, И.Юзеев, В.Нуруллин, Г.Рәхим, Р.Гатауллиннар бер сафта тезелешеп торалар... Исемнәре саналган әдипләребезнең иҗатлары бер-берсенекенә охшамаган, алар, һәммәсе дә диярлек, үзенчәлекле талант ияләре. Салих Маннапов шул үзенчәлекнең төсмерләрен берәмтекләп таба, барлый алган. Үзенчәлекне таба алу мәкаләләрнең үзгә формасын билгеләгән, аһәңен аерырга булышкан. Мәкаләләрнең чын күңелдән, чын уйлардан туганлыгы күзгә бәрелеп тора. Авторның йөгерек һәм ягымлы теле бар, кирәк икән, ул каты таләпләр дә куя белә.

Хуш... Арабызга беренче адымнарыннан ук ышаныч тудырган ныклы адымлы, туры сүзле иптәш килә. Без аны көтә идек...

Төкле аягың белән, Салих дус!.. Безнең союз чын кешеләргә дә мохтаҗ! Бик мохтаҗ!

Аяз Гыйләҗев
*17 май, 1982 ел. Казан*

## Йөрәк җылысы белән

...Китапка хөрмәт — халкыбызда буыннан-буынга яшәп килгән искиткеч матур йола. Китап кешене үзенең зурлыгына, көченә, матурлыгына ышандырып килгән, түбәнлектән, рәхимсезлектән, ваклыктан араларга ярдәм иткән.

Әмма соңгы елларда китап җыю, китап белән мавыгу үзенә күрә бер модага, «йогышлы чиргә» әверелеп бармый микән? Социологларның борчылып язуларына караганда, соңгы елларда китап уку әкренләп кими бара, уку культурасы түбәнәя.

Нәрсә соң ул уку культурасы?

Ул — китапның тәмен табып, мәгънәсен аңлап, әсәр нигезендә яткан гармонияне тоеп уку. Ул — китап турында уйлана, матур әдәбият аша тормышның тирән агымнарын күрә, сизә, аңлый белү.

Моңа ничек ирешергә соң?

Төп юлларның берсе — тәнкыйть сүзенә игътибарлы булу, үз тәэсирләреңне кеше фикерләре белән тәңгәл куеп, чагыштырып карау. Шуңа күрә дә мин яшь укучыларның тәнкыйтьче Салих Маннаповның беренче китабын укып чыгуын теләр идем.

«Сезгә ышанам» китабының иң көчле ягы — үзенчә фикер йөртеп, әдәбият турындагы үз карашларын ачык итеп белдерүдә. Кайвакыт яшь тәнкыйтьченең фикерләре моңарчы әйтелгән, инде күнегелгән карашларга бик туры килеп тә бетми. Ләкин авторны моның өчен гаепләргә ашыкмыйк. «Кайчагында үзгәрәк фикерлибез, үзгәрәк бәя бирәбез икән,— дип яза ул үзенең китабында,— сезгә каршы килү булып аңлашылмасын, өлкәннәр! Ул — яшьлектән, тормыш асылын төшенеп бетмәүдән дә түгелдер. Ул — сезнең фикер-хөкем йөртүнең дәвамы, яңа буыныдыр, мөгаен».

Бик дөрес һәм саф күңелдән, эчкерсез итеп әйтелгән!

Китапның тагын бер уңышлы ягы — аның хисле булуында, оста, үтемле итеп язылуында. Салих Маннапов беренче мәкаләләреннән үк укыла торган тәнкыйть язарга омтылды (кызганыч, әмма тәнкыйтьнең укылмый торганы да була шул!), аның стиле җыйнак, теле гади, аңлаешлы. Ул укучы белән ихлас сөйләшү формасын шактый урынлы куллана. Кайвакыт әдәби тәнкыйть мәкаләсен лирик чигенешләр яисә публицистик рухта язылган өзекләр белән аралаштырып бара.

Бер генә мисал. «Дәвам» исемле хезмәтендә тәнкыйтьче сугыш кырында яраланып, телдән калган, хәтерен югалткан солдат турында сөйли. Аның исемен, кайдан икәнлеген беркем дә белми, шуңа күрә аны госпитальдә Солдат дип кенә йөртәләр. Күп еллар үтә. Врачлар тырышлыгы бушка китми: көннәрнең берендә Солдат аңына килә, хәтере кайта, теле ачыла. Әнисе янына кайткан Солдатны каршы алырга бөтен авыл чыга. Һәм халык күңелендәге сугыш ярасы тагын бер кат яңара...

— Әнә шулай,— дип дәвам итә тәнкыйтьче,— сугыш авазы тыныч тормышыбызга, тыныч елларда иҗат ителгән әсәрләребезгә килеп керә.

Мондый чагыштырулар тәнкыйтьче фикерен тагын да үткенәйтә, аны йөрәк җылысы белән җылыта. Әйтергә кирәк, «Дәвам» — җыентыкка кергән мәкаләләрдән иң көчлесе, иң тетрәндергечедер. Х.Камалов, М.Мәһдиев, М.Юныс, Г.Әпсәләмов, М.Әмир, Н.Дәүли, И.Юзеев, Ә.Гаффар, Р.Вәлиев һ. б. язучыларның әсәрләрен анализлау нигезендә тәнкыйтьче бик тирән, уйландыра торган нәтиҗәләр ясый. Үткән сугыш турындагы әдәбият күз алдыбызга бик күп фаҗигаләрдән төзелгән дисбе булып килеп баса. Автор бу китапларның укучы күңелендә авырту-әрнү тойгысын тудыруын яшерми. «Әмма авырту,— дип дәвам итә ул,— кеше тәненең сәламәт тойгысы. Шул тойгыны югалтсак, без зарарланган төшебезне табып дәвалый алмас идек. Сугыш турындагы әдәбият та, тәнкыйтьче фикере буенча, безнең авырту тойгыбыз сыман кирәк. Ул безнең кешелекле асылыбызны яклап, кара көчләргә каршы яуга күтәрә». Илебездә Бөек Җиңүнең кырык еллыгын билгеләп үткән көннәрдә бу фикерләр аеруча урынлы, актуаль булып яңгырыйлар.

В.Нуруллин, А.Гыйләҗев, И.Юзеев, Г.Рәхим, Р.Гатауллин, Р.Миңнуллин иҗатларына багышланган мәкаләләрдә тәнкыйтьче, аларның әсәрләрен анализлау белән генә чикләнмичә, һәрберсенең шәхес буларак зурлыгын, җирлеген күрсәтергә, күңел биографиясен ачарга омтыла һәм күпчелек очракта үз теләгенә ирешә дә. Ул тыштан гади генә булып күренгән әдәби күренешләрнең катлаулы табигатен тоярга өйрәтә һәм беренче карашка артык катлаулы булган күренешләрнең гади хакыйкатен ача. Шунысын да әйтергә кирәк: автор, язучыга яки укучыга ошыйм әле дип, яраклашырга тырышмый. Исеме үк күрсәткәнчә, китап әдәбиятның зурлыгына, аның укучысына зур ышаныч белән язылган.

Салих Маннаповның тәнкыйтьче буларак тагын бер көчле ягы: ул татар әдәбиятын илебезнең күпмилләтле совет әдәбиятының казанышлары белән чагыштырып, дөнья әдәбиятының магистраль юлы белән тоташтырып карый.

Тәнкыйтьче бу китабы белән әдәбиятны тирәнрәк аңларга өйрәтә, китапка карата ихтирам хисе тәрбияли. Бу исә — бик кирәкле, изге эш. Чөнки, авторның үз сүзләре белән әйткәндә, дөньяда иң бәхетсез җан иясе — үз халкының культура хәзинәсенә тамыры белән ялгана алмаган кеше.

Рафаэль Мостафин
*(«Татарстан яшьләре»,*
*1985 ел, 25 май)*

## Тирәнлекне тою

Иҗатта тирәнлекне тою да җиңел түгел, һәм ул сыйфат һәркемгә тәтемәгән. Тоя белү —талант, бәхет; тоя белмәү — бәла, бәхетсезлек.

Салих Маннапов — бәхетле тәнкыйтьче. Татарстан китап нәшриятында чыккан китабының исеме генә дә автор уй-фикерләренең шигъри булачагын әйтеп тора: «Тамыр тирәнлеген яфрак тоя». Үзе үк шигъри юлга өнди, һәм, сизмәстән, кафияләп дәвам итәсең: «Шуңа имән яфракларын соңлап коя».

Китапның тәүге юлына игътибар итик: «Яңа яуган кардан алмагөл исе килә». Нинди шигъри киная соң бу? Бу сорауга мәкаләгә эпиграф итеп алынган «әнием сүзе» җавап бирә: «Балачакка кайту кешенең гомерен озайта». Димәк, кеше бөтен гомере буе бала чагыннан, яшьлек елларыннан аерыла алмый — гомер карлары яуганда да чәчәк исе аңкый.

Өлкән язучыларның автобиографик әсәрләреннән дә (аларны С.Маннапов Әмирхан ага Еникинең «Соңгы китап» исеме берләштерә дип әйтү ягында), Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә»сеннән дә, Аяз Гыйләҗевның «Мәхәббәт һәм нәфрәт» һәм «Язгы кәрваннар»ыннан да шушы алмагөл исен тоя, хәтта «балалар өчен» дип мөһер сукмаган китапларга да (Н.Фәттах — «Сызгыра торган уклар») «бала йөгереп керә», ди автор. Бу күзәтүләр, ничектер, нечкә күңел җепләре аша бер-берсенә килеп бәйләнә, һәм мәкалә — мәкалә генә булып калмый, ул лирика белән сугарылган бер хикәяне хәтерләтә, дияр идем.

«Тәллитут» дигән сәер исемле мәкалә дә язылышы белән шундый ук тәэсир калдыра, ул да балачакка һәм туган туфракка бәйле. «Туган туфракка сабый чакта җибәргән тамырлар гына кешене ватанлы итә, хәтерле итә — бәхетле итә». Табигать сурәтләренең мифлардан, җыр-бәетләрдән тәрәзә йөзлекләренә, кулъяулык читләренә «килеп кунганын» күрә белү өчен, йә булмаса киселгән агач төбендәге сырларны патефон тәлинкәсенә охшатып, анда нинди көй язылырга мөмкинлеге хакында уйланыр өчен, Ходай тарафыннан бирелгән үтә сизгер күңел кирәктер.

С.Маннапов үзенең фикер йөртүләрендә татар язучыларының әсәрләре белән чикләнми, аның әдәбият мәйданы киң, аңа рус язучысы Виктор Астафьев та, кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматов та, башкорт шагыйре Мостай Кәрим дә рухи азык бирә, әмма «шүрәле каргаган» киләчәксез авыллар, киләчәксез телләр хакында

пошынганда, исемсез елгалар хакында уйланганда үз җиренә кайта, хәтта күңеленнән Болгар илләренә сәяхәт кыла.

Китапта язучыларның иҗади портретларына байтак урын бирелгән. С.Маннапов һәр язучының, шәхеснең үзенә генә хас сыйфатын, характерын, иҗади үзенчәлеген оста тотып ала. Һәр язучыны, шагыйрьне иҗатлары белән бер-берсен бутарга мөмкин булмаган шикелле, тасвирлау чараларын да бутарга мөмкин түгел. Џәрберсенә берәр шигъри образ, штрих таба.

Мәсәлән, мин Хәсән ага Туфанның иҗатын һәм тормышын энәсеннән җебенә кадәр беләмдер, дип уйлый идем. Чыннан да, аның шигырьләре юлы юлга укылган, чирек гасыр чамасы аралашып яшәлде, бер бүлмәдә төннәр буе йокламый сөйләшеп чыккан чаклар булды; аның, С. Маннапов язганча, киеренке кичерешләр шагыйре, җил-давыллар очрашудан туган нык җегәрле уйлар шагыйре икәнен дә белдем төсле, әмма Туфан аганың «яшәү рәвеше — чын мәгънәсендә юл халәтендә» икәнлеген үзең өчен ачыклыйсың, һәм бөек шагыйрьнең «зур дөньясы, эчкәрәк, тирәнрәк кергән саен, шулкадәр иркен, чиксез, мәңгелек булып тоела башлый». Хәсән Туфанның, әйе, Җирнең, халыкның язмышы, киләчәге, аның мәңгелеге өчен янып яшәгәнлеге бөтен сыны белән күз алдына баса.

Туфан хакындагы мәкаләне автор — «Туфан тәрәзәсе», ә Сибгат Хәким хакындагысын «Язылмый калган җыр сагышы» дип атый. Алар янәшә тора. Әдәбиятта да, китапта да.

Җыентыкта язучыларның иҗади портретлары сериясе аерым урын алып тора, хәтта аерым-аерым сәхифәләр дә бар.

«Авылда комбайнчы булып эшләүче абзам бар минем. Унсигез яшеннән сугышка алынган. Гомере буе баш күтәрми эшләгән. Бик йомшак күңелле, сабыр-ихлас кеше. Зурдан кубасы берәр эш килеп чыкса, аның белән киңәш-уңаш итәргә тырышам. Ашыкмый гына тыңлар, суына төшүеңне көтәр, шуннан соң гына җай белән үз киңәшен бирер. Кем әйтмешли, беркайчан да яшелли урмас». Шулай башлана Хисам Камалов хакындагы мәкалә. Шунда ук язучы барлык холкы, яшәеше белән күз алдына баса, соңыннан инде детальләштерәсе генә кала.

«Уяу янартау шикелле кайнап-күкрәп торучы әдип...», «...ул, яшенне үзенә тарткан имән кебек...», «язучының йөзендәге җыерчыклар, чәнечкеле тимерчыбык сыман, тирән уела төшә, ул бөтен гәүдәсе белән, кемнедер әче җилдән ышыкларга иткәндәй, алга таба талпынып куя» — бу — Нәби Дәүли.

Сүз кадерен җаны-тәне белән тойган Габдулла Шәрәфи; «...яңа мәйданнар яуларга омтылучы кайбер кысыр чәчкәләрнең тамырын каерып ача, аларны көйдергеч кояш астына тартып чыгара» алган, «яңалыкка сусау, хезмәткә һәм яшәүгә сусау» кичергән Рахмай Хисмәтуллин; прозада, драматургиядә талантлы әсәрләре белән танылган, әмма оригиналь әкиятче дә булуы сагындырган Әхәт Гаффар портретлары укучының күңеленә сеңеп кала.

Әйе, күңелгә сеңеп калган фикерләр, күз алдына баскан сурәтләүләр күп. Алда әйтеп киткәнемчә, аерым сәхифәләр дә бар, алар Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Фәннур Сафин, Зиннур Мансуров иҗатына багышланган.

Китапта исемнәр байтак... Шулай да татар шигъриятенең кайбер күренекле һәм хөрмәтле исемнәре китапта чагылмавы сизелә, әмма бу хәлне тәнкыйтьченең күңел юнәлешенә туры килмәү белән дә аңлатырга мөмкиндер.

Әйе, исемнәр күп. Алар арасында шәхес булып җиткәннәре, киләчәктә шәхес булырдайлары бар. С.Маннапов аларның барысына игътибарлы, шулар арасында кайный, һәр сүзендә аларга булган мәхәббәте, кайгыртуы күренеп тора. Шундый якты йөзле исемнәр бар чакта «исемсез» китап язу мөмкин түгелдер. Әмма С.Маннапов та «тәнкыйтьченең эчендә тагы бер тәнкыйтьче утырганын» таный. Шуның өчендерме, «укыйсың — күңелне кузгалтмый» торган әсәрләр турында сүз барганда, «ни өчен уртакулның базары югары?», «тәрәзәсез-ишексез өй ... ул нәрсә?» дигән бик мөһим һәм кирәкле сорауларына җавап биргәндә, теге яки бу язучының, шагыйрьнең исемнәрен күрмибез. Бу, бәлки, китапның табигатенә туры килмидер... Ә шулай да җыентыктагы «юк! җиңел укылмаска тиеш шигырь!» дигән эндәшле җөмләгә үз карашымны әйтәсе килә: мин гомерем буена җиңел шигырьләрне авыр укыдым, хәтта укый алмый читкә куйган чакларым булды, ә «авыр» дигән шигырьләр һәрвакыт җиңел укылдылар.

Бу китапны да мин җиңел укып чыктым. Һәйбәт шигырь китабын укыган кебек укыдым. Шагыйрьлекне тумыштан, диләр, әмма Салих Маннапов шикелле тәнкыйтьчеләр дә тумыштандыр, чөнки аның һәр язмасында шигърият барлыгын тоймау мөмкин түгел.

Нажар Нәҗми
РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты
*(«Кызыл таң», 1988 ел, 15 декабрь)*

## «Тәрҗемә өлкәсендә яңа исем»

...Менә без әдәби тәрҗемә өлкәсендә яңа исемне күрәбез, ул — Мөдәррис Вәлиев.

...Һәр тәрҗемә әсәренең кыймммәте әлеге хезмәтне башкарып чыккан тәрҗемәчедән килә. Бу очракта бер үк авторның ике әсәре дә Мөдәррис Вәлиев тәрҗемәсендә тәкъдим ителә. Әсәрләрне янәшә куеп караганда, авторның иҗади үсеше белән беррәттән тәрҗемәченең дә казанышлары күзгә ташлана. Хәзер инде ул кыюрак эш итә, әсәрнең нәкъ татарча яңгыравына ирешергә тырыша һәм бу юнәлештә нык эзләнә, үзенең көчен дә, вакытын да кызганмый. Шунсыз әдәби табыш дигән иҗади хәзинә дә сине читләтеп үтә. Ә биредә хәтсез күп андый табышлар.

Әйтик, [геройларның] кыяфәте һәм үз-үзен тотышы әледән-әле үзгәрүен, лексиконы хәйран чуар булуын тәрҗемәче игътибар үзәгендә тота, кирәкле сүзләрне сайлый белүдә зирәклек-тапкырлык күрсәтә. [Әсәрдәге аерым] вакыйгалар гаять зур осталык белән тәрҗемә ителгән. Хәер, тәрҗемәченең уңышы-табышы дип бәяләрлек тәгъбирләрне бу романның һәр битендә очратып сөенергә мөмкин...

Бандитларның лексиконын, үзара сөйләшүен безнең телгә тәрҗемә итү җиңел булмагандыр, шактый озак уйлану-эзләнүне таләп иткәндер. [Мисаллар китерелә.]

Шушындый образлы урыннарга тап булган саен, Мөдәррис Вәлиев бит бу романны тәрҗемә итмәгән, саф татарча яңадан язып чыккан, дигән фикерең көчәя-ныгый бара. Шуннан инде, безнең сафка — әдәби тәрҗемә өлкәсендә эшләүчеләр рәтенә — көчле бер әдип килә, дип сөенәсең...

Кыям Миңлебаев
*(«Социалистик Татарстан»,*
*1991 ел, 13 сентябрь)*

## «Яшьлектән хат»

...Урманнарда әле билдән кар була, ләкин, көннәр әз генә сыну белән, яшь талларда песиләр күренә башлый. Алар, синең балачагыңны, туган ягыңны, алдагы ямьле язларны да искә төшереп, табигатьнең һәм тормышның салкын көннәрендә туңган җаннарны йомшак, җылы канаты белән сыйпап алгандай итә.

Тал песиләре...

Язучы Салих Маннаповның моннан нәкъ ун ел элек басылып чыккан «Тамыр тирәнлеген яфрак тоя» исемле китабын укыган чагында, безнең һәммәбезгә дә бик таныш һәм кадерле булган әнә шул тал песиләренең Әлки ягында «тәллитут» дип йөртелүен белгәч, бу сүзгә ихластан сокланган идем. Шушы табигать могҗиза-сының бер генә сүздән ясалган, матур җисеменә бигрәк тә тәңгәл килеп торган үз исеме бар икән ләбаса!

Шул ук әдипнең (хәзер инде Мөдәррис Вәлиев булып) Татарстан китап нәшриятында чыккан «Яшьлектән хат» исемле шигырьләр китабын кулга алгач та, күңелемә әлеге сокландыргыч яңгырашлы «тәллитут» сүзе килде, ә инде китаптагы шигырьләрне укып, алар тудырган хиссият һәм кичерешләр дөньясында яшәп алганнан соң, бу тылсымлы сүз яшьлек һәм туган як турындагы яңа бер симфониянең гүзәл яңгырашлы исеме булып йөрәк түренә үк кереп урнашты.

...Йолдызлар микән ул шулай,
Џәммә өенә ут алып,
Авылым көтә сыман!
.................................................................
Нинди кырыслану булсын! —
Әнкәй керфекләре төсле
Бәс сырган ылыслары!..

Шигырьдәге һәрбер ым, һәр билге күңелдәге туган якны сагыну, җирсү моңын тудыруга булыша. Шагыйрь «йолдызлар» дип яза, безнең күңелгә яктылык һәм ераклык мәгънәсе килеп сарыла. Чын сагыну хасияте шундый була ич!

Ә инде «Ут» дигән шигырьдә шагыйрь үзенең төш күрүен әйтеп, анда әнисенең янган өй эчендә түшәмне тотып торуын шундый эпик көч белән сурәтли ки, укучы күз алдына хәтта рәссамнар да көнләшерлек дәһшәтле һәм гаять тирән фикерле шигъри картина килеп баса. «Ул ялкында без өстәгән күпме рәнҗүләр бар, бардыр үпкәләр...»— дигән фикер исә әлеге драматик күренешне кеше йөрәгенә тагын да якынрак, газизрәк итә.

Шушындый рухтагы шигырьләр әниләребезнең җылы, лирик сурәтләрен дә күз алдына бастыра.

Күрше апа әйтеп хат яздыра,
Бер ашыгып тезә... бер тына.
«Уйлап йөргән сүзем күп иде дә
Хат яздырган чакта онытыла!»
.......................................................................

Буран, арып, бусагага ята.
Утлы күмер мичтә аллана...
Бөтен дөнья тынып тора, ахры,
Хат яздырган чакта аналар...

...Бүген безнең татар шигъриятендә яңадан илленче еллардагы кебек күпсүзлелек, мәгънәви көпшәклек шактый еш очрый башлады. Күңелне борчыган әнә шундый тенденция янәшәсенә куеп караганда, бу китаптагы аз сүзле, әмма күп һәм тирән мәгънәле чын шигъри әсәрләр бигрәк тә яратып кабул ителә. Музыка дөньясы белән чагыштырып карасак, андагы симфонияләрдә очрый торган полифония, күпмәгънәлелек китапның «Гөнаһлы уй» дип исемләнгән икенче бүлегендә бигрәк тә мул.

Гүя кемдер, изге тәсбих итеп,
Сиңа язган хатларымны тезгән...—
Тезелешеп очкан кыр казлары!
Мин буш оя булып карыйм сезгә.

Безгә таныш бер күренештән нинди яңа мәгънә чыгарды шагыйрь йөрәге! Кыр казларына мөнәсәбәттә бу «буш оя» дигән сүз никадәр сагыну, көтү, ымсыну кичерешләре хасил итә. Мөдәррис Вәлиевтә шундый поэтик рәсемнәр ясый белү сәләте көчле. «Гашыйклар төненә мине бер йолдыз итеп яктың»,— ди ул икенче бер шигырендә. Сөю хәләтен бик тә үзенчә әйтү бу!

Йолдыз дигәннән, безнең шигърияттә «йолдыз чире» дә күренгәләп алды бит әле. Җирдән һәм кешедән артык нык ераклашкан, чынбарлыктагы кешенең күңел яшәешенә тәңгәл килмәгән «тамырсыз» шигырьләр турында шулай язылды. Ә минем кулдагы бу китап исә, киресенчә, күк җисемнәреннән кеше йөрәгенә, кеше тормышына якынайта.

М.Вәлиев шигырьләрендә җирдәге табигать күренешләре дә бары тик кеше җаны турында гына сөйли. «...Синең сүзләр — язгы ташу иде. И орыштың мине, орыштың!» — дип башланган әсәр, мәсәлән, үзенең иң кайнар ноктасын таба:

Инде,
ярга ятып калган ләмгә бата-чума,—
әллә китеп бару,
әллә кайтып бару...

Күрәсезме, никадәр экспрессивлык, күп мәгънә һәм шигъри драматизм! Гадәттә, Балтыйк буе халыкларының нәфис фильмнарын караганда, хәтергә әнә шундый тирән фикерле поэтик күренешләр сеңеп кала. Биредә дә шулай. Китап белән очрашу бәхетен кичерәчәк укучыга мин тагын «Юлымны бүлде» дигән шигырьне дә бик тәмләп, ләззәтләнеп укырга киңәш итәр идем. Тәүге мәхәббәт хисеннән башланган тылсымлы һәм гыйбрәтле бер сәхифә сыман килеп чыккан ул.

...Мөдәррис әфәнде моннан алдарак чыккан бер китабындагы «Сүз кадере» дигән әдәби тәнкыйть әсәрендә арабыздан иртәрәк киткән бик әйбәт прозаигыбыз Габдулла Шәрәфи иҗаты турында тәфсилле, җитди әңгәмә алып бара, бу язучының иң зур уңышларыннан берсе итеп, әсәрләрендә сүзне гаять урынлы, төгәл куллануын билгеләп үтә. Ә инде хәзер кулыбыздагы яңа китапта шагыйрь Мөдәррис Вәлиев үзе дә иҗатта сүз кадерен белүенә бик матур мисал күрсәтә. Андагы әсәрләрнең барысы да диярлек күләм ягыннан кыска, укучы күңеленә җиткерелергә теләгән хис-кичереш төгәл шигъри сүзләр һәм поэтик ассоциацияләр ярдәмендә тулы килеш ирештерелә. Шигырьләрнең күбесе акварель белән ясалган романтик рухлы, якты рәсемнәр булып күз алдына килә, безгә шигъри энергияне биреп тора.

Китабын ачып җибәргәндә, шагыйрь, бик тә тыйнак төстә: «Кош теледәй генә бу китапта «шагыйрьлеккә» дәгъва һәм, иң мөһиме, андый ихтыяҗ юк. Бар булганы — бары тик күңел хәләте, җан хәрәкәте генә»,— дип яза. Ләкин авторның рухи яшәеше бай булгач, хис-кичерешләре тирәннән аккач, безнең дә иң кадерле, мөкатдәс хисләребезне чагылдыра. Шуңа күрә биредәге шигырьләр укучы тарафыннан үз итеп кабул ителә.

Китапның югары зәвык белән бизәлүен һәм яхшы техник эшләнешен дә исәпкә алсак, аның, чыннан да, ак яулык сыман куен кесәсендә, йөрәк янында гына йөртелердәй бүләк булуына ышанасың...

Яшьлек һәм туган як хисләрен тирәннән кузгатучы матур тәллитут кебек булып чыккан бу китапның шифасы, назы сезнең җаннарга да барып ирешсен иде, хөрмәтле укучы!

Мансур Вәли-Барҗылы
*(«Ватаным Татарстан»,*
*1998 ел, 14 август)*

Кайту

Хәзер күпләр китаптан бизде, дибез. Бу сүзләрдә хаклык бар. Аның каравы — парадокс — китаплар да бик күп чыга бит. Элегрәк, ягъни 15—20 еллар элек, мәгънәгә ия һәм дә кирәк китапны кулга төшергән кеше, төлке тоткан кебек, бәхетле, бүтәннәр алдында абруйлы, хәтта бай кеше исәпләнә иде. Ә хәзер? Урам-чатлар, киоск-киштәләр китаплар белән тулы. Дөресрәге, төрле төстәге, төрле форматтагы, төрле бизәктәге полиграфик товар белән тулы. Ә асылда чын китаплар, классик мәгънәдә без аңлаган яхшы китаплар сирәк һәм бик сирәк.

Әле күптән түгел — быелгы җәйнең эссе июнь көннәрендә кулыма бер яңа китап керде. Карап торырга матур, затлы китап. Күзне дә, кулны да иркәләрлек. Тышында авторның исеме — Мөдәррис  Вәлиев, титул битендә китапның исеме — «Яшьлектән хат». Үтә бер кызыксыну белән, үзгә бер хәләттә, бер тында укып чыктым мин бу китапны. Кичерешләр дә үзгә иде: яшьлегем искә төште, моңланылды да, эссе чүлдән талгын җилле яшел оазиска кергәндәй дә хис иттем, нечкә тоемга көйләнгән аерым строфалар сокландырды да, сискәндерде дә... Нәрсәдер яңага сусау булган, ахры (гәрчә миңа эшем буенча көнгә ким дигәндә 150—200 бит язма укырга туры килә). Чын мәгънәсендәге профессиональ осталыкка, төгәллеккә сусау. Сүздә чама хисен белгәннәргә сусау. Туган җир, Туган як турында, Ана һәм Яр турында төчеләнмичә, тыйнак итеп, серле дә, шул ук вакытта әдәпле итеп әйтә белгәннәргә сусау һәм дә, ахыр чиктә (без һәрберебез күпмедер дәрәҗәдә сабый бит әле!), эчтәлегенә ярашлы матур бизәкле «тәти» китапларга сусау... Шулай тәэсирләнеп укуның тагын бер сәбәбе бар. Заманында мин бу егетнең (хәзер инде дөньялыкта ат уйнаткан ир-егетнең) беренче шигырьләренә үземчә фатиха биреп, республика газетасында чыгарышкан идем. Бу — утыз еллап элек булган хәл. Ул вакытта аның исем-фамилиясе Салих Маннапов иде, уналтысы яңа тулган иде. Менә хәзер ул 45 яшьлек Мөдәррис Вәлиев булып беренче шигырь китабын чыгарган. «Татарстан яшьләре»ндә (30 октябрь, 1969) басылып чыккан әлеге фатиха-кереш сүздән берничә абзац китереп узасым килә.

«Таныш булыгыз: Салих Маннапов» дип атала ул бәләкәй мәкалә.

«Әдәбиятны бик яратып, аның сер-тылсымнарына төшенергә тырышып, үзләре дә каләмнәрен сынап караган укучылар арасында иң активлардан берсе — Салих Маннапов. Ул Әлки районы Татар Мулласы авылында яши. Алпар урта мәктәбенең 9 классында укый. «Коммунизм юлы» газетасы каршындагы әдәбият-иҗат түгәрәгенә йөри. Инде менә өч-дүрт ел буе аның матур гына шигырьләре район һәм республика балалар газетасы битләрендә басылып килә. Шигырьләрен игътибар белән күзәтеп, җентекләп укып барам. Миңа калса, яшьли ятим калып та, мәрхәмәтле, игелекле кешеләр куенында үксезлек күрмичә, тулы хокуклы гражданин булып чыныгып үсеп килүче, тырыш укучы, җәмәгать эшләренә актив катнашучы Салихның күңел түрендә шигъри талант чаткылары, кешеләргә әйтер сүзе, табигать күренешләренә, кешеләрнең яшәешләренә, гомумән, дөнья хәлләренә карата үзгә бер поэтик карашы бар.

Әлбәттә, Салихның шигырьләрендә әле төгәлсезлекләр, инде күпләр тарафыннан әйтелгән, кабатланган образлар, тиешле поэтик югарылыкка күтәрелә алмаган юллар, тәгъбирләр бар. Кайчак шигъри бизәкләр, образлар стихиясе аны төп фикер агышы магистраленнән читкә алып-алып киткәли: тәҗрибәсе җитенкерәмәгән яшь автор тарантас башындагы, атын тыя алмаган малайны хәтерләтеп куя... Сүзнең бөтен мәгънәви төсмерләрен, нечкәлекләрен сизеп, тоеп, аңлап, аның кадерен белергә өйрәнү, әйтереңне төгәл, кыска, шигъри итеп сөйли белү, ахыр чиктә, чын мәгънәсендәге осталык — вакыт, тәҗрибә һәм тырышлык белән килә торган сыйфатлар. Әгәр Салих, әдәбият эшенә ихлас күңел куеп, алга табан шуңа бар сәләтен һәм тырышлыгын салырга теләсә, аңа шатлык һәм газаплар белән тулы өйрәнү мәктәбен узарга туры киләчәк.

Тагын шуны әйтәсе килә: заманыбыз — акыл, гыйлем заманы, укымышлылар заманы. Үз эшләренең осталары, заманга иш һөнәр ияләре, белгечләр, нинди генә өлкәдә эшләмәсеннәр, аларның һәркайсы әдәбият-сәнгать турында шактый бай мәгълүматка ия. Димәк, алар яратып кабул итәрлек, уйландырырлык, күңелләренә хуш килеп, эстетик ләззәт китерерлек әсәрләр, бу очракта, шигырьләр язу — уен эш түгел. Димәк, бүгенге көн кешеләрен, үз замандашларыңны дулкынландырырлык итеп язу өчен, безгә тикле яшәгән бабаларыбыз калдырган хәзинә мирасны да, бүтән халыклар әдәбиятлары казанышларын да тирәнтен үзләштерергә, бүгенге талант ияләренең иҗатларын да яхшы белергә тиеш булабыз. Кыскасы, армый-талмый өйрәнергә, жаның-тәнең белән тырышырга, бар күңел байлыгын салып иҗат итәргә! Яшең уналтыда чакта, күңелең тулы дәрт-ашкыну булганда, һәммә авырлык чигенә әле! Яшьлек җиңеп чыкмаслык нәрсә бармыни ул дөньяда!»

Ярый, заманына хас (яшь чакта безне дә тәүфыйклы булырга бик шәп өйрәтәләр иде!) дидактик оеткы күбрәк булса да, яшь шагыйрьгә бу үгет-нәсыйхәтле язма беркадәр тәэсир иткәндер, бәлки. Ә хәзер шагыйрьнең үз китабына кереш сүз итеп язганнарын укып карыйк.

«Исәнмесез, хөрмәтле Укучы! Бу «хат»ны (ягъни китапны) язучы кем икән дип аптырап калмагыз. Мөдәррис Вәлиев — бик күпләр шикелле, гап-гади сүзләрнең шигъри юлларга әйләнеп китү хикмәтен бала чагында ук кичергән затлардан. Бер каләмдәшебез әйтмешли, әллә инде «Игезәкләр» йолдызлыгы астында туу аркасындамы, бишектә чакта ук «чып-чын» тәхәллүсе (псевдонимы), ягъни икенче исеме булган аның. Чынында, һич тә уйлап чыгарылмаган, кырыс дөнья бабай кушкан яңа исем-фамилия, тора-бара, үзеннән-үзе «Салих Маннапов» дигән әдәби кушамат булып китә. Ихтимал, ике исем кушып, бу малайга язмыш ике мәйданда берьюлы иҗтиһад итү мөмкинлеге биргән, бер үк вакытта, ким дигәндә икеләтә көч-хезмәт түгеп генә ике исемеңне дә аклый алу шартын куйгандыр...

Шигырьләре белән «күзгә чалына» башлаган Салихны төрле хәл-әхвәлләр әдәби тәнкыйть дигән өлкәгә алып кереп китә. Китаплары чыга, җәмәгатьчелектә танылa. Аннары инде гомумән дә аңа, Мөдәррис Вәлиев дигән рәсми исеме белән, нәшрият хезмәтен җигелеп тартыр чак килә. Мөгаен, нәширлек — шулай ук иҗат эшедер, һәм аны һәркем табигать биргән сәләтенә карап башкарадыр. «Күкрәгендә шигырь уты сау» булса да, беренче мәхәббәт шикелле, ул инде эчкәрәк йомыла, чит-ят, салкын-саксыз кулга калдырасы да килми башлый икән. Нигездә моннан күпмедер вакыт элек язылган «парчалар»ның бер өлешен болай туплап чыгару — «яшьлектән килгән хатлар»га кеше гомеренең кадерле һәм мәгънәле бер сәхифәсе итеп карау белән бәйле. Шуңа күрә әлеге китапның авторы, бәлки, инде «җитмешенче-сиксәненче елларда ук калган» Салих Маннапов түгел, ә аның бүгенге «варисы» — Мөдәррис Вәлиев булырга тиештер, дип уйланылды. Сез күрерсез: кош теледәй генә бу китапта «шагыйрьлек»кә дәгъва да һәм, иң мөһиме, андый ихтыяҗ да юк (дөресен әйтим, бу җөмлә мине сискәндереп һәм сагайтып та куйды.— Р.Ф.). Бар-булганы — бары тик күңел хәләте, җан хәрәкәте генә».

Документ рәвешендә китерелгән бу ике сөземтә-цитата (ретростатик язма чыкты бугай бу) күп нәрсәгә ачыклык кертә, байтак кирәк мәгълүмат бирә шикелле. Аларда — үсеш кардиограммасы, нәтиҗәсе матур булган метаморфоза.

Кыскасы, инангансыздыр, булдыклы, шәп егет икән бу Мөдәррис Вәлиев дигәннәре! Һәрхәлдә, «Казан утлары» күзлегеннән караганда тәгаен шулай. Ун ел редакциядә эшләп, журналыбызның иҗтимагый абруе өчен көчен кызганмаган зат. Аның бүген дә журналдан аерылганы юк. Инде унбиш еллап — редколлегия әгъзасы, даими авторыбыз. Дөрес, күбрәк ул әдәби тәнкыйтьче һәм җитәкче нәшир булып катнаша. Ә шагыйрь буларак иҗатын башлаган әдип «Казан утлары»нда нибары бер тапкыр — моннан 16 ел элек басылган икән. Журналыбызда шигырьләренең икенче тапкыр басылуы. Моны кайту димичә нәрсә дисең инде.

Равил Фәйзуллин
*(«Казан утлары»,*
*1998 ел, 8 нче сан)*

## «Китап» эчләрендә Китап

Бик тә үзенчәлекле китап бу! *(Китап: Татарстанда нәшрият эше: соңгы ун елдагы нәтиҗәләр һәм проблемалар. Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2001 ел).* Ул зур дәверләрне һәм катлаулы язмышларны колачлаган роман да, мавыктыргыч сюжетка корылган маҗаралы повесть яки төн йокыларыннан яздырган мәхәббәт тарихы да, шигъри моңнары ашып-ташып торган поэма да түгел. Бу китапның төп каһарманы — китап үзе, ягъни биредә сүз барлык роман-повестьларны, шигырь-поэмаларны, барча төр язма тупланмаларны үз эченә сыйдыра һәм аларны мәңге яшәтә ала торган кодрәт иясе — китап, Милли китап турында бара. Нәкъ менә Татар китабы тарихында, аның язмышында без шул дәвер һәм язмышлар чагылышын күрәбез, аның үз «башыннан кичергән» хәл-әхвәлләрне күңелдә кабат яңартабыз...

Кем идек, кем булдык димичә ни дисең, бүгенге заманның милли китабына сокланмыйча мөмкинме?! Аерма, кем әйтмешли, җир белән күк кадәрле! Тарих мәйданына яңа буын нәширләр килә. Милли китапның, ниһаять, чын сәнгать әсәре булып дөньяга чыга башлавына күңел сөенеп туя алмый. Дөрес, бүгенге нәширләр өчен дә хәл итәсе мәсьәлә-проблемалар әле җитәрлек. Моны без «Китап»ны укып чыккач күз алдына тулырак китерә алабыз.

Милли китап язмышы турындагы бу китапны каләмдәшебез, фикердәшебез Мөдәррис Вәлиев нәшриятка килгән беренче көненнән үк яза башлаган икән. Әүвәл — Татарстан китап нәшриятының баш редакторы, ан-

нары — «Мәгариф» нәшриятының директоры сыйфатында төрле дәрәҗәдәге киңәшмәләрдә чыгыш ясарга кирәк булганда, газета-журнал, радио-телевидение хезмәткәрләре интервью бирүен сорап мөрәҗәгать иткәндә, Дәүләт Советы һәм Хөкүмәт залларында да аңа милли китап язмышын кайгыртып уй-фикерләрен әйтергә туры килгән. Ниһаять, җәмәгатьчелек игътибарын милли китап һәм дәреслек проблемаларына юнәлтү ихтыяҗы туган чакларда, үзе, каләм остасы буларак, әнә шул еллар дәвамында байтак мәкаләләр язып бастырган.

Әлбәттә, биредә без әлеге чыгыш-мәкаләләрнең бер өлеше белән генә таныша алабыз. Җәм, җае чыккач, шушы урында мин дә, фикерем агышын бүлдереп, бер искәрмә ясап алуны кирәктер дип саныйм. Дөресен әйтим, «Китап» авторының хезмәтләрен болай үткән заман фигыльләре белән язуны дәвам итәргә кулым бармый, күңелем тартмый. Ник дигәндә, миңа, пенсиягә чыккач, аның җитәкчелегендәге нәшриятта редактор булып эшләү мөмкинлеге туып алды. Шуңа күрә аны якыннан беләм дип әйтергә теләвем. Ул иҗат эше өчен туган, һәм чәчмә, һәм шигъри әсәрләр яза, тынгысыз җанлы, таләпчән нәшир, оста редактор, «Мәгариф» нәшриятының эшчәнлеген киңәйтү өчен көчен һәм сәләтен кызганмый, милли китапның матур киләчәге өчен эшли. Шушы изге эшкә бирелгәнлек нәтиҗәсендә туган әлеге китап та авторның күпкырлы эшчәнлеген дәлилли.

Әмма ләкин шуны искәрергә кирәк, әлеге язмаларда һәм чыгышларда күтәрелгән кайбер мәсьәләләр бу еллар эчендә, табигый ки, үз чишелешен тапты. Бу китапта материалларны хронологик тәртиптә урнаштырырга тырышу да проблемаларның хәл ителү динамикасын күз алдына китерү нияте белән эшләнгән. Димәк, күп кенә очракларда тасвирланган ситуацияне, тәкъдим һәм тәнкыйди фикерләрне туктап калган сәгатькә карап торган кебек түгел, хәрәкәттәге тарих буларак кабул итәргә кирәк...

Гәрчә шулай булуы табигый да: бу китап «Мәгариф» нәшриятының мәйданга килүенә 10 ел тулганда, аның көндәлек яшәү сәхифәләрен кабат укып чыгу максатын куя. Мәйданнарда яңгырый торган кайнар телмәр-нотыкларны, газеталардагы «кикрикле» мәкаләләрне биредән эзләргә кирәкми. Нәшрият эше һәм тормышы үзе дә шулай: ул — салкын акыл һәм кайнар йөрәк белән башкарыла торган, мәгълүмати һәм һөнәри әзерлеккә, иҗади осталыкка, зур сабырлык һәм түземлелеккә ия булган затларның киеренке, җаваплы хезмәте...

Халкыбыз язмышында аерым урын биләячәк XX гасырның соңгы 10 елында милли нәшрият тормышын тасвирлаган бу хезмәт — шушы чорда мәйданга килгән «Мәгариф» нәшрияты коллективы һәм аның беренче директоры тарафыннан иҗат ителгән, инде тарихка әверелә баручы елъязманың элгәр битләре. Без ул тарихның дәвамлы булуын телибез: «Мәгариф» язачак сәхифәләр ничаклы күп булса — милләтебезнең гомере дә шулкадәр озын булачак.

Гарәф Шәрәфетдинов
Россиянең атказанган
мәдәният хезмәткәре
*(«Мәдәни җомга»,
2002 ел, 12 апрель)*

## Знаток книги и детской души

На соискание премии «Человек Книги» выдвинут Мударис Харисович Валеев — директор Национального издательства Республики Татарстан «Магариф».

Мударис Харисович, имея солидный опыт журналистской и издательской деятельности, проработав в самые сложные годы главным редактором Татарского книжного издательства, создал с «нуля» издательство

национальной учебно-педагогической и детской литературы «Магариф» (в переводе с татарского — «Просвещение»); как первый директор определил программу вновь созданного издательства и добился успешного выполнения этой программы....

Практически все, что увидело свет в последние десять лет в издательстве «Магариф», имеет большую социальную значимость.... Издательство «Магариф» стало самым крупным национальным учебно-педагогическим и детским издательством России, постоянным участником Федеральной программы книгоиздания России, дипломантом конкурсов «Детская книга», проведенных под патронатом президента Российской Федерации.

Грамотно строя творческую и экономическую политику издательства, Мударис Харисович фактически выпускает полностью ликвидную продукцию. Планы издательства «Магариф» привлекательны для широких слоев читательской аудитории. Как руководитель Мударис Валеев завоевал заслуженный авторитет не только в своем коллективе, но и в среде писателей и ученых, перед общественностью и руководством республики...

*(«Книжное обозрение»,*
*3 июня 2002 г.)*

## Рожденный
## под созвездием Близнецов

Может быть, поэтому, единственный ребенок у матери, он с младенческих лет имел... «близнеца»: в одном и том же лице его знали и как Салиха Маннапова (в миру), и как Мудариса Валеева (по документам). В семье дедушки, где мальчик оказался после смерти отца, словно желая проверить небытием и забвением, ему было присвоено второе имя — будущий псевдоним.

Пока Мударис учился в школе, а потом в вузе, его «близнец» — Салих — становился известным в округе молодым поэтом и готовил к изданию книгу стихов...

Я не сомневаюсь, что Мударис стал бы известен как неординарный литератор, если творческие возможности исчерпал бы только на ниве поэзии. Но в один прекрасный день он ощутил потребность выразить свою вторую сущность еще полнее, тогда появился новый литературный критик. К его голосу стали прислушиваться читатели, да и писательские круги не могли обойти его своим вниманием: еще до выхода первой книги Салих Маннапов был принят в творческий союз.

Назар Наджми, видный поэт Башкортостана, прочитав его книгу литературно-критических эссе, писал: «Говорят, поэтом надо родиться. Талант литературного критика у Салиха Маннапова, очевидно, также от рождения». Аксакала поразила не только принципиальность, глубина анализа и широта взглядов критика-литературоведа, но и поэтический стиль его пера. Назар-ага не знал, что Салих-Мударис — прежде всего поэт.

Творческая личность Мудариса Валеева нашла понимание и поддержку видных литераторов республики Сибгата Хакима, Гарифа Ахунова, Аяза Гилязева и других. Все эти годы Мударис Валеев и сам являлся наставником молодежи, и искренне заботился о росте творческой смены. Помнится, он руководил знаменитым студенческим литкружком КГУ «Альлюки», организовал заочную школу молодых критиков при газете «Татарстан яшьләре», был и среди первых членов редколлегии вновь созданного молодежного журнала «Идель». Многие годы являясь членом правления Союза писателей и редколлегии литературного журнала «Казан утлары», он неизменно помогал творческому росту молодых авторов.

Педагог по образованию и призванию, опытный журналист, талантливый писатель и общественный деятель — такова краткая характеристика директора учебно-педагогического издательства «Магариф».

«Издательство в издательстве», на высоком профессиональном уровне занимающееся национальной детской литературой, было создано Мударисом фактически «на общественных началах».

«Каждому поэту — такую бы книгу!.. Книгу, которую так роскошно выпустили в Казани (всем бы такой вот размах, каким обладает издательство «Магариф»!)...» — восхищалась «Независимая газета», увидев мою книгу. «Конечно, так стихи издавать не следует..., но иногда все-таки можно — в виде исключения, чтобы это подарочное издание стало своего рода итогом работы» — так, с «белой» завистью писал журнал «Дружба народов» о книге, изданной «Магарифом» (читай: Мударисом).

Кстати, говорят, бывает, иногда к директору обращаются не иначе, как к «*Магарифу* Харисовичу»,— то ли по ошибке, то ли с добрым юмором, но мне думается — это не случайно.

...В свободное от службы время Мударис Валеев, перевоплощаясь в Салиха Маннапова, как бы становится самим собой и доверяет сокровенные мысли чистому листу бумаги. В его произведениях объединяются два начала: поэтическое видение мира и аналитическое осмысление литературы, мягкий, почти лирический тон изложения и твердая, последовательная защита своих воззрений.

Когда он выступает как писатель, в его ответственности, проявлении особой заботы о собратьях по перу просматриваются опыт руководителя и профессиональные знания.

Именно такое двуединство определяет целостность творческой натуры писателя, издателя и общественного деятеля Мудариса Валеева.

Равиль Бухараев
лауреат премии имени М.Джалиля
*(«Молодежь Татарстана»,*
*11 февраля 2003 г.)*

## Мөдәррис Вәлиев (Салих Маннапов)

*Биобиблиографик белешмә*

Әдәбият тәнкыйтьчесе, шагыйрь, тәрҗемәче, нәшир һәм җәмәгать эшлеклесе Салих Маннапов (бу — аның әдәби тәхәллүсе; рәсми документлардагы исем-фамилиясе исә: Вәлиев Мөдәррис Харис улы) 1953 елның 30 маенда Татарстанның Әлки районы Яңа Камка (Мәүләшә) авылында дөньяга килә. Егерме сигез яшьлек әтисе, сугышта алган яралары ачылып, 1953 елда вафат булганнан соң, Мөдәррис ике айлык сабый чагыннан шул ук районның Татар Мулласы авылында яшәүче, әнисе Фәрдия ханым ягыннан бабасы Мәгыйз (Габделмәгыйз) Маннапов гаиләсендә тәрбияләнеп үсә. Шунда — башлангыч белем, күрше Алпар авылы мәктәбендә урта белем ала.

1971—1976 елларда Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Башлангыч мәктәптә укыганда ук шигырьләр язган һәм республика яшьләр-балалар матбугатында исеме күренә башлаган Мөдәррис университет студентларының атаклы «Әллүки» әдәби түгәрәген җитәкли. Бу чорда аның шигырьләре күмәк җыентыкларга керә, Татарстан радио-телевидениесе аша яңгырый. Ул шулай ук студентларның гыйльми җәмгыятенә яратып йөри, вузара фәнни конференцияләрдә докладлар белән чыгыш ясый, әдәбият фәненә караган беренче эшләре белән университет күләмендәге конкурсларда дипломант була. Фәнни эшкә сәләтен күреп, аңа Х.Госман, И.Нуруллин, Н.Юзиев кебек остазлары — танылган галимнәр игътибар итә, аспирантурада укырга калу турында тәкъдимнәр ясала; әмма ул университет дипломын яклаганчы ук «Татарстан яшьләре» газетасына эшкә урнашуны хәерлерәк күрә.

Гомумән, 1976 елның мартыннан алып бүгенгәчә С.Маннаповның (М.Вәлиевнең) тормыш һәм хезмәт юлы тулысынча татар матбугат дөньясы белән тыгыз бәйле. «Татарстан яшьләре» газетасында ул өч елдан артык эшли, әүвәл анда хәбәрче, аннан мәктәпләр һәм югары уку йортлары бүлеге мөдире вазифаларын башкара. 1979 елның августыннан ул — «Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәре: башта әдәби тәнкыйть, сәнгать һәм фән бүлегенең өлкән редакторы, аннары җаваплы сәркатип, соңга таба баш мөхәррир урынбасары булып эшли. 1989 елның февраленнән 1992 елга кадәр ул Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире, 1992 елның июленнән — яңа оешкан «Мәгариф» китап нәшрияты директоры хезмәтендә.

С.Маннаповның әдәби тәнкыйть өлкәсендә беренче җитди язмалары республика матбугатында җитмешенче еллар ахырыннан басыла башлый. 1984 елда Татарстан китап нәшриятында «Сезгә ышанам» исемле беренче китабы басылып чыга (бу хезмәте өчен ул Шәйхи Маннур исемендәге бүләккә лаек була). Тагын дүрт елдан икенче китабы («Тамыр тирәнлеген яфрак тоя». Татарстан китап нәшрияты, 1988), аннары рус телендә сайланма тәнкыйть мәкаләләре тупланган өченче җыентыгы («Возвращение Звезды». Татарское книжное издательство, 1992) дөнья күрә.

Бу китаплардагы тикшеренүләрендә — әдәби хәрәкәткә караган гомуми күзәтүләрендә, аерым конкрет әсәр яки язучының тулаем иҗаты турындагы мәкаләләрендә, иҗат портретларында һәм эссе характерындагы хезмәтләрендә — тәнкыйтьче XX йөз күренекле татар әдипләренең (Г.Бәширов, Ә.Еники, Х.Туфан, С.Хәким, Н.Дәүли һ. б.), сугыштан соң әдәбият мәйданына килгән бер төркем татар прозаикларының һәм шагыйрьләренең (И.Юзеев, Х.Камал, М.Мәһдиев, В.Нуруллин, Р.Гаташ, Г.Рәхим һ. б.) әдәби иҗаттагы индивидуаль үзенчәлекләрен, уңай һәм бәхәсле якларын, конкрет әдәби әсәр тууның фәлсәфи-иҗтимагый нигезләрен, тел-стиль хасиятләрен анализлый, гомумән, татар әдәбиятын тарихи аспектта тикшереп, бүгенге заман дөнья әдәбияты казанышлары яктылыгында татар прозасы һәм поэзиясенең үсеш юллары, тенденцияләре һәм ориентирлары хакында җитди сүз алып бара. Тәнкыйтьченең мәкаләләре, эсселары композицион төзеклеге, фикер-бәяләмәләренең заманча актуальлеге һәм ихласлыгы, язу стиленең шигъри яңгырашы, урынына бик туры китереп, теге яки бу әсәрне анализлау барышында халыкчан үткен-образлы чагыштырулар, афористик гыйбарәләрне мул куллануы белән дә игътибарны җәлеп итәләр. Бу сыйфатлар аның әдәби тәнкыйть мәкаләләрен җанландырып җибәрә, аларның эмоциональ тәэсир көчен арттыра.

С.Маннапов, бу елларда әдәби тәнкыйть өлкәсендә актив эшләве белән беррәттән, яшьлегендә күңеленә кереп утырган «беренче мәхәббәтен» — шигъриятне дә онытмый, тын гына, киң даирәгә белгертмичә генә, шигырьләр язуын дәвам иттерә. 1998 елда аның шул «яшерен» шигъри иҗатыннан сайлап алынган йөз иллеләп лирик шигыре «Яшьлектән хат» исеме белән Татарстан китап нәшриятында аерым җыентык булып басылып чыкты. Шигырьләрендә дә ул, бернинди риторик, ялган пафоска бирелмичә, үзе булып кала. Китабының төп тематикасын, эчтәлеген тәшкил иткән туган җиргә, кешеләргә, бигрәк тә илаһи зат —Анага мәхәббәт хисләрен, уй-фикерләрен шагыйрь укучы күңелендә аваздаш тойгылар уятырлык ихласлык, садәлек белән бәян итә. Аларда Дәрдемәнд шигърияте традицияләренә тартым үзгә бер моң-сагыш аһәңнәре дә сизелеп китә кебек.

Салих Маннапов (Мөдәррис Вәлиев) — күренекле мәгариф эшлеклесе, танылган нәшир, китап белгече. Дистә елдан артык инде «Мәгариф» Милли нәшриятының җитәкчесе буларак, ул татар милли мәгарифе системасын, китап бастыру эшен милли традицияләр һәм хәзерге заман таләпләре җирлегендә яңадан үзгәртеп кору, балалар бакчаларыннан алып югары уку йортларына кадәр тәгълим-тәрбия сабакханәләрен — мәктәпләрне, лицей-гимназияләрне заманча дәреслекләр, әлифбалар, сүзлекләр, бигрәк тә татар халкының тарихы һәм әдәбияты буенча гадел-объектив эчтәлекле уку әсбаплары, кулланмалар белән тәэмин итү, китапларның тышкы сыйфатын яхшырту, махсус серияләр рәвешендә аларның максатчанлыгын һәм төрләрен арттыру, нәшриятның дәвамлы матди базасын булдыру юнәлешендә чын мәгънәсендә киеренке һәм нәтиҗәле көрәш алып барды. М.Вәлиев, милли мәгариф концепцияләрен һәм татар китабы мәнфәгатьләрен яклап, хөкүмәт даирәләрендә һәм башка рәсми оешмаларда чыгышлар ясады, газета-журнал битләрендә мәкаләләр, интервьюлар бастырды. Аның бу төр язма материаллары «Мәгариф» нәшриятының ун еллыгына чыгарылган юбилей җыентыгын тәшкил итә («Китап: Татарстанда нәшрият эше: соңгы ун елдагы нәтиҗәләр һәм проблемалар». Татарстан Республикасы «Мәгариф» Милли нәшрияты, 2001).

М.Вәлиев татар китабын нәшер итү һәм татар балалар әдәбияты тарихыннан «XX гасыр ахыры татар балалар әдәбияты һәм балалар китабы» дип исемләнгән фәнни хезмәте нигезендә диссертация яклады, һәм аңа филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә бирелде.

Ул шулай ук матбугат, мәгариф һәм әдәбият өлкәсендәге казанышлары өчен Татарстанның атказанган мәдәният эшлеклесе дигән мактаулы исемгә (1989) һәм Муса Җәлил исемендәге Республика бүләгенә (2003) лаек булды.

М. Вәлиев тәрҗемәче буларак та билгеле. Аерым алганда ул рус телендә иҗат итүче татар язучысы Зөфәр Фәтхетдиновның берничә детектив повестен һәм романын, чуваш язучысы М. Юхманың Мулланур Вахитов турындагы тарихи романын татар теленә тәрҗемә итте. Аларның һәркайсы Татарстан китап нәшриятында аерым китап рәвешендә дөнья күрделәр. 1989 елда ул, «Балалар календаре» дигән исем белән, әдәби-нәфис һәм фәнни-популяр материаллардан зур җыентык төзеп чыгарган иде.

С. Маннапов (М. Вәлиев) — 1983 елдан Татарстан Язучылар берлеге, 1989 елдан берлекнең идарә әгъзасы. Ул шулай ук «Казан утлары» журналы һәм «Мәгърифәт» газетасы басмалары редколлегияләрендә дә күп еллардан бирле әгъза булып тора.

Рәис Даутов
*(«Татарстан язучылары»*
*дигән китапка әзерләнгән мәкалә.*
*24 февраль, 2003 ел)*

*Бу китап өчен каләм хакын*
*туган ягымдагы Татар Мулла,*
*Алпар авылларының ятим балаларына*
*хәер итеп тапшырам*

Литературно-художественное издание

*Валеев Мударис Харисович*

# ЛИНИЯ ЖИЗНИ

(на татарском языке)

Мөхәррирләре *Р.Х.Корбанов, Н.К.Нотфуллина*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Л.С.Золондинова*
Техник мөхәррире
һәм компьютерда биткә салучысы *Л.М.Тилк*
*Ф.Х.Макарова* җитәкчелегендәге корректорлар төркеме
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчеләр *Л.Р.Вафина, Э.Ф.Нурмөхәммәтова*
2 нче биттәге фоторәсем авторы — *В.Е.Мартинков*
8 нче һәм 416 нчы биттәге тугралар авторы —*Н.Нәкъкаш*

Нәшриятка 04184 нче лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.04.2003.
Форматы 75ә90 1/32. Офсет кәгазе.
«Tatar Korinna» гарнитурасы.
Шартлы басма табагы 17,5 + форз. 0,16.
Нәшер-хисап табагы 14,97 + форз. 0,28.
Тиражы 2000 д. Заказ Я-256.

Татарстан китап нәшрияты.
420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство.
420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Http: //www.tatarstan.ru/books/
E-mail: tki@books.kazan.ru

«Идел-пресс» нәшрият-полиграфия
комплексы унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.